# Казан утлары



5

май
1968

# Казан утлары

АЙЛЫК ӘДӘБИ ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ
ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ОРГАНЫ
КЫРЫК ҖИДЕНЧЕ ЕЛ ЧЫГА

5

МАЙ
1968

## Бу санда:

М. Ф. ВӘЛИЕВ. Хезмәт ияләрен интернациональ тәрбияләү—идеология эшенең мөһим бурычы. 3

ПОВЕСТЬ, ХИКӘЯ ҺӘМ ШИГЫРЬЛӘР

Г. АФЗАЛ. Дөнья сакта; Вәгъдә; Дулкыннар; Нинди үлчәү; Иске кабер ташларын караганда; Читкә киткәннәр сүзе; Патша һәм шагыйрь; Яшәмәдең; Болын — хәтфә; Ян, өзгәләп; Ике кеше. Шигырьләр . . . . . . . . . . . 14

М. МАЛИКОВА. Казан каласы — таш кала. Повесть . . . . . . . . . . . . . 17

Э. МӨЭМИНОВА. Онытмадым. Поэма-монолог. . 50

М. МӘҺДИЕВ. Без — кырык беренче ел балалары . . . . . . . . . . . . . . . 53

ЗӨЛФӘТ. Мәскәү; Айлы соната; Җиргә кирәк; Походтагы солдат кебек; Хемингуэй үлеме; Кеше; Өстәлемдә минем көрәгә; Ышаныч; Син йоклыйсың; Җырлый белмиләр бөркетләр; Шундый ташлар бар Казанда; Шушы халык чабатадан йөргән; Сине Блок үйлап тапкан бары. Шигырьләр . . . . . . . . 80

Ф. ЯРУЛЛИН. Сине шуңа яратам; Кое казучы карт сүзләре; Бусагалар; Кызыгып калам; Әллә күңел, әллә еллар; Үзгәреш. Шигырьләр. 85

С. САБИРОВ. Матрослар десанты. Очерк . . . 87

ЗАМАНДАШЫБЫЗ

Ш. БИКЧУРИН. Каты токым. Очерк . . . . . 93

ЯЗУЧЫЛАРНЫҢ VII СЪЕЗДЫ

М. ӘМИР. Иҗат дәрте . . . . . . . . . . . 107

МУСА ҖӘЛИЛ ЭЗЛӘРЕ БУЙЛАП

Р. МОСТАФИН. Серле йомгак эзеннән . . . . 123

ХАТИП ГОСМАНГА 60 ЯШЬ

ГАЗИ КАШШАФ. Хатип Госман . . . . . . . . 131

Х. ГОСМАН. Антитезалы тасвир кайлардан килә. 134

КПССның
ТАТАРСТАН
ӨЛКӘ
КОМИТЕТЫНЫҢ
ГАЗЕТА ҺӘМ
ЖУРНАЛЛАР
НӘШРИЯТЫ
КАЗАН

СӘЕТ КАЛЬМЕТОВКА 50 ЯШЬ

**Г. АХУНОВ.** Усал телле драматург . . . . . . 143

РЕВОЛЮЦИОН ХӘРӘКӘТ ТАРИХЫННАН

**Р. НӘФИКОВ.** Татар революционерларының разночинец-демократик хәрәкәткә катнашулары турында . . . . . . . . . . . . . . . 144

ӘЛИШЕР НӘВОИНЫҢ ТУУЫНА 525 ЕЛ

**Ә. НӘВОИ.** Бик күп аһ орсам; Дусларым яшерен яга торган; Гыйшыкта кемгә дә сердәш була алмас; Ярдан аерылса әгәр гашыйк; Тиле күңлем минем; Горурлыгың ташытма. Юлдан язды; Тәмуг белән; Каннан артык. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . . . 148

ЯҢА ТӘРҖЕМӘЛӘР

**С. ӘДһӘМОВА.** «Кара чәчкәләр» . . . . . . 151
**Ф. ШИҺАПОВА.** «Ялгыз җилкән» повестеның тәрҗемәсе . . . . . . . . . . . . . . . 153

ЮМОР һӘМ САТИРА

**З. НУРИ.** Ирексездән галәмче; Кеше һәм балта; Һаман тәнкыйтьләнүче; «Дан иясе»; Күренеп тора; Былчыракта; Хатыннарының холкы; Кунак киткәндә; Өч көн үткәч; Спектакль карaганда; Искиткеч яңалык; Дөрес адрес. Шигырьләр . . . . . . . . . . . . . . . 156
**Әдәбият һәм сәнгать яңалыклары** . . . . . . 158

**Редакциягә килгән кульязмалар кире кайтарылмый**

Редакциянең адресы: *Казань, ул. Баумана, 19. Дом печати, 2 этаж.*
Телефоннар: җаваплы редактор — 2-68-21, җаваплы секретарь — 2-68-21, бүлекләр — 2-39-52.
Хатлар өчен: *Казань, почтамт, почтовый ящик 63. Редакция «Казан утлары».*

Редактор урынбасары: **Ләбибә Ихсанова**
Редколлегия: **Хәй Вахит, Шәүкәт Галиев, Әмирхан Еники, Шәйхи Маннур, Рафаэль Мостафин, Газиз Мөхәммәтшин, Рафикъ Нәфиков, Атилла Расих, Гали Халит, Сибгат Хәким, Нил Юзиев, Мирсәй Әмир**

Производствога бирелде 15/III-1968 ел. Басарга кул куелды 22/IV-1968 ел. ПФ 09015. Кәгазь форматы 70×108¹/₁₆. Учетн.-изд. табак 12,2. Басма табак 10(14). Тираж 65 546 экз. Заказ Д-505. Бәясе 40 тиен.

ТАССР Министрлар Советы каршындагы Матбугат идарәсенең Камил Якуб исемендәге матбугат комбинатында басылды. Казан, Бауман урамы, йорт 19, 1968 ел.

**М. Ф. Вәлиев,**

КПССның Татарстан өлкә комитеты секретаре, тарих фәннәре кандидаты.

# ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕН ИНТЕРНАЦИОНАЛЬ ТӘРБИЯЛӘҮ— ИДЕОЛОГИЯ ЭШЕНЕҢ МӨҺИМ БУРЫЧЫ

Коммунистлар партиясенең барлыкка килү моментыннан алып бүгенге көнгә кадәрге теоретик һәм практик эшчәнлеге пролетар интернационализм принцибының гамәлдә гәүдәләнеше булды. Самодержавиене бәреп төшерү һәм пролетариат диктатурасы урнаштыру өчен революцион көрәш чорында партиянең тырышлыгы эшчеләр сыйныфын һәм барлык хезмәтчел халыкны, нинди милләттән булуларына карамастан, бердәм сыйнфый максатларны хәл итүгә, пролетариат революциясенең җиңүенә туплауга юнәлдерелгән иде.

Бөек Октябрь социалистик революциясенең җиңүе милли мәсьәләне чын-чыннан хәл итәргә мөмкинлек тудырды. Совет власте казанышларын яклау өчен, социализмның җиңүе өчен илебезнең барлык халыкларының бергәләп көрәшүе, совет дәүләтчелеге проблемаларын хәл итү, тормышның барлык өлкәләрендә, шул исәптән экономика һәм культура өлкәләрендә, фактик тигезсезлекне бетерү — милли мәсьәләне хәл итүдә һәм, шуның белән бергә, интернационализм принциплары нигезендә СССР халыкларының дуслыгын ныгытуда әһәмиятле маяклар булып торалар.

Бөек Ватан сугышында җиңү, шуннан соң халык хуҗалыгын торгызу һәм үстерү буенча, коммунистик төзелеш этабына күчү буенча бергәләп эшчәнлек совет кешеләренең бөек интернационализмын һәм патриотизмын раслаучы факторлар булдылар.

КПСС Үзәк Комитетының «Бөек Октябрь социалистик революциясенең 50 еллыгы» Тезисларында болай диелгән:

«Социалистик төзелеш процессында милли мәсьәлә буенча ленинчыл программа тормышка ашырылды, Ватаныбызның барлык халыкларының социалистик туганлыгы ныгып урнашты».

Интернационализм принциплары марксизм-ленинизм тәгълиматының асылыннан, социализмның табигатеннән, халык белән партиянең бурычлары гомумилегеннән килеп чыга. Бу принциплар милли мөнәсәбәтләр үсешенең ике тенденциясендә: һәр милләтнең чәчәк атуында һәм аларның һәрьяклап якынаюында чагылалар. Халыкның рухыннан, сыйныфлылык принципларыннан, социализмнан чыга торган чын миллилек интернациональлеккә каршы килми. Социалистик һәм коммунистик төзелеш шартларында милли һәм интернациональ нәрсәләр бердәм юлда булалар, бер-берсен тулыландыралар, үзара баеталар һәм милли мөнәсәбәтләрнең коммунизмга таба, милләтләрнең һәрьяклап якынаюына таба үсеш тенденциясен билгелиләр.

Совет кешеләренең интернационализмы, башлыча, өч фактор йогынтысында формалаша һәм үсә:

беренчедән, объектив фактор йогынтысында. Моңа социалистик җәмгыятьтә тормыш шартларының бөтен җыемтасы: җитештерү средстволарына җәмәгать милкенә нигезләнгән хуҗалыкның социалистик системасы, коммунизм өчен көрәш максатлары бердәмлеге, марксистик-ленинчыл идеологиянең бердәмлеге, җитештерү мөнәсәбәтләренең социалистик характеры, совет дәүләтчелеге һ. б. керә. Кыскача әйткәндә, Маркс язганча, «халыклар чыннан да берләшә алсыннар өчен, аларның гомуми интереслары булырга тиеш»;

икенчедән, СССРдагы барлык халыкларның яңа җәмгыять төзүдә уртак тырышлыгы, тормышның бөтен өлкәләрендә туганнарча хезмәттәшлеге һәм үзара ярдәмләшүе йогынтысында;

өченчедән, партиянең, комсомол, җәмәгать оешмаларының идеологик, тәрбия эшенең бөтен җыелмасы йогынтысында.

Монда шуны әйтеп үтәргә кирәк: гәрчә социалистик милләтләрнең һәрьяклап якынаюы — социализм һәм коммунизмның объектив закончалыгы булса да, бернинди объектив уңай шартлар да үзеннән-үзе генә милләтара мөнәсәбәтләрнең тагын да ныгуына китермиләр. Әлегә милләтләр һәм милли аерымлыклар яшәп килә икән, җәмгыять үсешенең объектив законнарын белүгә таянып, бу процесска аңлы рәвештә йогынты ясарга кирәк.

Советлар Союзының бердәм интернациональ Коммунистлар партиясенең җитәкчел һәм юнәлткеч роле милли мәсьәләне хәл итүдә ирешелгән уңышларның иң мөһим нигезе һәм бөтен совет җәмгыятен үстерүдә СССР халыкларының туганнарча хезмәттәшлеген, якынаюын тагын да үстерүнең гарантиясе булды һәм булып тора. Партиянең ленинчыл милли политиканы эзлекле рәвештә һәм тайпылышсыз тормышка ашыруы барлык халыкларның материаль һәм рухи көчләренең чәчәк атуын, коммунистик төзелеш практикасында СССРдагы барлык халыкларның милли интересларын да, шулай ук гомуми тормыш интересларын да дөрес исәпкә алуны тәэмин итә. Коммунистик төзелеш планнарын тормышка ашырганда, партия шуның өчен һәрвакыт уңышка ирешә: аның политикасы, илебезнең барлык халыклары интересын чагылдырып, аларны туганнарча бердәм семьяга туплый.

СССРда коммунистик төзелеш турындагы мәсьәләнең бер өлеше булган милли мөнәсәбәтләрне хезмәт ияләренең коммунизм өчен көрәшләре белән бәйләнештән тыш карарга ярамый. Коммунистик төзелеш практикасында гына партиянең юнәлткеч йогынтысында милли мөнәсәбәтләр дә дөрес тормышка ашырыла. Шул ук вакытта совет җәмгыятенең изге максатка — коммунизмга баруында һәрбер яңа адым, үз чиратында, милләтләр арасындагы мөнәсәбәтләрнең тагын да камилләшүенә һәм тирәнәюенә булышлык итә.

Коммунизм төзү чорында бөтен совет халкы алдына үзара бәйләнешле өч бурыч куелды: коммунизмның материаль-техник базасын булдыру, коммунистик иҗтимагый мөнәсәбәтләрне үстерү һәм яңа кеше тәрбияләү. Коммунистик төзелешнең бер өлеше буларак, милли мөнәсәбәтләрне үстерү яңа җәмгыять төзүнең әнә шул өч мәсьәләсе белән аерылгысыз бәйләнештә тора.

Милләтләр хезмәттәшлеген барлык чаралар белән ныгытуның ачкычын партиябез, элеккечә үк, дөрес экономик политикада күрә. «Экономика өлкәсендә киләчәктә дә совет республикаларының хуҗалыгын һәрьяклап үстерүгә юл тоту, производствоны рациональ урнаштыруны һәм табигый байлыкларны планлы үзләштерүне тәэмин итү өчен, — диелә КПСС Программасында, — республикалар арасында социалистик хезмәт бүленешен камилләштерергә, аларның хезмәт тырышлыкларын берләштерергә һәм яраштырырга, бөтен дәүләт интереслары белән һәрбер совет республикасы интересләрын бергә дөрес яраштырып алып барырга кирәк».

Бу программ положениеләрдән һәр республиканың, һәрбер районның, конкрет коллективның интернациональ бурычын үтәү өчен, кадрларны, барлык совет кешеләрен интернациональ тәрбияләү өчен бик мөһим нәтиҗәләр ясарга кирәк. Алар түбәндәгеләргә кайтып кала:

1. Интернационалист булу, интернациональ бурычны үтәү — ул коммунистик төзелеш бурычларын үтәүгә, илебезнең материаль байлыкларын ишәйтүгә өлеш кертү дигән сүз. Интернационализм конкрет, сизелерлек эшләрдә гәүдәләнергә тиеш. Хәзерге вакытта, без В. И. Ленинның тууына 100 ел тулуга хәзерләнгәндә һәм бишь-

еллык планны срогыннан алда үтәү буенча җаваплы зур йөкләмәләр алган чакта, моның әһәмияте аеруча зур.

2. СССРның халык хуҗалыгы бер бөтенне тәшкил итә һәм шуңа күрә теләсә кайсы республиканың экономикасы шул бөтеннең бер өлеше булып тора, ул илебезнең башка районнары белән иң тыгыз элемтәдә генә үсә ала. Совет җәмгыятенең үсеше шундый полосага керде ки, хәзер хуҗалык төзелешендә интереслар гомумилеге, материаль байлыклар муллыгына ирешү зарурлыгы милли интереслар яраклашырга тиешле билгеләгеч момент булып тора. Социалистик хезмәт бүленеше, специаллаштыру һәм кооперацияләү нигезендә производствоны үстерү шуны таләп итә: гомум дәүләт интереслары беренче планда торырга тиеш; илебезнең башка районнарына кооперацияләшкән поставкалар срогында үтәлергә тиеш; кадрлар үз вазифаларын үтәүгә бернинди җирдәшлексез һәм милли чикләнүсез, чын интернационалистларча карарга тиешләр. Кадрларны гомуми дәүләт интересларын аңлау рухында тәрбияләү интернациональ тәрбияләүнең бик мөһим бурычы булып тора. Коммунистлар партиясе кадрларны тәрбияләү буенча үзенең бөтен күпкырлы эшендә шуңа ирешергә омтыла: һәрбер партия, совет һәм хуҗалык работнигы күпмилләтле Ватаныбыз масштабларында фикер йөртергә өйрәнсен, аңа илебездәге барлык халыкларның ихтыяҗлары һәм сораулары үзенеке кебек үк якын булсын, ул үзенең эшенә гомуми халык хезмәтенең бер өлеше итеп карасын, аның иҗтимагый әһәмиятен аңласын.

3. Хуҗалык бурычларын тормышка ашыруның барышында район, шәһәр, республика, производство тармагы масштабында аерым предприятиеләр арасында социалистик ярыш җәелә, илебезнең төрле районнары арасында, башка республикаларның төрдәш предприятиеләре арасында тәҗрибә уртаклашу киңәя, бу исә, үз чиратында, производство һәм рухи тормышның төрле яклары белән танышу шартларында үтә. Бу вакытта шунысы бик әһәмиятле: һәрьяклап аралашу, туганнарча хезмәттәшлекнең һәм үзара ярдәмләшүнең үсеше партия оешмаларының идеологик эше белән беркетелсен, кешеләр аңында ул тирән эз калдырсын һәм иҗтимагый җитештерүне ишәйтүгә китерсен.

4. Коммунизмның материал-техник базасын төзү илебездәге барлык халыкларның иң якын хезмәттәшлегендә һәм үзара ярдәмләшүендә, барлык республикаларның һәм өлкәләрнең табигый, кешеләр һәм техник ресурсларын файдалану белән тормышка ашырыла. Братск ГЭСын төзү, чирәм җирләрне үзләштерү, Татарстанда нефть промышленносте булдыру, республикабызда химияне үстерү — боларга ачык мисал булып торалар. Интернациональ тәрбиянең нәтиҗәлелеген күтәрү өчен телдән һәм матбугат аша пропаганда алып барганда, тормыш һәм үзебезнең чынбарлык фактларыннан ачык итеп, шаблонсыз файдалана белергә кирәк, коммунистик төзелеш бурычларын үтәү өчен көрәштә халыклар берләшүенең бөек көчен сурәтләргә кирәк.

5. Хәзерге заман производствосы — промышленностьтамы ул, авыл хуҗалыгындамы — эре производство. Безнең республикада һәрбер производство коллективы күп милләтле. Шуңа күрә тору урыннарында, мәктәпләрдә, балалар бакчаларында да без төрле милләт кешеләренең аралашуын күрәбез. Шулай итеп, кешеләрнең хезмәтләре дә, яллары да, культура ихтыяҗларын канәгатьләндерүләре дә күп милләтле коллективларда бара. Бу исә интернациональ тәрбия өчен яхшы база булып тора. Мондый объектив шартлардан оста файдаланырга, тулаем коллективның һәм аерым милләтләр вәкилләренең ихтыяҗларын канәгатьләндерүгә исәпләнгән эш оештырырга кирәк.

6. Материаль җитештерүнең үсеше һәм шул нигездә хезмәт ияләренең доходлары үсү көнкүреш шартларын, иң әйбәт милли традицияләрне һәм гомуми культураның үсеш дәрәҗәсен исәпкә алып, яхшыртырга мөмкинлек бирә. Интернациональ тәрбиядә, кайбер милли искелек калдыкларын (ә алардан искелеккә табыну, консерватизм аңкый) бетерүдә боларның әһәмияте шулай ук аз түгел.

7. Коммунизмның материаль-техник базасын төзү, бишьеллык план заданиеләрен үтәү илебездәге республикалар һәм өлкәләр арасында кадрлар алмашусыз мөмкин түгел. Безнең республика территориясендә илебезнең төрле районнарыннан килгән белгечләр, эшчеләр эшли. Аларга шундый шартлар тудырырга кирәк: алар үзләрен «өйдә» итеп хис итсеннәр, интернациональ коллективларда дәрес идея чыныгуы алсыннар, безнең республика аларның «үз ватаннары» булсын. Бу бик мөһим эш.

Интернациональ тәрбиянең экономик үсешкә бәйләнешле кайбер мәсьәләләре әнә шулар.

Партиянең совет кешеләрен социалистик интернационализм рухында тәрбияләү буенча күпкырлы идеологик эшендә культура чараларының әһәмияте гаять зур. Коммунизм төзү чорында милләтләрнең һәм халыкларның идея бердәмлеге, аларның культуралары якынаю көчәя. Әнә шундый хезмәттәшлек, бигрәк тә безнең көннәрдә, СССР халыкларын рухи яктан якынайтуның төп чараларыннан берсе булып әверелә.

Социализм вакытында милли культураларның үсеше милләт аерымлыкларын тудырмый, бәлки халыклар арасындагы дуслыкның ныгуына китерә. һәрбер милли культура совет культурасының гомуми олы юлыннан кырыйда түгел, бәлки, гомуми социалистик эчтәлеккә ия булган хәлдә, башка культуралар белән тыгыз бердәмлектә үсә. Мондый үзара бердәмлек һәм үзара йогынты милли культураларның үсешенә бик тә уңай тәэсир итә, чөнки бу аларның һәркайсына рухи үсештә башка тугандаш халыклар ирешкәннәрнең иң яхшыларын үзләренә дә алырга мөмкинлек бирә. Үзара баетышу милли культураларны чикләми һәм ярлыландырмый, бәлки, киресенчә, интернационализм принципларына нигезләнгән күпмилләтле бөтен совет культурасының гомуми күтәрелешенә китерә. Иҗади аралашу процессында, социалистик милләтләрнең дуслыгында бөтен совет культурасы өчен гомуми булган яңа сыйфатлар барлыкка килә, үсә һәм үзара байый.

Шуны да истә тотарга кирәк, культураларның үзара йогынтысы һәм үзара баюуы культура хезмәттәшлеге шартларында тормышка аша. Бу хезмәттәшлек иҗади работниклар даирәсен генә түгел, бәлки киң халык массаларын да үз эченә ала. Культура хезмәттәшлегенең формалары никадәр күбрәк булса, бу процесска хезмәт ияләре никадәр активрак тартылса, культура чаралары да совет кешеләрен интернациональ тәрбияләүгә шулкадәр күбрәк һәм көчлерәк тәэсир итәләр.

Социалистик милләтләрнең бер-берсен үзара баетуы нигезендә барган культура хезмәттәшлеге, башка милләтләрнең культура казанышлары белән тагын да киңрәк һәм һәрьяклап танышу совет кешеләрендә эстетик зәвыклар формалаштыра, коммунизм төзелешендә аларның активлыгын күтәрә. Моңардан тыш, милли культуралар казанышлары белән үзара танышу Совет власте елларында барлык социалистик милләтләрнең материаль һәм рухи үсешендә нинди зур уңышларга ирешелгәнлекне күрсәтә. Шулай итеп, культура әсәрләре Советлар Союзындагы һәр халыкның гомуми максатларын һәм милли үзенчәлекләрен аңлау өчен бай материал бирә.

СССР халыклары культураларының үзара бердәм эш итүенең объектив нигезе бар һәм ул турыдан-туры илебездә социалистик стройның асылыннан килеп чыга. К. Маркс һәм Ф. Энгельс «Коммунистлар партиясе манифесты»нда ук инде күрсәтеп үткәнчә, тарихи үсеш барышында, бигрәк тә капитализм чорында, халыклар арасында социаль-экономик элемтәләр киңәя, культура һәм сәнгать өлкәсендә дә аларның үзара бердәм эш итүе, үзара тәэсир итешүе көчәя. «Иске җирле һәм милли бикләнгәнлеккә һәм бары тик үзең җитештергән продуктлар хисабына гына яшәүгә алмашка, — дип яздылар марксизм классиклары, — милләтләрнең һәрьяклап элемтәсе һәм бер-берсеннән һәрьяклап бәйлелеге килә. Бу хәл материаль җитештерүгә дә, шулай ук рухи җитештерүгә дә бер тигез дәрәҗәдә кагыла. Аерым милләтләрнең рухи эшчәнлеге җимешләре гомуми байлык булып әверелә. Милли берьяклылык һәм чикләнгәнлек торган саен инде мөмкин булмый башлый...»

Социализм чорында, К. Маркс һәм Ф. Энгельс язганча, милләтләрнең якынаюына булышлык итүче шартлар чиксез үсте. Бердәм социалистик экономика, милли изүне бетерү, барлык милләтләрнең һәм халыкларның тигез хокуклылыгы, СССР халыкларының коммунистик җәмгыять төзүдә гомуми кызыксынучанлыгы эчтәлеге буенча бердәм социалистик культура хәзер социалистик милләтләрнең материаль җитештерү өлкәсендә дә, шулай ук культура үсешендә дә үзара баетышуы өчен уңай җирлек булып әверелде.

СССР халыклары культураларының объектив рәвештә үсә барган үзара баетышу һәм якынлашу процессын шул да көчәйтә: коммунизм төзелеше үзе үк җәмгыятьнең һәр әгъзасыннан бөтен яктан үсешкә ирешүне, югары производство культурасы һәм рухи байлык таләп итә. Аңлашыла ки, коммунизм төзүче халыклар, әгәр милли чикләр белән генә чикләнсәләр һәм аерым бер милләт ирешкән рухи байлыктан гына

файдалансалар, культура үсешендә мондый дәрәҗәгә ирешә алмас иделәр. Барлык милләтләр культурасының чын-чыннан чәчәк атуына, киләчәктә коммунистик җәмгыятьнең бердәм гомуми кешелек культурасы формалашуга, гармоник рәвештә һәръяклап үскән кеше тәрбияләүгә бары тик бөтен халыклар культуралары казанышларыннан файдалану, милли культураларның якыннан хезмәттәшлеге, аларның үзара үтеп керүе һәм үзара бер-берсен баетуы нигезендә генә ирешергә мөмкин.

СССР халыклары культураларының якынаюы һәм үзара бер-берсен баетуы бер милли культураны икенчесеннән ясалма рәвештә аера торган киртәләр булмауны күздә тота. Бу уңайдан милли традицияләрнең асылын, милли культураларның үзенчәлекләрен дөрес аңлауның әһәмияте зур.

КПСС Программасында милли культураларның киләчәге коммунистик төзелешнең гомуми перспективаларыннан һәм иҗтимагый үсешнең яңа этабында милләтләр үсешеннән чыгып карала. Киң колач белән коммунизм төзү чорында һәрбер милләт чәчәк ата, милләтләр тагы да якыная, интернациональ коммунистик культура формалаша һәм үсә. Шуны да истә тотарга кирәк: коммунизмның гомум кешелек культурасы һәрбер милләт туплаган культура мирасыннан аерымланган рәвештә түгел, бәлки һәрбер милли культурада булган бөтен кыйммәтле хәзинәне максималь ачып бирү аша барлыкка килә. Без милли аерымлыкларны онытa алмыйбыз, шулай булгач, милли культураларның үзенчәлекләре барлык илләрдә социализм җиңгәннән соң да озак вакыт сакланачак.

Болар барысы да: милләтләр һәм милли культуралар үсешендәге үзбашкалыклар, милләтләрнең һәръяклап якынаюы һәм шуның белән бергә милли аерымлыкларның саклануы — партия политикасында исәпкә алыналар. Милләтләрнең һәм халыкларның һаман ныграк якыная баруының объектив процессын яклап, Коммунистлар партиясе шул ук вакытта милли үзенчәлекләрне санламауга да, шулай ук аларны күпертүгә дә юл куймый.

СССР халыкларының күпмилләтле культурасы эчтәлеге буенча социалистик һәм формасы буенча милли культура буларак үсә. Әлегә, милләтләр яшәгәндә, культураның милли формасы да үзенең әһәмиятен саклый. Ләкин моннан, бу форма үзгәрешсез кала икән, дигән нәтиҗә ясарга ярамый. Билгеле булганча, теләсә кайсы халык культурасының характерында иң әһәмиятлесе — аның идея эчтәлеге. Форма шушы эчтәлекне чагылдырырга тиеш, һәм халыкның тормышы байый һәм төрләнә барган саен, реаль чынбарлыкны чагылдыру формасы да төрле-төрле һәм күләмле була бара. «Социалистик милләтләр үсешенең тарихи тәҗрибәсе күрсәткәнчә, — диелә КПСС Программасында, — милли формалар үзгәрешсез катып калмыйлар, бәлки, искергән, тормышның яңа шартларына каршы килә торган һәрнәрсәдән бушанып, үзгә төс алалар, камилләшәләр һәм үзара якынаялар».

Шулай итеп, сәнгатьтә һәм әдәбиятта милли үзенчәлек гомум совет культурасыннан аерылган хәлдә гәүдәләнми, ә бәлки социалистик милләтләрнең интернациональ яшәү һәм көрәш шартларын турыдан-туры чагылдыру булып тора.

Социализмның һәм коммунизмның җиңүе өчен бергәләп көрәш, Коммунистлар партиясенең гаять зур тәрбия эше, политик, экономик һәм культура тормышы уртаклыгы йогынтысында социалистик милләтләрнең һаман күбрәк сандагы вәкилләре хезмәттә, көнкүрештә, культурада гомуми сыйфатларга, коммунистик җәмгыять кешеләренә хас сыйфатларга ия була баралар, бу сыйфатлар совет кешеләрен туганлаштыралар һәм шул ук вакытта социалистик милләтләрнең яңа сыйфатлары булып әверeләләр. Үз Ватанына кайнар мәхәббәт, югары идеялелек, коммунизм эшенә тайпылышсыз ышанганлык, хезмәткә һәм җәмгать милкенә коммунистларча мөнәсәбәт, эзлекле интернационализм, коллективизм кебек совет кешеләренең иң әйбәт сыйфатлары барлык социалистик милләтләрнең күпчелек вәкилләре өчен хас.

Совет милләтләре тормышында туган гаять зур уңай үзгәрешләр культура үсешә язмышы өчен дә эзсез калмый. Алар милли культураларның эчтәлегенә дә, формасына да актив йогынты ясыйлар. Коммунистик төзелештә уңышларга ирешелә барган саен, халыкларда интернациональ, коммунистик сыйфатлар үскән саен, милли культураларның социалистик эчтәлеге тирәнәя бара һәм ул үзләренең теле, художество традицияләре үзенчәлеге, җирле гореф-гадәтләре ягыннан күп төрле булган милли культураларны туганлаштыра торган нигез булып әверелә. Әнә шул юл белән социа-

листик эчтәлек милли формага актив йогынты ясый да, һәм аңарда төрле милләтләр өчен гомуми булган интернациональ элементлар даими рәвештә ныгый баралар. Милли форманың яңа эчтәлекне чагылдыра алмый торган элементлары я юкка чыга, я шундый дәрәҗәдә үзгәрә, алар хәтта үзләренә яңа эчтәлекне сыйдырырга сәләтле булалар.

Коммунистик төзелеш барышында милли культурада халыкларны аера торган, гасырлар артталыгы, зарарлы дини йогынты тудырган барлык нәрсә юкка чыга бара. Шул ук вакытта милли культураларның прогрессив яклары ишәюдән эзлекле рәвештә барлык совет милләтләре өчен уртак культура формалаша.

Без хәзер үк инде СССР халыклары культурасының хәзинәсе милли рамкалар чигеннән чыга торган иҗат җимешләре белән тулылануга күп мисаллар китерә алабыз. Милли культураларның бу әсәрләре интернациональ характер алалар, чөнки алар совет халыкларының рухи йөзенең гомуми, коммунистик сыйфатларын, барлык социалистик милләтләр өчен бердәм булган яңа, революцион традицияләрне гүзәл гәүдәләндерәләр. Мәсәлән, татар композиторы Нәҗип Җиһановның «Җәлил» операсы татар милли культурасының атаклы әсәре булып тора, ләкин аны барлык совет кешеләре зур кызыксыну белән тыңлыйлар. Чөнки опера эчтәлеге совет кешеләренең, ялкынлы патриотларның һәм эзлекле интернационалистларның яңа йөзен ачып бирә. Операда татар халкы улы Муса Җәлилнең тиңдәшсез батырлыгы күрсәтелә, шуның өчен анда барлык совет кешеләре өчен уртак булган идеаллар җырлана. Операның идея эчтәлеге ягыннан отышы шунда: композитор башка халыкларның музыкаль культуралары казанышларына да кушыла алган һәм шул ук вакытта үзенең индивидуаль һәм милли йөзен дә югалтмаган.

Тугандаш халыкларның әдәбият һәм сәнгать әсәрләре, әгәр алар һәрбер халыкның милли характерында килеп туган төп үзгәрешләрне исәпкә алып язылган булсалар, аның идея омтылышларын, якты киләчәк өчен көрәшен дөрес чагылдырсалар, СССРның барлык халыклары өчен дә якын һәм аңлаешлы булалар, алар тирән интернациональ яңгыраш алалар. Ватаныбыздагы күптөрле милләтләрнең сәнгать эшлеклеләренә Ленин премияләре бирелү әнә шул хакта сөйли.

Партия тарихи барлыкка килгән милли традицияләргә зур игътибар бирә; алардагы прогрессив моментларны кайгыртучанлык белән яклый һәм үстерә, бөтен совет халкы байлыгы итә. Шуның белән бергә, партия коммунистик төзелеш барышында совет социалистик милләтләре арасында барлыкка килә торган һәм аларның рухи уртаклыгын көчәйтүгә, ныгытуга хезмәт итүче яңа традицияләрне, гомуми сыйфатларны үткен күз белән күрергә һәм якларга өйрәтә.

Гасырлар дәвамында барлыкка килгән нәтиҗәле милли традицияләрне күп милләтле совет культурасы үзенә корал итеп ала. Ләкин ул, беренче чиратта, социализм һәм коммунизм эпохасы тудырганнарны чагылдыра.

Нәкъ менә шушы традицияләрдә халыкларның милли үзаңының яңа сыйфатлары геруча тулы чагылды. Милли формаларның, традицияләрнең яңа, социалистик эчтәлек белән баюы, Коммунистлар партиясенең культура үсешендәге гомуми закончалыкларны (ә шулар нигезендә социалистик милләтләрнең өзлексез якынаю процессы бара) исәпкә алуы СССР халыклары культурасының үзара нәтиҗәле хезмәттәшлек итүенең һәм совет кешеләрен интернациональ тәрбияләүнең мөһим өлеше булып тора.

Ләкин кайбер әдәбият һәм сәнгать работниклары милли үзенчәлекнең әһәмиятенә артык бәя бирәләр һәм СССР халыклары тормышында килеп туган төп үзгәрешләрне исәпкә алмыйлар. Андый художниклар милли культурада эчтәлекне түгел, ә форманы беренче урынга куялар. Шуның өстенә алар художество иҗатындагы милли үзенчәлекләрне үзгәрешсез һәм кабатланышсыз күренеш дип карыйлар. Нәтиҗәдә андый кешеләр кайвакыт безнең заман халкының тормыш шартларына һәм ихтыяҗларына туры килми торган, иске, зарарлы традицияләрне, гореф-гадәтләрне күтәреп чыгалар.

Әдәбият һәм сәнгать әсәрләре кешенең формалашуына гаять зур йогынты ясаганлыгын һәркем яхшы аңлый. Алар кешеләрнең җанына, йөрәгенә, акылына үтеп керәләр. Шуңа күрә художниклар халык алдында, партия алдында зур бурычлылар. Иң яхшы милли традицияләрне, сыйфатларны чагылдыручылар буларак, милли аңда, кешеләрнең эшләрендә һәм уйларында булган иң яхшы якларны ишәйтеп, алар үзләре алдындагы зур бурычлары турында даими уйларга, интернационалистлар булыр-

га тиешләр. Кайбер сәнгать һәм әдәбият вәкилләренең объектив үсә торган милли якынлашу процессын дөрес аңлап җиткермәүләре (бигрәк тә тел мәсьәләсендә), бөтен тормыш панорамасын күз алдына китерү урынына бер яклы гына фактлар белән мавыгу, татар милләтенең кайбер атаклы эшлеклеләре эшчәнлегенең интернациональ характерда булуын киметеп күрсәтү, милли традицияләрне примитив, бер яклы гына аңлау хезмәт ияләренең киң массасын интернациональ тәрбияләүгә бу-лышлык итә алмый.

* * *

Совет кешеләрен социалистик интернационализм рухында тәрбияләүнең һәм партия оешмалары үткәрә торган идеологик йогынты чаралары белән милләтчелек калдыкларына каршы кискен көрәшнең халыклар дуслыгын тагын да ныгытуда гаять зур әһәмияте бар.

Республикабызда хезмәт ияләрен интернациональ тәрбияләү буенча нәтиҗәле эш алып бару өчен бөтен объектив һәм субъектив шартлар бар.

Беренчедән, бу мөһим эшкә КПССның сугышчан отрядларының берсе — республиканың 167 мең кешене үз эченә алган партия оешмасы җитәкчелек итә, аның сафларында 60 милләт вәкиле бар. Бу — интернационалистларның зур армиясе.

Икенчедән, республикада пропагандистларның, лекторларның, партия работникларының, фәнни һәм иҗади интеллигенциянең югары квалификацияле отряды бар, алар марксизм-ленинизмның, пролетар интернационализмның бөек идеяләрен хезмәт ияләре аңына җиткерергә сәләтлеләр.

Шуны да исәпкә алу әһәмиятле: Татарстан ленинчыл милли политика нәтиҗәсендә барлыкка килде, ул — пролетар интернационализм идеяләре һәм принциплары тантанасының ачык мисалы.

Республикабызның революцион традицияләргә гаять бай булуының да әһәмияте бик зур: Казанда бөек интернационалист В. И. Ульянов-Ленин үзенең революцион эшчәнлеген башлап җибәрде, халык бәхете өчен көрәшчеләр Н. Федосеев, М. Горький, Н. Бауман, С. Киров һ. б. лар революцион эшчәнлекләрен Казанда башладылар.

Бу революцион традицияләр коммунизм төзү өчен көрәштә ишәйтеләләр. Республикада күп милләтле меңнәрчә коллективлар бар, алар коммунизмның материаль-техник базасын төзү буенча гомуми эшкә үзләреннән өлеш кертәләр. Илебезнең төрле республикалары һәм өлкәләре вәкилләренең көчләре, средстволары һәм осталыклары куелу нигезендә союз әһәмиятендәге корылмалар төзелә.

Партиянең XXIII съезды карарлары, КПСС Үзәк Комитетының шуннан соңгы карарлары нигезендә партия оешмалары интернациональ тәрбия мәсьәләләренә игътибарларын шактый көчәйттеләр. Эшнең формалары һәм методлары төрләнәнде, аңарда зарури конкретлылык артты. Гомуми фикер йөртүләр урынына совет кешеләренең көндәлек тормышыннан һәм хезмәтеннән алынган интернационализм күренешләре фактлары киң кулланыла башлады.

Фестивальләр, сәнгать көннәре үткәрү, башка республикалар вәкилләре белән бергә иҗади, фәнни, производство мәсьәләләрен тикшерүләр зур файда бирә. Шуны гына әйтү дә җитә: юбилей елында гына да республикабызда Ленинград сәнгать һәм әдәбият фестивале, РСФСР автономияле республикаларының яшь язучылары семинары, милли телләрнең үзара бер-берсен баетуы һәм үзара йогынтысы, Татарстанда ленинчыл милли политика тантанасы, театр сәнгате мәсьәләләре буенча теоретик конференцияләр һ. б. үткәрелде. Ульяновск шәһәрендә Татарстан культурасы көннәре уңышлы үтте.

Коммунистлар партиясе политикасына, марксизм-ленинизм тәгълиматына, бу тәгълиматны тормышка ашыру өчен көрәшкә турылыклы булу һәм бирелгәнлек совет кешеләренең тирән интернационализмының нигезе булып тора.

Партия һәм дәүләт кадрларының, хезмәт ияләренең миллионнарча массасының марксистик-ленинчыл хәзерлеге никадәр тирән булса, коммунизмның җиңүе өчен практик көрәшләрендә совет кешеләрендәге интернационализм шулкадәр нәтиҗәлерәк күренә. Шуңа күрә марксизм-ленинизм классиклары хезмәтләрен, партия съездлары, конференцияләре, КПСС Үзәк Комитеты Пленумнары материалларын, Коммунистлар партиясенең һәм Совет хөкүмәтенең җитәкче эшлеклеләре чыгышларын өйрәнүнең интернациональ тәрбиядә бик зур әһәмияте бар.

Хезмәт ияләрен тугандаш халыклар тормышының төрле яклары белән һәръяклап таныштыру безнең көннәрдә интернациональ тәрбиянең бик мөһим чарасы булып тора.

Бу мәсьәләдә телдән һәм матбугат аша пропаганда зур роль уйный. Газета һәм журналларда тугандаш республикаларның җитәкче эшлекләләре чыгышлары, алмаш һәм берләштерелгән полосалар, алмаш радио һәм телевидение тапшырулары, телдән пропаганда — теоретик конференцияләр, халыклар дуслыгы һәм пролетар интернационализм лекторийлары, «СССР халыклары дуслыгы» темасына лекция-концертлар, төрле халыкларның язучылары, художниклары һәм композиторлары иҗатына багышланган тематик кичәләр, лекцияләр һәм укучылар конференцияләре, даими эшләүче кинолекторийлар һ. б. киң кулланыла.

Интернациональ тәрбиядәге уңай фактлар кимчелекләрне томаламаска тиешләр. Бездә бу эштә файдаланылмаган мөмкинлекләр күп әле.

Идеология работникларының кайберләрендә шундый фикер яши: әгәр коллектив бер генә милләттән тора икән, анда, янәсе, интернациональ тәрбия белән шөгыльләнүнең хаҗәте юк. Андый иптәшләр шуны онытталар: интернациональ тәрбия белән милләтчелек һәм шовинизм кебек күренешләрне булдырмау өчен генә шөгыльләнергә кирәк түгел, бу эш яңа кеше формалаштыруның, партия политикасын, социалистик система үсеше, коммунистик хәрәкәт, халыкларның милли азатлык көрәше тенденцияләрен дөрес аңлауның состав өлеше булып тора. Кайда гына булмасын, нинди эшчәнлек белән генә шөгыльләнмәсен, совет кешесе һәр җирдә үзен интернационалист итеп танытырга тиеш.

Шундый ялгышлык та яшәп килә: кайбер иптәшләр күпмилләтле коллективта обстановка үзе үк кешеләрне интернационализм рухында тәрбияли, дип исәплиләр. Сүз дә юк, бөтен совет чынбарлыгы нигездә мондый тәрбиягә булышлык итә. Күпмилләтле бердәм производство коллективында эшләү иптәшлек, үзара ярдәмләшү мөнәсәбәтләрен тудыра. Ләкин актив идеологик йогынтыдан башка чын-чыннан интернационализм барлыкка килми икәнлеге дә ачык аңлашыла.

Интернациональ тәрбиядә тагын бер кимчелек бар: бу юнәлештә безнең чараларның нәтиҗәлелеге нинди, һәрбер форма да үзен аклыймы, кайберләре аларның нәтиҗәсез түгелме, — менә без шуларга аз әһәмият бирәбез. Кайбер социологик тикшеренүләрдән, мәсәлән, шундый фикер туа: лекцияләр азрак нәтиҗәле булып чыга, ә революция, сугыш, хезмәт ветераннары катнашында төрле конференцияләр, очрашулар үткәрү, революция һәм хезмәт даны урыннарына бару күбрәк тәэсир итә. Аңлашыла ки, эшнең нәтиҗәлелегенә бәя бирү өчен бердәм критерийның булуы мөмкин түгел, чөнки күп нәрсә конкрет хәлләргә: халыкның составына, яшәп килә торган традицияләргә, буржуаз идеология йогынтысы дәрәҗәсенә һ. б. бәйле була.

Ләкин шулай да без шуны истә тотарга тиешбез: интернациональ тәрбиядә проформага, формализмга, бушка эшләүгә юл куелмасын, барысы да максатка юнәлешле булырга, кешенең аңына, психологиясенә йогынты ясарга, аны үзенең интернациональ бурычларын күбрәк аңлау дәрәҗәсенә күтәрергә тиеш.

Хезмәт ияләрен интернациональ тәрбияләүдә Совет власте елларында Татарстанның экономик, политик һәм культура үсеше аеруча дәлилле материал булып хезмәт итәргә тиеш. Республикабызның материаль һәм рухи тормышында килеп чыккан гаять зур үзгәрешләр партиянең ленинчыл зирәк милли политикасы, халыкларның хезмәттәшлеге һәм туганнарча үзара ярдәмләшүе нәтиҗәсе булып тора.

Менә республикабызның һаман алга таба үсүен күрсәткән кайбер мәгълүматлар. Татарстанда тулай продукция күләме 1913 ел белән чагыштырганда 233 тапкыр үсте; икенче төрле әйткәндә, хәзер бездә бер көн ярым эчендә революциягә кадәр бөтен ел буена җитештерелгән кадәр күләмдә промышленность продукциясе эшләп чыгарыла.

Халыкның культура тормышында гүзәл үзгәрешләр туды. 9 театрның һәм филармониянең иҗади составы 700 дән күбрәк артистны берләштерә. Совет Татарстаны язучылары 50 роман, 100 дән артык повесть, 500 дән артык пьеса иҗат иттеләр. Аларның әсәрләре дөньяның күп кенә телләренә тәрҗемә ителделәр. Патриот шагыйрь Муса Җәлил шигырьләре бөтен дөньяга таралды.

Милли культураның чәчәк атуы бигрәк тә музыка сәнгате өлкәсендә ачык чагыла. Композиторларыбыз халык көйләрен гади эшкәртүдән, җырлар һәм кечкенә музыкаль пьесалардан башлап, кырыгынчы елларга инде җитлеккән әсәрләр: опера, симфония, балет иҗат итүгә барып җитте. Бүгенге көндә дә алар музыкаль культураның барлык жанрларында эшлиләр. Татарстан композиторлары 30 лап зур музыкаль-сәхнә әсәрләре иҗат иттеләр. Аларның иң яхшылары совет музыкаль культурасы хәзинәсенә керде. Җиһановның «Җәлил» операсы һәм Яруллинның «Шүрәле» балеты чит илләрдә совет сәнгатенең лаеклы вәкилләре булып торалар.

Совет власте елларында республикада югары белем алу зур үсешкә ирешә. Хәзерге вакытта республиканың 11 югары уку йортында 62 мең студент укый; бу — Австрия белән Швейцариянең икесендә булгандагыдан күбрәк. Вузларда, 52 фәнни-тикшеренү учреждениесендә 6000 гә якын фәнни-педагогик работник, шул исәптән бер академик, бер Фәннәр академиясе член-корреспонденты, 200 фәннәр докторы һәм профессор, 1 500 фәннәр кандидаты эшли. Докторлар һәм кандидатлар арасында 400 дән артык татар бар.

Болар — партиянең милли политикасы тантанасының ачык фактлары, интернационализм идеяләрен — СССР халыкларының туганнарча хезмәттәшлегенең көчен һәм тупланганлыгын пропагандалау өчен ышандырырлык яхшы материаллар.

Партиянең интернационалистик политикасын тормышка ашыру СССР халыкларын якынайта һәм туганлаштыра. Һәм, киресенчә, бу политикадан аз гына булса да читенү, шовинизм һәм милләтчелек калдыкларын теләсә нинди формада күрсәтү халыкларның туганнарча хезмәттәшлеген һәм якынаюын үстерү эшенә зыян китерә. Шуңа күрә социализм һәм коммунизм төзелешенең барлык этапларында партия һәртөрле милләтчелек һәм шовинизм калдыкларына каршы кискен көрәш алып барды һәм алып бара.

Милләтчелек үзенең табигате белән социализмга, дөньяга марксистик-ленинчыл карашка, халыклар дуслыгына дошман, ул социалистик милләтләр үсешенең һәм якынаюының объектив процессына каршы килә.

Безнең илебездә милләтчелек калдыклары массовый характерда түгел, чөнки аның социаль, политик һәм экономик җирлеге юк. Милли изүнең бетерелүе, социалистик милләтләр барлыкка килү, алар арасында тигезлек, туганнарча хезмәттәшлек һәм үзара ярдәмләшүнең социалистик мөнәсәбәтләре урнашу белән буржуаз милләтчелек идеологиясенең тамырлары да юкка чыгарыла.

Ләкин кайбер җирдәшлек күренешләре фактларында, милли аерманлыкны һәм аерылганлыкны вәгазьләүдә, үткәндәгене идеаллаштыруда, кенкүрештә һәм кадрлар сайлап алуда реакцион традицияләрне һәм гадәтләрне яклауда (андый очракта республикалар халкының күпмилләтле составы исәпкә алынмый һәм кайсы булса да бер милләт вәкилләренә өстенлек бирелә) милләтчелек калдыклары чагыла әле.

Мондый милләтчелек калдыкларының куркынычлылыгы аларның яшертен гәүдәләнүендә.

Хәзерге заман шартларында, империализм социализмны хәрби көч ярдәмендә бетерә алмаганда һәм ике системаның экономик ярышында бер-бер артлы җиңелүләргә дучар булганда, капиталистик илләрнең хаким даирәләре социалистик дәүләтләргә карата барыннан да элек идеологик диверсиягә зур өмет баглыйлар. Алар башлыча кешеләр аңында искелек калдыкларын җанландыруга һәм яклауга, түбән идеяләрне вәгазьләүгә исәп тоталар. Кешеләрнең милли хисләрендә уйнау, милләтчелек настроениеләрен кыздыру һәм шул нигездә совет халкының монолит бердәмлеген какшатырга омтылу да империализмның идеологик диверсиясе арсеналында тора.

Империалистик пропаганда йогынтысы милләтчелек һәм шовинизм калдыкларының яшәүчәнлегенең төп факторларыннан берсе булып кала. Моннан шундый нәтиҗә чыга: бу искелек калдыкларына каршы көрәш — ул, бер үк вакытта, буржуаз идеологиягә дә удар дигән сүз.

Идеологик эштә шуны да исәпкә алмый ярамый: милләтчелек һәм шовинизм Мао Цзэ-дун группасының коммунистик хәрәкәт бердәмлеген таркату һәм авантюристик уйларын тормышка ашыру буенча эшчәнлегендә төп корал булып әверелде. Милләтчелек күренешләре социалистик илләр дуслыгы эчендә булмаска тиеш. Шуңа

күрә Мао группасының антимарксизмын, милләтчелеген фаш итү, кешеләрдә интернационализм, бөтендөнья революцион процесс үсеше тенденцияләрен дөрес аңлауны тәрбияләү бик әһәмиятле.

Милләтчелек калдыкларының яшәүчәнлегенә йогынты ясаучы бүтән факторлардан түбәндәгеләрне күрсәтеп үтәргә кирәк.

Кешенең аңындагы һәм үз-үзен тотышындагы үзгәрешләр экономик һәм политик мөнәсәбәтләрдәгеләргә караганда акрынрак бара. Гәрчә Октябрь социалистик революциясеннән бирле 50 ел вакыт узса да, һәм бу еллар эчендә халыклар арасында хезмәттәшлекнең үсеше пролетар интернационализм идеяләре йогынтысында тормышка ашырылса да, шул нәрсә ачык күренә: чагыштырмача кыска тарихи срок эчендә барлык кешеләр аңыннан милләтчелек, искелек калдыкларын чыгарып бетерү читен.

В. И. Ленинның милли эгоизм, милли чикләнгәнлек — вак буржуаз калдыкларның иң тирәне, дип кисәтүе бүгенге көндә дә үзенең әһәмиятен югалтмый. Тарихи тәҗрибә күрсәткәнчә, кешеләр аңында капитализм калдыклары социалистик строй урнашканнан соң да озак вакыт дәвамында сакланып килә. Коммунистик төзелешнең хәзерге полосасында искелек калдыкларын тулысынча бетерү бурычы аеруча актуаль әһәмияткә ия булып тора.

Милләтчелек калдыкларының яшәүчәнлеге турында сөйләгәндә, шуны һич тә онытмаска кирәк: бу калдыкларны капитализмның бүтән калдыклары, бигрәк тә дин, яклый.

Динне, аның пролетар интернационализм идеологиясе белән сыеша алмый торган морален фаш итү хезмәт ияләренең киң массасына йогынты ясауны көчәйтүнең, аларны атеистик һәм интернациональ тәрбияләүнең мөһим чарасы булып тора.

Милләтчелек калдыклары шулай ук көнкүрештә реакцион гадәтләр күренешләрендә дә чагыла, аерым кешеләрнең халык, милли традицияләр исеме астында аларга тотрыклылык бирелүгә омтылуларында гәүдәләнә. Мондый карашларны яклаучылар милли традицияләрне реаль чынбарлыктан аерым хәлдә карыйлар, алар гадәтләр һәм традицияләр төрле була икәнлекне: аларның кайберләре асылында артта калган, консерватив, социаль һәм милли гаделсезлек тарафыннан тудырылган булуын, халыкның үткәндәге авыр тарихын чагылдыруын исәпкә алмыйлар. Андый традицияләр халыкның хәзерге этапта экономик һәм культура үсеше дәрәҗәсенә туры килә торган яңа традицияләргә кушылырга комачаулыйлар, милләтләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләрнең яңа рухын чагылдырмыйлар. Совет власте елларында халыклар тормышында яңа нәрсәләр белән баеган икенче бер гадәтләр һәм традицияләр прогрессив күренеш булып торалар. СССР халыкларының культурасы үсүен һәм үзара якынаюын стимуллаштыралар.

Революцион бәйрәмнәрне, яңа елны, аерым категория работникларның героик хезмәтенә бәйләнешле бәйрәмнәрне (шахтер, төзүче, тимер юлчы һ. б. көннәрен) бәйрәм итү СССРның барлык халыкларының гомуми әйбәт традицияләре булып әверелде. Аерым халыкларның күп гасырлардан бирле килә торган һәм прогрессив әһәмияте булган традицияләре бездә саклана алар, ул гына да түгел, аларга башка милләтләр вәкилләре дә актив килеп кушылалар. Мәсәлән, татарларда язгы кыр эшләре тәмамлануын Сабан туе бәйрәме белән билгеләп үтү күптәннән традиция булып килә. Хезмәт бәйрәме буларак, Сабан туе Татарстанда һәр ел саен үткәрелә, һәм, шунысы характерлы: аңарда республиканың 60 милләттән диярлек торган барлык халыклары катнаша.

Гадәтләр һәм традицияләр халык тормышы белән, аның социаль, экономик һәм культура үсеше шартлары белән тыгыз бәйләнгәннәр. Ә ул шартлар үзгәрешсез килеш калмыйлар, шуңа күрә, тормыш шартлары үзгәрү белән бергә, традицияләр дә үзгәрәләр. Милли гадәтләргә, традицияләргә бәя биргәндә, моның белән хисаплашмау һәм, — прогрессивмы алар яисә реакционмы икәнлегенә игътибар итмәстән — үткәндәге милли традицияләргә ябышып яту — СССР халыкларының алдынгы социалистик традицияләргә кушылуына аңлы рәвештә тоткарлык ясау, социалистик милләтләрне бер-берләрен үзара баету эшендә ясалма киртә булдыру дигән сүз.

Нәтиҗәле интернациональ тәрбия эше алып бару — халыклар тормышына хәзерге заман көнкүреше шартларын, социалистик милләтләрнең коммунизмга таба хәрәкәтен чагылдыра торган яңа традицияләрне кертүгә барлык чаралар белән булышлык итү

дигән сүз. Көнкүреш шартлары коммунистик тәрбиягә турыдан-туры кагыла. Шуңа күрә, милләт байлыгы дигән булып искергән гадәтләрне һәм традицияләрне саклап калырга маташучы кешеләргә кискен отпор бирергә кирәк, чөнки аларның теге яисә бу халыкның чын милли интереслары белән берникди дә уртаклыгы юк, ә бәлки чикләнгәнлеккә һәм милли бикләнгәнлеккә генә алып баралар.

Партиянең милли традицияләргә мөнәсәбәте КПСС Программасында ачык чагылдырылган. Партия, бер яктан, коммунистик төзелешкә комачаулаучы гадәтләргә һәм традицияләргә каршы кискен көрәш алып барырга, ә икенче яктан, — һәрбер халыкның прогрессив традицияләрен якларга, аларны барлык милләтләр байлыгы итәргә чакыра.

Милләтчелек калдыкларына каршы көрәш зур осталык һәм такт, совет кешеләренең милли хисләренә игътибарлы караш, совет халыклары тормышының милли-үзенчәлекле һәм гомум интернациональ якларын дөрес исәпкә алуны таләп итә. Шуңа күрә партия милли үзенчәлекләрне күпертүгә каршы көрәшү белән бергә, аларны кырый кагуга каршы да көрәшә. Алар икесе дә соңгы исәптә бердәй нәтиҗәгә — милләтчелек калдыкларын җанландыруга китерәләр.

Совет җәмгыяте тормышында социалистик интернационализм материаль җитештерү өлкәсендә дә, шулай ук культура өлкәсендә дә чагыла. Ул буржуаз идеологиягә каршы көрәш белән бәйләнгән, социалистик лагерь илләре арасында туганнарча хезмәттәшлекне ныгытуга, халыкара коммунистик һәм эшчеләр хәрәкәте белән барлык элемтәләрне киңәйтүгә һәм ныгытуга китерә.

Күпкырлы идеологик эшчәнлегендә партия оешмалары шуңа аеруча игътибар бирәләр: коммунизм төзүчеләрнең мораль кодексы принциплары барлык совет кешеләренең фикерләү образына, хәрәкәтләренә нык кереп урнашырга тиеш, аларның эчке ихтыяҗлары булып әверелергә тиеш. Хезмәт ияләрен интернациональ тәрбияләүдә, социалистик милләтләрне тагы да якынайтуда бу эшнең зур әһәмияте бар. Коммунизм төзүчеләрнең партиябез Программасында формалаштырылган мораль кодексы СССРдагы барлык халыкларның дуслыгы һәм туганлыгы, милли һәм раса дошманлыгына түзеп тормау, барлык илләр хезмәт ияләре белән, барлык халыклар белән туганнарча хезмәттәшлек кебек әхлакый принциплар турында сөйли. Мораль кодексның таләпләре — коммунизм төзүчеләрнең интернациональ сыйфатларының чын-чыннан тулы чагылышы. Аларны тормышка ашыру, КПСС Программасында әйтелгәнчә, СССР халыкларының тулы бердәмлегенә ирешүдә иң әһәмиятле өлеш булачак.

Чыннан да, мораль кодексның «Коллективизм һәм иптәшләрчә үзара ярдәм»; «һәркем барысы өчен, барысы да һәркем өчен»; «Кеше кешегә дус, иптәш һәм туган»; «һәркемнең җәмгать байлыгын саклау һәм ишәйтү турында кайгыртуы»; «Коммунизм эшенә бирелгәнлек» кебек гүзәл принциплары кешеләрне милли билгеләре буенча аермыйлар, ә бәлки халыкларны туганлаштыралар, теләсә кайсы социалистик милләт вәкиленең милли характеры формалашуда әһәмиятле сыйфат булып торалар.

Интернациональ тәрбия — җанлы, иҗади эш, ул торгынлыкка, догматик карашка түзми. Бу эшне үткәргәндә милли һәм интернациональ якларны, илебез халыклары арасындагы мөнәсәбәтләрне үткән чорда булган гаять зур үзгәрешләрне һәм милли мөнәсәбәтләрнең үсеш перспективаларын исәпкә алырга кирәк.

Октябрь революциясенең илебез халыклары язмышы өчен, бөтен дөнья революцион процесс үсеше өчен гаять зур җимешләрен аңлау шатлыклы. Фән, сәнгать, әдәбият эшлеклеләренең Октябрь идеалларын тормышка ашыруны мактап җырлаулары һәм коммунистик җәмгыять төзүгә лаеклы өлеш кертүләре гаять кирәкле, файдалы эш!

II ■ II

## Гамил Афзал

### Дөнья сакта

Якты көнгә
Зәңгәр төн бәйләнә.
Вакыт бара. Сәгать туктамый.
Күк томанга төренеп Җир әйләнә;
Җир әйләнә,
Дөнья йокламый.

Дөнья уйлый,
Дөнья сакта тора.
Бик болгавыр аның уйлары.
Бер Кояшка якты йөзен бора,
Бер Марска салкын йөзен бора, —
Кыл өстендә тора Җир шары.

### Вәгъдә

Ялан аяк кардан йөгерермен,
Котып салкынына түзәрмен,
Чәчем белән урам себерермен,
Тешем белән тимер өзәрмен.

Төпсез упкын аша сикерермен,
Агымнарга каршы йөзәрмен,
Таш өстендә гөлләр үстерермен,
Җырым белән җирне бизәрмен.

### Дулкыннар

Шаулыйлар дулкыннар,
Кайныйлар дулкыннар,
Ыргылып меңәләр ярларга;
Диңгездән меңәләр,
Диңгезгә чигәләр
Энҗеләр чәчрәтеп тауларга.

Үкерешә дулкыннар,
Сикерешә дулкыннар,
Ябырыла кыялар өстенә;
Ярларны юалар,
Ташларны юалар,
Ашкынып иркенгә, иркенгә...

Шауласын дулкыннар,
Кайнасын дулкыннар,
Тетрәсен кыялар күкрәге!
Алданган көчләләр,
Ярсыган үчләләр
Көрәшми гаделлек күрмәде.

●

Нинди үлчәү белән үлчәнелә
Яшәү көче, яшәү теләге!
Асфальт ташын тишеп күтәрелә
Күмелеп калган бәбкә үләне.

Килер заманнарның,
кояш төшеп,
Нәфис гөлләр үскән кырында,
Калын гасырларның сыртын тишеп,
Чыксын иде минем җырым да!

## Иске кабер ташларын караганда

Мең кешенең башын чабып өзгән
Җәллад кабере белән беррәттән,
Мең кешегә озын гомер биргән
Табиб кабере килеп эләккән.

Гомер юлын алар бергә үткән,
Берсе — үлем, берсе — тереклек.
Теге дөньяда да бергә икән
Кабахәтлек белән бөеклек.

## Читкә киткәннәр сүзе

Сандугачлы яшел урман,
Басу буйлары —туган җир;
Ямьле булса да чит кебек,
Кеше кадерсез булган җир.

Чокыр-чакыр, тимер дә таш —
Тормыш терәге корган җир;
Шыксыз булса да күңелле
Кеше кадерле булган җир.

## Патша һәм шагыйрь

Шагыйрь ялкын алган,
патша — алтын,
Шагыйрь җырын биргән,
патша — закон;
Закон илдә йөргән
хәсрәт булып,
Җыр йөрәккә сеңгән
хасият булып.

●

Франсуа Вийонга

Яшәмәдең тигез җирдә түмгәк
булып,
Яуга чыктың бар золымны
җиңмәк булып,
Нык кәрәштең,
көлә-көлә язганнарың
Муенына уралганчы элмәк булып.

●

Болын — хәтфә, күкләр — зәңгәр
сатин,
Таңнар комач кебек,
Ике гомер карап торсаң да син,
Күреп туймас кебек.

Көмеш айлы, чәчәкләре чыклы
Киче-иртәсе бар;
Мең үкенеч. Шушы матурлыкны
Куеп китәсе бар...

●

Ян,
өзгәлән,
әмма өмет өзмә,
Кояш тигез карый безгә дә.
Күккә карап зәңгәр юллар эзлә,
Күккә карап хаклык эзләмә.

Җиргә ябыш,
җирдән өмет өзмә
Җирдә бәхет бар ул безгә дә.
Җир астыннан алтын, ахак эзлә,
Җир астыннан хаклык эзләмә!

## Ике кеше

Тәхет терәгенә терсәк куеп
Утыручы хәтфә урында,
Фикер йөртә бар дөньяны суеп,
Зур каберлек ясау турында.

Тар урында дүрт урындык тезеп
Яткан кеше пальто ябына,
Бөтен дөнья бәхет, рәхәт күреп
Яшәячәк чорны сагына.

## Мәдинә Маликова

# КАЗАН КАЛАСЫ— ТАШ КАЛА

ПОВЕСТЬ[1]

## Чатнау

Дөнья тыныч түгел, дөнья афәт белән тулы. Кайдадыр зилзилә җилләре кубып, океаннарны ярларыннан чыгара һәм шәһәр-авылларны җимереп, суга гарык итә. Кайдадыр җир тетри, кайдадыр янар таулар ут чәчә. Көн саен меңнәрчә һәм меңнәрчә кешеләр һәлак була.

Хәвефле хәбәрләр йөри һавада. Алар төрле дулкыннарда, төрле телләрдә киләләр һәм радиоалгыч аша кереп тын квартирларны шом белән тутыралар. Вилдан аларны тыңлый да эченнән генә шөкерана итеп куя: «Ярый әле: без торган җирләр тыныч, ярый әле: без афәтләрдән ерак». Һәм шалт итеп икенче клавишага баса.

Радиоалгыч янә шомлы хәбәрләр сөйли: кайдадыр канлы сугышлар бара, кайдадыр патшаларны бәреп төшерәләр, һавадан самолетлар мәтәлеп төшә, канлы көрәшләрдә ил батырлары җан бирә. Бу фаҗигаләрне кешеләр үз башларына үзләре ясый. Барсына бер сәбәп: йөгәнсез хисләр, чамасыз теләкләр, дан эстәү. Ни җитми диген кешегә, нишләп тыныч кына яши алмый ул?

Вилдан шалт та шолт радиоалгыч клавишаларын баса, үзе күңелсез уйларының очына чыга алмый аптырый.

Ул тыныч яшәргә тели. Эшкә баргач, үзенә тапшырылганның һәммәсен тырышып үтиме ул? Үти. Өйгә кайткач, иркенләп ял итәргә хокукы бармы аның? Тормышының калган сәгатьләрен тату гаиләдә, тыныч кына үткәрергә хакы бармы? Бар.

Ләкин аңа да, бар афәттән, йөгәнсез хисләрдән, чамасыз теләкләрдән ерак торган, әз генәдән дә канәгать кешегә дә тынгы бирми дөнья. Аларның өенә дә афәт бәреп керде. Дөрес, бу алай аермачык күренми әле, әмма сизелә, бик сизелә. Моңа кадәр дә үзен шактый салкын тоткан Мәрьям көннән-көн аннан ерагая бара.

Я инде? Аңа соң, аңа ни җитми? Тормышлары түгәрәк. Вилданның бөтен тормышы гаиләдә. Ә ул канәгать түгел, әллә ни тели, әллә кая омтыла. Төннәр буе проект төзим дип утыра, юньләп йокы күргәне юк,

---

[1] Ахыры. Башы 4 санда.

ябыгып бетте, өй эшләрен карарга житешә алмый, чисталык-тәртип яклары шактый начарайды.

Вилдан әллә соң Мәрьям берәрсе белән бәйләнде микән дип тә шикләнеп караган иде дә, ләкин хатынның үз-үзен тотышында аны расларлык дәлил тапмады. Вилдан борчылуыннан укылып бетмәгән китабын ташлады, тартмадагы чәйләрнең беткәнен сизми калды.

Әйе, нихәтле генә сакланма, афәт өеңә бәреп керә икән. Менә бүген Мәрьям кара кайгыда: Сажидә апаның ире вафат булган. Ну, үлгән беткән, дип уйлый Вилдан, я инде шуның өчен кайгырудан кемгә ни файда? Тизрәк онытырга кирәк андый нәрсәләрне. Әллә кемне күмгәннәр дип, үз гомереңне кыскартып булмый бит инде.

Ә Мәрьямгә бер сүз әйтер хәл юк, күзләре сиңа текәлгән, ә үзе сине бөтенләй күрми дә, ишетми дә кебек.

Вилдан тагын бер кат шалт итеп «Маяк»ны тота да әллә кайчаннан бирле янында:

— Әти-и! Әти-и! Кораб ясап бир әле! Әти-и! Кора-а-аб! — дип еламсырап торган кызына борыла. Бераздан алар идәнне океан итеп, йөзеп китәләр, елтыравык кара чәчле ике баш бер-берсенә терәлгән, Фәйрүзәнең алсу капрон банты әтисенең колагын кытыклый.

...Мәрьям, иренең хәвефле кичерешләрен сизенсә дә, аларга әллә ни әһәмият бирмәде. Аның үз борчулары бар. Төннәрен Вилдан тыныч сулап йоклап ятканда, аның күзеннән йокы кача. Кара инде, ул утызга якынлашып килә ләбаса? Әле аның горурланырлык, мактанырлык бер генә эш тә кырганы юк бит. Шулай итеп балачактан төзергә дип хыялланып йөргән бәхет шәһәре салынмый калыр микәнни?

Шәһәр читендәге буш урында тугыз мең кешелек яңа микрорайон төзиячәкләр иде. Шәһәрнең генпланыннан Мәрьям бу турыда белде дә үзе проект төзергә алынды. Дөрес, бу микрорайонга проект төзү заданиесе дә бирелмәгән иде әле, бирелсә дә, андагы йортлар, әлбәттә, типовой проект буенча төзеләчәк иде.

Шулай да Мәрьям бу урында үзенең бәхет шәһәрен проектлаштырып карарга булды. Дөрес, бу инде ул яшь чакта хыялланган бер абстракт оҗмах түгел, матурлык законнарына буйсынган архитектура ансамбле булырга тиеш иде. Күңеленең ерак почмагында Мәрьям оялмыйча Шәүкәт күзенә күрсәтерлек проект иҗат итү теләге дә саклый иде.

Задание булмагач, проектны башлыча өйдә, төннәрен эшләргә туры килде. Кәгазь өстендә эшләүдән бигрәк күп уйланырга, күп укырга, исәпләргә кирәк иде. Чөнки мондый эштә иң әһәмиятлесе идея — ансыз юньле проект эшләп булмый. Вакыт кирәк, вакыт. Ә каян аласың ул вакытны?

Буйдак чагында Вилданның йорт эшләрен килеп-китеп эшләп йөрүче бер апа башкара торган булган. Өйләнгәч, Вилдан аңа расчет бирде: «Чит кешенең квартирыма килеп йөрүен бер дә яратмый идем, котылдым», — диде. Өстәвенә, ялгыз кешегә таман гына квартир, өч кешелек гаилә өчен бик тар икән, анда Мәрьямнең сызымнарына урын табылмады. Бернинди шарт юк, мөмкинлек юк. Хатынының: «Уф, ардым бүген!» — дигән сүзләренә Вилдан матур күзләрен зур итеп ача: «Чынлапмы? Төкер эшеңә, азаплама үзеңне. Дөньяның эше бетмәс, ял итеп ал, иртәгә эшләрсең калганын». Ә Мәрьямгә ашыгырга кирәк — вакыт сизелми дә узып китә бит. Житмәсә, борчуы да һаман булып кына тора.

Бүген менә Сажидә апа янына барырга кирәк. Елый да елый, бичара, һич юана алмый. Өендә ике кызы бар, шулай да көн саен мастерскойдан берәр кеше аның янына кунарга бара: чөнки аның чирләп китүе ихтимал, ул-бу булса, бала-чага нишли ала? Бүген Мәрьям чираты — Сажидә апаны ул бик якын итә, ярата, һич бармый кала алмый.

Бу турыда Мәрьям Вилданга эштән кайткач та әйтмәде. Вилданның бу эшкә ризалык бирмәячәген күңеле сизеп тора иде аның. Вилданның хәтерен калдыру бүген бигрәк тә яхшы түгел. Ул үзе хатынының күңеленә охшамаслык бернәрсә дә эшләми. Киресенчә, аңа ярарга тырыша: бүген менә көтелмәгән бүләк тә алып кайткан иде. Фәйрүзәгә кечкенә тартма тоттырды да:

— Мә, кызым, әниеңә илтеп бир әле, — диде.

Тартма эченнән кара бизәк төшерелгән көмеш беләзекләр килеп чыкты. Борынгы беләзекләр. Каян эзләп тапкандыр. Мәрьям аларны киеп кенә карады да тизрәк салып куйды: ул үзен бу бүләккә хакы юк сыман сизде. Гомумән, Вилдан хатынын бизәргә ярата, үзе бүләк иткән алка-йөзек, брошкаларның аңа килешүен күреп чын күңелдән сөенә торган иде. Тик соңгы вакытта бүләкләр дә арадагы бозны эретә алмый башладылар.

Алар торган саен бер-берсеннән ерагая бардылар. Вилдан Мәрьямне чибәрлеге, тыйнаклыгы, житдилеге өчен ярата һәм аның үзенеке генә булуын, хисләрен, уйларын, омтылышларын гаиләгә генә багышлавын тели. Ә Мәрьям исә ижатында дус, кинәшче, олы терәк эзли, ләкин аның эшен Вилдан аңламый да, аңларга теләми дә. Институтта сәләтле, абруйлы белгеч саналган архитектор Закирова өенә кайткач кечерәеп киткәндәй була, гап-гади хатын, хәтта уңмаган хатын булып кала. Вилдан аның уңмаганлыгына тешен кысып, «менә бит мин нинди яхшы ир», дигән кыяфәт белән түзә иде.

Мәрьям ашарга әзерләп, кухня өстәленә барын тезеп куйды да, Вилдан белән Фәйрүзәне чакырырга бүлмәгә чыкты.

— Әни, — дип кычкырды Фәйрүзә. — Утыр син дә корабка. Әйдә бергә китәбез.

Мәрьям «кораб»ның кырыйларында үзенең сызымнарын күреп, өнсез калды.

— Корабыгыз минем проект буенча төзелгән икән, ә?

Вилдан урыныннан кузгалды:

— Но-о! Каяле, кызым, карыйк әле. Кирәк сызыммыни ул? Үзең дә инде, кирәк әйберне теләсә кая ташлыйсың.

Вилдан корабны сүтте дә кәгазьне кулы белән сыпырып тигезләргә тотынды.

— Таптың инде син дә үзеңә азап, — диде ул өстәлдән башын күтәрми генә. — Ашарыңа юк кеше төсле кыланасың. Ни бирә сиңа бу эш? Акчамы? Данмы? Әгәр эшеңдә мәҗбүр итәләр икән, төкер дә чыгып кит. Мин сине үзебезнең заводның төзелеш бүлегенә любой вакыт урнаштыра алам.

Бу турыда инде беренче тапкыр гына сөйләшү түгел, шуңа күрә Мәрьям сүзгә кереп тә тормый.

— Ашарга әзер. Әйдәгез, — генә ди.

Ләкин Вилдан моның белән генә туктамый әле. Аның җай чыкканда әйтеп бетерәсе килгән сүзләре бар:

— Һәрхәлдә, институтында юньле эш чыкмаслыгына ышангач, үзең дә минем белән килешерсең әле. Төзүче ич син, менә дигән һөнәрең бар, нәрсәгә җыен юк-бар белән азапланырга.

Табын янында чит кешеләрдәй тын гына утырдылар. Хәтта Фәйрүзә дә боегып киткәндәй иде. Ире өстәл яныннан кузгалгач кына, Мәрьям, инде хәзер әйтми калу мөмкин түгел дип, сүз башлады:

— Беләсеңме, мин Сажидә апа янына барып кунарга вәгъдә биргән идем бүген.

Вилдан хатынының ни әйткәнен тиз генә аңлый алмады, күрәсең. Бераз торгач кына телгә килде:

— Ник?

— Ну, мин сиңа әйткән идем ич инде. Анык ире үлде. Бик кыен аңа хәзер.

— Булса соң? Син нишли аласың анда? — Вилданның тавышында ризасызлык, канәгатьсезлек яңгырады.

— Янында кеше булгач, җиңелрәк аңа. Һәрхәлдә, мин килергә вәгъдә бирдем.

— Бармыйсың. Юньле хатын ир ташлап, бала ташлап, җиде төн уртасында әллә кая йөрми. — Вилданның йөзе каралып чыкты, күзләре чуен төсенә керде, иреннәре югарып киткәндәй булды. — Әни кешегә мәет киткән өйдә йөрү гомумән ярамый. Чир ияртеп кайтып балага йоктыруың бар.

— Аңла, мин бармый кала алмыйм. Мин вәгъдә бирдем. Аннары, әгәр үз башыңа кайгы төшкәч, дусларың янына килмәсә, сиңа да авыр булыр иде бит? Шулай бит?

— Булса булыр. Анык урынына мин беркемнән дә нинди дә булса корбан таләп итмим. Әгәр минем белән әз генә исәпләшәсең икән, ике аягыңның берсен дә атламыйсың. Менә шул. Анык туган-тумачалары бардыр, шулар юатсын.

Вилданның ияге сизелер-сизелмәс кенә калтырый башлады. Түгәрәк, нәфис ияк ихтыярсызлыкны күрсәтеп тора. Җитмәсә, астыннан икенче ияк үсә башлаган. Кай арада шулай тазарган диген, егет чакта юк иде бит. Мәрьям үзен-үзе кулга алырга тырышып:

— Мин барыбер барам! — диде.

— Алай мине санга сукмыйсың икән, рәхим ит. Гомумән мөнәсәбәтләрне өзә аласың.

Вилданның күптән җыелып килгән ачуы ташып чыкты. Дәгъва зурга китә башлады. Мәрьям чөйдән пальтосын алды да чыгып китте.

## Калалар һәм кешеләр

Йортлар язмышы да кешеләр язмышына охшаган: төзеләләр, яңа чакта бөтен тирә-якны бизәп торалар, аннары әкренләп картаялар, тузалар, тын гына үләләр. Йортлар язмышы кешеләр язмышы белән уртак: сугышларда яраланалар, җимереләләр, афәт килсә, вакытсыз искерәләр, тузалар. Тыныч, мул елларда ишәяләр, матурланалар. Йортларга карап илнең иминлеген белеп була.

Калалардагы таш йортларның гомере озын. Аларны салган кешеләр күптән юк инде, әмма шушы йортларда аларның матур хисләре, якты хыяллары, тормышы һәм язмышы саклана. Калалар үзләрендә кешелек тарихын саклыйлар.

Җир йөзенә яңадан-яңа буыннар килә, һәрберсе үзенчә йортлар сала, һәрберсе шәһәрне үзенчә яхшырта һәм үзенчә бизи.

Шул рәвешле калада бер-берсенә охшамаган төрле йортлар барлыкка килә. Шулай да һәр каланың үз йөзе, үз үзенчәлекләре, үзенә бер бөтенлеге бар. Калалар калаларга охшамый, чөнки аларны төзегән халыклар да бер-берсенә охшамаган.

Гаҗәеп кала Казан! Нинди генә йортлар, нинди генә биналар юк биредә. Ак стеналы кремль, гади формада, ләкин искиткеч матур Сөембикә манарасы, университет колонналары, Петропавловский соборының бизәкле манаралары һәм челтәрле тәрәзәләре. Шулар янында типовой кварталлар, тимер-бетоннан һәм пыяладан салынган биналар. Казанны башка калалардан аерып торган, аны матур һәм күңелгә якын иткән үзенчәлеге шунда: биредә кеше үзенең табигать баласы икәнен онытмый. Күп калаларда урамнар коридор кебек, кая карама күз таш стенага терәлә. Ә Казанда алай түгел. Кайда гына булма, урам башында, я чаттан борылгач та Иделнең яки Казанның комлы ярын яки

шәһәр тирәсендәге урманнарны, яисә урман кебек яшел иркен паркларны күрәсең. Көндез кояшы-болыты, кичен ай-йолдызы күз алдында, аларны биек стеналар кешедән ерагайтмый.

Мәрьям үз проектын төзегәндә, Казанның нәкъ менә шул үзенчәлеген истә тотып эшләргә тырышты. Яңа квартал урман буенда булачак иде, шуңа күрә кешеләр үзләрен урманда яшәгәндәй хис итсеннәр, иртәләрен сандугач сайравы ишетелеп торсын, ачык тәрәзәләрдән урман һавасы бәреп керсен.

Кварталның гомуми күренеше генә әзер иде әле. Мәрьям аны Газизгә күрсәтеп, аның белән киңәшергә дип әзерләп куйган иде.

Май азагы, көн җылы, матур. Агачларның яңа гына яфрак ярган чагы, алмагачларның шау чәчәктә вакыты иде. Эш бетәр алдыннан гына мастерскойга Шәүкәт килеп керде.

Апрель аенда автобуста очрашканнан бирле аларның күрешкәне юк иде. Ул чакта институтка керергә Шәүкәтнең әллә вакыты булмады, әллә батырлыгы житмәде.

Ул һәммә кешегә берьюлы баш иеп исәнләште, бөтен мастерской аша туп-туры Морат өстәле янына узды. Элеккечә күкрәгән киереп, хуҗаларча атлый, дулкынланадырмы-юкмы, аны бер дә сиздерми. Кue чәче кашларына ук бөселеп төшкән, үзе әфлисун кабыгы төсендәге кыска җиңле ефәк күлмәк һәм яшел чалбар кигән.

Мәрьям ул утырган якка карамаска тырышты. Тик аның очраклы гына ташланган карашы да аны ут кебек көйдерә, бераз саңгыраурак әкрен тавышыннан йөрәк әрнеп авыртып китә иде. Ул проектын Шәүкәткә күрсәтеп, аның фикерен ишетергә теләде. Ләкин ничәмә-ничә пар күз алдында аңа проект күрсәтү мөмкин түгел иде.

Мәрьямгә аның хисләрен барсы да сизәдер, йөрәге ничек шашып типкәнен барсы да ишетәдер кебек тоелды. Бигрәк тә Шәүкәт моны тоеп утырадыр. Мәрьямнең исә эч серләрен аңа да, башкаларга да белгертәсе килми иде. Ул урыныннан кузгалды, планшетын кулына алды һәм аркасында Шәүкәтнең күз карашын тоеп, мастерскойдан чыгып китте.

Коридорга чыккач, аның тез буыннары йомшап китте, ул стенага сөялде, тик кемнеңдер мастерскойдан чыгып килгәнен ишетеп, тизрәк турайды. Ишектән Шәүкәт килеп чыкты. Ул Мәрьямне үзен көтә дип уйлады, ахры, әллә аның чыгып китүен үзенә ишарә дип аңлаганмы? Һәм ул дустанә якын итеп елмайды.

— Бу ни? — диде ул, планшетка чиертеп.

— Бу — проект кебек әйбер шунда. Газизгә күрсәтмәкче идем.

— Ә миңа, миңа күрсәтмисеңмени?

Мәрьямнең оялганын, кыенсынганын сизгәч, Шәүкәт батыраебрак китте.

— Син миңа вәгъдә биргән идең бит!

— Кайда күрсәтим соң? — диде Мәрьям, аптырап. — Биредә караңгы ич.

— Әйдә соң, урамга чыгыйк...

Алар Чехов базары аша үтеп, тын бакчага керделәр. Мәрьям планшетын сукмак кырыендагы диванга куйды. Шәүкәт кашларын җыерып планшетка текәлде. Ул озак кына бер сүз дә дәшмәде. Эскәмия янындагы яшь каеннарның чиста, ачык яшел яфраклы тармаклары талгын җилдә тирбәлә, аларның озын күләгәләре Шәүкәт өстенә төшә иде.

Мәрьям дә эскизга текәлде. Ул проектны, беренче тапкыр карагандай, Шәүкәт күзе белән күрергә һәм аның ни әйтәчәген алдан чамаларга тырыша иде. Аның күз алдына, планшеттагы эскиз түгел, чын шәһәр, моңарчы күрелмәгән гаҗәеп кала килеп басты.

Аның уртасында ак таштан салынган мәктәп. Мәктәп янында спорт мәйданы, бассейн, аннан парк, ул урманга тоташа. Портлар унике,

тугыз, жиде, биш, өч катлылар. Алар мәктәп тирәсендә ярым түгәрәк хасил итеп урнашканнар. Бер генә йорт та турыпочмаклы түгел, алар төрле формада. Барлык квартирлардан урман куренеп торырлык, бер генә тәрәзә дә күрше йорт стенасы белән капланмый. Өч катлы бер йорт түбәсендә җәйге кафе. Һәр йортның балконнары аерым фасонда эшләнгән, рәшәткәләре төрлечә. Балкон араларына һәм кәрнизләргә гранит вагы кушылган штукатуркага төрле төстәге милли бизәкләр ясалган.

Биек биналар янында бер-ике катлы көнкүреш хезмәте күрсәтү биналары, кафе. Микрорайон кырыйларыннан киң бульварлар килеп урманга тоташа.

— Кызганыч, моны тормышка ашырып булмас инде, — диде Шәүкәт ахырда.

— Алай димә, — дип каршы төште Мәрьям. — Монда тормышка ашыра алмаслык авыр нәрсә юк. Мин фантазиямне бәйдән ычкындырып, Казанда булдыра алмаслык нәрсә ясамадым. Хәзерге заман өчен бу искитәрлек проект түгел. Монда шул биек йортлар өчен лифтлар, төсле штукатурка өчен гранит вагы кирәк булачак инде.

— Синең һәр йортыңа индивидуаль проект кирәк булачак ич! Алар бер-берсенә охшамаган! — Шәүкәтнең тавышында кызгану ишетелде.

— Барыбер ул әллә ни кыйбатка төшмәячәк. Алар бер үк төрле детальләрдән салына. Аннары монда зур мәйдан алынмый, урынны төзелешкә әзерләүдән шактый экономия булачак. Хәзер обстановка үзгәрде бит, индивидуаль проектларны күп бирәләр, ә бәлки, рөхсәт итәрләр.

Шәүкәт иңбашларын сикертеп куйды: янәсе, минем моңа тамчы да ышанычым юк, тик синең өметеңне генә өзәсем килми.

Ул кесәсеннән авторучка чыгарды да, эскәмиягә утырып, планшетны әйләндерде һәм фанерга сыза башлады.

— Йортларың шәп, матур. Композициясе уңышлы. Безнең Казан халкының төшендә дә күргәне юк әле мондый районны. Ләкин бер-ике замечание әйтәм, үпкәләмә, ярме!

Мәрьям елмайды.

— Әйдә, әйт!

— Мин бу районны тагын да матурлар идем әле. Беткән баш беткән, булгач-булгач, булуы житсен. Синең «яшел тапларың» яссы. Урыны тигезмени? — Мәрьям әйе дип ым какты. — Яса шунда калкулыклар! Котлованнардан алган җирне өйсеннәр шунда! Үлән чәчәргә кирәк. Җәен балалар качыш уйнарлар, кышын чана шуарлар. Шәп бит, ә? Балконнарның кайберләре бик үк матур түгел. Стиле ятышмый...

Дөрес сөйли иде Шәүкәт! Мәрьям аның нәкъ ул эшләп житкерә алмаган урыннарны тотып алуына һәм шунда ук гаҗәеп матур вариантлар тәкъдим итүенә куанып торды.

Бу минутта чынлап та чибәр иде Шәүкәт. Аның калку маңгайлы, юка иренле түгәрәк йөзендә үзенә бер нур, яктылык балкый иде.

Бераздан ул рәсемнәрен аркылы-торкылы сызды да башын күтәрде:

— Юк, уйла әле син. Бу әле башка кинәт килгәне генә. Ныклабрак уйласаң, тагын да яхшырак вариантлар табылыр, шулай бит! Әгәр минем башка берәр уй килсә, мин сиңа әйтермен.

— Әллә соң кәгазь битенә йортларның урынын гына сызып биримме? — диде Мәрьям, сөенеп. Аның өчен Шәүкәт әйткәннәр иң олы мактаудан да кадерлерәк иде.

— Кирәкми. Биш-алты йортның гына планын хәтердә дә тотармын, пенсиягә чыкмаган бит әле мин.

Әйе, алар Шәүкәт белән бер телдә сөйләшә алалар, бер-берсен аңлыйлар иде. Хәтта күңелдә әйтелми калган уйлары, яшереп куйган,

үзләренә үзләре икърар итәргә курыккан хисләре дә бер-берсе өчен сер түгел иде кебек. Шәүкәт күргәзмәгә куясы картинасын алып килгән булган да, шуны төзәтергә икән исәбе. Жюри членнарының да әйткәннәрен искә алырга кирәк бит. Аның Казаннан тиз арада гына китмәячәген белгәч, Мәрьям җиңел сулап куйды.

## Вилдан киткәч

— Мин иртәгә китәм.
— Кая китәсең?
— Таганрогка, командировкага.

Июнь уртасы, көн чалт аяз. Шар ачык тәрәзәләрдән кичке кояш нурына чумган шәһәр күренә. Каршыдагы «Пампушки» кафесының пыяла стеналарында кичке шәфәкъ чагыла. Бүлмә җиләс, ярым караңгы. Вилдан майка белән чалбардан килеш, идән уртасындагы чемоданына йомарланган күлмәкләрен ыргыта.

— Алай салма инде... — ди Мәрьям, шактый сүзсез торгач. — Кая, үтүкләп бирим.

Вилдан борылып та карамый. Ул электр бритвасын күн футлярга тыгып азапланган җиреннән теш аралаш кына:

— Мәшәкатьләнмә, зинһар. Чит ирнең күлмәкләрен үтүкләү күңелле эш түгел бит, — ди.

— Син миңа китәреңне әйтмәгән идең...

Мәрьям аптыраган иде. Аның күңеле шомланып китте. Үз йөрәгендә нинди хисләр кайнаганын ул үзе дә аңлап бетермәгән әле, ул тойгыларының ташып китүеннән курка... Китмәсен Вилдан, аның янында булсын...

Ә Вилдан бертуктаусыз мырлый:

— Кайчан әйтим әле аны... Башка берәүне җибәрмәкчеләр иде, үзем үтенеп сорадым. Бөтенләй чит кешеләр кебек яшибез, миннән тәмам туйдың, ахры. Фәйрүзә киткәнгә ун көн, шуннан бирле минем белән ун авыз сүз дә сөйләшкәнең юк.

Мәрьям кызын авылдагы туганнарына кайтарып куйган иде. Араларны бәйләп торган бала ерагайгач, алар бөтенләй читләшеп киттеләр. Мәрьямнең ире белән сөйләшер сүзе юк иде: институттагы хәлләрне сөйләргә ул үзе кушмый, башны катырма, туйган төрле гайбәттән, көнчелектән, мактанудан, дип кенә җибәрә. Мәрьямнең бөтен уйларын биләгән проект турында шулай ук ишетәсе дә килми. Ни сөйләшәсең инде шулай булгач? Үзе дә тешләк бит ул, шаярмый, көлми, анекдотлар белән кызыксынмый. Укыган китапларын сөйләр иде — анысы Мәрьямнең үзенә ошамый.

Шулай да Мәрьямнең Вилданны җибәрәсе килмәде. Хәзерге вакытта, күңелендә менә-менә кубарга торган давылны тыярга бер таяныч кирәк иде аңа. Ул Вилданга якын ук килде дә, аның йөзенә туры карап, ялварулы тавыш белән дәште:

— Китмә, Вилдан, зинһар, китмә. Бик үтенеп сорыйм синнән.

Тәкәббер хатынының болай ялынып торуы аның кирелеген генә арттырды.

— Хәзер соң инде... Ничек кенә булмасын, минем китүем яхшырак. Син югында бик яхшылап уйла да барысын да хәл итеп куй. Яки — яки...

Нәрсәне хәл итәргә? Ничек? Моны Мәрьям ачык кына белми иде әле.

Вилдан да киткәч, тәүлек бик нык озайды кебек. Ул проектын берничә көн эчендә төзәтеп тә куйды.

Баштарак, бу проект өстендә эшләргә тотынганда, ул аны ничек тормышка ашырылачагы турында төпләп уйламаган да иде. Аның өчен иң әһәмиятлесе эшне ничек тә очлап чыгу һәм үз көчен сынап карау иде. Хәзер инде, канәгатьләндерерлек проект төзегәч, хыялындагы йортларны чынга ашкан итеп күрәсе килде аның.

Бәхетсезлеккә каршы, группа җитәкчесе Морат Шәехзадинның чираттагы идея белән мавыккан чагы иде. Хәзер аны богаулап торган чылбырлар бераз чишелде — архитекторларга кайбер очракларда индивидуаль проектлар төзергә рөхсәт бирелә башлады. Шунда тагын бер фаҗига ачылды: озак елларга сузылган иҗат ачлыгы фикер торгынлыгына китергән. Заманалар үзгәргән, таләпләр икенче — ә архитекторлар һаман шул иске традицияләрдә тәрбияләнеп үскән кешеләр булып калганнар. Яңа стильгә, яңа төзү ысулларына, матурлык дигән нәрсәнең үзенә яңача карарга тырышу — аяныч хәлләр, хәтта көлке вакыйгалар китереп чыгара иде. Мисалга, «Шәфәкъ» ресторанының Шәехзадин проекты буенча эшләнгән интерьеры яңа стильгә пародия булып чыкты: аның кара түшәмен аркылы-торкылы итеп беркеткән тимер араталар башка төшәр кебек, анда-санда тонык кына янган лампочкалар күңелгә шом сала, саргылт стеналар тигезле-тигезсез, буй-буй. Түр стенага смальтадан ясалган мозаика — Сөембикә манарасы — гомуми тәэсирне йомшартмый иде. Иң аянычы — бу интерьер революциягә кадәр үк сырлап-бизәп салынган бинаның тышкы күренешенә, зур көзгеле, сырлы кәрнизле, мәрмәр баскычлы вестибюленә һич туры килми иде. Боларны архитектор Шәехзадин үзе дә яхшы аңлый, тик аның бу турыда озак уйлап торырга вакыты юк, ул яңа проектлар белән мавыккан.

Әйе, замана рухына туры китереп иҗат итү — җиңел эш түгел иде. Морат геометрик формалар белән мавыкты. Ул эзләнә, уйлана, уңышсызлыкларыннан азаплана һәм әз генә уңышка да башы күккә тиеп сөенә. Әле менә күз күрмәгән, колак ишетмәгән формада цирк бинасы салырга йөри. Конструкторны да, баш инженерны да эшкә җиккән, аңа расчет кирәк.

Ул Мәрьямнең планшетына күзләрен текәде, тик күзләре белән күрмәде дә кебек. Бу ни тагын? Кем заказы? Заказ булмагач, ник кирәк? Ай аллам, юк белән башны катырмасана, туп-туры директорга кер. Ул каршы килмәсә, мин риза.

Морат кулы белән планшетны өстәленнән төртеп төшерде дә, карандаш алып, алдындагы кәгазьгә эллипс сызарга тотынды.

Директор көзге төсле ялтырап торган зур өстәл артында утыра иде. Мәрьям кергәч, укып утырган кәгазьләрен бер кырыйгарак этте. Алдында борынгы заманда ук чыгарылган зур вентилятор хәйран җил чыгарып пыр-пыр әйләнә. Кәгазьләр очмасын өчен, директор аларны мәрмәр пресс белән бастырып куйды. Ялтыравык өстәлдә аның талчыкчан озынча йөзе чагыла иде.

— Мин бер проект китергән идем, — диде ул өстәлдәге директор шәүләсенә.

— Нинди проект ул? — Директорның тавышы ягымлы иде.

— Менә бер микрорайонга.

Директор учлары белән яңакларын ышкыды:

— Картлык галәмәтедер инде, нинди микрорайонга заказ алганыбыз хәтердән чыгып киткән.

— Аңа заказ юк әле.

Чын директор да, өстәлдәге шәүлә дә, маңгайларын җыерып, Мәрьямгә текәлделәр. Аннары директор планшетны алып, шәүләсе өстенә куйды.

— Һе, кызык кына бит бу, кызык кына... Тик бу проектны тормышка ашыруның кыенлыгын сез үзегез дә яхшы беләсез бит. Финанс бирмәя-

чәкләр, бу төзелеш материалларын табу — хәзергә Казан шартларында мөмкин эш түгел. Күп хезмәт куйгансыз, ләкин, кызганычка каршы, юкка...

Директор планшетны кире Мәрьямгә сузды.

Мәрьям, ишек янына барып җиткәч, бөтен барлыгын җыеп, калтыранган тавыш белән сорап куйды:

— Шулай ук бернинди мөмкинлек юкмыни?

— Булмас, дим шул. Ул хәтле районны индивидуаль проект белән төзетәләрме соң... Аннары аның тәртибе бар бит, башта горсоветка мөрәҗәгать итәргә кирәк. — Аннары Мәрьямнең сөмсере коелганын күреп күңеле йомшарды. — Ятып калганчы атып кал, ди, Соловьев белән сөйләшеп карыйк соң...

Соловьев шәһәрнең баш архитекторы иде.

Эшнең өметсезлеге директорның тавышына ук бәреп чыккан иде. Ул вентиляторны үзенә таба борды да, күзләрен йомып, йөзен рәхәт җилгә куйды.

## Ник яшәргә бу дөньяда?

Шәүкәт ачыктан-ачык Мәрьям янына килеп йөрергә базмады. Морат янына дигән булып, сылтау табып килде ул.

Мәрьямгә якын килеп сөйләшмәде сөйләшүен. Эштән соң алар институт ишегеннән өчәү бергә чыгалар, ә дамбаның теге ягына барып җиткәндә икәүдән-икәү генә калалар иде.

Алар һәр көнне диярлек очраша башладылар. Мастерскойдагы очлы күзләр өчен бу сер булып калмады, билгеле. Әмма Мәрьям бу турыда уйлап та карамады.

Бишәр катлы таш йортлар белән әйләндереп алынган зур ишек алдының уртасында яшь өрәңгеләр үсә. Алар кечкенә әле, көндез күләгә бирми, кичен ят күзләрдән сакламый. Шул сирәк агачлар арасына эскәмияләр куелган. Урамнарда йөреп аргач, әллә кайчан кайтып китәргә кирәклеген бик яхшы белсәләр дә, аерылыша алмый йөдәгән Шәүкәт белән Мәрьям шул эскәмияләрнең берсендә утырып торалар. Ишек алдына тәрәзәләрдән генә якты төшә, күз бәйләнгән чак. Күк йөзе аксыл-зәңгәр, бер кыры китек ай үтә күренмәле кәгазьдән ясалган кебек. Каршыдагы тротуардан да, аңдагы сукмактан да кеше өзелми. Шәүкәт үз алдына карап, әкрен тавыш белән сөйли, бармак араларындагы сигареты сүнә бара, ул аны оныткан.

— Мин соңгы елларда бик нык уйлана башладым әле. Ярый, менә бу кеше — табигатьнең хуҗасы дигән булабыз үзебезне. Ә чынлабрак карасаң, бер бөҗәктән, чебеннән, кырмыскадан ни аермабыз бар безнең? Бөҗәк тә үлә, кеше дә үлә. Бары да бетә, юкка чыга. Кая китә кешенең хисләре, мәхәббәте, хыяллары? Ни мәгънә талпынуында, янып-көюендә, иҗат итәм дип тырмашуында? Галәм чиксез. Мин шул чиксезлекне һич күз алдына китерә алмыйм. Әйтик, ракетага утырып, яктылык тизлеге белән очасың, очасың... Үлгәнче очасың... Аннары синең балаларың, оныкларың оча... Уйлап карасаң, шул чаклы куркыныч. Кеше генә түгел, җир шары үзе дә ул чиксез галәмдә бер ком бөртеге кебек кенә. Ә кеше, кеше ком бөртегеннән дә чыдамсызрак. Уйлап караганда, ул чиксезлек каршында бер бөҗәк белән кеше арасында бер аерма да юк.

— Ник булмасын, — ди Мәрьям. — Бөҗәкләр үлем турында уйлый белмиләр, ә кеше уйлый, үләчәген белә. Менә сиңа алар арасында беренче аерма.

Шәүкәт Мәрьямнән бу газаплы уйларын таратуны өмет итә иде. Мәрьям исә мондый җитди сөйләшүгә әзер түгел, шуңа күрә үзе дә шомланып, югалып калды.

— Әгәр бөҗәкләр үлем турында уйланмыйлар икән, димәк, алар кешедән бәхетлерәк, — дип сүзен дәвам итте Шәүкәт. — Ә кешенең уйлануыннан ни файда? Ә ул һәрнәрсәнең серенә төшенергә тырыша, төпченә, казына, ачышлар ясый. Миллион еллар тырыша, баш вата торгач, атом бомбасы иҗат итте кешелек! Кешелекнең үсү нәтиҗәсе, аның акыл җимеше — бомба! Җир йөзендә тормыш әсәрен юк итү чарасы! Я, уйлап кара, шуннан да искитәрлек, шуннан да куәтле тагын берәр нәрсә уйлап тапканмы кешелек? Юк. Кешелекнең иң бөек ачышы — үзен-үзе үтерү чарасы. Ул бомба безнең башыбызга һәр минутта килеп төшәргә мөмкин һәм безнең үзебездән дә, иҗатыбыздан да тузан бөртеге дә калмаячак. Ә җир һаман шулай кояш тирәсендә әйләнер, галәм һаман чиксез булыр, вакыт шул ук тизлектә уза торыр. Тик без генә булмабыз.

Шәүкәт сүнгән сигаретын комсызланып суырды, аннары кесәләреннән шырпы эзләргә тотынды, тапмагач, сигаретын читкә атып бәрде.

— Үзем үлгәч, дөньяда, галәмдә ни эшем бар минем? Джоконданың елмаюыннан Леонардо да Винчига ни файда? Ул үлгән, берни белми, сизми, елмаямы-юкмы Джоконда — аңа барыбер! Мәңгелек материя күзлегеннән караганда Монна Лиза — чүпрәккә сыланган бер-ике кашык буяу гына бит!

Шәүкәт, Мәрьямнең күз карашыннан ни уйлаганын аңларга тырышып, текәп карады.

— Я, ник дәшмисең? Синең бу турыда уйланганың юкмы әллә? Әгәр уйланмыйсың икән, син бик бәхетле.

Күктәге ай яктырды, җанланды, нур чәчә башлады. Күк йөзе тирәнәйде, караңгыланды, чекерәеп йолдызлар калкып чыкты. Мәрьям пышылдап сөйли башлады:

— Әгәр Леонардо да Винчи бер генә минутка терелсә һәм аннан болай дип сорасалар: «Кешелекнең бөек художнигы һәм галиме Леонардо да Винчи, синең дөньядан киткәнеңә 447 ел. 447 ел инде син дөньяда юк. Ләкин синең әсәрләрең яши, алар исән, Джоконданың елмаюы бөтен дөнья халкын сокландыра. Әйт әле, Леонардо да Винчи, Монна Лизаның яшәве-яшәмәве синең өчен барыберме, юкмы?» дип сорасалар, ни дип җавап бирер иде ул, синеңчә? «Мин Монна Лизага гомеремне бирдем. Ул исән чакта, мин дә үлмәм», — дияр иде. Шулай бит? Юк, кешеләр мәгънәсез яшәмиләр. Әгәр алар син әйткәнчә, бөҗәкләр кебек мәгънәсез яшәсәләр, без кыргый хайван хәлендә булыр идек. Кешеләр безнең өчен калалар салганнар, киемнәр теккәннәр, китаплар язганнар, дарулар ясаганнар... Без үзебез генә бу турыда аз уйлыйбыз. Ә безгә искиткеч күп нәрсәләр бирелгән! Әгәр кешеләр мәгънәсез яшәп, мәгънәсез үлсәләр, без мондый булмас идек. Әгәр беләсең килсә, кешелекнең иң бөек казанышы — атом бомбасы түгел, ә хәзерге заман кешесе. Егерменче гасырның акыллы, белемле, сәламәт, озын гомерле, куәтле кешесе.

— Бигрәк китапча сөйлисең инде син. Бигрәк купшы сөйлисең. Егерменче гасыр кешесе, имеш. Ә мин менә үземнең шушындый булуымнан һич тә канәгать түгел, һич тә. Җирдә аяк терәп торырлык урын таба алмыйм.

Мәрьям аның иңенә кулын салды.

— Шәүкәт. Талантлы кеше ич син! Синең юлың бер генә ич — иҗат! Бәлки... бәлки, сиңа юл бирмиләрдер? Бәлки, аңламыйлардыр сине... Әллекке кебек?

Шәүкәт авыр көрсенде дә, күңелсез уйларын селкеп ташлагандай, сискәнеп урыныннан кузгалды.

— Мин үземә алкышлар таләп итмим... Кирәкми! Әйдә әле, башка нәрсәләр турында сөйләшик!

Алар дәшмичә генә, әкрен атлап урамга чыктылар. Берсе дә сүз башларга базмады. Мәрьям ана күп нәрсәләр әйтергә теләи: сиңа авыр булды инде, бәлки, янында кул бирерлек, ярдәм итәрлек дусларың да булмагандыр. Ләкин болар барысы да олы максат, иҗат белән чагыштырганда ул кадәрле үк әһәмиятле нәрсә түгел бит. Син бирешмә генә, нык тор, күнелең генә сынмасын, синең тормышта үз сүзеңне әйтерлек көчең дә, гомерең дә бар бит әле, — дип әйтергә теләде ул. Тик үзенә дөрес тон сайлый алмавыннан курыкты һәм шуңа күңелендәгесен әйтми калды.

## Хыяллар җилгә очты

Горсовет Мәрьям проекты буенча микрорайон төзергә ризалык бирмәде. Мәсьәлә бик тиз хәл ителде, проект хыялый, тормышка ашмаслык һәм артык кыйммәт нәрсә булып күренгән булса кирәк. Шуңа күрә юк белән баш катырып, бу мәсьәлә буенча Мәскәүләргә барып йөрүне кирәк дип тапмаганнар. Мәскәү барыбер ризалык бирмәячәк.

Күңелсез хәбәрне Мәрьямгә директор үзе җиткерде. Ул башын тәрәзә ягына борып утырган иде, каршында басып торган архитектор Закировага туры карамады да. Аның ялтыравыклы өстәлдәге шәүләсе дә җитди һәм моңсу иде.

— Нишлисең, — диде директор, — үз башыннан биеккә сикереп булмый. Күләнә карап чумарга кирәк иде, ә синең проектта чама дигән нәрсә югалган... Ләкин ул микрорайон төзеләчәк. Типовой йортлар булачак анда. Менә шуны проектлау эшен ул, Мәрьям Закирова, үз өстенә алса иде.

Мәрьям бу эштән катгый рәвештә баш тартты.

— Нишләп? — диде директор, гаҗәпләнеп. — Сез инде ул квартал булачак урынны җентекләп өйрәнгән, өйләрне урнаштыру, тышкы оформлениенең кайбер элементларын булса да үзегез эшләгән проекттагыча калдырырга мөмкин.

— Мин бөтен эшли алганымны эшләдем инде. Башкача булдыра алмыйм. Аның күпмегә төшәсен башта ук чутлап бирәсе калган безнең. Анда артык күп сумма кирәкми. Урынны төзелешкә әзерләүдән шактый экономия була иң.

— Ярый, — диде директор, бармакларына текәлеп. — Мин сезнең фикерегезгә бик кушылам. Әмма биредә бу сүзләрне сөйләп торуның файдасы юк. Тиз арада яңа проект эшләргә кирәк.

— Әнә, Гаделшина шырпы капларын бик оста эшли.

— Әгәр сез баш тартасыз икән, эшне чыннан да аңа тапшырырга туры киләчәк. Чакырыгыз әле, зинһар.

Камәриянең түбәсе күккә тигән иде, билгеле. Ул хәтта Мәрьямне кызгануын күрсәтергә тиеш тапты. Директордан чыгу белән, аның янына килеп басты:

— И-и, Мәрьямкәем, җаныкаем, була инде ул шулай юкка эшләүләр. Эшлисең, тырышасың-тырмашасың — кабул итмиләр. Ну ничего, син бер дә борчылма, җаным, менә дигән проектлар эшләрсең әле...

Бары шунда гына Мәрьям бу җиңелүнең бөтен авырлыгын сизде. Әле директор алдында басып торганда бу хәбәр аның аңына барып ук җитмәгән икән. Әрәм китте йокысыз төннәр, матур хыяллар, тырышулар, кат-кат эшләүләр. Барысы бушка, юкка чыкты. Мәрьямнең төшләренә кергән сихри кала урынына, шырпы каплары кебек бертөсле җансыз йортлардан торган типовой квартал салыначак. Сәләтсез, зәвыксыз Камәрия тантана итә. Аның чепуха! Йөз ел торырлык төссез квартал үсеп чыгачак! Аны бит бер салгач төзәтеп, рәтләп, икенчеләй эшләп булмый! Ул кимендә бер-ике гасыр шулай торачак! Ә Мәрьям-

нең бәхет шәһәре шул кәгазьдә калачак. Берничә елдан ул проект балаларына һәм оныкларына күрсәтергә генә ярый торган сурәткә әйләнәчәк. Чөнки заман бик нык үзгәрә, яңадан-яңа төзү материаллары чыга, биналарның формасына караш, гомуми матурлык төшенчәсен аңлау үзгәрә бара. Шулай итеп бу проектның берничә ел үтүгә кыйммәтен югалтуы мөмкин. Эскизлардан, Вилдан кебек, бала уенчыгы ясарга гына кала.

Бик рәнҗеде Мәрьям, бик ачуы килде. Ләкин ул үзенең үпкәсен, ачуын юнәлтер кеше тапмады. Нинди көчләр каршы төшкән аның юлына? Кемнәр иҗат итәргә ирек бирми аңа? Горсоветмы? Камәриямe?

Билгесезлек, үзеңә каршы көчләрнең күз алдында булмавы кимсендерде, өметсез хәлгә куйды. Кирәкми ул проектлар! Туйган ул азаплардан! Авыртмас башка тимер тарак табып йөргән Мәрьям үзе юләр! Моннан соң акыллы булыр, бер проектка да тотынмас. Башы тыныч булыр!

Мәрьямнең миен мең төрле уй, күңелен каршылыклы хисләр көйдерде. Ул кемгә дә булса барып ачы фаҗигасен сөйләргә, елап күңелен бушатырга, юату сүзләре ишетергә теләде. Андый кеше — Мәрьямне аңларлык якын дус, үз башыннан да шундый ук кайгы һәм кимсенү кичергән иҗат кешесе бар дөньяда. Ул кеше — Шәүкәт иде.

## Тирән күл буенда

Кеше дөньяга ике килми. Ярар инде, бу тормышымда ялгыштым, икенче тугач, хатамны кабатламам, дөрес яшәрмен, бәхетле булырмын, дия алмыйсың. Тормыш — хат түгел, аны төзәтеп язып булмый.

Ә бәндә хатадан хали түгел. Күп вакыт хата ясаганыңны сизми дә каласың. Вакыт үтә, хатаңны күрәсең, тик соң була инде.

Менә шулай кайчандыр Шәүкәт хата ясады. Аның хатасы Мәрьямнең дә ялгышуына сәбәп булды.

Әйе, Мәрьям күңеленнән Шәүкәтне аклады. Яшь чагында егетнең үз хисләрен үзе аңлап бетермәгән булуы мөмкин иде бит. Аннары аның теге кыз белән очраклы рәвештә бәйләнүе дә мөмкин. Дөрес, Мәрьям үзе андый очраклы бәйләнешләрне аңлый алмый, ул үзе андый мөнәсәбәтләрнең булуына да ышана алмый. Ләкин кайбер кызларның Мәрьямгә охшамаган булуы бик табигый нәрсә ләбаса. Алар башкача уйлый, башкача яши икән, моны гаепләп буламыни? Һәрхәлдә, Шәүкәт үзен намуслы егет итеп күрсәтте, кызны хур итеп, бәхетсез итеп ташлап китмәде. Бу үзе генә дә аның кешелекле булуын күрсәтеп тора ләбаса.

Шулай итеп, Мәрьям күңеленнән Шәүкәтне аклады. Тормыш аны сабыр булырга, дөньяга киңрәк карарга, кешеләрне гафу итәргә өйрәткән иде.

Шул ук вакытта ул үзенең төссез, бернинди хиссез, сөюсез яшәгән елларын исенә төшереп, хәйран калды. Я алла! Никадәр гомере әрәм киткән. Бу чын мәгънәсендә яшәү түгел, тормыш түгел. Ул күңеле белән тәмам картайган икән. Шәүкәтне яратмаган булса, ул әле һаман да шулай мәгънәсез яшәгән булыр иде. Яратмаган, җаны сөймәгән, бөтенләй ят кеше белән гомер итү — үзе бер әхлаксызлык ләбаса!

Мәрьям киләчәктә ни буласын белми, бу турыда чынлап уйланырга башы да җитми, әмма кире чигенергә мөмкин түгел, ул булдыра алмый. Алар икәү, икегә бүлгәч, авыр йөк тә, ачы хәсрәт тә җиңеләя, Шәүкәт белән бергәләшеп хәл иткәч, ике гашыйкка бернәрсә дә авыр булмас кебек иде. Ничек кенә булмасын, элекке тормышка кире кайту мөмкин түгел иде — бу турыда үзара сөйләшмәсәләр дә, Мәрьям шулай исәпләп йөрде. Иҗади хыяллары чәлпәрәмә килгәч, аның телгәләнгән йөрәге Шәүкәткә тагын да көчлерәк омтылды, ул бары аның

янында гына жанлана, аның белән бергә чакта гына кайгысы тарала иде. Тормышта олы бер терәге, яшәвенең мәгънәсе — мәхәббәтендә генә калган кебек тоелды аңа.

Җылы, жилсез төннәрнең берендә алар, инде Мәрьямнең өенә кайтып житкәч, хушлашмадылар, кире борылдылар да аулаграк урамнар буйлап киттеләр. Тимер юлга килеп чыктылар һәм шпаллар буйлап көнбатышка юнәлделәр. Тоңык кына ялтыраган рельслар еракка, күз күрмәгән, колак ишетмәгән сихри урыннарга илтәләр кебек. Менә рельслар калтырый башлый, яман үкереп, житәкләшеп барган бу ике кешене бөтен дөньяга фаш итәргә тырышкандай маңгаендагы прожекторы белән яктыртып, каршыга поезд килә. Алар читкә тайпылалар, әмма юл калку булганлыктан, ерак китеп булмый. Җир тетрәтеп, дөбершатыр әллә инде йөзләп товар вагоны уза. Поездан зәһәр жил бәрә.

Поезд шактый ерагайгач та әле, рельслар тәгәрмәчләр көенә жырлыйлар. Ниһаять, тынлык урнаша. Бары ТЭЦ кына уфылдый һәм уң якта ут дингезендә йөзгән завод кала.

Мәрьям Шәүкәт иңенә таянып рельс өстеннән бара. Бала-чага кебек кылана, иркәләнә ул. Бераз баргач, арттан кисәтүле тавыш яңгырый:

— Рельс өстеннән йөрмә, кызый. Ялгыш сөртенеп, аягыңны сындырырсың.

Алар сизмәгәннәр дә, карт тимер юлчы, кечкенә фонарен болгап, үтеп бара икән.

Берсе дә, житте инде, кире борылыйк, димәде, алар Тирән күлгә килеп життеләр.

Текә яр астында тыныч су тоңык кына ялтырый. Тулган ай күл суында үзен күреп, сокланудан хәйран калган. Бер ярда үскән нарат-лар ай нурында коенәлар, икенче яр астында кара күләгә.

Алар ярдан төшеп, күләгәгә яшеренделәр. Су янында шактый салкынча икән, юка жакет кына кигән Мәрьям әллә туңып, әллә дулкынланудан калтыранып куйды. Шәүкәт, канатын җәйгән бөркет кебек, пинжәген ачып, аны чакырды. Аларны ике генә адым аера иде. Мәрьям бер атлады, ике... Яр кырыенда ике урынына бер генә шәүлә калды. Мәрьям аның иреннәреннән татлы балын да, исерткеч шәрабен дә, ачы агуын да берьюлы эчте. Аның башы әйләнде, йөрәгеннән чыккан кайнар дулкын бар тамырларын көйдерде. Ялтырап яткан күл, яр буендагы тыныч наратлар, түгәрәк ай — бөтен дөнья чайкалды, авышты, ауды...

Алар комда утыралар. Мәрьям яңагын Шәүкәтнең күкрәгенә куеп, йөрәгенең тигезсез тибүен тыңлый. Шәүкәт тетрәнгән бармаклары белән аның чәчен сыйпый.

— Кара әле миңа!

Мәрьям башын артка ташлап аның йөзенә карый. Бу йөз искиткеч матур, акыллы, серле тоела аңа.

Шәүкәт бармагы белән аның иренен сыйпый.

— Ирен сызыкларың искиткеч матур синең. Гомумән синең йөзең, тавышың көләр өчен яратылган. Беләсеңме, мин сине онытa алмаячагымны кайчан аңладым?

— Кайчан?

— Хәтерлисеңме? Сез коридорда теннис уйный идегез. Мин килеп стенага сөялдем. Син ул көнне гадәттәгедән житез, сизгер идең. Син барысын да жиңдең һәм көлдең дә көлдең. — Шәүкәтнең назлы пышылдавына якын куактан сандугач моңы килеп үрелде. — Минем күз алдыма Казанка, парк, тын урамнар килде. Мин сине әлегрәк, артык кычкырып көләсең дип, гел тыеп килә идем. Бары шул көнне генә синең көлүеңнең кадерен белдем.

Мәрьям дә ул көнне яхшы хәтерли. Шәүкәт өйләнгәннән соң берничә ай узгач булды ул вакыйга. Шәүкәт карап торганга, аның өчен көлгән иде ул. Ул карап торганга барысын да жиңгән иде...

— Аһ, Шәүкәт, ярый әле син бар дөньяда, ярый әле без очрашканбыз! Юкса мин күп нәрсәдән мәхрүм калган булыр идем! Бик чибәр син, Шәүкәт!

Ул тын гына елмая:

— Булыр инде. Сиңа гадәтләнгәнгә генә шулай күренә.

Сандугачлар урманны яңгыратып сайрарга тотындылар. Күк гөмбәзен очлы башлары белән терәгән наратлар — сакчылар кебек хәрәкәтсез торалар. Якындагы тимер юлдан күңелле тыкылдап поезд үтеп китте. Паровоз тавышы еракларга айкалды...

Мәрьям куе үлән арасыннан зәңгәрсу яктылык сипкән кортка күрсәтте:

— Үзе кечкенә генә, нуры шундый көчле! Шул хәтле нур каян килә икән аңа?

— Алып биримме?

— Кирәкми, тимә! Кулга тоткач нуры сүнә аның. Болай да күп янасы калмаган инде, әнә таң атып килә.

Таң атканда сандугачлар сайравына кушылып, Мәрьямнең көлүе яңгырады. Иртәнге томан белән өртелгән күл өстендә икәү, су чәчрәтә-чәчрәтә, куыша-куыша су коендылар.

Куе үләнле чыклы аланда каралып ике эз калды...

Алар шәһәргә җәяү кайтып җиттеләр — автобуслар йөри башламаган иде әле.

Тимер юл буенда ике каен үсеп утыра: берсе ямь-яшел, икенчесе корыган.

— Кара инде боларны, — диде Шәүкәт. — Теге купшы каен яшь кызлар көлмәге кигән әбигә охшаган. Ә икенчесе, яшьли корыганы, табигый, матур. Шулай бит?

Мәрьямгә калса, яфраклы агач искиткеч матур иде. Аның җиргә кадәр салынган бөдрә тармакларында, юан, ак кәүсәсендә тереклек көче бар кебек. Ә корыган агач үле ботакларын шәфкать сорап күккә сузгандай...

Әмма Мәрьям бу юлы Шәүкәт белән бәхәскә кермәде. Кояш үрелеп шәһәр урамнарына сыңар күзе белән караганда, алар аерылыштылар. Мәрьям үбәргә яңагын гына куйды да, борылып карамаска тырышып, ашыгып китеп барды.

## Күргәзмәдә

Морат бераз тын ала, Морат ял итә. Башына, нервларына вакыт-вакыт ял биргәләмәсә, ул киеренкелек белән эшли алмас иде, әлбәттә.

Морат ял иткәндә тик кенә утырып тора алмый, шук малай шикелле кызык ясарга, көләргә җай эзләп йөри. Мондый чакта аннан сак булырга кирәк: бөтен кеше алдында көлкегә калдыра ул. Дөрес, ул моны явызлык белән эшләми, шулай да алдын-артын уйламый, кеше хәле белән һич исәпләшеп тормый, шунлыктан күпләрнең хәтерен калдыра.

Дөньядан хәбәре китеп, уйга чумып утырган Мәрьям Морат өчен чын-чынлап табыш булды. Ул озын итеп скрепкалар тезмәсе ясады, аның бер очын бик җайлап, узып китмәгән арада, сак кына Мәрьямнең итәгенә беркетте. Үзе бу шуклыгыннан бик канәгать, кычкырып көлүдән көчкә генә тыелып тора, башкаларга, көлмәгез, әйтмәгез, дип Мәрьямнең җилкәсе аша үзе кебек нечкә, озын бармагын яный. Ул гына түгел, Морат бик тырышып, линейка, циркуль белән сызып, җилем ябыштырып, калькадан очлы калфак ясады, аны кызылга, яшелгә буяды, аны папкага салып, Сажидә апа янына килү сылтавы белән, бүлмә буе күтәреп килде һәм күзләрен бер ноктага төбәгән хәлдә хәсрәт дәрьясына чумып утырган Мәрьямнең куе кара чәченә кадап куйды.

Булмәдәгеләр кайсы стенага борылып, кайсы өстәлгә иелеп пырх-пырх көлештеләр: шамакай калфагы киеп, уйга чумып утырган хатынның кыяфәте чыннан да көлке иде.

Ә Мәрьям Шәукәт турында уйга чумган. Ул әле генә күргәзмәдән кайтып утырды. Күргәзмәнең кайчан ачылачагын Шәукәт әйтмәгән дә иде. Аңлашыла: ул Мәрьямгә картинасын күрсәтергә теләмәгән. Шуңа күрә Мәрьям күргәзмә ачылуын чит кешеләрдән ишетеп, ялгызы гына барып карады. Залның ишеген ачып кергәч тә, Шәукәт картинасын әллә кайдан бер карауда таныячагына ышанган иде ул. Юри зал уртасына басты да дүрт стенадагы рамнарны да, урыныннан кузгалмыйча, ерактан карап чыкты. Юк, тапмады. Бер әйләнде үз тирәсендә, ике — юк, күрмәде Шәукәтне. Шулай ук куймадылар микәнни аның эшен бу күргәзмәгә, тагын да хаксызга рәнҗеттеләр микәнни? Шәукәтне, меңнәр арасыннан бер күрүдә танып булырлык талантлы Шәукәтне, тагын хурладылар микәнни?

Мәрьям стеналар буйлап әкрен генә йөреп чыкты. Юк Шәукәт... Рамнардагы этикеткаларны укырга башына да килмәде аның, ул бит Шәукәтнең картинасын болай да бер күз салуда танып алачак!

Ахырда, аптырап, почмактагы өстәл артыннан сирәк-мирәк тамашачыларны ялкау гына күзәтеп утырган, модный киенгән кызга мөрәҗәгать итте ул:

— Художник Аитов эше юкмыни биредә?

Кыз бик белдекле кешедәй елмайды:

— Бар, булмаган кая! Күргәзмәнең кадагы! Әнә теге баштагы зур полотноны күрәсезме?

— Кайсы?

— Әнә, «Көтүче жыры» дип атала...

— Сез ялгышасыздыр. Мин Аитов турында сораган идем.

Кыз үпкәләгәндәй булды:

— Ничек ялгышыйм инде! Мин Аитовның үзен дә бик яхшы беләм. Берничә ел инде таныш без аның белән. Искиткеч талантлы кеше. — Кыз илһамланып сөйли башлады. — Сез төсләр гаммасына гына игътибар итегез: төсләр ачык, чиста, алар кеше күңеленә бик көчле тәэсир итәләр...

Мәрьям аны тыңлап бетермәде, полотно янына китте.

...Күзләрне камаштырырлык җете кызыл җилән, башкорт бүреге кигән кәҗә сакаллы бер карт калкулык башындагы олы ташка утырган да курайда уйный. Аның аяк очына, Мәрьямгә йөзе белән, аякларенә таянып, түгәрәк битле малай сузылып яткан. Калкулык астында кыр ышыклау полосалары белән тигез шакмакларга бүленгән басулар, бакчалар. Офыкта күргәзмә әсбапларда гына була торган авыл: ап-ак йортлар, антенналар һ. б. Зәңгәр күктә үрнәк-күргәзмә болыт...

Мәрьям картинага озак карап торды. Композиция, рәсем, төсләр ягыннан караганда барысы да үз урынында. Менә бу җире начар, дип тотынып хурларлыгы юк кебек, киресенчә, мактарлык урыннары да шактыйдыр. Ләкин монда кеше күңеленә тәэсир итәрлек, караучыны дулкынландырырлык көч һәм хисләр сизелми. Картинада курай күренә, тик аның моңы ишетелми. Гомумән Шәукәтнең һәр сызыгы белән йөрәккә тәэсир итә торган палитрасы күренми.

Мәрьям үзен:

— Ул бит яшь әле, үсә-үсә өйрәнер. Хәтта гениальларның да башлангыч чорда иҗат иткән өйрәнчек әсәрләре шедевр булмаган, — дип юатырга тырышты. Ләкин ул һәр гениның иң начар рәсемендә дә кешене дулкынландыра торган, үзенә генә хас каләме сизелгәнен белә иде. Ә биредә андый каләм сизелми иде шул.

Артык җентекләп карый торгач, Мәрьямгә бөтен картинада фальшь сизелгәндәй тоелды. Буяулар артык ачык. Күзне ертып торалар. Автор

кешеләрне маңгайларына бәреп шаккатырырга тырышкан. Мәрьям хәтта Шәүкәтнең бу картинаны ни кыяфәттә язганын күргәндәй булды: кашларын җыерган, рамга тарткан киндерне сөзәргә җыенгандай башын иеп эшли, ә күңеле белән әллә кайларда гизә. «Без божества, без вдохновения». Иҗат эшендә үзеңне мәҗбүр итү шулкадәр авыр эш бит! Илһамсыз, дәртсез, бер тырышлык белән генә, үз-үзен мәҗбүр итеп язылган бу картина Шәүкәтнең җилеген суыргандыр, тормышын бер газапка әйләндергәндер үзе дә! Бигрәк тә ул үзенең урта кул, чырайсыз әсәр иҗат иткәнен белгәндер, белми мөмкин түгел. Мескен, бичара!

Мәрьям бер уйлады да кызганды Шәүкәтне, икенче уйлады да нәфрәтләнде. Аның күңел түрендә, үзе дә аңлап җиткермәгән коточкыч шом кузгалды. «Һәлак булган Шәүкәт, беткән, юкка чыккан! Аны хәзер яңадан тергезү мөмкин түгел. Бөтенесен өр-яңадан башлау өчен яңадан туарга кирәк. Ә аның яше утызга җиткән инде!»

Шушы ике сәгать эчендә, картина алдында басып торганда, Мәрьям Шәүкәт күңелендәге моңарчы үзе өчен билгеле булмаган караңгы почмакларны күргәндәй булды. Гомумән, аңа Шәүкәт яңа ягы белән, яңа яктылыкта күренде һәм бу Шәүкәт — таныш түгел кеше, намусы чиста түгел кеше иде. Мәрьям өчен бу кеше тирәсендә балкыган нур сүнде. Ул хәтта үткәннәренә, үзләренең мөнәсәбәтләренә дә яңача карады һәм моңарчы аның өчен сер булып калган күп нәрсәләр хәзер ачыклангандай булды. Ләкин әле Мәрьям боларның барысын да тиз генә аңлап җиткерә алмады. Берничә көннәр буе каңгырып, аптырап йөрде ул.

Моратның яшел костюмлы озын гәүдәсе гел күз алдында чайкалып тора кебек.

— Мәрья-әм! Авызыңны ачып утырма, җор бул! Вилданың көньякта нишләп йөри дип беләсең! Җәлләмә акчаңны, бир миңа йөз тәңкә! Мин бер-ике көн эчендә менә дигән компрматериал алып кайтырмын үзеңә! Гомерлек документ булыр!

Мәрьям, шамакай калфаклы башын күтәреп, Моратның сүзен аңлап җиткермәгәндәй карап утыра. Аннары төссез тавыш белән:

— Нәрсә ул компрматериал? — ди.

— Компрометирующие материалы, юләр. — Морат бөгелә-сыгыла көлә. — Аның тамагы тук, эше юк, җитмәсә кояш йөрәкне кыздыра. Вилдан түгел, фәрештә дә чыдамый анда. Пляжда берәр хаңым белән янәшә кызынып ятканын сиздерми генә карточкага төшереп алам да — менә сиңа компрматериал. Ә син, бичара, монда ач утырып ябыгып беттең инде!

Булмәдәгеләр тыела алмый көләләр.

Ишекне шар ачып, каты басып, мастерскойга җил-җил атлап Ирина Сергеевна килеп керде:

— Ха-ха-ха! — дип рәхәтләнеп көлде ул. — Әллә сез цирк өчен клоунны да үзегездә генә әзерләмәкче булдыгызмы? Ни кидең син, Мәрьям?

Мәрьямнең, берни аңламый үзенә карап торганын күргәч, аның башындагы калфагын салдырып, алдына куйды, үзе мастерскойның аргы башында, эшкә чумгандай кыланып утырган Моратка бармак янады:

— Синең эшендер әле, юньсез! Ял иткән чагыңдыр.

Морат борылып карамый, тик тавышсыз көлүдән аның җилкәсе калтырый.

Һәрвакыттагыча Ирина Сергеевнаның күңеле шат, дәрте ташып чыккан, ул баскан урынында тик тора алмый, таптана.

— Ну, ничек, Мәрьям, эшләр? Барамы? Минем янга бер кереп тә чыкмыйсың син, ә? Әллә үпкәләдең инде?

— Юк, үпкәләмәдем. Йомышым юк иде, шуңа кермәдем.

— Йомышың булмаса да кер! Әйдә әле, әйдә! — Ирина Сергеевна, моның алдында сөйләшмик дигәндәй, Камәрия ягына күз кысып куйды. — Монда комачауламыйк, безгә кереп сөйләшик.

Ул Мәрьямнең проекты турында бүген генә ишеткән икән. Әллә кайчан миңа керергә кирәк иде, дип әрләп тә алды. Урындык алып килеп, башта Мәрьямне утыртты, аннары үзе өстәл артына урнашты.

— Менә без Газиз белән киңәштек. Әлбәттә, бөтен бер микрорайонга проект ясау турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Синең анда бик оригинальный йортлар бар икән. Башта без менә шуларның берсен төзеп карыйк. Син хатын-кыз, милли кадр. Менә шуңа басым ясап, тиешле оешмалардан рекомендация, отзыв яздырып, мәсьәләне кабыргасы белән горсовет алдына куярга кирәк. Якаларына ябышырга кирәк, «юк» дип әйтергә телләре бармаслык булсын. Анысын син булдыра алмассың, без Газиз белән икәү эшләрбез. Ә син бик матурлап, аяктан егарлык итеп, эскизыңны яса. Урам яктан күренеш булсын. Бар, шуны эшлә.

Мәрьям каршы әйтеп карады:

— Мин бит бөтен бер комплекс эшләгән идем. Барысы да булсын иде...

— Менә кызык! Син әллә ни теләрсең! Менә мин бүген коммунизмга керергә бик теләр идем дә, булмый шул. Мөмкин нәрсәне сорарга кирәк. Торак йортлар типовой проект буенча салына инде, бер микрорайон турында сүз дә булуы мөмкин түгел. Син башта аларның берсен әйбәтләп эшләп бир. Микрорайоннарына да чират житәр. Еллар гына тыныч булсын, әллә нинди калалар төзерсең әле. Ә хәзергә бар, эшлә. Эскизын шушы арада китерсәң, бик шәп булыр иде.

## Чигенү

Казанка өстендә вак дулкыннар шаяра. Алар йөгерешеп киләләр дә, бетон ярга бәрелеп, кире чигенәләр. Су кырыеннан ниндидер җанвар шуып үткәндәй була.

— Кара әле, кара! — ди Мәрьям Шәүкәткә. — Нидер йөгереп йөри түгелме?

— Юк ла, дулкын шулай сугыла.

Алар бетон ярда, офыкка якынаеп килгән кояшка карап утыралар. Кичке йомшак нурлар шаян дулкынчыклар белән уйный. Табигать көндезге эсседән соң иркенләп тын ала.

Мәрьямнең йөзе уйчан, Шәүкәт нидер сизенгәндәй караңгы чырайлы, аның учында Мәрьямнең кулы.

— Шәүкәт, мин күргәзмәдә булдым!

Шәүкәтнең кулы сизелер-сизелмәс кенә тетрәнеп куйды. Әллә Мәрьямгә генә шулай тоелдымы? Тагын тынлык. Ахырда Шәүкәт түзми:

— Ну, ничек соң, нигә дәшмисең?

Мәрьям, дулкыннардан күзен алмыйча, әкрен генә әйтә:

— Син андый түгел идең, Шәүкәт...

— Ну, әйт, кай җире җитешми, кай җире ярамаган?

— Барысы да әйбәт, һәммәсе тиешенчә. Тик кураең гына син теләгән көйне уйнамый.

— Нинди көй уйный соң ул?

— Ул гомумән уйнамый. — Мәрьям гаепле кешедәй башын ия төште. — Гафу ит, миңа синең көтүчең таяк кабып утыргандай тоелды.

Шәүкәт, Мәрьямнең кулын бетонга ташлап, кесәсеннән сигарет эзләргә тотынды:

— Акыл сатарга яратасың син, менә нәрсә. Гомумән, бер эше буенча гына кеше турында фикер йөртеп булмый әле. Минем иҗатымда кайбер җитешсезлекләр бардыр, булмый калмас. Шуңа күрә укырга

керәм дә бит инде. Менә институтта укып чыккач, курае да сызгырыр, башкасы да булыр.

Мәрьям көрсенеп куйды.

— Бирсен ходай!

Аның тавышында өметсезлек ярылып ята иде.

Тагын тынлык. Тагын дулкыннар бер-бер артлы бетонны ялап узалар. Шәүкәт сигаретын сындырып суга ыргытты. Аннары Мәрьямнең битен учларына кысып, йөзенә туры карады:

— Син бит миңа, гений булмасаң да, гади Шәүкәт булып калсаң да яратырмын, дигән идең...

— Әйе, әйткән идем.

— Хәзер башкача уйлыйсыңмы әллә?

— Юк. Хәзер дә шулай уйлыйм... Шәүкәт булып калсаң... дигән идем шул мин.

Шәүкәт бу сүзләрнең серенә төшенә алмагандай шактый вакыт тын утырды. Назлы дулкын бетон яр кырыеннан, елгыр хайвандай, берничә тапкыр йөгереп узды.

— Тагын акыл сатасың. Ни дип әйтүең инде бу, үзгәргәнсең, дисеңме?

Мәрьям әрнүле тавыш белән аның яшькелт күзләренә туры карап әйтте:

— Әйе, син танымаслык булып үзгәргәнсең!

— Ашыкма, таныр сың әле. Мин бер шәкерт кенә ич хәзергә. Менә укып чыгыйм... Хәер, сиңа ярап булмас. Жюри теге картинага яхшы бәя бирде.

Мәрьям бу турыда тагын да сөйләшеп, үзенең дә, Шәүкәтнең дә кәефен кырырга теләмәде.

— Син китәсең инде алайса, — диде ул. — Ә мин нишлим?

Бу киләчәк турында батырчылык итеп беренче тапкыр сүз башлавы иде аның.

— Изге ният тә бул! — диде Шәүкәт ваемсыз гына. Ул тагын үпкәләгән иде.

— Ансы шулай да бит... Тик минем тормыш та үзгәрер, ахры. Моннан ары элеккечә яшәп булмас...

— Нишләп?

— Соң мин Вилданнан китәргә тиеш бит инде.

Бу сүзләрне әйткәч, үзенә-үзе ачуы килде Мәрьямнең: әйтерсең, ин әһәмиятлесе — Вилдан белән аерылу-аерылмауда.

Шәүкәт бөтен гәүдәсе белән аңа таба борылды:

— Шул чаклы кырт кисәләрмени? Гел үзең турында гына уйлыйсың син, әйеме?

— Әлбәттә. Минем синеке генә булырга теләвем—эгоистлык, билгеле.

Мәрьямнең ирониясен Шәүкәт сизмәмешкә салышты:

— Бу безнең икебезнең генә серебез булып калырга тиеш. Бу очракта Вилданның нишләрен белеп булмый. Шау-шу чыгарыр, гауга куптарыр... Минекеләргә барып ишетелсә... Үзең беләсең, минем быел укырга керәсем бар... Уку мәсьәләсен генә хәл итик инде. — Ул, Мәрьямнең өнсез калганын күреп, тавышын йомшартырга тырышты. — Аннары шәхси тормыш мәсьәләсенә күчәрбез. Мин барыбер синсез яши алмыйм. Үзең дә беләсең ич. Тик син ашыкма, ашыкма гына. Бераз сабыр ит...

...Мәрьям ничек урыныннан кузгалып, ничек урамга килеп чыкканын хәтерләми. Бар көченә сиренасын улатып чапкан «ашыгыч ярдәм» машинасы астына керә язгач кына аңына килде ул. Ак халатлы ир врач ачык ян тәрәзәнең өске рамына чытырдап ябышкан. Машина каты чыелдап Мәрьям янына туктады да, ул читкә тайпылуга, кузгалып күздән югалды. Кемдер авыр хәлдә, кемгәдер ярдәмгә ашыгалар иде...

Урамнарда газоннар шау чәчәктә, юкәләрдән баллар тамган чак — татлы истән башлар әйләнә. Таш стеналардан эссе бөркелә.

Ә мастерскойда гадәттәгечә караңгы һәм салкынча. Бүлмә эче иркенәеп калган, чөнки күпләр ялда.

Морат тагын дөньясын оныткан, шәһәр паркын бизәү буенча эскизлар төзи. Ул үзе баш күтәрми эшли, башкаларга да тын алырга мөмкинлек бирми. Мәрьям ишектән килеп керү белән, аны үз янына чакырып алды:

— Син ни белән шөгыльләнәсең әле?

— Мена йортны эшләп конструкторга бирдем. Тышкы оформлениесен Газиз эшли.

— Анысын беләм! — Түземсезлектән Моратның йөзенә кызыллык бәреп чыкты, күзлек пыялалары елтырап куйды. — Хәзер нишлисең?

— Яңа кафеның эчке оформлениесенә тотынырга торам.

Моратның сабырлыгы бетте. Ул урыныннан сикереп торды да кычкыра ук башлады.

— Ни булды безнең архитекторларга? Бу нихәл? Эш муеннан! Әнә тагын бер йортка индивидуаль проект төзергә кирәк. Ә бездә безобразие! Эшкә күңел бирү юк, җаваплылык сизү юк! «Тотынырга торам», имеш! Тотынырга тормый юньле архитектор, эшли, эшли!

Морат сүзен тәгалләп, кире урынына утырды һәм кычкырып көлүдән чак кына тыелып торган Мәрьямгә «кит!» дигәндәй кул селтәде.

Мастерской җитәкчесе Шәехзадин өчен бар дөнья архитектура белән чикләнгән иде. Ул үз тирәсендә эшләгән кешеләрнең ничек яшәгәнен, ни уйлаганын белми дә, белергә дә теләми. Анынча, кеше эш турында, шул проектлар турында гына уйларга тиеш иде. Ул, Мәрьямнең күңел төшенкелеге белән һич исәпләшмичә, аннан эш таләп итеп торды һәм шуның белән, үзе дә сизмәстән, архитектор Закированың газаплы кичерешләрен җиңеләйтте.

Кичке уңайда Газиз кергән иде, Морат белән бер-ике авыз сүз генә сөйләште дә илтифатсыз гына Мәрьямгә дәште:

— Теге йортның оформлениесен эшләдем мин. Сиңа ошармы инде, юкмы...

— Кайчан алып киләсең соң?

— Әле Жилплощадкадан кайтып килә идем. Туры монда килүем түгел... Әйдә, барып карыйсыңмы, машина ишек төбендә тора...

Мәрьям, «җибәрәме соң» дигәндәй, Морат ягына ишарә ясады.

— Әй, Морат, — диде Газиз, тавышын күтәреп. — Закирова белән объектка барып кайтыйк әле!

Морат, «бәйләнмәгез әле» дигәндәй, иңбашларын гына сикертеп куйды.

Заманында Шәүкәт Газиз турында «дилетант», ягъни күп нәрсәдән хәбәрдар булса да, иҗатка сәләтсез кеше дигән иде. Ул хаклы булмаган. Газизнең кулыннан күп эш килә.

Ул Мәрьям алдына йорт фасадына ясалырга тиешле милли бизәкләрнең өч вариантын куйды: теләсә кайсын сайлап ал. Һәркайсы бик пөхтә итеп, зур тәгәллек белән эшләнгән. Һәркайсы үзенчәлекле, матур. Хәзер шуларның берсен проект авторы сайлап ала, ә икесе ташлана: Мәрьямгә бу әрәм хезмәт булып күренде.

— Кайсын сайларга белмим инде. Өчесе дә бик ошый. Ник соң син өчне эшләдең? Берсе дә бик җиткән булыр иде.

— Алар унау иде әле. Калганнары, минемчә, карап торырлык та түгел.

Газиз, бер папкадан эскизлар алып, бер-бер артлы Мәрьям алдына ташлады:

— Менә кара... Бусында мин төсләрен таба алмадым... Бусында формасы бик матур түгел... Бусы артык куе бизәкле... бусы сыек. Хәер, үзең кара...

Ул үз хезмәтенә чит күз белән карый белә һәм аек фикер йөртә иде. Мәрьям аның шул чаклы эшли алуына да һәм үз хезмәте турында шулай таләпчән фикер йөртүенә дә гаҗәпләнде. Ул да һәр проектның берничә вариантын ясый, ул да эзләнә, тик һәр вариантны бу кадәр төгәллек белән ясамый, әгәр ясаса, үз хезмәтенә сокланып һәм мактанып карый... Дөрес, моны кешегә сиздерми ул, шулай да...

— Я, кайсы ошый? — ди Газиз.

— Барсы да ошый... Менә бусы бигрәк тә.

Газиз калган эскизларын җыеп папкасына салды:

— Нәкъ шунысын сайлап алырсың дип уйлаган идем аны.

— Проектны кире каксалар, никадәр хезмәтең әрәм була инде, — диде Мәрьям.

— Минемчә, проект кабул ителәчәк. — Газиз өстәлне әйләнеп чыкты да, Мәрьямгә каршы утырып, сигарет кабызды. — Мин жирлекне әзерләп куйдым, кайбер кешеләр белән сөйләштем. — Ул көчле кешеләрдәй эре кыяфәткә керде. «Я алла, син дә кыланчык икәнсең әле, дип уйлады Мәрьям. Синең дә үзеңне күрсәтәсең килә». Газиз инде көне буе эштә булган, ләкин кунакка барырга җыенгандай пөхтә, чиста. Тамчы да арганлык сизелми. Җиңнәре сызганып куелган ак күлмәгендә кер заты да, бер җыерчык та юк. Дулкын-дулкын куе коңгырт чәченен ник бер бөртеге тузгып чыксын. Ул тезен чәнчеп утырган да, калын иреннәрен турсайтып, түшәмгә төтен боҗралары очыра. Мәрьям бүлмәне күздән кичерде: шкаф өстенә дөнья кадәр планшет өелгән, стенадагы озын-озын өч киштәгә гипс, мәрмәр, агач һәм пластилиннан ясалган эреле-ваклы фигуралар, бюстлар тезелгән. Тәрәзә янында гына кечкенә шкаф — анда буяулар, нииндидер тартмалар, пумалалар... Өстәлдә дә һәрнәрсә кул астында, үз урынында. Бүлмә кысан, әйбер күп булуга карамастан, һәркайда тәртип, чисталык. Бүлмәнең буяу исе аңкыган һавасы күңелне дулкынландыра кебек. Бу гади урын гына түгел, биредә кеше иҗат итә, аның күңеле гүзәллеккә, матурлыкка омтыла. Тормыш ваклыклары кертелми монда...

— Әллә бераз позировать итәсеңме? — диде Газиз, тынлыкны бозып.

— Әле син минем портретны ясау фикереннән ваз кичмәдеңмени?

— Ю-у-к! Син үзең вакыт тапмадың бит. Кая әле, теге киндер исән булырга тиеш!

Газиз сигаретын сүндерде дә шкаф артыннан таныш рамны тартып чыгарды:

— Менә икән!

Рамны әле генә үзе кузгалган урындык аркасына терәп куйды, шалт итеп утны кабызды. Бүлмә эче шактый караңгыланган икән инде, Мәрьям ирексездән күзен йомды.

Киндердән аңа калкурак яңак сөякле, менә-менә көлеп җибәрергә торган калын иренле яшь кыз карады. Кызның озынча күзләре дөньяга могҗиза көтеп карыйлар. Моннан алты ел элек Мәрьям шушындый булды микәнни?

Ул сумкасыннан түгәрәк көзге чыгарып, үзенә карады. Әйе, бу ул — Мәрьям, тик бик үзгәргән Мәрьям. Аның күзләрендә күңелсез уйлар чагыла, иннек сөрткән иреннәрендә елмаю галәмәте юк, яңаклары суырылып киткән, күз төпләрендә әз генә җыерчыклар беленеп тора. Мәрьям, көрсенеп, көзгесен кире сумкасына яшерде.

— Да-а, — диде Газиз дә сузып кына. — Теге чакта бу портретны ясап бетерәсе калган. Ул вакытта синең особый чагың иде. Гашыйк

иден син. Лэйлэ кебек. Әйе, Лэйлэ, Зөһрэ, Джульетта һэм инженер Закирова. Хәер, ул чакта фамилиян башка иде бугай.

Мәрьям күңелсез көлемсерәде:

— Ник, син мине хәзер гашыйк түгелдер, дип беләсеңме?

— Ну... хәзер инде... — Газиз нигәдер телен тешләде. Ул портрет янындагы урындыкка утырды. — Хәзер... — диде түшәмгә карап. Мәрьям аның барысын да белгәнен, тик бу турыда фикерен әйтергә кыймаганын сизде.

— Я, әйт инде... нәрсә хәзер?

Газиз батырайды:

— Һәрнәрсәнең үз вакыты бар бит. Мәхәббәтнең инде бигрәк тә. Унҗидедә-унсигездә гашыйк була кешеләр. Яшь чак — ахмак чак. Ә инде, әйтик, яшең егерме биштән узгач, гашыйк булып булмый шул... Аның кирәге дә юк. Кайбер тиләләр «сөям» дип йөрилэр дә бит, әмма ул мәхәббәт түгел, яман чиргә әйләнә. Кырыкка җиткәч, скарлатина белән авырган кебек. Кешене эштән чыгара ул. Ир белән хатын арасындагы мәхәббәт иҗатка ярдәм итә дигән сүзгә ышанмыйм мин. Гашыйк булгач, хәтта бөек Паганини да скрипкасын ташлаган! Шул булдымы файдалы нәрсә!

Газиз кызып китте, урыныннан сикереп торды да, ишек янына басып, сүзен дәвам итте.

— Мөнәсәбәтләрдә акыл өстенлек итәргә тиеш! Акыл! Ә хисләр, хисләр барсы да сәнгатькә, иҗатка бирелсен. Мондарак кил әле?

Мәрьям, хәйран булудан авызын ачып, урыныннан кузгалды да берике адым ишеккә таба атлады. Ул Газизнең сүзне ничек дәвам итәрен һич чамалый алмады. Ә Газиз алтын балдаклы матур кулы белән артистларча жест ясап почмакка күрсәтте. Почмакта ак җәймә белән капланган әйберне күргәч, Мәрьямнең келт итеп исенә төште: анда теге «Исәнме, кояш» дип аталачак сын тора иде бит әле.

Газиз киң селтәнеп җәймәне тартып алды, аның җиле Мәрьямнең битенә бәрелде.

Сын әзер диярлек иде. Кеше тәне төсле алсу груша агачыннан ясалган йөз тере кебек, җанлы кебек иде. Чибәр, яшь кыз, кулларын күкрәгенә куеп, сөенеп, дулкынланып карап тора. Бар да дөрес, пөхтә эшләнгән, бар ягы да җитә кебек. Бюст ошый, ышандыра, уйландыра. Лэкин... лэкин бу Микеланджело түгел, Роден да түгел. Бу Лотфуллин, сәнгать кыясына менә торган баскычның Роденнан шактый түбән аратасында торган Лотфуллин иде. Әгәр Газиз әле генә мәхәббәт турында фәлсәфә сатмаса, бу чагыштырулар Мәрьямнең башына да килмәс иде, бәлки. Лэкин хәзер ул бу әсәрнең, гәрчә ул сәнгать әсәре булса да, түбән дәрәҗәдә торуының сәбәбен аңлады: аның авторы бигрәк дөрес яши, бигрәк пөхтә кеше шул. Анда талпыну, омтылыш юк. Хисләр кайнавы җитми аңа. Дөрес, гашыйк булгач, Паганини бер ел буе скрипкасын ташлап торган, лэкин скрипкасын кулына алган чакта, ул чын тылсымчыга, могҗизачыга әверелгән. Юк, йөрәкнең талпынуы, хисләрнең ташуы бөрсе дә бушка түгел, алар кешегә канат бирәләр.

Билгеле, Газиз иҗатын юкка чыгару, кимсетү урынсыз. Чөнки Микеланджелолар, Роденнар мең елга бер генә туалар. Шуңа күрә һәр иҗат кешесенең дөньяда үз урыны, үз кыйммәте бар. Әгәр ул чын күңелдән иҗат итсә, әгәр ул фальшька бирелмәсә...

Әйе, Лотфуллиннар кебек чын күңелдән хезмәт итүчеләр булмаса, сәнгать үләр иде, Роденнар да тумас иде. Шулай булгач, сәнгатьтә, иҗатта көчең җиткәнне башкару, кулыңнан килгәнне булдыру, әзмекүпме үз сүзеңне әйтү — үзе зур бәхет бит!

Газиз Мәрьямне сокланудан телсез калган дип белде, ахры, бик канәгать булып:

— Менә күрдеңме инде, — диде дә, сынны бик кадерләп җәймәгә төреп куйды.

Кем белә, бәлки художник Лотфуллинга да чын мәхәббәт килер, килер дә күп нәрсәләргә аның күзен ачар әле.

Тик Мәрьям түгел. Газиз аңа ошый, ул аның белән дус булуына бик шат. Ләкин беркайчан да ул Газизне сөя алмаячак. Элегрәк, Шәүкәткә кадәр очраткан булса да, сөя алмас иде. Ник? Аны ничек аңлатасың? Ник моны сөясең, ник тегене сөймисең? дигән сорауга берәүнең дә юньләп җавап биргәне юк бит әле.

## Кояш баегач

Мәрьямнәр тәрәзәсенә кояш төшкә кадәр генә карый. Кичке уңайда ул йортның икенче ягына күчә. Кояш баер алдыннан, каршы йортларның тәрәзәләрендә һәм «Пампушки»ның пыяла стеналарында шәфәкъ кызыллыгы чагыла башлагач, Мәрьямнәр бүлмәсе караңгылана, моңсулана, почмакларга эчпошыргыч күләгәләр оялый.

Мәрьям өенә бик соң кайта, ул үзен кая да булса барырга, йөрергә, кино карарга мәҗбүр итә. Өйгә кайтып керүгә, ятар вакыт житкән булсын. Яткач та йокыга китәрлек арылсын.

Бу йорт аңа чит инде. Ул бернәрсәгә дә үкенми, үзен гаепләми, әгәр гаебе бар икән, аның өчен җәзасын алырга риза иде. Ул инде бу йорттан чыгып китәчәгенә күңелен беркетеп куйган, бу турыда алдан ук Вилданга хат та язмакчы иде, тик аның адресын да, кайчан кайтачагын да белмәгәнгә күрә, хат яза алмады. Вилданның үзеннән дә ике ай буена бер хәбәр дә килмәде.

Кичләрен авыр иде Мәрьямгә — эчтән янган хәсрәт утыннан тыны кысыла, күңеле тула, тик елый алмый ул. Уйларының очына чыга алмый. Тик Фәйрүзәне уйлап кына үзенә юаныч таба. Аны тизрәк авылдан алып килеп, кочагына кысса, иреннәре белән тыгыз битенә орынса, куллары белән куе чәчен сыйпаса, җиңелрәк булыр иде кебек... Ләкин авылга кайтып килү өчен өч көн вакыт кирәк, ә Моратның бу турыда ишетәсе дә килми: эшнең шул чаклы тыгыз вакыты, кая ул! Менә теге атнада, менә киләсесендә, дип сузып тик йөртә. Ярый ла: эштә әз булса да онытылып торасың, ә өйдә, тын өйдә ялгызың һич түзәр тәкать юк.

Мәрьям үзен эшкә тотынырга мәҗбүр итте, һәр нәрсәне үз урынына куйды, тузанны сөртеп, идәнне юып чыгарды. Радионы бар көченә кычкыртып сөйләтте. Бөтен җирдә ут кабызды. Телевизорны тоташтырды. Өйдә нииндидер сагыш оялагандай күңелсез иде. Ник болай соң әле?

Ахырда ул кухняга чыгып, газ кабызды, чәй кайнатырга куйды. Өйгә әзрәк ямь кереп китте. Мәрьямнең әллә кайчаннан бирле газ кабызганы юк инде. Бөтен квартирга цейлон чәенең хуш исе таралды. Мәрьям иң матур чынаякка каты итеп чәй ясады. Инде утырып чәй эчим дигәндә генә бик каты чәрелдәп звонок шалтырады. Мәрьям сискәнеп китте.

Ишек төбендә Вилдан басып тора иде. Йөзе гадәттәгедән дә кararак төсле. Әллә кояшта янганга, әллә кәефсезлектәнме?

Мәрьям ирексездән артка чигенде:

— Син... кайттың дамыни?

— Күрәсең ич. Көтми идеңме әллә? — Вилданның тавышы карлыккан. Ул чемоданын почмакка атты да, тузанлы ботинкаларын да салмыйча, бүлмәгә узды һәм радионы туктатып, телевизорны сүндереп, урындыкка утырды. Ул бер хәрәкәтсез, күзләрен стенадагы бер ноктага терәгән хәлдә калды. Берәү дә сүз башламады. Мәрьям башындагы яулыгын салып, чуар ситсы халатын тарткалап куйды да диванга барып утырды.

Вилдан хатынының сүз башлаганын көтә иде булса кирәк. Ул бер сүз дә әйтмәгәч, ниһаять, хәрәкәткә килеп, күкрәк кесәсеннән солдат хаты төсле иттереп өчпочмаклап бөкләнгән кәгазь кисәге тартып чыгарды да өстәлгә ташлады:

— Мә, укы!

Хат яхшы сызым кәгазенә тушь белән язылган, имзасы юк. «Син анда йөргән арада монда хатының тик кенә тормады...» Әһә, ишеттергәннәр дә инде. Иренмәгәннәр, Вилданның кайсы шәһәрдә, нинди заводта икәнен белеп йөргәннәр. Каян белгәннәр, диген!

Хат язучы берне биш иткән. Анонимчыдан такт саклауны, дөреслекне генә сөйләүне таләп итеп булмый инде анысы. Баш ватып торасы да юк, кем язганы мәгълүм... Камәрия стиле сизелеп тора. Мәрьям елмаюдан чак тыелып калды. Камәриянең дә файдасы тияр икән. Ул бу хаты белән Мәрьямгә ничаклы яхшылык эшләгәнен үзе белмәгәндер дә әле, бичара. Беренчедән, хәзер Вилданга, менә шулай булды, мин шул сәбәпле китәм, дип анлатып торуның кирәге юк. Икенчедән, бу хатны Вилдан моннан берничә көн элек алган, хәзер инде аның кызуы сүрелгән, ул хәзер Мәрьямнең китәчәген дә көтелмәгән хәбәр дип кабул итмәячәк иде.

Ул шоколад төсендәге куе коңгырт күзләрен Мәрьямгә төбәп җавап көтә иде:

— Я, ни диярсең?

Әгәр Мәрьям: «Юк ла, бер явызы араны бозарга маташа, ышанма»,— дисә, Вилдан, әлбәттә, хатынына ышаначак һәм үзен өстеннән тау төшкәндәй хис итәчәк иде. Ләкин Мәрьям аның күзләренә туры карап, эченнән тартып чыгаргандай авыр итеп:

— Мин аның белән очраштым шул...— диде.

Вилдан артка чайкалып китте. Хатынының күзгә карап: «Мин гаепле»,— дип утыруы аның зиһенен таратып җибәрде.

Мәрьям урыныннан торды да стена эчендәге шкафтан мендәр, матрац, юрган, чиста җәймәләр алды, кухня идәненә урын җәйде, ишекне эчке яктан урындык белән терәтте һәм утны сүндереп ятты. Өстәлдәге бер чынаяк чәй эчелми калды.

Күктә ялгызы нур чәчеп йөргән тулы ай тәрәзә аркылы Мәрьямнең йөзенә карады. Мәрьямнең күңелендә дә бушлык һәм тынлык иде. Инде барысы да хәл ителгәч, ул кайгырмады да, уйламады да. Бүлмәдә идәнне шыгырдатып әрле-бирле йөрүче кеше аның өчен бөтенләй ят кебек тоелды.

Ул Вилданның газаплануын күреп тора. Әлбәттә, аңа гарьлектер инде. Ләкин ни дисәң дә үзенә генә хас омтылышлары, хисләре, уйлары, холкы-табигате белән дөньяда башка берәүгә охшамаган Мәрьям кирәк түгел аңа. Яхшы хатын кирәк Вилданга, бары шул гына. Дөньяда яхшы хатын булырлык кызлар әзмени? Ә Мәрьям олы мәхәббәт турында, үзенең нәкъ менә Мәрьям булганы өчен сөелүе турында хыялланган иде. Бары шундый мәхәббәт кенә кешегә бәхет китерә дип уйлаган иде ул.

Мәрьямне андый олы бәхет читләтеп узды. Ә бәйләнчек ай тәрәзәдән күзгә туры карый. Ялгыз ай, бәхетсез ай! Хәер, ялгызлыгын сизми ул, ахры, ничә карама — чырае якты. Ә менә кеше ялгыз калса, ул беркемгә дә кирәк булмаса, аның яшәвендә ни мәгънә кала? Менә шушы минуттан Мәрьям юк булса, аңа беркем дә офтанмас иде кебек. Вилдан хыянәтче хатыныннан котылыр, кызы — Фәйрүзәсе аның янында калуга сөенер генә иде. Фәйрүзәгә дә юньсез ана ник кирәк? Ә Шәүкәт Мәрьямне яшь чаклары исенә төшкәндә генә уйлап куядыр. Үлгәнен ишеткәч, бер көрсенер дә онытыр, мөгаен. Кеше сөйгән чакта җанын бирер кебек, аерым яшь алмас кебек, бер заман оныта да куя сөйгәнен — кызык бу мәхәббәт... Төзелеп беткән, ләкин тормышка

ашмаган проектлар гына кызганыч булып калачак... һәм Фәйрүзә, Фәйрүзә... Әнисез ул ничек яшәр?.. Фәйрүзәнең түшенә, хуш исле күлмәгенә йөзен яшереп авыр суласа, Мәрьямнең бар кайгылары җиңеләер иде кебек тоелды.

## Һәркемнең үз кайгысы

Урам тулы халык арасында кеше ялгыз. Беркемнең беркемгә кирәге юк кебек. Багананы да, кешене дә бәрелмәс өчен әйләнеп узасың. Мәрьям дә ялгыз бүген. Һәм шушы миллионга якын халкы булган шәһәрдә барып бәрелер кешесе, сыенып почмагы юк аның.

Бер начар гына почмак булса да ярап торыр иде шунда. Вилдан белән бер квартирда яшәү бик авыр югыйсә.

Уйлый-уйлый тәмам башы каткан инде Мәрьямнең, шуңа күрә ул нинди дә булса тәвәккәл эшкә дә сәләтле түгел хәзер. Гаилә кайгысын бер читкә ташлап, төннәр буе проекты өстендә утыра. Дөрес, әллә ни илһам да, искитәрлек идеяләр дә килми башка, шулай да эш юата, көннәргә мәгънә бирә. Кулда каләм бар чагында, үзеңне тормыштан читтә калган, кирәксез кеше дип санап булмый икән.

Ябыгып, сулыгып киткән Вилдан белән сөйләшмиләр, бер квартирда, икесе ике почмакта чит кешеләр кебек яшиләр. Тора-бара бу хәлгә күнеккәндәй булдылар хәтта. Мәрьям кичләрен ашарга хәстәрләгән була. Ә инде бүлмәдә икенче берәү, гәрчә ул чит-ят кеше булса да, ач утырганда, тамагыңнан ничек ризык үтсен?

Мәрьям кухня ишегеннән башын тыга да телевизор тавышы аша ишетелер-ишетелмәс итеп:

— Ашыйсың килсә, кер, мин итле бәрәңге пешердем, — ди.

Бу сүзләр әкрен әйтелсә дә, Вилдан ишетә. Бераз уйланып утыргач, керә. Кара-каршы утырып тын гына ашыйлар, аннары Вилдан:

— Рәхмәт яусын!.. — дип бүлмәгә чыгып китә.

...Мәрьям утны сүндереп, гадәттәгечә идәндәге матрацка яткач, Вилдан кухняга керде.

— Ярар инде, азаплама үзеңне. Чык бүлмәгә. Газ янында куркыныч бит!

Мәрьямнең йөрәге чәнчеп куйды: Вилдан да ялгыз бит дөньяда, аның да беркеме юк! Ләкин аның кайнар учын иңендә сизгәч, бөтен тәне куырылып килде һәм ул ихтыярсыз читкә тайпылды.

— Кирәкми!

Хәер, бу сүзләрнең кирәге дә юк иде, Вилдан аның тайпылуыннан ук барысын да аңлаган иде инде...

Хәзер инде бергә тору мөмкин түгел иде.

...Дөньяда ваемсыз кеше бармы икән? Әнә Саҗидә апа коридор почмагында моңаеп басып тора. Ак чыраендагы шадралары гадәттәгедән ныграк беленә, гадәттә елмаючан күзләре дымлы. Саҗидә апа — менә дигән оста, пөхтә копировщица. Морат аңардан мөмкин кадәр күбрәк эшләтергә тырыша. Ләкин Саҗидә апа ашык-пошык эшли алмый, үз көе бар аның. Хәзер Мoратның акны-караны күрми эшкә чумган чагы, ул Саҗидә ападан да шуны таләп итә һәм ачуы килгән чакларында хәтер саклап тормый. Ә Саҗидә апаның күңеле сынык. Ире үлгәч, ул бөтенләй кыюсызланды, гел куркып яши торган булып китте: куып чыгармасалар ярар иде, кызларым гына чирләмәсен инде, сугыш кына була күрмәсен...

— Менә бераз сулу алырга чыктым әле, — диде ул Мәрьямгә. — Мoратның да җене чыкты инде бу арада. Әкрен эшлисең дип теңкәгә тия. Ашыгып-кабаланып булмый шул ул. Карале, Мәрьям, җитешә алмый дип куып чыгармас бит, ә?

— И-и, Сажидә апа, ни сөйлисез сез? Сезне куып, андый копировщицаны каян тапсыннар алар? Юкка хафаланып йөрмәгез. Морат сезне чыгам дисәгез дә эштән җибәрмәячәк.

Сажидә апа кыска, йомшак бармаклары белән таяныч эзләгәндәй Мәрьямнең беләгенә ябышты.

— Шулкадәр кәефем юк, Мәрьям. Эчем поша, читен. Гамир хәсрәтеннән һич кенә дә айный алмыйм. Бөтен таянычым шул булган икән, гел шуңа ышанып кына яшәгәнмен икән дөньяда. Кызларымның үз тормышы, аларга да гел елап кына утырып булмый. Эчеңне бушаткан- чы рәхәтләнеп сөйләшер кешем дә юк ичмаса.

Аның ачык күзләреннән мөлдерәп яшь бөртекләре агып төште. Ул йөзен дә чытмады, сулкылдамады да, яше акканын сизмәде дә хәтта. Яшь аралаш елмайды:

— Һи-и, Мәрьям, минем зарымны тыңлап туйгансыңдыр инде син дә. Һаман үземне генә туглыйм. Син ничек яшисең соң? Вилдан командировкадан кайтмагандыр бит әле?

— Кайткан иде дә бит...

Мәрьям теш арасыннан сыгып кына, гаиләнең бозылып китүен, үзенең квартир эзләргә чамалавын әйтте. Квартир тапса, кызын да алып килер иде тизрәк, бик сагынды. Сажидә апа игътибар белән тыңлады, үз кайгысын да бер минутка гына булса да онытып торды кебек. Ул бернәрсә дә төпченмәде, болай да күбесен белә, белмәгәнен казына торган гадәте юк. Тизрәк Мәрьямгә ярдәм итү ягын карады:

— Безгә кил син, Мәрьям. Кил әле, бүген кич утырырга гына булса да, коймак пешереп чәй эчәрбез, рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз. Күпме бергә эшлибез, бер серләшергә вакыт тапмыйбыз. Кил әле, кил, яме. Хәер, кайтып та йөрмә, Вилданга гына шалтырат та, эштән ук безгә китик!

Шуннан соң Мәрьям өенә кайтмады. Берничә көннән көндез кереп Фәйрүзәнең әйберләрен җыеп алды, үзенең дә иң кирәк кием-салымнарын чемоданга салды. Кием шкафының өске тартмасында аның бизәү әйберләре салынган шкатулка тора иде. Мәрьям аны да ачып карады. Бу фирүзә кашлы йөзекне Вилдан кызы тугач бүләк иткән иде. Гәрәбә беләзекләр — аның 8 нче март бүләге. Мәрҗәннәрне дә төрле елларда, төрле бәйрәмнәргә ул алып биргән иде. Бизәнү әйберләренең кыйммәтен белә, нәрсә килешкәнен дә яхшы сизә һәм аны бизәргә тырыша иде ул. Мәрьям ул бүләкләрнең барысын да шкатулкага кире салып, урынына куйды һәм шунда кечкенә генә ят тартмачык күреп алды. Ачып караса — алкалар, кыйммәтле кызыл ташлар кан тамчылары кебек тамып торалар. Моны, күрәсең, Вилдан Мәрьямгә әле бу баруында алган булгандыр да, эшләр болайга киткәч, аның турында сүз кузгатырга җай чыкмагандыр... Мәрьям трюмо каршына басып, алкаларны киеп карады. Килешәләр. Иреннәргә шундый иннек яксаң, кара күлмәк кисәң, искиткеч булачак. Тик күлдән сәгатьне дә, йөзекне дә салырга туры килер. Менә шулай: кара чәч арасыннан бары тик алкалар гына күренеп-күренеп китәргә тиеш, ул Мәрьямнең йөзенә серлерәк, уйчанрак төс бирер... «Менә юләр, диде Мәрьям үз-үзенә, бу алкаларга хакың юк бит инде синең». Ул алкаларны салып кире куйды, бүлмәгә соңгы тапкыр күз йөртеп чыкты, квартир ачкычын өстәлгә куйды. Һәм әкрен генә ишекне япты. Инглиз йозагы челт итеп бикләнеп калды...

Менә шулай бетте бу тарих. Менә шулай көз башында ук нокта куелды инде аңа. Бу мәсьәләне комиссияләрдә, җыелышларда тикшереп кенә берни дә үзгәртеп тә, төзәтеп тә булмый. Эшләнәсе эш эшләнгән, кылынасы кылынган.

Баштан кичкәннәрне чит кешегә сөйләп тә, аңлатып бирү дә мөмкин түгел.

...Мәрьям һаман тәрәзә янында басып тора иде әле. Аһ, житәр инде, житәр, искә төшкән саен йөрәкләр өзгәләнә, уйлаган саен буталасың гына. Эштә генә һәммәсе ачык: уйланасың, хыялланасың, газапланасың, тырышасың — һәм башка бер идея килми калмый. Ул уенны барсына да сөйлисең, урамда очраган һәркемгә туктатып сөйлисең килә. Кәгазьдә, каләм астында йортлар тугандагы бәхетне әйтеп тә, аңлатып та бетерерлек түгел. Шундый минутлар өчен мен газаплар чигеп тә яшәргә була дөньяда. Бу яктан Мәрьям бик бәхетле булды, аның проектлары кәгазьдә калмый: Мәрьям төзегән проект буенча йорт салырга барлык инстанцияләрдән рөхсәт алынды. Конструктор аны шунда ук эшләп тә бирде. Хезмәттәшләре Мәрьям өчен сөенештеләр, бер Камәрия генә пыр тузып йөрде...

Ижатың шулай алга барганда, алма кебек кызың тупырдап үсеп килгәндә, мин бәхетсез, дип булмый инде. Нишлисең бит, иреннән аерылуда Мәрьям үзе гаепле, үзе. Һәм хәзер генә аның янына кире дә кайтып булмый. Бердән, башыннан үткәннәрдән соң ул Вилдан белән тора алмый, икенчедән, тора алган сурәттә дә, өстеннән шундый сүзләр йөргәндә яман ат сөйрәп ничек кайтып керәсең? Бу бит аны ире каршында кимсетәчәк, түбән хәлгә куячак, ә андый рольне башкарырга теләге дә, көче дә юк аның.

Мәрьям авыр сулап урыныннан кузгалды. И-и, сәгать икенче киткән икән инде. Сажидә ничек тәмле итеп, рәхәтләнеп йоклый, әйләнми дә, кымшанмый да. Ә Фәйрүзә гадәтенчә юрганын тибеп очырган. Мәрьям аның өстен ябып, диван кырыена салынган кулын үпте. Кызчык: «Кит, тимә!» дигән шикелле йокы аралаш кулын юрган астына яшерде. Әнисенең назлы үбүе кемнеңдер тупас орынуы булып төшенә керде, ахрысы.

## Соңгы очрашу

Моратның чын-чынлап ачуы чыккан, ул кызарынган, бүртенгән, күзлеген бер кия, бер сала. Артык дулкынланудан, аптыраудан теле көрмәкләнә аның:

— Кая синең гостиницаң? — ди ул Мәрьямгә. — Кая? Кая синең ике атна буе эшләгән эшең? Бу ни хәл? Бу нинди җавапсызлык?

Ул күзлеген киеп, җавап эзләгәндәй, бөтен мастерскойга күз йөртеп чыга. Ләкин барысы да башларын иеп, эшкә чумгандай утыралар, бу әкәмәттән көлгәнен берәү дә сиздерми.

Мәрьям үзенең әле кичә генә командировкадан кайтканын әйтеп карый. Ләкин кая ул? Андый сәбәпләр белән теләсә кем алдында аклана аласың, тик Шәехзадин аны оныткан һәм исенә төшерергә теләми дә. Таптың сылтау! Син җир читенә китсәң дә, таш яуса да, эшеңне башкар! Эш баштан ашкан, архитекторлар җитешми, заданиеләр дөнья кадәр! Ә менә җыен ялкау, төрле сылтау табып, тырай тибеп йөри. «Әнә, диде ул Мәрьямгә, синең проект буенча йортны сала да башлаганнар инде. Барып күрдеңме? Проект буенча эшлиләрме?» Мәрьямнең анда да булмаганын белгәч, Морат теленнән язды һәм кит янымнан, күрәсем дә килми, дигәндәй кулын селтәп урынына утырды.

Юкка шулкадәр кыза Шәехзадин. Мәрьям шунда ук киенеп объектка барып кайтты. Бер дә алай кот очарлык нәрсә юк, нулевой циклны бетереп кенә киләләр, бар да проект буенча эшләнә. Кырык яшьләрендәге, зәңгәр күзле, кискен хәрәкәтле прораб бик эшлекле һәм акыллы кеше кебек күренде. Ул архитекторны үзенә теләктәш кеше итеп каршы алды, киләчәктә ешрак килүен үтенде. Артык шапырынмыйча, тыйнак кына үзенә проектның ошавын әйтте. Дөрес, архитектор иптәш төзүчеләр алдына шактый авыр мәсьәләләр куйган. Төсле штукатурка өчен гранит вагы табып булырмы, юкмы әле... Шулай да тырышырбыз.

Яхшы проект буенча матур биналар төзү безнең үзебезгә дә бик күнелле бит, диде прораб. Һәм күн перчаткасын салып, зур, көчле кулын сузды. Аның белән саубуллашып, автобус тукталышына таба бераз баргач, Мәрьям борылып, төзелеш мәйданына тагын бер кат күз йөртеп чыкты. Зур кран, озын муенын бик салмак борып, зур чиләк күтәрә — ташчыларга измә илтә. Аста торучы телогрейка кигән кыз, ике кулын баш өстенә күтәреп, кранчыга ишарә ясый — болайрак, тегеләйрәк. Ташчыларның өч бригадасы җайга салынган житез хәрәкәтләр белән стена салалар. Бераз күзәтеп торгач, йортның үскәнен күрәсең. Кардан әрчелгән, түмгәкле, кызыл балчыклы җирдән ак кирпеч стеналар күтәрелә. Һәм алар Мәрьям сызган сызыклар буенча эшләнәләр. Архитектор Закированың күнелендә генә яшәгән бина дөньяга килә.

Мәрьям йортның салынып беткәч нинди булачагын күз алдына китерде. Менә шушы ак, садә җир өстендә, күгелҗем нечкә ботаклары урелеп челтәр ясаган кышкы урман фонында ул йорт бик урынлы булачак. Табигать һәм матурлык законнары буенча да ул нәкъ менә шушы ноктада басып торырга тиеш кебек.

Вакыт узу белән Мәрьям ул йортның житешсезлекләрен дә күрә башлар, бәлки. Архитектор Закированың сәнгатьтә үз урынын алу өчен ясаган беренче адымы гына булып калыр, бәлки, бу проект. Ләкин, ничек кенә булмасын, бу йорт Мәрьямнең тормышка ашкан хыялы, аның иҗат кешесе булуын исбат итүче олы дәлил, аның рухи үсешенә бәя бирерлек үлчәү. Дөньяда шушы эш өчен дә яшәргә була иде.

Мәрьям үзен юк-барга әрәм иткән көчләре, хисләре өчен ачуланып, бүгеннән үк эшкә тотынырга һәм бернигә карамастан иҗат белән генә шөгыльләнергә дигән ният белән кайтып керде. Тик мастерской ишегенә барып та житә алмады, аны Сажидә апа туктатты һәм жиңеннән тартып вестибюльгә кире алып китте. Ул бик дулкынланган, агарынган йөзендә шадралары тагын да ныграк беленеп тора иде.

— Мин сине баядан бирле көтеп йөрим инде, — Сажидә апа пышылдап кына сөйләсә дә, кеше ишетмәсен дигәндәй як-ягына каранып алды. — Шәүкәт килде бит.

Мәрьямнең һични аңламагандай күзләрен зур ачып торганын күргәч, аңлатырга тотынды:

— Бая ук килгән иде инде. «Мир» кинотеатры янында көтәрмен дигән иде... Син мастерскойда күренеп йөрмә инде, һаман шул объектта дип белсеннәр...

Сажидә апа Мәрьямнең аркасыннан этеп диярлек ишектән чыгарып җибәрде:

— Бар, бар... Кеше күзенә кереп торма...

Ишек төбенә чыккач, Мәрьям сәерсенеп үзенә-үзе елмаеп куйды. Менә мәзәк, тапкан килер көнен. Аның мәктәбендә кышкы каникулдыр, мөгаен. Кызык, ни сөйләр икән... Күрешеп тормасаң да ярар иде, нигә иске җәрәхәтләрне тырнарга. Хәер, барыбер комиссия каршында җавап бирәсе бар. Барсы өчен берьюлы җавабын да тотармын, ди Мәрьям. Ул йөрәгенең шашып тибүен үзе дә сизмәмешкә салыша. Хәзер генә игътибар итте: көн болытлы, моңсу икән. Дымсу һава хәрәкәтсез, кичәге буран өйгән йомшак көртләр керләнеп өлгермәгәннәр әле.

Шәүкәт гадәтенчә күкрәген киереп торса да, күгәргән йөзеннән шактый нык туңганы сизелә. Ул урамда кәшәкә сугып йөрүче бер өер малайга көч биреп, кинәш биреп тора иде.

Ул Мәрьямгә елмаюсыз, кашын җыерып карады һәм салкын бармаклары белән кулын каты кысты:

— Ашыгыч эшеңнән аерган булсам, гафу ит.

— Юк, әле объекттан кайтып кына килешем иде.

Алар, пыр тузып чапкан малай-шалайга карап, бераз дәшми тордылар.

— Я? — диде Мәрьям, ниһаять.

— Я! — дип җавап бирде Шәүкәт.

— Соң, егет бул инде. Инде мине чакыргансың икән, мин чыкканмын икән, төшке ашны бергә ашарга тәкъдим ит. Үзең дә җылынырсың... — Мәрьям кул сәгатенә карап алды. — Безнең дә обед житкән.

— Ә мин кыймый торам. Син, бәлки, минем белән бер табыннан ризык җыярга риза булмассың?

— Риза, әйдә.

— Кая барабыз соң?

— Безнекеләрнең күбесе кольцодагы диэтик ашханәгә йөри.

Мәрьямнең көлемсерәвен Шәүкәт әллә аңламады, әллә юри аңламаганга салышты. Ул урамнан узып барган сыңар яшел күзле «Волга»га кул болгады, машина туктауга шарт итеп ишеген ачты да Мәрьямгә ишарә ясады:

— Рәхим итегез!

Диэтик ашханәгә кермәделәр, Киров урамындагы иске йортларның берсенә урнашкан, кысан, караңгы һәм өсләреннән бензин исе аңкып торган шоферлар белән тулы ашханәдә капкалап чыктылар. Алар каршында ике ят ир утыра, тирә-якта поднос күтәргән кешеләр әйкәлә иде, ике авыз сүз дә сөйләшә алмадылар. Мәрьям сиздермәскә тырышып Шәүкәтне күзәтте. Шактый үзгәргән кебек. Әллә картайган инде. Юк ла, берничә ай эчендә кеше сизелерлек олыгаймас. Сүрелгән кебек. Тискәре кара чәчләре генә һаман шулай маңгаена төшеп йөдәтә икән. Шәүкәт аны элеккечә кискен хәрәкәт белән төзәтә.

Урамга чыккач, Казанкага, Киров дамбасына таба юнәлделәр. Тротуарда бозлавык, узган-барганнар шуып, озын-озын шугалаклар шомартканнар. Яшьләр өчен кызык, картлар өчен куркыныч нәрсә: ялгыш бассаң, таеп егылуың бар. Мәрьям ул юллардан шуды, Шәүкәт читләтеп үтте.

— Я, ни эш кыру? — диде Шәүкәт. — Теге микрорайон төзеләме әле?

— Микрорайонны үткәреп булмады. Индивидуаль проект буенча бер йорт төзим.

— Менә күрдеңме? Күрдеңме? — Шәүкәтнең тавышында усал кинәну ишетелде. — Ә син бәхет шәһәре төзергә хыялланган идең. Ю-ук, төземи тор әле!

— Мин ул чаклы өзгәләнмим аңа, — диде Мәрьям сабыр гына. — Барсы да алай тиз генә булмас инде. Хәзер индивидуаль проектлар төзергә кирәк... Калалар салырга да вакыт житәр. Еллар гына имин булсын. Әнә, Морат яңа циркның проекты өстендә эшли. Бик оригиналь идея тапкан ул.

Мәрьям: «Ә син аның турында сәләтсез кеше дигән идең», — димәкче иде дә, телен тешләп калды. Әллә кайчан сөйләшенгәннәрне хәзер иск: төшереп тору кемгә кирәк?

Алар дамбага ук килеп җиттеләр. Яннан гына күңелле тыкылдап, яшел вагонлы поезд узып китте. Алар тимер юлны аркылы чыгып, ак кар өстендә күкселләнеп яткан тар сукмактан әкрен генә атладылар. Сукмак кардан биек. Агачларның шәрә ботаклары ямьсез тырпаеп тора. Аларда җан әсәре сизелми. Кайчан да булса яз килүенә, бу чыбыкларның терелүенә, яшеллеккә төренүенә ышанасы да килми. Бу агачлар үлгәндер кебек. Казанка да кар каплаган кыр кебек, кар-боз астында хәрәкәт булуына — су агуына күңел ышанмый. Күксел басу күксел күккә тоташкан. Һава да хәрәкәтсез, тынып калган. Авыздан бөркелеп чыккан пар да тиз генә таралмый, беразга оешып тора.

Алдан барган Мәрьям туктады да борылып Шәүкәткә карады:

— Ә син нишлисең? Ник үзең турында бер сүз дә сөйләмисең?

Шәүкәт күзләрен сукмакка төрәгән килеш саңгырау тавышы белән күнелсез генә җавап бирде:

— Сөйләрлеге юк. Укытам. Сәгать тугызда йокларга ятам. Режимны бик нык саклыйм.

— Чынлапмы?

— Валлаhи! Сәламәтлек бик кадерле нәрсә бит. Ә сәнгать күп корбан сорый. Аның түбәсе Каф тавыннан биегрәк. Гомер буе җан тартышып үрмәләрсең — ә менеп житә алырсыңмы? Анысы билгесез. Ярты юлдан мәтәлүең дә бик мөмкин. Юк инде, дөньяга бер генә килдем мин.

Бу яңа Шәүкәт, Мәрьямгә бөтенләй таныш булмаган Шәүкәт иде. Шулай ук ул бөтенесен дә югалтты микәнни?

— Ә соң институт? Син институтка кермәкче идең бит әле?

— Институт бер генә... ә минем кебекләр... буа буарлык. Ярый әле: мин моны үз вакытында аңладым. Гомер буе алданып яшәсәм, начаррак булыр иде.

— Димәк, «Джоконда»...

Шәүкәт Мәрьямнең күзенә туры карап, иреннәрен кысып:

— Мин яшь булганмын ул чакта, — диде. — Ахмак булганмын.

— Ә мин hаман ахмак әле, димәк?

— Син hәрвакыт хыялый кеше идең. Күзеңне ачыбрак карасаң, син минем хаклыгымны аңларсың.

— Мин, киресенчә, торган саен күбрәк хыялланырга кирәгенә ышанам. Дөрес, төрле вакытлар була. Кайчак бик авырга туры килә. Беркайчан теләгеңә ирешмәссең кебек. — Мәрьям янындагы агачның ботагын тартып күрсәтте. — Менә кара, шәп-шәрә чыбык бит бу. Ә яз килер, бу ботакны да яшел яфрак сарыр. Тик бөреләргә генә салкын тимәсен, тик алар гына hәлак булмасын... Синең өчен дә яз килер әле.

— Нигә миңа яз? — Шәүкәт ачы көлемсерәде. — Миңа кыш та ярый. Һәрхәлдә, мин дә югалып калмам әле. Менә партиягә керәм. Озакламый мәктәп директоры булырмын... Аннары күз күрер...

Мәрьям аңа күзләрен зур ачып аптырап карап торды. Бу шул Шәүкәт, ул өзелеп сөйгән Шәүкәт бит инде. Мәрьям аның өчен тормышның бар яменнән ваз кичәргә, барысын да аның аяк астына салырга әзер иде... Ә баксаң, ул гади кеше, тормышта башка кешеләрдән бераз гына булса да өстенлек яулап алырга тырышучы гап-гади бер бәндә икән. Һәм аңа кемнең дә булса мәхәббәте ике тиенгә дә кирәк түгел, әлбәттә. Чөнки әлеге өстенлекне яулап алуда Мәрьямнең хисләре бернинди ярдәм дә күрсәтә алмас иде. Гомумән, Мәрьямнең аны уйлапниләр кичергәнен, газапланганын белде микән ул?

Менә хәзер Шәүкәтне якасыннан тотып селкергә, яңагына сугарга иде. Теге чакта, күпердә, чәчәк белән кыйнаган төсле... Ничек кенә булса да аны бу хәленнән чыгарырга, hич булмаса, ачуын китерергә иде. Күңелендә хис уянсын, пошынып тирә-якка карасын, яшьлек хыялларын исенә төшерсен иде.

Тик Мәрьямнең аны ачуланырга, аңа кул күтәрергә хакы юк, чөнки андый олы хокук бирерлек хис — мәхәббәт юкка чыккан иде инде.

Мәрьям аңа башка бер сүз дә әйтмәде. Алар икесе ике телдә сөйләшәләр hәм барыбер берсен-берсе аңлый алмаячаклар иде. Мәрьям күз керфекләре чыланганын сиздермәскә тырышып, тиз генә кул сәгатенә күз төшереп алды hәм көр тавыш белән әйтергә тырышып:

— Бәй, безнең обед әллә кайчан үткән икән ич! — диде. — Ну Мораттан эләгә инде миңа...

Ул Шәүкәтне әйләнеп узар өчен кабаланып сукмактан читкә басты hәм тездән карга батты.

— Их син! — диде Шәүкәт аның терсәгеннән тотып. — Якын килергә шулкадәр куркасың икән, үзем читкәрәк китеп торган булыр идем.

Аннары аның артыннан барганда, әкрен тавыш белән әйтеп куйды:

— Безнең бергә булмавыбызда син мине генә гаеплисең. Ә бит барысына да син үзең гаепле... Син миннән әллә нинди зур эшләр көттең. Үзең дә хыяллар белән яшисең... Мин синең янда үземне кечкенә, көчсез итеп хис итә идем, кимсенә идем. Һаман шундый әле син...

Стадион янында аерылыштылар. Шәүкәт Мәрьямнең бармак очларына иреннәре белән сак кына кагылды. Үзе сиздермәскә тырышса да, ул тыныч түгел, үткәннәрне уйлап аның да күнеле әрни иде, күрәсең.

Ул, Мәрьямнең троллейбуска утырганын да көтмичә, стадион коймасы буйлап китеп барды һәм бер генә тапкыр да борылып карамады. Кара пальтодан һәм кара бүректән булганга, ул соры бетон койма фонында бер яссы шәүлә булып кына күренә иде. Мәрьям йөрәге сызлаудан ыңгырашмас өчен тешләрен кысты. Бу шәүлә аның матур хыяллар, якты өметләр, сөенечле минутлар белән бизәлгән яшьлеген алып китә кебек иде. Дөрес, тормыш бетмәгән, тормышның яртысы, жиң сызганып эшләр чоры, янып иҗат итәр еллары алда әле. Шатлыгы да, уңышка ирешеп сөенгән көннәре дә күп булыр. Ләкин болар берсе дә яшьлектәгечә беркатлылык белән шатланып каршы алынмас һәм кичерелмәс. Барысы да башкача булыр. Инде Мәрьям элеккечә чиксез ышаныч белән бөтен барлыгын багышлап ярата да алмас. Хисләр башка төрле булыр, аларны сабыр акыл йөгәнләр.

## Сынау

Ул көнне Мәрьям комиссиягә керә алмады. Көндез аны сорап, эзләп караганнар да, тапмаганнар икән.

Икенче көнне эшкә килү белән, директорның секретаре, бик мөһим эш белән йөргән кешедәй, житди һәм кискен тавыш белән Закированы директор бүлмәсенә чакырды. Барысы да сискәнеп киткәндәй булдылар, бүлмәдә шомлы тынлык урнашты. Морат кына жилкәсе аша секретарьга күзлек пыялаларын ачулы ялтыратып алды. Комиссиягә дигән нәрсәне ишетү белән жене чыга иде аның: «Йөриләр шунда, вакыт уздырып, эшкә комачаулап». Секретарь аның карашын хәбәренә дә алмагандай, горур кыяфәт белән шык-шык басып чыгып китте. Аның артыннан ук Мәрьям дә директор кабинетына юнәлде.

Кара күн белән тышланган авыр ишекнең салкын тимер тоткасына кагылгач, ул үзенең уч төпләре тирләп чыкканын сизде. Башындагы уйлары буталган, үзе алдан ук кимсенгән иде ул. Кеше алдында акланып маташу, үзен алар уйлаганга караганда яхшырак күрсәтү өчен мактану дигән нәрсә аның табигатенә каршы булганга, ул үзен ничегрәк тотарга, ниндирәк тонда сөйләшергә икәнен белми иде. Ә дөрес тон таба алу, комиссия членнары белән уртак телдә сөйләшү бик зур әһәмияткә ия булачак нәрсә иде... Хәер, бу турыда алдан ныклап уйланмаган, уйлануның файдасы тиярме-юкмы иде әле, һәрхәлдә, тизрәк бу күнелсез эштән котылырга кирәк иде һәм Мәрьям салкын суга сикерергә теләгәндәй бар ихтыярын җыеп, авыр ишекне ачты.

Зур өстәл артында, директор урынында шешенке кызыл чырайлы, чал чәчле абзый утыра. Аның зур юан гәүдәсе буй сызыклы соры костюмына көчкә генә сыеп тора кебек.

Бу кешене Мәрьямнең элек тә күргәләгәне бар иде: ул горисполкомның төзекләндерү бүлегеннән Дуденко дигән кеше. Дуденко — танылган намус иясе санала, горисполкомда эшләгән утыз ел гомерендә бер генә гаеп эш тә эшләмәгән, киресенчә, башкаларның кыек эшләрен күреп, кисәтеп, төзәтеп йөри, имеш. Бу кадәресен кеше күп сөйләми,

чөнки намуслы булу — нормаль күренеш, аның турында әйтеп торуның һич кирәге юк. Тырнак очы чаклы да гөнаһы юклыгын, илле елдан артык гомерендә бер генә кагыйдәне дә бозмаганын Дуденко адым саен үзе сөйләп йөри иде. Бу турыда әңгәмә корганда, ул тыңлаучыга шундый хәйләкәр, үткен итеп, керфек тә какмыйча карый, әйтерсең, синең мең төрле гаебеңне таба. Тырышып-тырышып эзләсәң, гаеп дигән нәрсәне һәркемнән табып була инде аны... Дуденконың үткен карашы астында гөнаһсыз шаярулар да, микроскоп астында зурайгандай, олы җинаять кебек күренәләр иде.

Өстәвенә Дуденко яшькә шактый олы булганга, аның белән аеруча итагатьле сөйләшергә туры килә, чөнки олыларга ихтирам белән карау, сүзеңне алар әйткәннән өстен куярга тырышмау балачактан безнең канга сеңгән инде ул.

— Узыгыз, утырыгыз! — диде Дуденко эшлекле тавыш белән. Шундук, нидер эзләгәндәй, алдында яткан кәгазь битләрен актарырга тотынды. Аннары бик җитди, бик мөһим эш башкаргандай, Мәрьямгә сорау бирде:

— Сез архитектор Закирова буласыз, димәк?

— Әйе.

Дуденко үзенең кем икәнлеген әйтеп тормады, аны башкалар, һичшиксез, белергә тиеш, дип исәпли иде, күрәсең. Һәм ул артык тәкәллеф саклап тормыйча, үгезнең мөгезенә тотынды.

— «Чулпан» кинотеатрында ремонт ясаганда булган вакыйгалар турында сөйләгез.

Бу кинотеатр Мәрьямнең күңелендә вакыт-вакыт сызлый торган җәрәхәт булып калган иде. Ул никадәр генә тырышмасын, аның проектын бозып, тамаша залы стеналарын сары чүпрәккә урап, түшәмен пычрак-зәңгәр төскә буяп куйдылар. Мәрьям сорауга коры гына җавап бирде:

— Проектын мин төзегән идем. Ләкин реконструкция проект буенча эшләнмәде...

— Ә кинотеатр директоры белән конфликтка кергәнегез булдымы?

Дуденконың акаебрак торган тоныкыкүзләре кешегә текәлеп, керфек тә какмый бик озак карап тора ала иде. Күрәсең, ул Мәрьямнең никадәр күбрәк гаебен тапса, шулкадәр канәгатьрәк булачак...

— Кызганычка каршы, без директор белән уртак тел таба алмадык, — диде Мәрьям, аның күзләренә туры карап.

— Ә мастерской житәкчесе иптәш Шәехзадин сезгә ничегрәк карый? Эшегездә тоткарлыклар ясыймы?

— Яхшы карый. Тоткарлык ясамый.

Бу мәче-тычкан уенын хәтерләтә башлады: әйтерсең, Дуденко Мәрьямне тотарга чамалый, ә ул исә сорауларга бик шома җавап биреп тоттырмаска тырыша иде. Ләкин Дуденконың кулында Мәрьямне бер бәрүдә сугып ега торган корал бар иде: ул да булса аның уңышсыз чыккан шәхси тормышы, Аитов. Һәм ул һич тартынусыз һөҗүмгә күчте:

— Сез быел Аитов белән очраштыгызмы?

Бик тыныч, хәтта битараф тавыш белән бирелгән бу сораудан Мәрьямнең битенә кызыл тимгел бәреп чыкты. Ул үзенең йөрәгенә тупас рәвештә бәреп кергәндә һичничек үзен-үзе яклый алмавын сизеп гарьләнде, рәнжеде, кимсенде. Ә Дуденконың симез чыраенда бернинди үзгәреш тә күренмәде.

— Я, ни диярсез?

Мәрьям зиһенен җыеп, нинди дә булса җавап биреп өлгермәде. Каерылып ишек ачылды, бернинди рөхсәтсез-нисез Морат килеп керде:

— Закирова, сине телефонга! Бик ашыгыч сорыйлар.

— Закированың эше бар, — диде Дуденко сабыр гына. — Соңыннан шалтыратырлар.

Морат аңа ачыктан-ачык: «Эшлексез, утырасың ачу китереп», — дигәндәй мыскыллап карады.

— Әйтеп караган идем дә, бик житди эш белән, диләр, бер минут та кетә алмыйбыз, диләр, — диде. Аннары: — Объекттан шалтыраталардыр, сез сөйләшсен дип төзелешне туктатып тормаслар шул, — дип тә өстәде.

Мәрьям, Морат Дуденкодан үч алу өчен генә кергәндер, дип уйлаган иде. Юк икән, телефон трубкасы өстәлдә ята иде.

— Сез Закировамы? — диде трубкадагы нечкә хатын-кыз тавышы. — Сезнең ирегез мотоцикл астына эләкте...

Мәрьям башына органдай аңгыраеп китте. Нинди ир? Вилданмы? Ничек инде ул мотоцикл астына эләксен, ди? Үз гомерендә бер генә тапкыр урамда йөрү кагыйдәләрен бозмаган Вилданмы? Урамны ул, милиционер кебек, турыпочмаклап, яшел светофорга гына чыга торган иде бит.

— Ало, ало, сез тыңлыйсызмы? — диде нечкә тавыш. — Исән ул, исән! Шамский больницасында ята...

Больницага барып кергәндә дә, Мәрьям Вилданның мотоцикл астына эләгүенә ышанып житмәгән иде әле. Менә хәзер ул барып керер һәм бөтенләй ят кешене күрер... Больницаның киң баскычы, биек стеналары ук кеше күңеленә шом салып торалар иде. Ярым караңгы коридорда, ишек төбендә утыручы ак халатлы түтәй, «хәзер сестраны чакырам», дип ашыкмыйча гына, алпан-тилпән килеп китеп барды. Кая ашыксын ул? Вилданның үлем хәлендә ятуына аның исе китәмени? Әгәр һәр авыру өчен өзгәләнә башласа, ул биредә эшли дә алмас иде.

Нечкә гәүдәле, талчыккан чырайлы, зур кара күзле сестра тиз килеп чыкты тагын.

— Сез Закиров янынамы? Рая апа, гардеробны күрсәтегез! Халат бирегез!

— Ничек соң аның хәле? — диде Мәрьям кинәт карлыккан тавыш белән. — Куркыныч түгелме?

— Болай куркыныч юк кебек. Баш мие селкенгән. Хәзер аңына килде инде... Сезне танымаса, гаҗәпләнмәгез. Андый очракта хәтер югалу гаҗәп түгел. Әкренләп бары да исенә төшәр әле.

Шәрә стеналы ак палатага эңгер-меңгер керә башлаган иде инде. Шыксыз тимер караватларда биш кеше ята икән. Тәрәзә янындагысы китап укый, берсе аякларын салындырып карават кырында утыра. Соры халат итәге астыннан ак ыштан балаклары күренеп тора. Өч караватта ятып торалар. Кайсысы Вилдан?

Сестра ишек янындагы карават янына үтте.

— Сезнең янга килделәр.

Һәм койка янына табуретка китереп куйды да чыгып китте.

Вилданның башы ак марля белән уралган иде. Мәрьям аның күзләрендә ачы газап күрәчәген уйлап, тетрәнеп, куркып аңа карады. Вилданның шоколад төсле күзләре елмаялар иде. Гадәттәгечә матур, сөйкемле елмаю иде бу. Мәрьям үзен кулга алырга тырышты. Вилданның авызы да марляга уралган булганга, ул аны сөйләшә алмас дип уйлады һәм мөмкин кадәр күбрәк сөйләргә тырышты:

— Менә сиңа мә! Ә мин, Закиров мотоцикл астына эләккән дигәч, ышанмый торам тагын! Булмас, дим, һич мөмкин түгел бу, дим... Хәзергә хәтле ышанасым килми әле!

Вилдан авырлык белән булса да сөйләшә ала икән.

— Үзем дә аптырашта... Күземне ачсам... монда ятам... Үлүе бер дә озак эш түгел икән...

Мәрьям ни диярга белми торды. Сүзне борырга теләп, Вилданның одеял өстендә яткан, бинтка уралгангамы, шешкәнгәме, юан, хәрәкәтсез сул кулына ишарә ясады:

— Авыртамы?

Вилдан «әйе» дигәндәй, керфекләрен генә какты. Аннары нидер исенә төшкәндәй сорап куйды:

— Ә Фәйрүзә?

— Фәйрүзә бакчада. Әле сәгать дүрт кенә бит.

— Ә, әйе, үзем илткән идем бит...

Вилдан буталып китте, Фәйрүзәне бакчага Мәрьям илтте, чөнки алар икесе дә Сажидә апаларда торалар бит...

Вилдан ялгышканын үзе дә сиздеме, әллә яралары авыртуга түзепме, күзләрен түшәмгә терәде, торган саен аның йөзе караңгылана барды.

— Юк... сез өйдә кунмадыгыз бит...

Мәрьям ни дияргә белми, тумбочкадагы шоколадка ымлады:

— Каян килгән бу шоколад?

— Ә-ә, местком вәкиле килгән иде... Күчтәнәч... — Мәрьямнең йөрәге сулкылдап куйды: мескен Вилдан янына шул местком вәкиле килмәсә, кем генә килер икән. Мәрьям аның бер генә дустын да белми иде.

— Ә мин ашыктым. Берни дә алып килмәдем. Кибеткә кереп чыгыйммы? Ни китерим?

— Сок... Алма согы... Я сөт... Эчәсем килә... Китап алып кил... иртәгә...

— Нинди китап?

— Тукайны... Ачкыч күршеләрдә... Син кайтсаң дип калдырган идем. — Аннары Мәрьямгә сәер караш ташлап, әкрен генә әйтте: — Яшисе килә... Шулхәтле яшисе килә...

Күрәсең, ул үлемнән калганына, тормышка кире кайтуына шулкадәр шат иде, яшәү шатлыгы көчле авыртуларны җиңеп чыга, бу дәртле хис алдында Мәрьям белән булган ыгы-зыгылар да кечерәеп калган иде.

— Йөз ел яшәрсең әле, — диде Мәрьям, аны кызганудан һәм дулкынланудан тамагына килгән төерне йотып. — Мондый афәттән котылгач, гомерең озын булачак синең.

Вилдан озак итеп Мәрьямнең күзләренә карады. Аның моңсу күзләренең төбендә, бик тирәндә, каты әрнү, сызлану яшеренгән иде. Әйтерсең ул теле белән әйтми генә: «Ә минем озак яшәвем сиңа ник кирәк?» — дип сорый иде ул. Мәрьямгә дә кирәк булмагач, кемгә, ник кирәк соң ул? Кем аның язмышы белән кызыксына да, кем аның өчен кайгыра? Җәмәгатьчелек каршында яхшы атланып килгән местком членнарымы?

Элек Вилданга үлем котылгысыз, ләкин бик ерак нәрсә булып күренә иде. Хәзер инде, аның өстенә селтәнгән афәттән котылгач, аны яшәү дәрте биләп алды: тормыш белән мөнәсәбәтләрне ныгытасы, үзен бу дөньяга ныграк итеп, таза җепләр белән бәйлисе килә башлады. Шул ук вакытта ул бу җепләрнең азлыгын, нечкәлеген күреп сызлана иде... Ни генә димә, аның Мәрьямнән дә якын кешесе юк, шуңа күрә, ана үпкәсе зур булса да, ул аларны бәйләп торган зәгыйфь кенә җепкә тотынмый булдыра алмады.

— Иртәгә килерсеңме?

— Әлбәттә. Эшкә барганчы керермен...

Мәрьям инде аралар өзелгән, дип күңелен беркетеп куйган иде. Юк икән. Менә хәзер ул, йөзе күгәреп киткән, бинтларга уралган, хәлсез һәм хәрәкәтсез Вилдан янында, аның сызлануларын бүлеп үз өстенә алырга әзер хәлдә утыра, аның исән калуына сөенүдән килгән күз яшьләрен тыя алмый иде...

◇■◇

Энҗе Мөэминова

## Онытмадым

*Поэма-монолог.*

Мәктәп залы,
Түрдә — стенд тора.
Ә стендтан карый рәсемнәр.
Алар арасында синең дә
Миңа бүләк иткән рәсемең бар.

Яшьлегемнең бөреләнеп килгән чагы
Искә төшкән саен,
Шунда киләм мин.
Юксыну һәм сагыну тойгысына
Түзә алмый башым иям мин.

Шушы рәсем аша,
шул стендтан,
Син карыйсың көлеп.
«Ник картайдың?..
Ә мин һаман да яшь...» —
Диясеңдер кебек.
«Син бит минем өчен
җир йөзендә
Иң кадерле кеше...
Бүген мин китәм...
Сугышка...
Көт син мине, яме!..»
Дигән сүзләреңне ишетәм...

Һәм мин көтәм.
Әле һаман көтәм!
Сиңа биргән изге вәгъдәмне,
Хисләремне,
шулай беркетәм.
Кайтмасыңны,
Кабереңөстендәге туфракны
инде күптән
Гөлләр күмгәнлекне,

Үз күзләрем белән күреп ышансам да,
Мин һаман көтәм!
Гомеремнең көзе җитеп килгәндә дә,
Күңелемдә сине йөрткән өчен,
Мин үземне яшь дип хис итәм.
Мин ялгызым...
Гаиләм дә юк минем,
Корган оям да...
Мин үземне

ялгыз итеп сизмим шулай да!
«Күрмисеңме әллә,
Кемнәр генә баш иминәр синең алда!
Юкны көтәсең!
Гомер ике килми!...
Чәчәк кебек елларыңны әрәм итәсең», —
Дигән шелтә сүзләрен мин
Бик еш ишетәм.
Әнә шундый сүзне сөйләүчеләр
янында мин,
Һәм тик шул чагында
Үземне бик ялгыз хис итәм.

Синең кабереңөстендә
«Мәңгелек» ут яна.
Искә алып һәрбер килгән кеше
Гөлләр куя аңа.
Һәм һәр елны,
Синең туган көнең җиткән саен,
Монда,
Минем белән бергә
Әниең килә!
Миңа карап:
«Кызым!» — диеп кенә
Әйтә дә ул,
Чал башын ия.
Өзгәләнеп әйткән шушы сүздән,
Барысын аңлыйм мин.
Ләкин бу вакытта
аны юатырдай
Сүзләр генә таба алмыйм мин.

* * *

Үзебез укыган класс бүлмәсенә
Мин һәр көн керәм;
Анда мин тарих буенча
Дәресләр бирәм.
Сөйлим мин илебез үткән
Зур көрәш юлын.
Искә алам
Ватан тарихына
Алтын юллар язып киткән
Һәрбер батыр кызын
һәм улын.

Андый чакта,
Үзем дә сизмәстән,
Мин борылам
Син утырган парта ягына.
Шул вакытта миндә
Ялкын кабына!
Синең төсле уйчан,
җитди карап,
Бер яшүсмер утыра каршымда.
Хисләр тулы утлы сүзләремне
Мин аңарга сөйлим барысын да.
«...Онытмадык.
Берсен дә онытмадык.
Алар онытылырдай түгелләр;
Ил күгендә алтын йолдыз булып,
Ялкынланып янар гомерләр...»
Һәм мин күрәм:
Аның йөзләрендә утлар кабына!
Әйсерсең лә, ерак йолдыз уты
Күзләрендә чагыла.

Шул чагында, күнелем яшәрүдән,
Тоташ ялкын булып янам мин.
Шул чагында авыр хезмәтемнең
Нәтиҗәсен күрә алам мин.
Шул чагында
Мин үземнең
Көчем арткалыгын
хис итәм!
Шул чагында гүя мин синең дә:
«Рәхмәт!» — дигәнеңне ишетәм.

**М. Мәһдиев**

# БЕЗ—КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ

*Сугыш елларында педагогия училищесында укыганда көндәлек дәфтәре алып барган идем. Аз гына үзгәреш кертеп шул көндәлек дәфтәремне укучыларга тәкъдим итәм. Бу — хикәя дә, повесть та түгел. Монда уйлап чыгарылган бер нәрсә дә юк. Бары тик кеше исемнәре генә үзгәртеп бирелде.*

**АВТОР.**

## Менә дигән бер майор...

Коридорга чабата тузаны аркылы көлтә-көлтә булып кояш нурлары сузылган иде. Менә дөньяның рәхәте кайда икән! Әле кичә генә без колхоз басуларында көлтә кертә, бәрәңге ташый идек. Үгезне туарып тәртә арасыннан этеп чыгарганга әле тәүлек тә тулмаган. Тырнак төпләрендәге дегет, оекбаштагы арпа кылчыклары, бирчәйгән уч төпләре — кичәге тормышның истәлеге әнә шулар. Миләр катып калган, аларны кыймылдатмаганга өч-дүрт ай. Миләрдә ике-өч кенә тирән сыр бар. Аның берсе — сугыш, канкойгыч сугыш турында. Фронтка икмәк кирәк. Без, атасыз калган тәртипсез малайлар, әнә шул икмәкне кырдан җыеп заготзернога озатырга тиешбез. Без инде дүрт җәй шулай эшлибез. Миндә икенче сыр — ашау турында. Кайда гына, кайчан гына авызга кабарлык нәрсә булса, без аны кабарга, йотарга тиешбез. Ә йотарлык әйбер һәр җирдә бар. Көлтә йөгендә утырып кайтасың — бодай башы уып ашыйсың. Урман буенда күшә, су буенда кыр суганы, җир җиләге очрый. Амбар тирәсеннән узганда кесәгә борчак тутырып китәсең. Алабута, кычыткан, чөгендер, яшь бәрәңге яфрагы — болары ашка китә. Табигать бай — үз баласын ул ничек тә саклый. Миндә өченче сыр... Өченчесе — юк. Кичә юк иде...

Бүген беренче октябрь — сугышның дүртенче көзе. Без аркага капчыкларыбызны асып, кемнеңдер теләге буенча, укырга килдек. Үгезләрдән, дегет, камыл исеннән, күксел урманнардан, зәңгәр тетенле, көйгән бәрәңге исе килеп торган басулардан безне кем аерды? Ник аердылар? Моны беребез дә белми.

Җәй буе борчак, яңа бәрәнге, әвендә киптерелгән, тетен тәме сеңгән яңа арыш умачы ашап, капчык күтәреп, тән ныгып беткән — бүген әнә шул кечне кая куярга белгән юк. Кичә кичен генә мунча кергәнне сылтау итеп, бүген битен дә юмаган унбиш-уналты яшьлек малайлар училище коридорында колхоз тузанын кагалар. Менә коридорның бу почмагында Түбән Кенә малайлары. Барысы да чиста ыштырдан, яңа чабатадан. Менә зәңгәр сырмалар кигән Карадуган малайлары — һәммәсе кишер ашыйлар. Мөрәле малайлары кесәләрен әйләндереп бер төрерлек тәмәке эзлиләр, шул арада ду килеп бәргәләшеп алалар. Чабыш атлары кебек барысының да борын тишекләре киңәйгән. Беренче кыңгырау чылтыраса да, класска керергә уйлап та караган кеше юк.

Кинәт өлкән курс малайларыннан берәү:

— Завуч!.. — дигән бер генә сүз кычкырды да класска кереп юк булды. Аның артыннан коридорның яртысы бушап калды. Коридор буйлап электр тогы узгандай булды һәм без, тун миләребезне кыймылдатып өлгергәнче, тузан болыты эченнән ялтыравыклы күзлек пыялалары күренде. Миләр кыймылдады. «Әһә, шул ике пыяла — завуч икән», — дип уйлап алдык. Ике пыяла безне гипнозлагандай итте. Аяклар класска өстерәделәр. Коточкыч тынлык урнашты. Мин класска күз төшердем. Бүрегеи салырга акылы житкән Мөрәле малайларының чәч төпләренә хәтле кызарган, башларыннан пар күтәрелә. Нәкъ шул секундта ишек ачылып аннан ике түгәрәк пыяла күренде. Миләр кызукызу эшләделәр. Нигә алай? Нәрсә, безнең кеше күргәнебез юкмы әллә? Безме? Без бит фронтка икмәк житештергән малайлар...

— Шапки снять!

Тәрәзә пыялалары зыңгылдап китте. Кемнендер парта астындагы сөт салган чирек литрлы шешәсе идәнгә тәгәрәде.

Завуч — рус теле укытучысы икән.

Тынлык урнашты. Тәрәзәдән еракта сары басу күренә, аның күк белән тоташкан урынында тук кибәннәр өем-өем булып утыралар, биектә-биектә тилгәнме, нииндиер кош тирбәлә. Күк йөзе зәп-зәңгәр. Көлтә йөге өстендә үгез көенә баруы нинди рәхәт иде! Ә монда кыймылдарга да шикләнеп утырасың... Күзлекле кеше кесәсеннән сапды зур тарак алып озын чәчләрен рәтләде. Аннары күзлеген салып, аны ап-ак кулъяулык белән озаклап сөртте. Күзлеген салгач, бу кеше бөтенләй хәтәр булып тоелды. Гел йөгән белән күреп ияләнгән ат янына, йөгәнен салгач, барырга куркасың. Ул әллә нинди талый торган ат күк тоела...

— Мин сезгә рус теле укытырмын, ребятки, — дип, күзлекле сүз башлады. — Мин бүгенгә сезнең белән татарча сөйләшәм. Ләкин без, акрынлап, дәрестә русча сөйләшүгә күчәрбез...

Һи-и, безнең өчен бу яңалык түгел! Без моны инде бишенче класстан бирле ишетеп киләбез. Барыбер, бернәрсә дә чыкмаячак. Бик әллә кем булып кылансаң, үзеңне сугышка да алып куярлар әле. Гәүдән бик төз, тавышың таза күренә. Менә дигән бер майор чыгар үзеңнән...

— Миңа алтмыш яшь, — дип дәвам итте күзлекле калын, көр тавыш белән, классның нәрсә уйлаганын сизгәндәй. — Минем сезне культуралы, белемле кешеләр итеп күрәсем килә. Укып бетергәнче миндә рус теле өйрәнсәгез — үкенмәссез. Мин үзем Мәскәү татары. Поездларда йөргәндә сезнең як халкының рус сүзләрен сытып сөйләшүенә минем йөрәгем әрни. «Брач бареньe белән чәй эчә», дип сөйләгәннәрен ишеткәндә, мин бөгелеп төшәм, оялуымнан кая керергә белмим. Беренче дәресне без шуңа күрә бик җиңел бер эштән башларбыз. Сез миңа ике баганага бишәр сүз языгыз. Беренче баганага «б» авазына, икенче баганага «в» авазына башланган сүзләр булсын. Мин шул сүзләрдән чыгып кемнең кем икәнен үзем чамалармын...

Борыннар тартылды, каләмнәр кыштырдый башлады. «Җинел» генә дигән эш шактый авыр булып чыкты. Парта араларыннан кайнар һава күтәрелгәндәй булды, кемнендер каләме сынды, берәүнең карасы түгелеп, кемнендер чалбарын буяды, кайсыдыр язуын бозды...

Зур газаплар белән унар сүз язылып бетте. Күзлекле парта араларында йөри башлады. Ул һәр кешенең дәфтәрен алып, күз йөртеп чыга. Һәр дәфтәрнең үзенә аерым чырае. Бер төрле дәфтәрне алгач, «әһә-әһә» дип тиз генә карап ала да:

— Кайсы мәктәптән? Укытучың кем иде? — дип сорый. Кайбер дәфтәрне почмагыннан чеметеп җирәнеп кенә кулына ала, авызы кыйшаеп китә, йөзе сытыла. Үзе бер сүз дә дәшми, теге малай да моның чытык йөзен күреп кып-кызыл булып утыра, башын аска ия...

— Фамилия?

Тәрәзә пыяласы тагын зыңгылдап китте. Тез башлары ямаулы күксел чалбар кигән Мөрәле малае, үлем җәзасы алган кешедәй, башын түбән иде, партаны шыгырдатып басты. Ун минут элек кенә бу малай коридорда бөтенебезне чалып егып, изеп йөргән иде.

— Зарифуллин, — диде ул, ияген бишмәт якасына яшереп.

Күзлекле исә башкача бер сорау да бирмәде. Ул Зарифуллинның пычранган дәфтәрен парта өстенә төшереп җибәрде. Аннары кесәсеннән дүрткә бөкләнгән ап-ак кулъяулык алды да бармак очларын сөртте. Моны ул шулкадәр чын итеп эшләде, бу вакытта бөтен классның күзе шунда гына булды. Әйтерсең, Зарифуллинның дәфтәр битендә микроблар өелеп яталар икән, әйтерсең, ул микроблар күзлеклененң кулына да үрмәлиләр икән. Бу микроблар керсә, кешене чирләтәчәк икән...

...Мәскәү татары шулай итеп бу дәрестә безне җинде. Ормады, сукмады, хәтта бер генә тапкыр ачулы сүз дә әйтмәде, шулай да җинде.

Без авыл мәктәбендә иркенлектән тулысынча файдаланган идек. Ир укытучылар юк, хатын-кызлар гына... Укытучылар да безнең кебек үк ачлар, уты[illegible]ары юк. «Бәлки безне дә сугышка алырлар әле», — дип җибәрергә дә күп сорамый идек. Шунлыктан күбебез тәмәке тарта, теләгән дәресенә керә, теләмәгәненнән кайтып китә иде. Әнә шундый иркенлектән соң Мәскәү татарының безнең өстән ниндидер власть урнаштыруына, әлбәттә, риза булмадык. Тәнәфескә чыккач әле тел шомартып маташтык:

— Һи-и, исегез киткән икән, мондыйларны гына бөккән бар инде!

— Ә бездә, ә бездә... Моннан да усал иде, химиядән укытты берәү. Рогаткадан «шалт» тегенең күзлегенә бер малай. Шуннан соң майлагандай булды...

— Ә безнең авылда... Ә безнең авылда...

Малайлар шаулаштылар, ләкин барысы да моның болай гына, бүрәнә артыннан бүре куу гына икәнен беләләр иде. Моны Зарифуллин да бик яхшы аңлаган һәм ул, сүзгә катнашмыйча гына, горизонттагы кибәннәргә таба карап, тәрәзә янында тора иде...

## Ата кара тараканның кан әйләнеше

Әркәшә Пермяков — рус малае. Аның чиркәү кушкан исеме Аркадий булгандыр инде. Ләкин туганнан бирле татар авылында яшәгәнлектән, ул Әркәшәгә әйләнгән дә беткән. Хәер, башка яктан да ул нәкъ безнең кебек: русча бер авыз сүз белми — чөнки әти-әнисе дә гомер буе татар авылында яшәгәнлектән, гел татарча гына сөйләшәләр. Киеме дә татарча: өстендә брезент тышлы бишмәт, аягында кызыл буяулары чыккан олтанлы маңган итек. Бөтен булган аермасы — фамилиясендә һәм... су коенганда гына күренә.

Аның этисе авылда ветеринар булып эшли. Халыкта ветеринар дигән сүз юк, «ат врачы» дигән сүз генә бар. Аксап йөргән кәҗәңне дәваласа да, бозаулый алмый яткан сыерны бозаулатса да, Пермяковның исеме гел «ат врачы» булып калды. Җиденчене бетергәч, Әркәшә дә ат врачлыгына укырга китә икән дип сөйләгәннәр иде — ләкин укытучы булуны артыграк күргән, ахрысы, безнең белән училищега килде. Наданлыгы бер дә безнекеннән ким түгел, ләкин рус грамматикасы дәресендә кинәт кенә дәрәҗәсе күтәрелде.

Икенче дәрестә без инде ия белән хәбәр табу, җөмлә турында кагыйдә әйтү кебек эчпошыргыч эшләр булыр дип тора идек. Бөтенләй башкача булып чыкты.

— Сез — колхозчы крестьян малайлары, — дип сүзен башлады Мәскәү татары, — һәм киләчәктә дә күбегез авыл балаларын укытыр. Менә без авыл халкы өчен кирәк булган кайбер сүзләр белән танышыйк әле. Исегездә тотыгыз, мин яздырачак сүзләрнең бик күбесен руслар үзләре дә белми. Бигрәк тә шәһәрдә яшәгәннәре. Я, сезнең татарда кызыл ат буламы?

Безнең өчен бу сорау — сорау да түгел.

— Кызыл туры, — дип кычкырабыз.

— Ә сары ат?

— Була!

— Кара ат?

— Кара туры!

— Менә хәзер шуларны русча әйтегез.

Без тынып калдык. Мөрәле малае Әлтафи миңа борылып пышылдапкына болай диде:

— Чукынды, малай, монда ат печүчеләр әзерлиләр икән, укытучылар түгел.

Ләкин мин аңа җавап бирергә өлгермәдем. Укытучы безне яна сораулар белән күмде:

— Ә атның бәкәле русча ничек булыр? Ә бәкәл өстендәге ялы ничек? Ә? Менә монысын руслардан да бик сирәк кеше белә.

Әркәшә әнә шул дәрестә танылды. Ул бер-ике сорауга дөрес җавап бирә алды. Мәскәү татары аны мактап: «Май чүлмәгенең тышыннан билгеле», — диде. Без, борыннарыбызны тарта-тарта, тактадан күчереп яздык һәм гаҗәпкә калдык: баксаң, ике атның төсе бер үк төрле булып та, ялы, койрыгы икенче төрле булса, рус телендә икесенә дә аерым исем бар икән. Дәрестә татарча да шактый мәгълүмат алдык. Ат төсе без уйлаганча ике-өч төрле генә булмый икән. Аның коласы да, җирәне дә, алмачуары да була икән! Каян белеп бетергән боларны Мәскәү кешесе? Әйтерсең, ат врачы булып эшләгән. Әллә, югыйсә, чыннан да, ат врачымы икән? Бу сугыш вакытында кемнәр генә кем булып йөрми. Әнә, лесхоздагы почта начальнигы, алтмыш биш яшьлек Иван Георгиевич, безгә рәсем дәресеннән керә. Училищеның хуҗалык мөдире Исмәгыйль агай да безгә зоология укыта бит әле!

Мәскәү татары, чыннан да, ат врачы дигән фикергә килдек. Бу фикерне бигрәк тә Әлтафи куәтләде. Рус теле укытучысы ат врачы икән... Әһә, әйтәм җирле, беренче дәрестә үк ул «татарлар брач дип сөйләшәләр... Шуның белән йөрәгемне әрнетәләр» дип сөйләнгән иде. Үзенә кагылганга икән... Аңлашылды. Ләкин ат врачлары бик алама булалар иде. Менә безнең авылның Пермяковны алып кара инде. Җилкәсендә көн-төн калын күн сумка. Үзеннән әллә нинди дегетле дару, авызыннан сарымсак исе килеп тора. Күн фуражка гына киеп йөри. Ә бу? Алла белсен...

Рус теле дәресендә дәрәҗәсе күтәрелеп киткән Әркәшә бер көн эчендә ике фәннән харап булды.

Берсе — әлеге дә баягы рәсем дәресендә.

Иван Георгиевич бу жирләрдә беренче земский больницалар, почта бүлекләре ачылганда ук дөньяга килгән кеше икән. Ул беренче дәрестә үк безгә мондагы алпавыт утарының тарихын, беренче больница, беренче почта бүлегенең ничек ачылуын сөйләде. Үзе революциягә кадәр гимназия белеме алган, аннан нindидер институтта укып, элемтәче булып киткән. Әтисе потомственный дворянин булган икән. Моны ишетүгә безнең колаклар торды. Әлтафи, моңа һич тә риза булмыйча, бөтен класска ишетелерлек итеп татарча:

— Череп таркалган сыйныф, — диде.

Әркәшә дә моңа кушылып:

— Алайса, безде алпавыт калдыгы укыта икәд, — дип куйды. Әркәшәнең һәрвакыт борыны тыгылган була һәм ул бервакытта да борын авазларын әйтеп мәшәкатьләнми иде.

Ләкин алпавыт калдыгы безне ормады-сукмады, ә кемнең нәрсәгә сәләтле икәнлеген белү өчен өстәл өстенә тумбочка утыртып куйды да шуны кәгазьгә төшерергә кушты. Я хода! Кемнәрдән нәрсәләр генә чыкмады! Ну, тапты эш бу картлач үзе дә! Ирекле рәсем дисен иде ул хет! Менә ичмасам авыл мәктәбендә укытучылар безгә шулай дип кенә әйтәләр иде. Кем этәч, кем куян, кем яфрак ясый иде.

Тумбочканы әмәл-чәмәл китергәч, Иван Георгиевич, нәкъ безнең теләкне белгәндәй, ирекле рәсем ясарга кушты. Әркәшә әнә нәкъ шул ирекле рәсем белән харап булды.

...Дәрес бара. Һәркем кыштыр-кыштыр килеп нәрсәдер эшли, артка борыла, кемнәндер нәрсәдер сорап ала, мышкылдый. Берәүләр ясаган рәсемнәрен резинка белән выжылдатып бозалар, икенчеләре сугышка кадәр үк алынган буяу карандашының калдыгын тел очына тидерә-тидерә буйыйлар. Иван Георгиевич парталар арасында йөреп тора. Аның аксыл сирәк чәчләре бер як кырыйдан юл ачып майлап таралган, аксыл мыегы нәкъ борын астында гына урталай бүленеп, борын турысында ирене ялтырап тора. Шуңа күрә сөйләшкәндә ул кишер ашап утырган куянга охшап китә. Аның киемнәре иске, ләкин бик пөхтә. Һәр дәрескә муенына кара лентадан ясалган күбәләк куеп керә. Үзе бераз гына бөкре һәм аякларын өстерәбрәк йөри. Грек, Рим сәнгате турында искиткеч яратып сөйли. Чабаталы малайлар булсак та, һәркайсыбызга «сез» дип кенә сөйләшә. Әлтафи, саташып әллә ничә тапкыр үзе турында «без» дип җавап бирде. Без аңа иyләнгәнмени соң! Иван Георгиевич һәркемгә нindидер бер кинәш бирә, җылы сүз әйтә.

— Менә сезнең яфрагыгыз сабагына караганда бик кечкенә чыккан, — дип, телен шартлатып куя...

— Ә менә сезнең әтәчегез бик әйбәт. Тик нигә аның шпорлары юк? Ә? Сезнең авылда әллә әтәчләр шпорсызмы?

— Яхшы, бик яхшы. Сездән киләчәктә менә дигән рәсемче чыгарга мөмкин. Тик шунысы бар: куянның бервакытта да колагы яшел булганы юк.

Кинәт Иван Георгиевич «әә» иткән тавыш чыгарды. Карасак — аның кулында Әркәшә дәфтәре. Рәсем укытучысының куллары дерелди, икегә бүленгән мыегының очлары берсе аска төшә, икенчесе өскә күтәрелә сыман тоелдылар...

— Сез... Сез... — Ул, кулъяулыгын чыгарып, ютәлләргә керешә. — Сез нәрсә эшлисез, ә? Я, басып сөйләгез әле? Бу нинди натурализм? Сезгә ничек... — Ул ютәлени буылды. — Сезгә ничек оят түгел? Сез нинди бәләкәй хулиган? Совет мәктәбе эчендә сез нәрсә эшлисез?

Карт кыштыр-кыштыр атлап өстәле янына китте. Калтыранган куллары белән журналда Әркәшәгә икеле куйды. Аннан рәсем дәфтәренең битен ертып алды да, йомарлап, мич артындагы утыннар арасына ыргытты. Натуралист Әркәшә, кып-кызыл булып, түбән карап утырды.

Ахырдан гына билгеле булды: ул, айгыр рәсеме ясаганда, бераз чаманы югалтып җибәргән икән.

Иван Георгиевич исә дәрес беткәнче ютәлләде.

Бәхетең бер йомарланмасын... Аннары бетте диген. Рәсем дәресендәге вакыйгадан айнып та житмәдек — зоология дәресендә тагын Әркәшәне бастырып куйдылар.

Укытучы керер алдыннан гына Әркәшә сөйләнеп утырган иде:

— Мин үзем бер нәрсә дә белмим, ничек кенә сөйләрмен инде. Шулай диеп әйтеп кенә бетерде...

— Узган дәрестә, — диде юан корсаклы хуҗалык мөдире урыныннан торып, — без ата кара тараканның кан әйләнешен өйрәндек.

Ул авызын зур итеп ачып бер иснәде. Ахырында бераз гына үкереп авызын япты.

— Пермяков, — диде ул, журналга карамыйча гына, — узган дәрес материалын бик һәйбәтләп безгә сөйләп бир. Ә сез тынлап утырыгыз.

Зоология укытучысы куенына кереп озак кына актарынды да чынаяк зурлыгындагы сәгатен тартып чыгарган булды. Әлтафи артка борылып елмаеп куйды. Узган төн генә йокы алдыннан Әлтафи сөйләнеп яткан иде: имеш, зоология укытучысына корчаңгы йоккан, шуна күрә дәрес вакытында сәгатен караган булып бер кашынып ала икән.

Мәет тә мәет, Әркәшә дә мәет. Ябык муенын бөгеп, бераз шакмакка охшаган башын бик нык иеп акрын гына басты. Җиденче класстан килгән гадәт буенча, ачык китабын алдагы иптәшенең аркасына сөяп куйды да сөйләмәкче булды. Ләкин җөмләнең беренчесен һич кенә дә ерып чыга алмады.

— Ата кара тараканның кан әйләнеше... Кан әйләнеше... гаять... гаять...

— Я, я, — ди укытучы сәгатен озак итеп куенына сала-сала, — я, шуннан... — Әркәшәнең каушаудан борыны тыгылды.

— Ата кара таракаттык... Кара ата таракаттык... гаять... гаять...

Ах, бу «гаять»не! Язалар да соң инде китап авторлары да, ач калгырлары!

— Кара тараканның кан әйләнеше гаять... гаять...

«Гаять» Әркәшә өчен капкын булып чыкты. Күпме генә тыпырчынмасын, ул аннан ычкына алмады. Биология укытучысы, авызын зур итеп ачып күңелсез генә тагын бер иснәде дә, Әркәшәгә икеле куйды.

— Син, пнимаешь, оятсыз рәвештә хөкүмәтне таларга килгәнсең. Хөкүмәт сиңа көненә биш йөз грамм ипи бирә, ә син, пнимаешь, икеле аласың. Менә мин синең ипи карточкаңны тоттырып калдыртыйм әле, булгахтырга әйтеп... Ата кара тараканның кан әйләнешен белмәгән кое кая бармакчы буласың син, ә? Оятсыз син, пнимаешь, актык сүз шул сиңа... — дип сүгеп тә алды.

Әркәшә киселгән арыш башагыдай партага ауды. Капланып ятты. Ипи карточкасы... Ник аңа тия бу завхоз, ә? Әркәшәләрнең өйдә сигез бала. Әтисе бер үзе эшли. Колагы чукрак булу аркасында сугышка алмадылар. Башкаларга тигән льготалар аларга тими. Колхоздан авансқа алган икмәк өстән чыгып бара. Семьяда иң олы бала булган Әркәшә авансны биология дәфтәренең соңгы битенә үзе язып бара. Менә дәфтәрнең ул бите әле дә ачык. «Колхоздан ашарга алынган. 1944 елда» дип язып та куелган. Әркәшә вак яза, пөхтә яза. Хәрефләрне авыштыруны бер дә яратмый, һәр хәрефен туры гына итеп утыртып куя. Үзе өчен язганда хәрефләрне ул тары бөртеге кадәр зурлыкта гына яза. Дәфтәр битеннән туп-туры бер багана төшеп киткән.

12 *кг* арш
8 *кг* арш
12 *кг* арш
14 *кг* арш

Бу багана бик биек. Ләкин ни өчен «арыш» дигәндә бер хәрефне төшереп калдыра ул? Әркәшәне белмәссең, ул йомык күнелле малай...

Ата кара тараканның кан әйләнеше янадан бөтен классның тамак төбенә төен булып утырды. Ну, бу ата кара тараканны! Кансыз гына яшәсә булмаганмы соң ана, кансыз бөҗәкләр бит әнә дачурта!

«Эһ» иткән тавыш юк. Кабер тынлыгы. Завхоз сәгатен алырга куенына кереп бара. Чыннан да, сәгатьне бик озаклап ала. Әлтафи сүзе дөрес булыр. Ләкин бу хәл ата кара тараканнан коткармаячак. Кара таракан — котылгысыз. Тагын кем генә харап бу...

— Абый, Исмәгыйл абый, — дип урыныннан торды Әлтафи кисәк кенә. — Безнең бит кичә бәрәнге җирендә чиләкләр калды.

Класс өстеннән ниндидер җиңел һава дулкыны узды. Күзләр ниндидер өмет белән Әлтафига текәлделәр. Хәзер нәрсә дә булса булыр... Тик тараканнан гына котылырга иде.

— Я, я, Хәлимов, нәрсә әйтмәкче буласың моның белән?

— Соң, абый, нәрсә әйтергә дип шул инде: дәрес урынына әллә басуга гына барабызмы? Кайтышлый складка берәр чиләк бәрәнге күтәреп кайтырбыз.

Мең яшә, Әлтафи! Исмәгыйл агай куен кесәсенә тагын кереп китте. Әлтафи ыргыткан кармакка шул арада хәйләкәр, мут Баязитова жим киертте.

— Абый, имә, безнең класс малайлары тимер көрәкләрне кайрыйбыз дип әйтәләр. Көрәкләр бик үтмәсләнгән, кичә дә уч төпләре кабарып чыкты.

Зоология укытучысы шул секундта юк булды. Аның урынын хуҗалык мөдире алды. Класс җиңел сулап куйды.

— Бәрәңге алып кайтырга дисезме? Ашханәгә каграз бүген бәрәңге кирәк. Ә дәреснең ничә минуты калган соң? Ә кемнәр көрәк кайрый беләә? Кулларыгызны күтәрегез әле? Яхшы. Бүген дәрестән соң складка килерсез.

Исмәгыйл агай нәрсәдер уйлагандай күзен йомып торды. Аннан кинәт кенә яктырып журналга тотынды.

— Тукта, без бит әле исемлек тикшермәгән.

Ул акрын гына исемлек тикшерә башлады. Күренеп тора, ана нәрсә беләндер вакытны уздырырга кирәк. Исемлек тикшерү менә болайрак барды.

— Абдуллин!

— Мин!

— Әһә, Абдуллин бар. Аны бар дип куябыз. Ярый, Абдуллин булды, билгеләдек. Баязитова?

— Мин!

— Әһә, Баязитова да бар. Ярар, аны да бар дип билгеләп куйдык. Инде килеп Зарифуллин? Ә? Әллә юкмы?

Беразга гына соңга калган Зарифуллин да сикереп торып басты.

— Ә, бармыни? Мин, әллә юкмы дип торам. Шулай, бар дип билгелибез.

Безгә нәкъ менә шушы гына кирәк иде. Беребездә дә сәгать юк, шулай да чама белән чирек сәгать дәрес калгандыр. Болай булса, эш начар түгел. Исемлек әле зур, һәрхәлдә, ата кара тараканга кабат кайтылмас... Жай гына барган эш Әркәшәгә житкәч тагын тәртелде. Әркәшә баягы ударлан әле дә айнып житмәгән иде һәм укытучы аның фамилиясен әйткәндә ул, әлбәттә, жавап бирерлек хәлдә түгел иде. Ләкин йөз сум акчаң булганчы йөз дусың булсын! «Пермяков» дигән сүз чыгуга, Әлтафи утырган жиреннән генә нәкъ Әркәшәнең үзе тесле әйтергә тырышып җавап бирде:

— Пид!

Барыбыз да шыпырт кына хихылдаштык. Әлтафи, әлбәттә, тотылды. Әле генә бик эшлекле кыяфәттә бәрәңге алып кайтырга тәкъдим керткән Әлтафи инде аяк үрә бастырып куелган иде.

— Кешенең физик кимчелегеннән көләргә һич тә ярамый, Хәлимов, — диде биолог куенына керә башлап. — Ярамый. Ул нинди шовинизм ул, пнимаешь? Шовинист булырга ярамый, шту син...

Ләкин никадәр генә каты әйтелмәсен, дәрес бетеп, класстан чыкканда Әлтафиның йөзендә ниндидер шатлык балкый иде. Ни дигән сүз ул шовинист? Шайтан белсен! Ләкин менә шул хикмәтле сүзне Әлтафига ябыштырып куйдылар бит әле!

Шулай, горур кыяфәттә шовинист Әлтафи коридорга чыгып китте. Класста иң арткы партада натуралист Әркәшә генә ятып калды...

## Зарифуллин калырга булды

Ике атна чамасы вакыт үтте.

Дәрес бара.

Бүген томанлы һава, басу түрендәге кибәннәр күренмиләр. Хәер, аларны инде ындыр табагына ташый башлаганнар иде. Авыл басуындагы шул кибәннәргә карасаң, ничектер җанга рәхәт булып китә иде, инде алар да югалып баралар.

— Ян Амос Коменский, — ди кылыч борынлы педагогика укытучысы, — баланың дөрес тәрәккъкый итүе өчен дүрт шартны нигез итеп ала. Бу турыда сез беләсез. Менә хәзер Коменскийның «Бөек дидактика» дигән хезмәте турында кем миңа сөйләп бирер. Ягез әле, ягез!

Укытучының бусы да күзлекле. Тик монысының күзлеге зәңгәр һәм бик калын. Шуңа күрә ул җанга салкынлык өрә. Укытучының бармагы журналдагы исемлек буенча түбән төшә. Бармак «А» хәрефен узды. Абдуллинның авызы ерыла. Ул елмаеп артка карый. Баязитова чатнаган иреннәрен шатлыгыннан ялап ала — бармак «Б» хәрефеннән дә узып китте. Гыйззәтуллинның бите ап-ак киндергә әйләнә: зәңгәр күзлекнең бармагы шул фамилия тирәсендә туктап кала.

— Моны безгә әйтеп бирер... Хәзер моны безгә әйтер... безгә әйтер...

Я, хода! Нигә дип шулай газаплыйсың! Әйт, тизрәк әйт фамилиясен, кем булса да булыр, тик болай газаплама гына!

— Моны безгә хәзер бик яхшы итеп сөйләп бирер... Зарифуллин.

Кинәт кенә Гыйззәтуллинны очкылык тота башлады. Педагогика дәресе аның өчен ул кадәр куркыныч түгел, ләкин ул һәрвакыт «педагогика» сүзен әйтә алмыйча иза чигә. Педагогика расписание буенча беренче дәрес булып керә, гомуми торактан училищега килеп житкәнче салкында авызлар күшегеп бетә... Туңган авыз белән «педагогика» дип әйтүе, әлбәттә, уен-муен түгел. Монда теләсә кем буталырга мөмкин. Гыйззәтуллин — әгәр аны педагогика дәресендә бастырып куйсалар — бер дә исе китмичә генә «федәикә» дип сөйли бирә. Булмастаен белгәч ул инде бөтенләй башын ватмый... Бәхетсез Зарифуллин исә Коменскийның «Бөек дидактика»сы турында сөйләргә дип басты. Сипкелле яңагын зәңгәр бишмәтенең сап-сары мех якасына яшерде. Өметсезлек белән күзләрен тәрәзәгә төбәде. Анда кыеклап яңгыр ява, мондый көнне колхозда эш булмый. Каравыл өенә җыелып тәмәке төреп, күргән-белгәнне сөйләп яту никадәр рәхәт була иде.

— Я, я, Зарифуллин... Аны сөйләргә кыенсынсаң, Иоганн Генрих Песталоцци карашларына туктал. Бөек швейцар педагогының баланы тәрәккъкый иттерү турындагы карашлары нидән гыйбарәт?

Үтерде. Суйды. Ах, ике-өч йөз ел элек Коменский белән Песталоцци туганчы укуы бик җиңел булгандыр. Зарифуллинның күз аллары караңгылана, аның алдында ниндидер бөҗралар очып йөри башлый. Ул

тузып юкәсе чыккан чабатасын бер өзлексез идәнгә ышкый. Кичә урамда эт тизәгенә басылган булырга тиеш. Юкәне харап итә инде ул. Авылга кайтканчы таралып китсә нишләсе булыр? Ах, тукта әле, нинди юкә? Песталоцци бит әле. Ә зәңгәр күзлек, әйтерсең, тырнак астына энә тыга...

— Яле, яле, сөйләп җибәр әле? Ә? Әллә кыенмы? Уйла, уйла яхшылап.

Зарифуллин бүген үк училищедан качарга карар бирде. Аның колаклары, керфекләре тирләде. Шул минутта ул үзенең баш миен бик сыек хәлдә итеп күз алдына китерде. Баш мие шулпаланган! Тизрәк качарга кирәк! Тизрәк авылга, үҗәт, каты муенлы үгезләр арасына, җылы ат абзары тирәсенә! Ул барысын да күтәрер, өстерәр, ындырга төнге сменага чыгар, тик менә бу Коменский белән Песталоццидан гына коткарыгыз...

— Песталоцциның педагогик идеяләрен кем дәвам иттергән? Яле, яле, Зарифуллин.

Сыекланган ми чайпалып алды.

— Дистервег, — диде Зарифуллин шатлыксыз гына. Аңа хәзер барыбер иде.

— Ого, ого, молодец! Менә, молодец, Зарифуллин. Яхшы, бик яхшы бу.

Зарифуллинга тагын кайгы төште. «Бик яхшы» дип торганда ничек итеп училищедан качарга инде?

Дистервег турында Әлтафи сөйләде. Әлтафи класста иң зур малай, аның кесәсендә һәрвакыт чакматаш белән филтә һәм бакчада үстергән яшел тәмәке булыр. Аның кесәсе әллә ничә җирдән янып тишелгән. Ләкин ул телгә оста.

— Дистервег бөек педагог булган, — дип күз дә йоммыйча алып китте ул. — Ул бик күп китаплар язган. Аның китаплары бик зур әһәмияткә ия. Ул анда балаларны яхшы тәрәккый иттерергә кушкан. Шулай итеп, Дистервег бик зур әһәмияткә ия булып тора.

Әлтафи бишле алды...

Тәнәфес вакытында Зарифуллин белән Гыйззәтуллин коридор башына барып нәрсәдер сөйләшеп тордылар. Йөзләрендә шатлык дигәннең әсәре дә калмаган иде. Зарифуллин ябыгып киткән, педагогика дәресе аның итен суырган кебек иде. Класс бүлмәсенә ул тәртә арасына җигелергә кергән үҗәт үгез кебек авыр керде.

Аның артыннан ук Мәскәү татары күренде.

Үтүкләнгән чалбардан, ефәк шнурлы, ялтыравыклы кап-кара ботинкалардан, ап-ак күлмәктән. Шул ук хәрәкәтләр: зур тарагы белән озын чәчләрен янга сибелдереп рәтләде, күзлеген сөртте, көмеш чылбырлы куен сәгатен чыгарып өстәлгә куйды... Класста көр тавыш яңгырады.

— Узган дәрестә, ребятки, без сезнең белән «Слово о полку Игореве» әсәрен өйрәнә башладык. Мин бүген тагын үзем укыйм. Сез тыңлап кына утырыгыз. Рус теленең байлыгына, әсәрнең көенә игътибар итегез. Борынгы шагыйрь менә ничек язган:

«Трубы трубят в Новгороде, стоят боевые знамена в Путивле. Игорь ждет милого брата Всеволода. И сказал ему Всеволод: «Один брат, один свет, светлый ты, Игорь..!»

Тигез, көчле, яңгыравыклы тавыш. Бу тавыш безнең хыялларны әллә кайларга алып китә. Без үгезләрне, кибәннәрне онытабыз. Дөньяның чиге безнең авыл басуындагы кибәннәр янында гына түгел икән. Дөньяның яратылышы да күптәннән икән. Тарих бик карт, бик тәҗрибәле икән. Ә без тарихны нибары сугыш — кырык беренче елгы сугыш башланган көннән генә башлана дип уйлый идек.

Мәскәү татары күзлеген сала да кия, сала да кия. Безнен тун миләребез үзеннән үзе кыймылдыйлар, без инде хыялларыбыз белән кыпчаклар, славяннар арасында йөрибез. Менә өермәдәй кыпчак гаскәре... Менә тимер алкалы җиләннәр, авыр шлемнар кигән, чукмар тоткан славяннар. Зур тояклы атларына атланып алар далада баралар. Атларының аяк астында җир селкенә... Гомер буе походларда йөргән, баш астына ияр салып йоклый торган сугышчылар...

«А мои куряне — опытные воины, под трубами пеленаны, под шлемами взлелеяны, с конца копья вскормлены, дороги им известны, овраги знакомы, луки у них натянуты, колчаны открыты, сабли заострены; сами скачут — словно серые волки в поле, ища себе чести, а князю славы...»

Бераздан без моны хор белән укыйбыз. Мәскәү татары безнен тигез тавышыбызны ишетеп шатлана, күзлеген сала-кия:

— Во! Во! Во! — дип нишләргә белми. Шул хәлдә тәнәфесне белдереп кыңгырау чылтырый...

— Калырга! — дип хәл итте Зарифуллин. — Калырга, тырышып карарга кирәк.

## Йокы килә

Авылдан училищега кадәр нәкъ унике чакрым. Тулай торакка кичтән барып кунасы килми. Ял көнне анда салкын, шыксыз була. Болай, ичмасам, атна кыскара: биш кич кунсаң, атна тәмамлана. Ләкин дүшәмбе көн иртән торып дәрескә баруы — әҗәл. Кемдер: «Дүшәмбе — авыр көн», — дип әйткән, имеш. Ул кеше моны инде дүшәмбе көн иртән йокыдан торуны искә алып әйткәндер.

Тышта әле караңгы. Утлар алынмаган. Буран себереп тора. Менә Рәдифләр тәрәзәсе. Ут юк. Рәдиф сигезенчене бетергәч прицепщик булып эшли башлады да менә кышкы төндә рәхәтләнеп йоклый. Алар өендә йокы аеруча тәмле. Менә киң чиста идән. Анда тәгәрәшеп Рәдифнең энеләре йоклый. Аска толып, тун җәйгәннәр. Чәбәләнеп беткәннәр. Бер энесенең аягы икенче бер энесенең муенына салынган. Ә иң кечкенәсе, ике яшьтәгесе, мүкәләгән килеш капланып яткан. Аларда һәр төнне шулай. Их, нигә генә укып йөрергә, нигә прицепка гына утырылмаган соң?

Авыл артта калды. Алда кара кучкыл урман. Анда буран юк, бүрекнең колакларын ычкындырасың. Тып-тын, җылы. Менә аланда печән кибәннәре. Ул кибәннең астында бик рәхәттер. Анда берәр җәнлекнең оясы бардыр. Алар этисе, әнисе, балалары бергә җыелышып җир җиләге исе килеп торган печәндә рәхәтләнеп йоклыйлардыр. Их, нигә безнең заманда могҗиза булмый икән? Булсын иде менә шулай: синең каршыңа бер кеше килеп чыга. Ул сине таный. Болай ди:

— Энекәш, бүген уку төштән соң бит...

Менә шуннан, нәкъ шушы турыдан печән кибәннәре янына кереп китәр идең дә астына ук кереп йоклар идең. Озак итеп, рәхәтләнеп йокларга иде. Ләкин теге кеше чыкмый... Кибәннәр инде артта калдылар.

Яктыра башлады. Урман да бетте. Кырда салкынча, себерә торган буран. Иртәнге сорылыкта урман кырындагы училище бинасы күренә. Бер катлы агач йорт, урман буена сыя алмыйча, кырдагы кар диңгезенә таба сузылып таралып ята.

Класста җылы. Морҗа исе, башка тия торган зәңгәр ис. Бөтен буыннар талып кала, тар парта арасында тик утыруы шундый рәхәт... Ләкин күзгә нәрсәдер өелә, нәрсәдер укытучы өстәле яныннан очып килә, туп-туры синең күзеңне каплый, баш аска төшеп китә... Юк, бу

әйбер бинокль икән. Әнә шуның ике трубасы эченә йокы тутырылган. Тыгызлап. Шул бинокль кара тактадан ычкына да, салмак кына тирбәлеп синең күзеңә килеп терәлә. Менә труба эчендәге төтен сыман әйбер чыгып синең күзләреңне каплый. Баш кисәк кенә аска сыгылып китүгә, бинокль юк була.

Әллә каян укытучы тавышы ишетелә:

— Баш килеш: Буран

Иялек килеш: Буранның

Юнәлеш килеш: Буранга, —

дип нәрсәдер сөйли. Шул арада бу сүзләр барысы да вак кисәкләр булып оча башлыйлар. Аларның һәрберсе бер кисәк йокы икән. Алар күзгә килеп керәләр, башны авырайталар. Баш тула. «Буран, буранның, буранга... Буран, буранның буранга...» Өстәл янында басып торган апа да һич тә укытучы түгел. Ул теге, печән кибәннәре янында очрарга тиешле кеше икән. Ул кеше дә түгел, ә әллә нинди мамык сыман төтеннән оешкан бер гәүдә икән. Ул үзе йокы икән. Менә ул аз-азлап йокы очырта икән.

— Буран, буранның, буранга...

Буран, буранның, буранга...

Мамык сыман гәүдә бөтенләй таралып беткәч, барлык укучыларга башларын өстәлгә салып теләгәнчә йокларга рөхсәт ителәчәк икән... Юк, алай түгел, монда парталар юк, бу — печән кибәне төбендә икән. Менә хуш исле печәнне тишеп кергәннәр дә йомшак тәпиләренә башларын салып ике куян йоклап ята. Ул куяннарның берсе баш килеш, икенчесе иялек килеш икән. Ә кибәннең бу ягын өстән зур итеп казыганнар. Анда Рәдиф үзенең энеләре белән йоклап ята. Кечкенә энесенең аяк бармагы Рәдифнең авызына ук тиеп тора, барысы да күкрәкләрен селкетә-селкетә мышлыйлар. Шунда ук кибән төбендә бер патефон әйләнеп утыра. Пластинкадан бию такмагы ишетелә:

— Буран, буранның, буранга...

Шул көйгә кибән арасында бер олы апа бии. Үзе бии, үзенең күзләре йомык, рәхәтләнеп йоклый. Әһә, ул таныш кеше — татар теле укытучысы Рабига апа икән. Куяннар да, Рәдиф тә, аның энеләре дә, Рабига апа да рәхәт чигәләр... Тик сине генә ниндидер ачы тавыш бүлдерә. Ул — кыңгырау тавышы икән.

Грамматика дәресе тәмам.

Өйгә эш: «Чиләк» сүзен ике төрле санда да төрләндереп дәфтәргә язып килергә...

Рабига апа җәнлек тиресеннән теккән соры тунының җиңеннән кулларын чыгара. Аның дәресе дүшәмбедә беренче сәгать булганлыктан, соңга калучылар да, йоклап утыручылар да була. Йоклаган укучыларга ул ачуланмый. Тик дәресеңне генә белеп кил.

— Сезнең каныгыз азайган, — ди ул. — Менә сугыш бетәр, теләгәнчә шикәр, яшелчә, җиләк-җимеш ашарсыз. Йоклау — кан азлыктан ул...

Шулай да, йокы — рәхәт эш.

## Колаямбу плантациядә эшли

Шулай да, бу уку дигәннәре...

Таш кисәр идек, укымас идек! Менә ташлыйм, менә качам дип йөри торгач, инде икенче чирек тә үтеп бара. Иң авыры рус теле, дибез. Юк, алай түгел, иң авыры психология! Аты коргыры фән! Меланхолик, сангвеник, холерик, флегматик, имеш. Гыйззәтуллин — меланхолик, Әлтафи — флегматик, Зарифуллин — холерик, имеш. Юк, иң авыры, шулай да, немец теле. Үзе булсын ул бер дигән дошманыңның теле,

шуны тагын өйрәнеп ят. Шуның өстенә укытучысы — нечкә аяклы, чандыр яңаклы, шүрәле бармагыдай нәзек озын бармаклы ир уртасы бер кеше. Уң кулындагы озын урта бармагын күзенә терәгәндәй чукый-чукый белем бирә.

— Eine fremde Sprache ist eine Waffe im Kampf des Lebens[1].

— Син ничә тел белсәң, шуның кадәр әйбәт кеше... — фәлән-төгән дип йөрәкне боза.

— Син бүген бер икеле алдың — димәк, син Гитлер тегермәненә бер чүмеч су салдың. Син бер бишле алдың — димәк, син фашизмга удар ясадың.

Һәр сүзе — ярага тоз. Җитмәсә, татар сүзләрен дә үзенчә бозып сөйләп үзәккә үтә. «Бүген» дими, «бөгөн», «соңга калдың» дими, «сына калдың»... Шуңа күрә сүзе авыр, һәр җөмләсе баш миенә чүкеч белән суккан күк.

— Немец теле — бөек тел. Немец милләте дөньяга Гетене, Шиллерны, Бетховенны бирде. Немец халкы кешелек җәмгыятенә Марксны, Энгельсны, Бебельне, Либкнехтларны бирде. Эрнст Тельман немец телендә сөйләшә...

Миләр кабара, баш шаулый...

— Немец телен Владимир Ильич бик яхшы белгән. Фридрих Энгельс сигездән артык тел белгән...

Я хода, моннан соң ничек яшәрбез, бер генә чит тел белмибез бит! Шуны уйлагач, баш мие бөтенләй эшләүдән туктый. Ә сары күлмәкле чандыр ир тукуын дәвам итә.

— Без бөгөнге көндә сезнең белән немец милләтенә каршы көрәшмибез. Без сезнең белән кешелек җәмгыятенең иң кабахәт адәм актыклары — фашистларга каршы көрәшәбез. Немец булу әле ул фашист булу дигән сүз түгел...

Чандыр кул уйный да уйный. Менә хәзер ул уйнаудан туктар, хәзер ул кемне дә булса бастырыр. Бу — бик коры кеше, моның белән шаярып булмый. Бу — белдергәнче укытачак. Каптык... Кем генә котыртты соң безне укырга... Нинди хәерсез сәгатьтә юлга чыгылды соң? Ну, бу ипи карточкасы! Шуңа кызыгып кына харап булдык бит!

— Бөгөн без узган дәрестә өйрәнгән «Колаямбу» текстын кабатлыйбыз.

Тагын газап, тагын баш өстендә рәшә, күз алдында бәҗралар. Әйе, әйе, бу текст хәтердә, бик хәтердә. Гомердә онытылырлык итмәден узган дәрестә. Һәр сүзен хор белән әйттереп җаныбызны каһәрләдең. «Нох айн маль, нох айн маль» дип җелегебезне суырдың. Янәсе, тагын бер мәртәбә, тагын бер мәртәбә. Менә монда бер сүз бар, дидең, анысы французча. «Плантаге» дип язылган, «плантэжэ» дип укырга, дидең. Кат-кат кисәттең. Ул көнне Әлтафи хәтта авылына хат та язды. Имеш, немец телен без инде су урынына эчәбез, ну, шуның өстенә аз-маз француз телен дә өйрәнгәлибез...

Чираттагы корбан — Гыйззәтуллин.

...Класста сыек кына калтыравыклы тавыш ишетелә. Иҗек саен төртелеп, чигенә-чигенә, хут белән кисәк алдырып, Гыйззәтуллин укый. Бите кып-кызыл. Ышан син аңа, минем каным аз дип йөргән була үзе.

— Колаямбу арбэйтэтэ... арбэй... арбайтете... ауф... ауф... эйнэр... айнэр план... планта...

Харап кына булмаса ярар иде бала! «Плантэжэ» кирәк, кеше буласың килсә, берүк, хәтерлә, шулай укы. Юк, газап барысын да оныттырган...

---

[1] Бер чит тел белү — тормыш өчен көрәштә бер корал (немецча).

— айнэр планта... планта...

Чигерде. Бер хәл булыр. Хәзер кызулык белән чыгып киткәндә ни булса да булыр.

— ауф айнэр плантаге ин Африкэ.

Нәкъ шул секундта класста кемдер төчкереп җибәрде һәм «плантаге» шул тавышка күмелде. Бөтен класс берьюлы сулыш алды. Дөм бәхетсез түгел икәнсең, Гыйззәтуллин!

Ләкин... ләкин, күрәчәкне күрми гүргә кереп булмый, диләр. Гыйззәтуллин бу төчкерү аркасында әле үзенең нәрсәдән котылганын белми иде. Сары сатинлы гәүдә алгарак сузылды. Озын бармак класс өстенә таба очты.

— Нох айн маль!

Класс янадан тораташ булып катты. Күрше бүлмәдәге пианинода җыр укытучысы уйный, ахрысы, нигәдер гел бер теленә басып бер үк тавышны бирә. Бу тавыш класстагы авыр тынлыкта «маль, маль, маль, маль» булып ишетелә. Язмыштан узмыш юк. Нох айн маль икән, нох айн маль, чәнчелеп китсен...

Бөтенләй сыекланган кызлар тавышы белән Гыйззәтуллин теге җөмләгә тагын кереп батты.

— Колаямбу... янбу... ямбу... Колаямбу арбайтэтэ ауф айнэр...

Кара син дуңгызны, ничек шома бара!

— Ауф айнэр плантагэ ин Африкэ.

Классны коры яшен суккандай булды. Сары күлмәкленең зәһәр тавышы яңгырады. Озын бармак Гыйззәтуллинның каш өстенә атылды.

— Плантагэмы, плантэжэмы?

Бу шулкадәр каты, шулкадәр кычкырып әйтелде ки, юк-барга ышануы белән дан тоткан Әлтафи хәтта култык асларын сыпырып алды.

Гыйззәтуллин теге коры яшен чатнаган вакытта авызын ачып калган иде, берничә секунд буена шуны яба алмыйча катып торды. Бите ап-ак булды. Ләкин сары күлмәкле нигездә мәрхәмәтле кеше. Ул Гыйззәтуллинның битенә кызыл таплар чыккач кына янадан дәште.

— Кабатла минем арттан, — диде.

Аның тавышы, һәр сүзе чырт-чырт итеп чатнап чыга иде. Физика кабинетында электр тогы ясый торган бер машина бар. Шуның аксыл тәгәрмәчен бик каты әйләндергәч, металл щеткалары чарт-чорт киләләр. Һавага әллә нинди җиңел, төссез ис тарала. Моны, имеш, озон дип атыйлар. Сары күлмәк эчендәге юка гәүдәсен, озын бармагын селкетеп сөйләгәндә, моңардан да шундый ток тарала. Чарт-чорт... Класска хәтта озон исе чыккандай була.

— Кабатла минем арттан: мин ялкау, игътибарсыз малай. Ну!

Беттек. Тагын бер чартнау... Гыйззәтуллин, питон авызына үз ихтыяры белән кереп барган гипнозланган куян шикелле, берни аңламыйча аның артыннан кабатлый.

— Мин ялкау, игътибарсыз малай.

— Минем дәрескә әзерлексез килүем — бөгөн дошманга ярдәм итүем дигән сүз.

— Минем дәрескә әзерлексез килүем дошманга... дошманның... дошманнан ярдәм итүем дигән сүз.

Гыйззәтуллинның күп яшәсә — ике-өч минутлык гомере калгандыр. Менә-менә ул бу кешенең каршында кисәк авар. Тагын әйттермәсә генә ярар иде, харап була бит малай...

— Кабатла: мин бөгөн икеле алам.

— Мин бүген икеле алам...

— Шуның белән мин Гитлер тегермәненә бер чүмеч су салам.

— Шуның белән мин... мин... Гитлер тегермәненә... чүмечләп... бер чүмеч су салам.

Ну, нык кеше икән бу Гыйззәтуллин. Тәки бөтенесен әйтеп бара бит!
— Кабатла: ләкин мин алдагы дәрескә әзерлек белән киләчәкмен. Тырышып укып мин фашизмны җиңү көнен якынайтачакмын...
Гыйззәтуллин биреште. Тавышы теткәләнде, вак-вак кисәкләргә таркалды, бер өзлексез борынынннан акты. «Якынайтачакмын» сүзен әйтеп бетерә алмыйча, кинәт кенә урталай сынып, партага ауды.
Сары күлмәкле исә безгә бүтәнчә бәйләнмәде. Бераздан йомшак кына тавыш белән болай дип сөйләп китте:
— Суда еракка йөзгән кешедә билгеле бер урында шикләнү туа. «Әә шушында батсам?» дип куркып куя ул. Менә шул ноктаны узгач, ул кеше үзенең көченә ышана башлый һәм алга таба җиңелрәк бара. Сез дә хәзер менә шул ноктада. Ләкин без моны узарбыз. Әйе, узарбыз! — Аның тавышы тагын чартлый башлады. — Партия, хөкүмәт бездән укытучы кадрлар көтә. Институт студентлары бүген кулларына корал тотып фашизмга каршы көрәшәләр. Сезнең күбегез, ихтимал, җидееллык мәктәптә чит тел укытучысы булып эшләр. Партия, хөкүмәт мине бүгенге көндә фронтка җибәрмичә, сезне укытырга куштылар. Мин үземнең сугышчан бурычымны ил алдында намус белән үтәргә тиеш. Сезнең яхшы укуыгызга ирешү — минем изге бурычым. Һәм мин моңа сезнең белән берлектә ирешәчәкмен! — Шул вакыт урта бармак безнең өскә атылды һәм тавышы чартлады.
— Һичшиксез, ирешәчәкмен!
...Дәрес бетте. Без авыр кайгы баскан кыяфәттә урыныбыздан тордык. Ул немец телен ничекләр итеп өйрәнербез? Ә бу үзенекен итми калмый инде. Моның хәтле көчәнүгә баш ничек чыдасын? Әнә ул, Гыйззәтуллин, кеше була алырмы инде?
Без, малайлар, класс бүлмәсендә калдык. Елмаерга тырыштык, булмады. Тәрәзә янына җыелышып күзләребезне еракка текәдек. Беркем бер сүз дәшмәде.
Шул вакыт класс ишегендә тагын сары күлмәкле күренде. Җиңенә кызыл бәйләгән, димәк, бүген ул дежур укытучы. Безгә карамыйча гына, яны белән басып болай диде:
— Дежур укучы форточканы ача, парта өсләрен, тактаны сөртә. Калганнар барысы да, коридорга чыгып, җырлы уенга керәләр.
«Ача, керәләр...» Бу сүзләргә җиңел холыклы Зарифуллин бик гарьләнде.
— Әллә ачмый торгандыр!
— Әллә керми торгандыр! — дип ишек ябылуга ул бик нык үртәләнде.
Кара син аны, ә, каян килгән куәт бу кешедә! «Ачыгыз» дими, «уенга чыгыгыз» дими. Юк, үзен алай ваксытмый. Хәтта безгә карамый да бит. Ачалар, керәләр, имеш.
Партадан башын күтәреп, иң беренче булып Гыйззәтуллин чыгып китте. Бичара! Мәктәптә җиде ел укып аның бер генә мәртәбә дә кызлар белән җырлы уен уйнаганы булмагандыр. Шулай, Гыйззәтуллин теге сары күлмәкле янына үз ихтыяры белән китте. Әлтафи исә бик батыр кыяфәттә гәзит кәгазеннән ясаган карталарын чыгарды. Безнең арада кечкенә генә ыгы-зыгы булып алды. Сүзне Зарифуллин башлады.
— Нәрсә бу, бигрәк тагын мыскыл итәм дигәч тә!
— Ие! Кызлар белән түгәрәк уен уйнарга, бигрәк тагы! Ничә ел колхозда эшләгән башың белән, оялмыйча!
— Һи, исегез киткән икән, уен уйнау мәҗбүри түгел. Чыкмыйм мин и вчу. Анысына билге куя алмый ул!
— Дөнья явызы ул, беләсен килсә. Белденме шуны? — Зарифуллин шул урында бүленеп калды. Чөнки ишектә сары сатин күренде.
— Зарифуллин, ни өчен уенда түгел?

Зарифуллин ялан баш тора иде, ниндидер ансыз хәрәкәт ясап башыннан бүрек эзләде. Ләкин бүрек парта астында икән.

— Абый мин...

— Юк, син сорауга җавап бир: ни өчен син уенда түгел?

Зарифуллин шулай итеп бер сүз әйтә алмады. Ул бер читкә барып басты. Эшнең бик житдилеген аңлаган Әлтафи карталарын җыеп тиз генә уенга таю юлын карады.

— Хәлимов, син кая барасың?

— Уенга барам, абый!

— Юк, тукта, урыныңда кал.

— Абый, мин уенга кермәкче идем.

— Юк, сың инде. Хәзер кермисең.

— Абый, керим инде, ә?

— Әйтеп торам: хәзер сың инде.

Әлтафи баскан урынында катып калды. Ни өчен соң? Нәрсәгә соң? Ну, бу укытучыларның сөйләшүе! Каныц катарлык итеп сөйләшәләр бит! Һәм, гомумән, нигә «соң» дип әйтми, ә «сың» дип сөйли? Үзәккә үтәрлек булсын дипме?

Кара такта буена барыбыз да тезелеп бастык. Әле ике минут элек кенә барыбыз да геройлар идек. Ә хәзер уенга керергә ялынабыз — кертмиләр. Безнең мангайлар каршында озын бармак уйный:

— Сез сугыш вакытында теләсә нинди тәртипсезлекләр эшләп өйрәнгәнсез. Бөген аңа нокта куябыз. Мин сезнең, болай булсагыз, каныгызга тоз салырмын! Сез — булачак педагоглар! Сезгә балалар белән уен оештырырга кирәк булачак. Ә сез тәрәзә янына җыелып карта сугасыз! Сезнең каныгызга тоз салырмын мин! Ә хәзер Хәлимов карталарын күтәреп минем янга керә...

...Ул көнне төн бик мажаралы булды. Гыйззәтуллин төнене ике тапкыр кычкырып уянды. Әллә нәрсәләр әйтеп саташты. Зарифуллин төшләнеп көлде. Мин, йокыга китә алмыйча, юка, иске одеялга төренеп, күзләремне йомып яттым. Тәрәзә артында буран сызгыра, өй нигезенә терәлеп үскән тигәнәкме, нәрсә, буран белән селкенеп стенаны кытырдата. Караңгы һәм куркыныч! Йокламаган көе саташам. Имеш, ишек янындагы йомры мич бөтенләй мич түгел икән, аның төсе дә ак түгел, өстендә сары сатин күлмәк икән. Әнә ул мичтән озын бармак үсеп чыга, ул бармак күз арасына таба сузыла һәм мичтән тавыш чыга:

— Тоз салырмын!

— Тоз салырмын! — ди.

...Шулай газаплы төн узды. Иртәгесен һәркем күргән төшен сөйләде. Гыйззәтуллин төшендә Гитлерны күргән икән. Бик зур тегермән буасы, ди. Шунда тегермән арыгына атланып Гитлер утыра икән. Кулында сигездән үргән камчы, ди. Гыйззәтуллин буа астындагы ниндидер бер чокырдан үрмәли-үрмәли чүмеч белән су ташый икән. Чүмечен шул арыкка бушатуга, Гитлер теге камчы белән чыжылдатып аның аркасына суга һәм:

— Нох айн маль! Нох айн маль! — дип тагын теге чокырга төртеп төшерә икән...

Зарифуллин кичтән юк кына бер әйбер аркасында Әлтафи белән бәргәләшеп алган иде. Төшенә дә Әлтафи кергән. Имеш, Әлтафиның беләгеннен кемдер пәке белән ярган, ди. Шул ярага немец теле укытучысы бик пөхтәләп, әкренләп кенә вак тоз сибә, ди. Әлтафи күзләрен йомып, тешләрен кысып газаплана, ди...

...Немец теленең алдагы дәресендә өч малай бишле алдылар. Болар Зарифуллин, Пермяков һәм Гыйззәтуллин иде.

Сары күлмәкле дә безгә ошый башлады. Хәер, кышка таба ул, сары күлмәген салып, свитер киеп йөри иде инде...

— До — ре — ми — фа — соль — ля — си — до...

До — ре — ми — фа — соль — ля — си — до...

Укытучы хатын күгәргән бармаклары белән пианино клавишаларына баса да шулай җырлый. Класста борын тунарлык салкын. Тышта бүген дә рәхимсез буран. Аякларда чабата. Өзелеп-өзелеп ашыйсы килә. Һәркем сәгать икене көтә. Сәгать икедә ашханәдә бирәр савыт өшегән кәбестә шулпасы бирелә. Аның өстендә тәңкәләр йөзеп йөри. Ашханә мөдире әйтә, һәр бала башына биш грамм көнбагыш мае салына, ди. Күз алдында әнә шулар. Ләкин күгәргән бармаклы апа шыгырдап каткан ботинкалары белән пианиноның педальләренә басқан да балаларны җырлата:

— До — си — ля — соль — фа — ми — ре — до...

До — ре — ми — фа — соль — ля — си — до...

Әле ике ай элек кенә бәрәңге басуларыннан, урмандагы питомник эшләреннән, ындыр табакларыннан аерылып килгән чабаталы малайлар, тула оеклы кызлар, «до» белән «ре»нең тыштагы буранга ни катышы барлыгын аңлый алмыйча, гаҗәпләнеп тавыш бирәләр:

— До — ре — ми...

Педагогия училищесына быел бик күп балалар алдылар. Дөрес, кайберләре ипи карточкасына кызыгып килде. Дүртенче елын барган сугыш һәркемне тамак мәсьәләсенә аек карарга өйрәтте. Әнә шуна күрә пианино янында утырган бу күгәргән иренле чандыр латыш хатыныннан берәү дә көлми. Ул бер латыш коммунистының хатыны, аның иреннән дүрт ел инде хат килми. Кырык беренче елда бу хатын эвакуация белән монда кайткан һәм юка пальто, юка кара ботинка белән инде дүртенче кышын уздыра...

Ә программа бер нәрсә белән дә исәпләшми...

Бүген җыр дәресе ике сәгать.

Тәнәфестә кул сугыш уйнап бераз җылындылар. Кызлар, җылы эзләп, агартылмаган мичкә аркалары белән сырыштылар. Звонок булды. Салкыннан күгәреп туңган укытучы тагын пианино клавишаларына басты.

— Программа буенча без сезнең белән бүген «Ой, ты, зимушка-зима» дигән җырны өйрәнергә тиешбез, — диде ул.

Ә тышта рәхимсез буран улый. Ашханә ачылырга нәкъ бер сәгать бар иде. Салкын класста төрле партада төрлечә сыек тавышлар — «до» лар, «ре»ләр, «ми»ләр кутәрелеп, бер гомуми хор тәшкил иттеләр.

Ах, ты, зимушка-зима,  
Белоснежная пришла...  
Эй, эй, ай да-люли,  
Белоснежная пришла.

Бу җыр күнелләрне тагы да өшетте. Юк, моны элекке заманда толып яки чикмән киеп чана башына утырган, почта станциясендә кайнар борщ ашап чыккан кызыл битле кучер җырлагандыр... Яки тук карынлы, каны уйнап торган яшь гусар кибитка эчендә барганда дәртләнеп җырлагандыр... Ах, бу рәхимсез программаны. Бер дә генә дә бу салкын класста моны җырласы килми бит... Моны җырлагач, тыштагы буран тагы да котырыбрак китә кебек. Ләкин җырларга кирәк шул.

Белоснежная пришла  
Все дорожки замела.  
Эй, эй, ай да-люли,  
Все дорожки замела.

Ашханәдәге тетя Поля инде озын саплы чүмече белән кәбестә шулпасын бушатадыр. Ашханә түшәменнән инде тамчы тамадыр. Өстендә балык күзедәй өч-дүрт май тәңкәсе йөзгән шулпа никадәр тәмле...

Все дорожки да и пути
И не стать и не пройти...
Эй, эй, ай да-люли,
И не стать и не пройти...

— Башлангыч классларның программасында менә бу жыр бар, — ди укытучы хатын ботинкаларын педальдән алып. — Ягез әле, тагын бер тапкыр кабатлыйк...

— Ах, ты, зимушка-зима...

Бәлки, туңган аякларын, күшеккән кулларын, ачлыкны онытып, ул да бу жырны болай гына, программада булганга гына жырлап утырадыр. Бәлки, күңеле белән ул үзенең туган жире Латвиянең сагыз исе килеп торган нарат урманы эчендә йөридер. Хыялы белән, бәлки, ул юка ботинка эчендә каткан аякларын Балтик диңгезе буендагы сары, жылы, эре комда бастырып торадыр. Ярмалы карны шәфкатьсез рәвештә биткә бәрә торган тыштагы буран, бәлки, аңа июль аендагы диңгезнең ак дулкыннар валын салмак кына Рига пляжына тәгәрәтүен хәтерләтәдер. Бәлки, чыннан да шулайдыр... Ә программа менә дәрес ахырында кабатларга, материалны ныгытырга куша.

— До-ре-ми-фа-соль-ля-си-до...

До-ре-ми-фа-соль-ля-си-до...

## Гренландиядә тәмәке үсә

Бүген безнең класста яңалык: дүрт дәрестән соң, укуны бөтенләй ташлап, Гыйззәтуллин качты.

Барысы да юктан гына булды. Рус теле укытучысы аннан:

— Что было задано на дом? — дип сорады. Бу — бик гади сорау иде, ләкин Гыйззәтуллин коелып төште. Борынын тарта-тарта ул бер жөмлә эчендә чыккысыз булып буталды.

— Назание да ном... Надано за дом... Занадо за ном... — дип озак газапланды, тирләде... Укытучы аны такта янына чыгарды да тикшерү өчен бер жөмлә яздырды. Гыйззәтуллин тактага:

«Карим опоздал на урок», дип язып куйды. Эш бик жиңел — иянең астына бер сызык, хәбәрнекенә ике сызык сызасы да, шуны русча сөйләп бирәсе иде. Гыйззәтуллин, әлбәттә, боларны эшли ала иде, ул иянне дә, хәбәрне дә тапты. Ләкин укыганда «урок» сүзендәге басымны беренче ижеккә күчереп харап булды.

Укытучы моңа бик зур игътибар бирде. Сүзне башта ижекләп, аннан бөтене белән әйттерде. Әйбәт чыга. Ләкин шуны жөмләсе белән укыганда басым яңадан беренче ижеккә күчеп утыра. Менә бәла!

Мәскәү татарының куллары калтырый, тавышы үзгәләнә. Инде без булып, безнең дә Гыйззәтуллинны кыйныйсыбыз килә. Укытучы урынында булсак, билләһи, инде өзеп ташлаган булыр идек. Ләкин ул алай итми.

— Шушы сүзне дөрес укымыйча торып алга таба бара алмыйбыз, — ди ул. Гыйззәтуллин инде күзләрен өметсезлек белән бушлыкка төрәгән, булмастаена тәмам ышанган. Аның күзләре жансыз, пыяла...

— Син өметеңне жуйма, Гыйззәтуллин, — ди аңа укытучы — әгәр училищены тәмамлаганчы минем кулда укысаң, син барыбер русчаны бик әйбәт беләчәксең. Мин моңа ирешәчәкмен. Минем изге бурычым ул, аңладыңмы?

Кыңгырау чылтырап Гыйззәтуллинны бу тораташ хәленнән коткарды. Ләкин шул көнне үк аның училищедан качуына ачуыбыз килде. Ни өчен ачуыбыз килде? Моны без ул вакытта аңламадык. Күп еллар үткәч кенә бер нәрсә аңлашылды: шул көннән башлап без Мәскәү татарын инде ярата башлаганбыз икән... Бәлки Гыйззәтуллинның училищедан качуына рус теле дәресе төп сәбәп тә булмагандыр?

Кем белә? Бу көн аның өчен, гомумән, уңышсыз булды. Иртән, дәрес башланганчы, ул Әлтафи белән бәргәләшеп алды. Әлтафи егерме сигезенче елгы, аның, әлбәттә, сугыш башланганчы ук мускуллар ныгып калган. Гыйззәтуллин аңа көч җитмәсен сизгәч, бер читкә таю ягын карады һәм укытучы кергәнче гел бер сүзне кабатлады.

— Мөрәлеләр белән тапма да, өләшмә дә...

— Мөрәлеләр белән бәйләнсәң, башың судтан чыкмас...

— Мөрәледә кеше төсле кеше бармени соң анда...

Икенче дәрес — география укыту методикасы дәресе иде — анда да Гыйззәтуллиннан сорадылар. Методика җиңел фән, телгә бай булсаң, анда бирешмәскә була, шулай да сугышып алуның хикмәте булдымы, Гыйззәтуллин беткәнче ялгыш сөйләде: ярымшарлар картасын ул җидесигез мәртәбә шарымъярлар картасы дип атады...

Аннан зоология... Иртә уңмаган кич уңмас, кич уңмаган һич уңмас, диләр. Зоология дәресендә Баязитовага ярдәм итәр өчен генә бастырылган Гыйззәтуллин бөтенләй кешелектән чыкты. Ул «елга хламидоманадасы» дигән сүзне һич кенә дә ерып чыга алмады. Күпмедер газаплангач «елга Хәмидулла анасы» дигән бер җөмлә чыкты — ләкин ул Гыйззәтуллинның көлкегә калуына гына сәбәп булды. Аннан ул беткәнче «хаф сава» дип сөйләде. Монысына укытучы да көлми булдыра алмады.

Шулай Гыйззәтуллинның арадан китүе күңелләргә шом салды. Ул бер трагик геройга әйләнде. Ул көнне барыбызның да кәеф начар булды, бары тик соңгы дәрес — география дәресе генә күңелле узды.

... Училищеда география фәненә сабыйларча гашыйк ирле-хатынлы географлар бар иде. Алар өчен дөньяда географиядән башка берни дә юк. Шуңа күрә бөтен училище география белән җенләнгән. «Яшь сәяхәтче» түгәрәге дисеңме, «Синоптик» җәмгыяте дисеңме — барысы да бар. Безнең класска географиядән ире керә иде. Ул сөйләгәндә бөтен дөньяны онытасың: ул сине Африка чүлләрендә эсселәтә, Патагониядән Утлы җир утрауларына алып чыга, Һиндстан джунглиларында адаштыра. Ул сөйләгәндә дәреснең үткәнен сизми дә каласың. Бөтен класска бер генә дәреслек бар. Шуңа күрә теге-бу илнең халкы, экономикасы турындагы мәгълүматларны хәтердән сөйләү бик авыр. Ләкин географ безгә икелене куймый диярлек. Менә ичмасам ул кеше!

Сугыш елларының кырыс тормышы географларның семьясын мәктәптән-мәктәпкә сөреп йөрткән, боларның бала-чага да, кием-салым да юк, үзләре белән бер-ике бәйләм китаплары гына бар. Алар элеккеге леспромхоз йортының бер бүлмәсен алып торалар иде — без аларга берничә мәртәбә утын илттек. Өйләрендә — шыр ялангачлык. Шкаф өстендә бер глобус, ялангач стенада ярымшарлар картасы. Морҗа агартылмаган, тәрәзәләрдә пәрдә юк, савыт-саба күренми. Коры өстәлнең уртасында аш тәлинкәсе тора, аның эче тулы тәмәке төпчеге: ире дә, хатыны да өзлексез тәмәке тарталар. Иренең яңак сөякләре калкып тора, үзенең авызы тулы көмеш теш. Сугышка кадәр чибәр, шәп егет булгандыр. Аның ашказанының яртысы юк дип сөйлиләр иде. Кайчандыр яхшы булып исәпләнгән каракүл пальтосының якасы инде такырайган, кесә тирәләре beләүләнеп ялтыраган. Аның сул кесәсендә һәрвакыт янчык белән тәмәке һәм кәгазь булыр. Дәрес тәмамлануга, ул

бер кулына журнал тота, икенче кулы белән кесәсеннән янчыкны суы-рып ала да кызу-кызу чыгып китә. Мөмкин булса, ул дәрес вакытында да берне төреп тартыр иде. Бу кешенең тәмәкегә мәхәббәте шулкадәр зур иде — теләсә кайсы илнең экономикасын сөйләгән вакытта һәрвакыт ул илдә «хуш исле тәмәке үстерелә» дип әйтмичә булдыра алмый иде. Көмеш тешләре бик күп булганлыктанмы, «с» «ш» авазларын ул «ч» авазына әйләндереп сөйли һәм хуш исле тәмәке урынына «хуч ичле тәмәке» килеп чыга иде. Тәмәкене телгә алганда бу кеше автомат рәвештә кесәсенә кулын тыга, кайвакытта янчыгын да сөйрәп чыгара. Янчыгына нииндидер кызганулы караш ташлый, аны кире тыкканда авызына су җыелып тагы да сакаулана, кайвакытта бөтенләй ялгыш сөйләп куя. Без аның бу гадәтләрен инде өйрәнеп беткән идек...

— Ужган дәречтә беж Гренландия турында укыдык, — дип сүз башлады ул, янчыклы кесәсенә кулын тыккан килеш. — Кем җавап бирергә тели?

Тагын шул ук исемлектән бармак белән кеше эзләү, тагын газаплар... Класс өстенә төшкән авырлыкны бу дәрестә Әлтафи күтәрде. Дөресрәге, укытучының бармагы аның фамилиясенә тукталды. Әлтафи «дык-дык» басып (ул зур-зур эш ботинкалары киеп йөри иде) кыю рәвештә карта янына барып басты, күрсәткеч таягын алып аны Канадага төртте дә сөйли үк башлады.

— Гренландия бик зур җир кисәге, — дип алып китте ул, — андый зур җир кисәге бик сирәк очрый. Анда бик суык, анда аюлар, жирафлар, кыр кәҗәләре һәм моржлар яши...

— Чин нәрчә, — дип бүлдерде аны укытучы, — әллә күжең чыккан-мы? Гренландиямени ул?

Күрсәткеч таягы белән Атлантик океанда шактый йөзгәч, Әлтафи Гренландияне тапты.

— Гренландиянең каҗылма байлыкларын әйт, — диде укытучы янчыклы кесәдә кулын уйнатып.

Әлтафи өчен бу — ике тиен бер акча.

— Гренландия казылма байлыкларга бик бай. Ул яктан Гренландия бик зур әһәмияткә ия булып тора. Казылма байлыклар анда җирнең астында да, өстендә дә бик күп...

Әлтафиның озын сүзен тыңларга сабырлыгы җитмәгән географ аны тагын бүлдерде.

— Мәчәләгә конкретрак кил, Хәлимов!

Гренландиядән чыгып тагын адашмас өчен, күрсәткеч таягын Әлтафи картага бик нык терәп тоткан иде һәм ул мәсьәләгә конкрет килде.

— Гренландия казылма байлыклардан түбәндәге байлыкларга бай: тимер, күмер, корыч, чуен, бакыр, көмеш, алтын, җиз, торф...

— Тагын, — диде географ, яңагына тотынып. Аның теше сызлый иде бугай.

— Тагын... тагын... алтын, җиз, торф... Тагын... Гренландиядә хуш исле тәмәке үстерелә...

Шул сүз генә чыккан иде, географ каешланган янчыкны сул кесәсеннән өстерәп тә чыгарды... Без көлешеп җибәрдек. Географ, алдан-ганын сизеп, авыз суларын җыя-җыя янчыкны кире тыкты һәм журнал янына килде. Аның бу вакытта йөзе бик нык чытылган иде.

— Утыр, Хәлимов, — диде ул, еламсыраган тавыш белән, — бер дә ачтраумно булмады бу. Икелек чиңа...

Гыйззәтуллинны югалту кайгысы география дәресеннән соң онытылып китте. Бөтен класс Гренландиядә «хуш исле тәмәке» үстергән Әлтафины мыскыл итте.

## Дунай елгасында Ярославна елый...

Тышта чатнама суык.

Ноябрьның рәхимсез кырыс җилләре үзәккә үтеп исәләр. Юл каткагына чабаталарны чыдатыр хәл юк. Училищеның озын коридорында җылы. Иртән дәрескә кадәр, тәрәзә янына җыелып, тәүлек эчендә җир шарында булган хәбәрләрне эшкәртәбез. Сугыш, имеш, яңа елга бетәчәк, ди. Сугыш беткәч, безне дә моннан, урман буеннан, Ташлытауга кайтарачаклар, ди. Зарифуллинның әнисе хезмәт көненә пот ярым борчак алган. Әлтафилар авылында бер хатынның сугышта югалган ире төнлә белән кайтып кергән, хатынына мунча ягарга кушкан. Ире мунча ләүкәсенә менеп утыргач, теге хатын күз салса — тегенең маңгаенда сыңар зур күз икән. Хатын авызына килгән беренче сүз — бисмилласын әйтеп, ялан тән мунчадан чыгып йөгергән. Теге бер күзле нәрсә:

— Ну, бәхетең бар икән, тураклап кисмәккә тутырадыр идем,—дип гырылдап калган, ди...

Шундый салкын көннәрнең берсендә училищеда укулар булмады. Рус теле укытучысының хатыны үлгән дип хәбәр иттеләр. Ул инде шимбә көн үк үлгән икән, без моны дүшәмбедә генә, авылларыбыздан җыелган көнне генә белдек.

... Нина Яковлевна кечкенә генә гәүдәле бер хатын иде. Сары коңгырт төлке якалы пальтосына борынын яшереп бер кочак дәфтәр күтәреп иртән училищега йөгереп килә иде. Ире белән һәрвакыт бер-беренә «сез» дип дәшәләр иде. Моңа барыбыздан да бигрәк Әлтафи гаҗәпләнә иде. Без бер генә мәртәбә дә аның, ире янына килеп, дөнья хәле турында сөйләшкәнен ишетмәдек. Әйтерсең, ул ире белән түгел, бары тик укыту бүлеге мөдире белән генә сөйләшә иде.

— Сез миңа икенче курсларны дәрестән соң ун минутка алып калырга рөхсәт итә алмассызмы, Хәлил Фәтхиевич?

— Сезгә мөрәҗәгать итәргә мөмкинме, Хәлил Фәтхиевич?

Училищеда алар әнә шулай сөйләшәләр иде.

... Менә без үз гомеребездә беренче мәртәбә күмү процессында катнашабыз. Лесничествоның үзендә зират юк, гадәт буенча, христианнарны күрше рус авылына илтеп күмәсе икән. Салкын җилгә каршы гроб бара. Гробны укытучылар күтәргән. Шуларның берсе — Хәлил абый. Ул шул ук ялтыравыклы ботинкадан, тик аның өстеннән галошлар гына киеп куйган, каракүл якалы пальтодан, өлгеләп тегелгән, түбәсе төймәле соры кепкадан. Башын түбән игән, бер сүзсез атлый да атлый...

Зираттан кайтканда да ул шулай дәшмичә түбән карап кайтты. Аларның балалары юк идеме, әллә таралып беткәннәрме — карт ялгыз калды. Тулай торакка кайткач, картның язмышы турында малайлар арасында бәхәс купты. Зарифуллин иртәгә дә, берсе көнгә рус әдәбияты дәресе булмас дигән фикерне куәтләде. Алдагы дәрескә «Игорь полкы турындагы сүз»дән «Плач Ярославны» дигән бүлекне ятлап киләргә кушылган иде. Болай булгач, синең Ярославнаң кайгысы калдымыни кешедә? Әлтафи рус теле укытучысына хәсрәтен оныту өчен бик каты аракы эчәргә кирәк, дип фәлсәфә сатты. Имеш, шунсыз кеше булып булмый икән.

Нәкъ шул көнне училищега Гыйззәтуллин әйләнеп кайтты. Ул бик ябыккан, күзләре шешенгән, муеннарын йон баскан, битендә кан заты калмаган. Капчыгы да буп-буш. Өзек-тәтек аңлатуына караганда, ул әнисе янына кайтырга шүрләгән дә, Пошалым башы дигән авылда үзләренең чыбык очы кешеләрендә бер атна яшәгән. Ләкин ашау ягы бик такы-токы булганлыктан, анда озак яту мөмкин булмаган. Аның инде кичә иртәдән бирле бер бөртек ризык капканы юк икән. Ашханәдә аш пешкәнче әле ике сәгать вакыт бар иде... «Тамак ачканда файдасы бик зур», дип Әлтафи аңа тәмәке суырттырды. Гыйззәтуллин бер-ике суы-

рып тончыкты да, мич буена барып, үрсәләнеп коса башлады. Аннан, иреннәре күгәргән хәлдә, матрасы алынган такта караватына килеп ауды.

Без юраганнар иртәгесен үк күккә очтылар. Кыңгырау чылтырауга, класс ишегеннән күзлек пыялалары күренде. Без, инде рус әдәбияты дәресе барыбер булмый, дип, бүрекләр кигән килеш, Гыйззәтуллиннан бер атна эчендә ниләр күргәнен сөйләтә идек. Тәрәзә пыялалары зыңгылдап куйды:

— Шапки снять!

Бер секунд эчендә дөнья үз урынына урнашты. Әйтерсең лә, рус теле укытучысының хатыны үлмәгән, әйтерсең лә, класска Гыйззәтуллин әйләнеп кайтмаган...

— Мин башта сезгә үзем укып күрсәтәм, ребятки, — диде укытучы, — аннан сезнең ничек ятлаганыгызны тыңлармын.

Укытучы күзлек аша классның артына карый. Китап тоткан кулы бераз гына дерелди. Тавышы көчле, тигез. Менә ул сугыш хәбәрләрен бирүче Мәскәү дикторының тавышы белән укып китте...

«На Дунае слышится голос Ярославны: одинокой кукушкой рано утром кукует... «Полечу кукушкою по Дунаю, омочу бобровый рукав в реке Каяле, утру князю кровавые его раны на могучем его теле!»

Күнелләр тагын еракларга киттеләр. Ноябрь салкыны да, бер күзле женнәр дә, гроблар да онытылды. Күз алдында тик бер генә нәрсә калды: дулкыннарын бәреп утырган Дунай елгасына кояшның иртәнге нурлары баткан. Яр буенда йөзем куаклары. Әнә кап-кара шәлъяулыгы өстеннән кыйммәтле мех белән эшләнгән бүреген кигән хатын — Ярославна, күзләрен еракка текәгән дә, иренең исән-сау кайтуын теләп аллаларга дәшә...

Борынын тарта-тарта Зарифуллин сөйли:

«О ветер, ветрило! Зачем ты так сильно веешь, зачем ты мечешь ханские стрелы на своих легких крыльях на воинов моего мужа? Разве мало тебе веять вверху под облаками, лелея корабли на синем море?»

Күзләрен чылт-чылт йомып, түшәмгә карый-карый Әлтафи сөйли: «Светлое и пресветлое солнце! Всем ты тепло и пригоже. Зачем, господин мой, простер свои лучи на воинов лады, в поле безводном жаждою согнул им луки, тоскою замкнул колчаны?»

Бу дәрес, ничектер, безгә инде газап түгел, ә күңелле, рәхәт бер эшкә әйләнеп бара. Зәңгәрсу күмер исе таралган класс бүлмәсендә Мәскәү татарының көчле бәрхет тавышы яңгырап-яңгырап китә, бөтен күзләр аңа текәлгәннәр, ә ул классны гипнозлый бара...

## Онегин су алырга чират тора

Ялтыравыклы ак чынаяк таш белән тышланган мич. Өске ягында бизәкле ташлар. Җиз капкачлы куышлар. Мичтә, шарт-шорт килеп, ак чыршы яна. Тәрәзәләр зәп-зәңгәр булып катканнар, төнге буран, үзенә бер корбан сорагандай, түбәне чытырдата. Элекке заманда бу йорт зур алпавытның дачасы булган. Шәһәрләшкән алпавыт җәйләрен шушы мәһабәт агач йортта, сирень бакчасы эчендә яшәгән. Нибары егерме биш ел элек әле шулай булган. Әлбәттә, алар үзләренең нәзек бармаклы, ак чырайлы курсистка кызлары белән бу йортта гәпләшеп чәй эчкәннәрдер, асраулар, подносларга салып, аларга ширбәт ташыганнардыр...

Ә бүген бу бүлмәдә мич каршында без утырабыз. Мәскәү татары мич янтыгында тез башына минем сочинениене куйган да тикшереп утыра. Хата турында сүз озын булмый. «Ничек кирәк иде?» — дип кенә сорый да, дөресен әйткәч, төзәтеп куя. — Ә менә дөрес язылган

Урыннардан барысы бик авыр. Ни өчен болай яздың? Нинди кагыйдәгә нигезләп? Ә ни өчен алай түгел? Шулай сорый да күзлек өстеннән карап куя. — «Так, так, так...»

Шуннан ул торып өстәленә бара. Анда аның төреп куйган тәмәкесе була. Шуны алып килә дә мундштугына киертә, мичтән кыскыч белән күмер ала, тәмәкесенә ут кабыза. Тирән итеп бер суыра да, күзлек өстеннән карап:

— Давай, закурим, — ди. Мин каушап китәм, борын йомшый. Бер сүз дә дәшмим. Ә ул тәмләп бер суыра да болай ди:

— Мин сиңа болай, шаярып кына әйтәм, кызык өчен генә. Син тартма әле аны. Менә актык курскача миндә русча укысаң — югалмассың. Сине тормышта зур эшләр көтә. Бер вакыт син зур, хөрмәтле кеше булырсың да, минем янга, миңа рәхмәт әйтергә килерсен. Шул вакытта син миңа: «Давай, закурим», — диярсең. Миңа бик яхшы сортлы папирос тәкъдим итәрсең. Ул вакытта сугыш беткән булыр, мин дә Мәскәүдә булырмын...

— Ә беләсеңме, «мундштук» каян алынган? «Мунд» — немец сүзе, авыз дигән сүз. «Штук» — әйбер дигән сүз. Авызга каба торган әйбер. Галстук та шулай бит. Немецча муен яулыгы дигән сүз.

— Ә син татарның классик әдәбиятын беләсеңме? Русча әлегә берни дә укымаганыңны беләм. Ләкин син бик күп нәрсә белерсең. Карл Бишенче: испан теле алла белән, француз теле дуслар белән, немец теле дошман белән, итальян теле хатын-кыз белән сөйләшү өчен уңайлы дип әйтә торган булган. Ләкин мәшһүр Ломоносов болай дип өстәгән: әгәр дә император җәнапләре рус теле белән дә таныш булса, ул телдә боларның һәркайсы белән дә сөйләшү мөмкинлеген күргән булыр иде. Ә татар телендә роман язучылардан кемнәрне беләсең? Шәриф Камалны гынамы? Башка кешене ишеткәнең юкмы? Башка зур язучыларыгыз булмаганмы? «Казакъ кызы» дигән әсәрне ишеткәнең бармы?

Ул мичкә утын өсти. Минем тез башларым жылына, чабатадан парлы юкә исе күтәрелә. Укытучы пиджагын сала, жилеткадан гына кала, ләкин галстугын салмый. Ул шкафыннан кара күн тышлы, алтын хәрефләр белән язылган китап күтәреп килә.

— Менә бу 1898 елгы басма, — ди ул, бик саклык белән генә китапны ачып. — Икенче курста без моны узарбыз. Бу, брат, бөтен китапларга китап. «Евгений Онегин»... Моны яратмаган кеше рус телен белә алмый. Бу әсәр бөтен рус теленең амбары. Татьяна нинди гүзәл кыз, ә?

«Не спится, няня, здесь так душно...»

Ул, күзлеген сала-кия, күңелдән укып китте.

— Ничек диләр, Евгений Онегин — артык кеше, дип укыталармы? Юк, алай гына түгел шул. Монда бөтен бер заманның фәлсәфәсе, теле, сулышы. Әгәр син шушы әсәрне ярата алсаң — рус әдәбиятын үзләштерә алырсың... — һәм ул Онегин турында укып китте.

Тышта буран һаман улый. Сугыш кырында да шундый зәһәр буран булса, анда бу төнне күпме кеше катып үләр...

...Карт укытучы жылы өеннән мине соң гына озатты. Мин киез итек, чабата исе килеп торган тулай торакка кайтып йокыга яттым. Зарифуллин тешен шыгырдата, Гыйззәтуллин авызын чап-чоп китереп төшләнеп нәрсәдер ашый иде.

Минем төшемә төнлә Евгений Онегин керде. Ул кап-кара ялтыравыклы цилиндрдан, ак перчаткалардан һәм бер саплы күзлектән иде. Имеш, иртәнге якта ашханәдә кайнар су алырга аның белән бергә чират торабыз, икебезнең дә кулда немец солдатының котелоклары, Онегинның да аягында чабата.

...Ул кышны, сочинение язган саен, һәрберебез укытучының мич каршында әдәбияттан өстәмә дәрес алып кайттык.

# Моны Фадеев кына шулай яза ала

Сугыш бетте, сугыш бетте...

Без инде сугыштан соңгы тыныч елда укыйбыз. Инде коммерческий бәя белән әллә ничә тапкыр ипи сатып алдык. Рус теле укытучысы инде өр-яңа яшькелт материалдан китель тектерде. Җилкәләре киң кешегә никадәр килешә икән ул китель! Нәкъ маршал инде. Аның тавышы тагы да көрәйде. Без инде Гогольне, Пушкинны, Лермонтовны, Толстойны, Некрасовны өйрәндек. Безнең миләрдә хәзер сырларның исәбе-хисабы юк. Хәзер төнлә йоклар алдыннан Зарифуллин белән Әлтафи Лермонтовның романтизмы турында бәхәс алып баралар. Гыйззәтуллин инде йоклаганда Некрасов белән саташа. Ул «Кому на Руси жить хорошо» әсәре буенча бишле алды... Әлтафи хәзер рус теле укытучысы белән коридорда авыл хәлләре турында сөйләшеп тора һәм саф рус телендә сөйләргә тырыша. Мәскәү татары елмая, дәресләрдә безгә хәзер катлаулы сораулар бирә...

Без инде училищеның Ташлытаудагы элеккеге йортын карап кайттык. Яз көне иде. Училищеның мәһабәт бинасы янында кояшка чыгып баскан ак чырайлы, күзлекле, озын торыклы кешеләр барысы да газета укыйлар. Боларны Сталинград сугышында әсирлеккә төшкән фашистлар диләр иде. Барысы да бер төсле озын ботлылар. Безгә күтәрелеп карамадылар, укыйлар да укыйлар. Тере фашистларны күрү безгә бик нык тәэсир итте. Иөрәкләр кызу-кызу типте, тамаклар чатнады. Берebез дә бер авыз сүз сөйләшмәдек. Ә тегеләр берни булмагандай, укыйлар да укыйлар. Без үзебезне дүрт ел буенча ачлыкта, салкында тилмертүчеләрне күрдек. Ул көнне кич гомуми торакта сүз шулар турында гына булды. Алар нәрсә уйлап яшиләр икән? Безнең җиргә корал күтәреп килгәннәренә үкенәләрме икән? Бәлки, аларның барысы да гаепле дә түгелдер? Нигә алар безгә күтәрелеп карамадылар икән?

...Ә берничә айдан без үзебезнең төп йортка әйләнеп кайттык. Ташлытау станциясеннән әсирләрне төягән соңгы эшелон чыгып китте. Аларны Германиягә, өйләренә озаттылар дип сөйләделәр. Әсирләр яшәгән киң якты бүлмәләрдә бер атнадан соң дәресләр башланды...

Ул көннәрдә без Фадеев иҗатын өйрәнә идек. Рус теле укытучысы акрынлап безне Левинсон, Бакланов, Метелицага гашыйк итте. Ничек иреште ул моңа, беребез дә сизми калдык. Безнең өчен ул көннәрдә дөньяда Левинсон отряды гына бар иде. Левинсон отрядының тар-мар китерелүе безнең йөрәкләрне тетрәтте, хәзер инде укытучы да «теге урынын укыгыз, моны укыгыз» дип әйтми, ул безнең хисләргә юнәлеш кенә биреп тора. Ул безнең кебек күп инструментлы оркестр белән оста дирижердай җитәкчелек итә, безгә сөйләтә, сораулар бирә. Күп вакыт, түзә алмыйча:

— Туктагыз, ребятки, бу урынын үзем укымыйча булдыра алмыйм, — ди. — Минә тыңлап торыгыз. Рус теле никадәр бай, никадәр сыгылмалы ул.

Һәм ул безне Ерак Көнчыгыш урманнарында йөртеп әллә нинди уйсулыкларга алып чыга. Дулкынланудан аның тавышы калтырый, калын тавыш яңгырап-яңгырап өзелгәләп ала...

«Лес распахнулся перед ними совсем неожиданно — простором высокого голубого неба и ярко-рыжего поля, облитого солнцем и скошенного, стлавшегося на две стороны, куда хватал глаз. На той стороне, у вербняка, сквозь который синела полноводная речица, — красуясь золотистыми шапками жирных стогов и скирд, виднелся ток. Там шла своя веселая, звучная хлопотливая жизнь. Как маленькие пестрые букашки, копошились люди, летали снопы, сухо и четко стучала

машина, из куржавого облака блесткой половы и пыли вырывались возбужденные голоса, сыпался мелкий бисер тонкого девичьего хохота».

Укытучы бу җөмләне чигереп тагын бер кат укый.

— Игътибар итегез, Фадеев кына шулай яза ала, — ди.

Ул үзе кулына китап тоткан, ләкин без инде сизеп торабыз: ул бу өзекне күңелдән укый. Аның безнең алда артист буласы килми, ә китап тотуы бары тик үзенең хисләрен, тавышын йөгәнләп тору өчен генә кирәк. Без сизеп торабыз, ул безгә инде бик күп әсәрләрне, соклана-соклана: «Моны Пушкин гына яза ала, моны Толстой гына шулай әйтә ала», — дип укыды. Бу өзекне дә ул, һичшиксез, безгә ятларга бирәчәк, икенче дәрестә күзлеген кулында әйләндерә-әйләндерә безне тыңлаячак, яхшы сөйләүчеләр булса, рәхәтләнүеннән: «Во! Во! Во!» — дип торачак, әгәр берәрсе бер сүзнең басымын гына күчереп куйса да, битен җыерып, аны туктатачак һәм: «Тәмен бетердең», — диячәк. Ә хәзергә әле ул Фадеевка соклана-соклана үзе укый...

«За рекой, подпирая небо, врастая отрогами в желтокудрые забоки, синели хребты, и через их острые гребки лилась в долину прозрачная пена белорозовых облаков, соленых от моря, пузырьчатых и кипучих, как парное молоко».

— «Как парное молоко» — күрәсезме, ничек? Моны Фадеев кына яза ала!

...Тәрәзәдән түбәнгә күз ташласаң — Ташлытау болыны җәелеп ята, ак төтеннәр бөркеп Казан ягыннан поезд килә. Бу дәрес бетүгә, Әлтафи әнә шунда — станциягә йөгерәчәк, төшке ашка биргән треска кисәген ул Мәскәү — Свердловск поезды пассажирларына ун сумга сатачак, шуңа күрә сирәк-мирәк кенә ул станция ягына карап ала. Яз килә, җир, үзенең ярлылыгына оялгандай, ач тамакларга өмет биреп яшелгә төренә, күңелләргә җылылык өсти. Тукта, кемгә авыррак булды икән? Левинсонгамы, безгәме? Левинсонның идеаллары бөек булган. Менә аның отряды тар-мар килгән. Ул шушы яшел уҗымлы җирдә гаделлек булсын өчен көрәшкән. Шул юлда аның иң ышанычлы көрәштәшләре һәлак булган. Нинди фаҗигале үлем белән Метелица, безнең бөтен классыбыз белән гашыйк булган Метелица үлгән... Ә бездә нибары тамак кайгысы. Оят түгелме?!

Укытучы кинәт кенә туктап калды. Бу — сирәк була торган хәл. Әйтерсең, көйле инструментның бер кылы өзелде. Шулай да бер секундтан мәһабәт гәүдәсен турайтып, күзлек пыялаларын ялтырата-ялтырата ул укуын дәвам итте.

«...Левинсон обвел молчаливым влажным еще взглядом это просторное небо и землю, сулившую хлеб и отдых, этих далеких людей на току, которых он должен будет сделать вскоре такими же своими, близкими людьми, какими были те восемнадцать, что молче ехали следом, — и перестал плакать; нужно было жить и исполнять свои обязанности».

Укытучы шап итеп китабын япты да тәрәзә буена барып басты. Безгә ул яны белән тора иде. Класста кабер тынлыгы урнашты. Нәрсә булды? Без бер-беребезгә карамадык, шулай ике-өч минут дәшмичә утырдык. Укытучы кузгалды. Чалбар кесәсеннән дүрткә бөкләнгән кулъяулыгын чыгарды, күзләрен сөртте. Моны ул яны белән торып эшләде. Аннан безгә борылды да, күзлеген кулында әйләндергәләп:

— Картаям, ребятки, күңел нечкәрә бара,— дип, кыңгырау чылтыраганчы ук чыгып китте.

...«Тар-мар» әсәрен без атна буе үзлегебездән укый-укый шаштык. Левинсон елаудан туктаган урында безнең күңелләр елады. Күңелләр ташыды да ташыды, ә Хәлил Фәтхиевич бераздан шул әсәр буенча сочинение яздырды.

# Ташлытау урамнарында өермә болыты

Урамнарда инде балчык ярыла, тузан чыга. Җәй килде, корылык, кыйммәтчелек белән җәй килде. Әлтафи балык сатып барлыгы алты йөз сиксән сум акча җыйды, аның агач сандыгында хәзер мең данәсен бергә төргән «Волна» дигән папирос ята. Әлтафи хәзер географларның иң якын дусты булып китте. Базарларда аракы күренә башлады, йомырка, пешкән бәрәңге сатучы чибәр егетләр астан гына алып стакан белән аракы да салдыралар. Военторгта орден, медаль колодкалары өчен ленталар сатыла, Иләт ягыннан килгән мари хатыннары орден ленталарын өчәр-дүртәр метр алалар. Әлтафи әйтүенә караганда, аны күлмәк итәгенә тегәләр икән...

Безгә дә әллә нинди исәпләр керә башлады. Унжиде яшь тулды бит, шайтан алгыры. Стипендия алган көннәрнең берсендә Зарифуллин белән без дә военторг янындагы бер ларекка тукталдык. Нәрсәдер эшлисе килә. Сугыш беткәнгә инде күпме вакыт үтте. Укый башлаганга ничә ел... Унсигезгә чыгып барабыз. Нәрсәдер эшләргә хакыбыз юкмы әллә безнең? Безме колхозда эшләмәгән, безме фронтны ипи белән тәэмин итмәгән? Безме иң авыр елларда ачлыктан сыкранмыйча фәннәр өйрәнеп ятмаган?

...Буфетта эшли торган яһүд хатыны безгә кырлы кечкенә стаканнарга салып кызыл аракы бирде. Эчтек. Йөз граммы сигез сум туксан тиен, диде. Бер унлык, тагын ике өчәр сумлык, тагын бер сум сиксән тиен акча бирдек. Күңелне күтәрәсебез килде, ләкин берни дә тәэсир итмәде. Тукта, нинди йөз грамм? Каты әйберләр үлчәве бит ул! Сыек әйберне алай гер белән үлчиләрмени? Безнең авылда майны гына шулай гөрәнкәләп үлчиләр иде. Йөз грамм... Бу сугыш әллә нәрсәләр китереп чыгарды. Сыек әйберне кайсы җүләре шулай гер белән үлчи инде? Кайттык, Әлтафидан парын бер сумга «Волна» алып тартып карадык...

Иртәгесен рус әдәбияты дәресендә безне гомер дә булмаган хәл көтә иде...

Бу инде безнең кичәге азынуыбызга күрәдер. Хәлил Фәтхиевичның башы аска иелгән, чәчләре таралмаган. Кәефсез генә өстәл янына узды. Безгә карамыйча гына урындыкка утырды, журнал ачты. Без тын калдык. Ул ручкасын алды, журнал битенә нәрсәдер язды. Үзе тонык кына тавыш белән: «Так, так, ребятки», — дип дәрес буе сөйләнеп утырды. Безгә күтәрелеп карамаган көенчә, бер сүз әйтмичә чыгып китте.

Икенче көнне шул ук хәл кабатланды...

Без укытучыбызга нәрсә булганын белә алмый гаҗизләндек. Географларга «Волна» сатарга кергән Әлтафи куркыныч хәбәр ишетеп чыккач, без тынсыз калдык. Менә ике-өч көн инде Хәлил Фәтхиевичне бер кеше директор бүлмәсенә алып керә дә нәрсәдер сораша икән. Имеш, ул ниндидер Ибраһимов дигән язучы белән таныш булган икән. Имеш, ул бөтенләй дә Мәскәү татары түгел, ә Бәләбәй башкорты икән. Тагын әллә ниләр бар икән... Әнә шуларның барысы турында завхоз Исмәгыйль донос язган һәм чартлатып җавап биреп тора, ди... Рус теле укытучысының укучылар алдындагы авторитетыннан ул күптән көнләшеп йөргән икән.

Ул төнне тулай торак шөпшә оясыдай гөж килде. Малайлар бүлмәсендә төн буена беркем керфек какмады. Гыйззәтуллин таң атканда Әлтафидан илле тиенгә бер «Волна» сатып алып тартты. Чыгарылыш имтиханнары җитеп килә иде, иртәгесен, беркем бер нәрсә укымаган көе, училищега җыелдык. Кыңгырау чылтырады. Беренче дәрес рус әдәбияты булырга тиеш иде, берәү дә класска кермәде. Барыбыз да, ишек

төбенә жыелып, укытучылар бүлмәсен күзәтә башладык. Безгә элеккеге хәлебезгә кайту өчен тик бер генә нәрсә кирәк иде: менә хәзер укытучылар бүлмәсенең ишегеннән Хәлил Фәтхиевич күренсен, аның күзлек пыялалары ялтырап алсын иде. Аннан без дәррәү класска керер идек, ул класска күз ташлап, үзенең зур тарагы белән озын чәчләрен сибелдереп янга тарап куйсын иде. Аннан без күңелдән ятлаган өзекне сөйли башласак иде...

«Чуден Днепр при тихой погоде, когда вольно и плавно мчит сквозь леса и горы воды свои...»

...Безгә рус әдәбияты урынына география керде.

Рус телен шәһәрдән килгән бер ят кеше укыта башлады. Хәлил Фәтхиевич кая китте? Безнең күңелне шул борчый иде. Училищедан күңел сүрелде, житмәсә элеккеге директорны эшеннән алып яңаны китерделәр. Монысы беренче көнне үк яңа тәртип кертте: малайларга галстуксыз училищеда күренмәскә. Военторгка чиратка тезелдек. Нинди бөрчекле, нинди чәчәкле галстук булса — берсе дә калмады. Аякка чабата киеп, галстук тагып училищега килдек. Беренче дәрес алдыннан линейкага тезделәр. Иң шәп галстук Әлтафида иде. Аның галстугына яшелле-кызыллы чәчәкләр төшерелгән. Әлтафиның аягында кырык өченче размерлы эш ботинкалары, солдат чалбарының төбе тез астына салынган. Ул горур кыяфәт белән линейкада басып тора — ничә әйтсәң дә ике-өч атнадан ул башлангыч мәктәп укытучысы дигән исем алачак. Яңа директорның бүгенге көн өчен яңа фәрманын тыңладык. Бүген укулар булмый, бөтен кеше комиссия узарга тиеш.

...Ыгы-зыгы килдек. Докторлар ике көн буе безнең арык күкрәкләребезне тыңладылар, каткан тез башларыбызга сугып карадылар, ничә елдан бирле тиешенчә файдаланмаган тешләребезне тикшерделәр. Ярославналар, Онегиннар, Левинсоннар онытылдылар. Шуның өстенә өч көннән соң жан тетрәткеч приказ укылды. Классташыбыз Баязитованы комиссия вакытында ачылган бер гөнаһысы өчен училищедан чыгардылар. Гыйззәтуллинның үпкәсе авыру дип табылган һәм аңа тулай торактан чыгарга әмер бирелде.

Коры, кырыс жәй башланды, аяк астында үләннәр көйде, Ташлытау урамнарында өермә болыты йөрде. Жир ярылды. Бу — кырык жиденче елның эссе июле иде...

## Телеграф чыбыклары сызгыралар...

Гомер дигәнең — иң бәрәкәтсез нәрсә. Менә аннан соң инде егерме ел вакыт үткән. Гыйззәтуллин белән Зарифуллин ничә елдан бирле урта мәктәптә рус теле укыталар. Әркәшә дә инде Аркадий Павловичка әйләнгән. Район үзәгендә мәктәп директоры икән. Әлтафи гына ничектер укытучылык эшен ташлаган. Ул хәзер — райпотребсоюз председателе.

...Машинаның ишеген ачам да моннан күп еллар элек китап күтәреп атлаган сукмакка аяк басам. Элек училище торган урында машиналар паркы корганнар. Көзнең кыска көне монсу гына кичкә авыша. Сыек пычрак белән капланган таш юл тасмадай сузылып түбәнгә төшеп китә. Түбәндәге рус авылында тынлык, юл буендагы телеграф баганалары карасу боз белән капланганнар. Жир өстенә тын гына кич килә. Таш юл буендагы, әби патша утырткан, дип без ышанып сөйләгән каеннарның корган төпләре карачкыдай бозланып торалар. Кар катыш алатилә жир жәйрәп ята. Элек кибәннәр утырган горизонтта яшь наратлар тезелеп киткән.

Тынлык, тынлык. Кырлар инде буш калган, ап-ак шифер түбәле фермалар өстендә жылы пар күтәрелә. Төз лапас асларында тип-тигез

итеп өелгән утын әрдәнәләре, лапас эченнән коры печәннең хуш исе аңкып тора. Кырыс кына төньяк җиле исеп китә, түбәндәге рус авылында «дынк-дынк» итеп нәрсәдер кагалар. Мин баш киемемне салам һәм урманга таба барам. Шул секундта урман буеннан искән җилгә: «О ветер, ветрило! Зачем ты так сильно веешь?» дип дәшәсем килә. Бозланып каткан карачкыл баганаларга, «әби патша каеннарына» дәшеп сорыйсым килә: безнең балачакны сез хәтерлисезме? Безнең эзләрне саклаган берәр истәлек бармы? Чал тарих! Синең битләреңдә безнең эзләр бармы? Менә шушы каеннарга, шушы баганаларга карый-карый без монда белем алдык, безнең түн миләребез менә шушы урында кыймылдый башладылар. менә шушы урында без үзебез җиккән үгезләрдән тыш дөньяда Татьянаның мәхәббәте булганлыгын белдек, Бәлага гашыйк булдык, Левинсон белән Метелицага сокландык.

...Мин караңгы урман сукмагыннан таш юлга килеп чыгам. «Лес распахнулся перед ними совсем неожиданно...» Минем колагымда әнә шул тавыш яңгырый. Ул тавыш каяндыр җир астыннан чыккан кебек. Караңгы төшә, телеграф баганалары сызгыралар. Буранмы, яңгырмы булыр? Әллә аязгамы? Күңелдә буран да, яңгыр да...

Мәрхәмәтле җир! Нигәдер, мин синең шундый томанлы, буранлы, яңгырлы көннәреңне яратам. Син ул вакытта миңа ышанычлырак тоеласың. Әссе, коры көннәреңдә аяк асты ярылган, өермәле, коры җәй минем исемә төшә. Андый көннәрдә Ташлытауның аракы сатучы спекулянтлары, чебен җыелган сыра мичкәләре, галстук таккан чабаталы малайлары искә төшә.

Телеграф чыбыклары сызгыра, машина тасма булып җәелгән юеш юлдан караңгылыкка таба чаба.

Сау бул, минем тормышка аяк баскан, күзем ачыла башлаган җирем!

Машина фаралары бозлы баганаларны ялыйлар. Чабасы, чабасы килә, машинадан төшеп күкрәкне ачып, дымлы салкын кичтә караңгылыкны ярып, пычрак ерып алга барасы килә...

Барырга, барырга да, сызгырып утырган яфраксыз агачлар арасындагы җылы йортка кереп, өлкән яшьтәге, озын чәчле укытучы каршына басарга һәм:

— Давай, закурим, — дип елмаерга иде...

## Соңгы сүз

Авыр, кырыс юллар үтелгән. Ничек үтә алганбыз, ана каян көч килгән? Әйе, әйе, хәтерлим. Левинсон ни өчен алга барган? Отряды тармар килгәч тә өметен җуймаган. Урман караңгылыгыннан чыккач, ул алдында якты дөнья күргән. Кешеләрне күргән. Елаудан туктаган. «Нужно было жить и исполнять свои обязанности».

Шулай. Безгә дә яшәргә һәм үз бурычыңны үтәргә кирәк иде.

Әйе, яшәргә кирәк иде...

Ах, син җил!

Син һич тә агачларны селкетмисең. Син бары тик телеграф чыбыкларына гына кагыласың да шомлы итеп сызгырасың. Аязга булса да, яңгырга булса да сызгырасың.

Син миңа яшьлегемне сөйлисең...

## Зөлфәт

### Мәскәү

«Москва слезам не верит».
Рус халык мәкале.

... Күз яшьләренә ышана Мәскәү:
Ташлардан сора, ташлардан сора,
Кызыл мәйданга ишелеп яуган
Карлардан сора...
Алардан сора!..
Һәрбер ташта бар тарих кызуы,
Табаның пешә монда кыш көне!
Саклый бу шәһәр Ленин тавышын,
Моңсу карашын саклый Пушкинның.
Бөтен дөньяга биш минут тынлык
Килгән мизгелдән алып бу шәһәр,
Әйе, ышанды күз яшьләренә,
Мәскәү дөньяга дәште: Иптәшләр...
Үткән көннәрне искәргән кебек
Кызыл мәйданга ак карлар ява.
Ленинча кебек монда һәр адым,
Пушкинча сагыш җанга чорнала.
Колак сала да урамнарының
Төрле телдәге сөйләшләренә,
Олы кайгыга ышана Мәскәү,
Ышана Мәскәү күз яшьләренә...

### Айлы соната

Пәрдәләргә, тәрәзәгә тиеп,
Теплоходның ак салонында
Бетховенның «Айлы соната»сы
Агыла да һаман агыла...
Ә дулкыннар авызлыгын чәйни
Чабышларга чыккан ат кебек.
Кан саугандыр, бәлки, йөрәгенә —
Ял төпләре аның чат күбек.
Яр өстеннән, яшен суккан микән,
Каерылып ауган бер имән,
Каерылган кулын алга сузып,
Ул мәрхәмәт сорый Иделдән.
Чәрдәкләнгән ай чайкала суда,
Киереп ачкан Идел күңелен...

Онытылып тыңлыйм әле менә
Айлы сонатаңны, Иделем!
Пәрдәләргә, тәрәзгә тиеп,
Теплоходның ак салонында
Бетховенның «Айлы соната»сы
Агыла да һаман агыла.
Актарыла, күбекләнә Идел...
Акчарлакның сына канаты...
Нишләттең син сабыр Иделемне,
Нишләттең син, «Айлы соната»?!

●

Җиргә кирәк җирнең үз җырчысы,
Үз җырчысы күккә дә кирәк! —
Сайрар өчен тургай күккә менә,
Сандугачка житә бер тирәк.

●

Походтагы солдат кебек бит без —
Ял итәбез бары привалда:
Кемне диңгез дулкыннары чайкый,
Кемне буран — Себер, Уралда...
Очрашабыз төрле вокзалларда,
Очрашабыз уйда, хатларда,
Очрашабыз туган илдән читтә,
Очрашабыз туган якларда.
... Һөҗүмдәге солдат шикелле без —
Кемдер барып житми привалга —
Кораблар да бата бит диңгездә,
Бөркетләр дә үлә Уралда.
Беләбез без күпме дошман каны,
Күпме дуслар каны акканны —
Тик барыбер Ватан солдаты без,
Россия ул — солдат Ватаны.
Беләм, илем, хыянәткә барсам,
Потым судан мәхрүм каласым —
Үтерә бит тибеп ана болан
Ят боланны имгән баласын.
Походтагы солдат шикелле без...
Ял итәбез бары привалда,
Кемне диңгез дулкыннары чайкый,
Кемне буран — Себер, Уралда.

## Хемингуэй үлеме

Урап ала тормыш: — Китмә! — диеп, —
Шатлыгың бар җирдә, кайгың бар...
— Китмә, абый, — диеп, йомшак кулын
Маңгаеңа куя каеннар...
— Китмә! — диеп кар иңелә күктән,
— Китмә! — диеп сулар челтери,
— Китмә! — диеп, Килиманджароның
Ташларына ятып җил йөри.

— Китмә! — диеп биргән вәгъдәләрен
Бугазыннан ала, җибәрми.
— Китмә... — диеп әйтеләсе сүзләр
Һаман аваз сала, җибәрми.
Яшәү һаман янәшәдә генә...
Яшәү һаман бара ул рәттән...
Җибәрмичә капкын сыман кыса
Тимер кулы белән йөрәктән.
Ләкин кеше каплан кебек бит ул
Үлеменә каршы чапканда:
Үз аягын чәйнәп өзә каплан,
Эләккәндә тимер капканга!

## Кеше

Чиксез күккә буем җитәр күк,
Шатлыкларым минем җирдә күп.
Яз килер күк җиргә — суласам,
Җыр ишетәм җирне тыңласам.
Күз нурларым күкне уяр күк,
Йөрәгемә җирем сыяр күк!
... Үз-үземне кайчак аңламыйм —
Әллә кеше, әллә алла мин?

●

Рәсүл Гамзатовка

Өстәлемдә минем көрәгә [1], дип,
Көрәгәнең төбе күләгә, дип
Җырланган җыр безнең якларда,
Җырланган җыр төрле чакларда.
Безнең куллардагы көрәгәдә
Тукай сүзләре бар — халыкка...
Алтын сүзләр язган көрәгәне
Күтәрәбез сезнең саулыкка!
Язмышлар да безнең бер үк язмыш,
Бер үк яктылыкта көнебез —
Татар халкы диеп белмәсәгез,
Тукай халкы диеп белегез.
... Санап кына чыгып буламыни?
Көрәгәдә күпме сүзләр бар,
Күпме халыкларның язмышы бар,
Рәсүл туган, күпме эзләр бар!..

## Ышаныч

Ышаныч ул Комаров күк нык тавышлы,
Тыңла әй, Җир:
— Мин үземне шәп хис итәм!
Ышаныч ул Җиһаншин күк көлә белә
Палубада шулпа пешкәч күн итектән.
...Ышаныч ул ак яулыклы әни кебек,
Ышаныч ул беркатлырак сабый кебек:
Чапаевны ярга йөзеп чыкмасмы дип,
Бер киноны икенче кат карый килеп.

[1] Көрәгә — эчемлек савыты.

●

Син йоклыйсың, Казан, минем күзгә
Йокы керми һаман. Күк йөзе
Җиргә иелгән дә нидер тыңлый.
Шул тынлыкта менә бер үзем.
Сөембикә ак томанга чумган.
Кабан күлен ак кар каплаган,
Ак Кремль ерак гасырларның
Серле дастаннарын ятлаган.
Син йоклыйсың, Казан, ак шәһәрем,
Кара көнен булган синең дә,
Күпме булды алар — кара көннәр
Минем ап-ак туган илемдә!
Кара кайгы була — ак бәхеткә,
Ак сөюгә — кара хыянәт,
Ак яшәүне кара үлем кисә,
Ак, карадан тора бу хәят.
... Син йоклыйсың, Казан, ә мин һаман
Уйларымның биек ярында.
Син сискәнден...
Төш күрденме әллә
Шул каралар, аклар турында?..

●

Җырлый белмиләр бөркетләр,
Сугыша белми былбыл,
Җырдан сызланмый бөркетләр,
Сугышта үлми былбыл.
Муса кайсы шул кошларның?
Җанына сыйган җир, күк —
Сугыша белгән былбыл ул,
Һәм җырлый белгән бөркет.

●

Шундый ташлар бар Казанда —
Шаһитләр, белә алар,
Ничек егылган Шамилләр,
Ауганнар Галимҗаннар.
Күпме кадерле исемнәр
Ташка язылмый кала —
Хаксыз калган исем булса,
Таш үзе аваз сала.
— Миндә Галимҗан каны! — дип
Калкына алар җирдән —
Ташлар түзми ялгышларга,
Ташлар хәтере тирән.
Үз баласын минем халкым
Үтерә алмый бәреп,
Бары һәйкәл салыр өчен,
Я язар өчен бәет!
Ташлар кызара беләләр
Кешеләр хатасыннан.
... Бүгенге көндә бу ташлар
Таш гасыр хаты сыман.

Ташлар белә үлгәннәрне,
Кисәтә исәннәрне.
Таш ирек бирми җуярга
Кадерле исемнәрне.

●

«Чакырылмаган кунак —
татардан да яманрак».
Мәкаль.

Шушы халык чабатадан йөргән,
Шушы халык аю биеткән —
Үткәненә карый үзе хәзер,
Караган күк таудан, биектән.
Карындыкны үтеп кергән якты
Чыкмый калган йортлар эченнән...
Чакырылмаган кунак булып үткән,
Үткән татар дошман өстеннән.
Чакырылмаган кунак булып кергән
Зимнийләргә, Перекопларга,
Чакырылмаган кунак булып кергән.
Паулюс качып яткан йортларга.
Тезләнүне белми минем халкым,
Дошманнарын җиргә яткыра —
«Чакырылмаган кунак — татардан да
Яманрак», — диләр, —
хактыр да.
Үз-үзеннән
яманрак татар
Дошман барда җирдә, үч барда —
Чакырылмаган кунак — дошманнарга,
Көтеп алган кунак — дусларга.

●

«... Ко мне приходит иногда
Она...»
А. Блок.

Сине Блок уйлап тапкан бары —
Синең өчен күпме шәм янган!
Төшкә генә бары керәсең син —
Күзләреңә күктән нур тамган.
Син үтәсең шушы урамнардан,
Кем өчендер бәхет күзендә...
Син кагылган көзге яфракларга
Кагылам мин — үзем сизмим дә.
Кемнедер мин ашыгып яратканмын —
Ашыгып сөйгәнсең син кемнедер.
Мин таныган матурлыкны синдә
Кем таныр да аны, кем белер?
Ничә тапкыр инде күрдем сине,
Ничә күрмәмешкә салыштым —
Ә син исә гел белмисең мине:
Синме, әллә минме ялгыштым?
Төшкә генә бары керәсең син,
Күзләреңә күктән нур тамган.
Сине Блок уйлап тапкан бары...
Синең өчен күпме шәм янган...

## Фәнис Яруллин

### Сине шуңа яратам

Гөнаһсызга кәефең кырсам,
Кирәксез сүз ычкындырсам,
Кичерә беләсен син.
Урынсызга шапырынсам,
Һәр мактауга авыз ерсам,
«Пешерә» беләсең син.

Эчендә янса да утлар,
Килеп керсә минем дуслар
Елмая беләсең син.
Сагыш басса иңнәреңне,
Көйләп моңлы көйләреңне
Моңая беләсең син.

Күреп эштә уңганнарны,
Бар яктан да булганнарны —
Көнләшә беләсең син.
Хакыйкатькә туры карап,
Гаделлекне генә яклап,
Сөйләшә беләсең син.

### Кое казучы карт сүзләре

Бервакытны ишек алдыбызга
Кое казытырга исәпләп,
Алып килдем кое казучыны,
Сукыр Галләм картны җитәкләп.
Галләм бабай бер дә ашыкмыйча
Тәмәкесен төреп көйрәтте.
Ишек алдын кат-кат йөреп чыкты,
Барлап куйды ломны, көрәкне.
Туктый-туктый ике-өч адым саен
Җиргә ятып нидер тыңлады,
Аннан әйтте: «Улым, монда сезнең
Су чыгардай урын булмады.
Казысаң да барыбер бушка булыр,
Бу урында рәтле чишмә юк.
Һәр казыган җирдән су да чыкмый,
Менә шуны, улым, истә тот».
....Әгәр кайчак бер дә төпле фикер
Әйтеп булмый икән язып та,
Уйлыймын мин: чишмәсе юк, ахры,
Файда чыкмас димен казып та.

## Бусагалар

Бусагалар, бусагалар,
Сезнең аша кемнәр үтми,
Сезнең такыр битегезне
Нинди генә табан үпми!

Һәрнәрсәгә битараф сез,
Кем килсә дә үткәрәсез.
Нинди авыр аякны да
Сыкранмыйча күтәрәсез.

Белсәгез сез, нинди хәбәр
Китергәнне минем монда.
Сынып төшәр идегез бит
Сезгә аяк баскачтын да.

Аякларны монда кадәр
Көчкә-көчкә килдем сөйрәп:
Якын кешем торган йортка
Килдем авыр кайгы төяп.

## Кызыгып калам

Кызыкмыйм мин һаваларда
Очып йөргән бөркетләргә;
Бөркетләрдән биегрәк
Менгәнем бар бит күкләргә.

Кызыктырмый күкрәк киереп
Дулкын ярган пароход та;
Телим икән — утыра алам
Аңарга мин һәрбер портта.

Кызыктырмый машиналар,
Барысында да йөри алам:
Җиргә дөп-дөп басып үткән
Кешеләргә кызыгып калам...

## Әллә күңел, әллә еллар

Басуларда иген күкрәп унса да,
Талларыма сандугачлар кунса да,
Өйләр саен ак күмәчләр пешсә дә,
Ракеталар айга барып төшсә дә,
Ачсалар да яңа нефть катлавын,
Күрсәм дә мин бер чибәрнең атлавын,
Җылы яктан кошлар урап кайтса да,
Бер якыным үз бәхетен тапса да,
Шатланамын, омтыламын яшәргә,
Әллә күңел, әллә еллар яшәрә.

## Үзгәреш

Кинәт чибәрләнден, сеңел,
Абау, күзем тимәсен.
Күлмәкнең дә килешлесен,
Бик матурын киясең.
Үзгәрде көлешләрең,
Үзгәрде йөрешләрең.

Һәр кешене сокландыра
Буй-сының, килешләрең.
Йөзләреңдә гел елмаю,
Хисләрең таша бугай.
Күзгеләргә еш карыйсың
Яз якынлаша бугай.

● ● ●

Сафа Сабиров

# МАТРОСЛАР ДЕСАНТЫ

ОЧЕРК

*1918 елның җәендә, яшь совет илен революция дошманнары һәрьяклап утлы боҗра белән камап алган авыр көннәрдә, Ленин фәрманы белән Иделдә хәрби флотилия төзелә, аның комиссары итеп сыналган большевик Николай Григорьевич Маркин билгеләнә. Кыска гына вакыт эчендә флотилия зур көч булып әверелә. Н. Маркин һәм аның сугышчан дуслары — революцион матрослар — Казанны һәм республикабызның Идел, Кама буе шәһәрләрен, авылларын акчехлардан, Колчак бандаларыннан азат итү өчен көрәшләрдә искиткеч батырлыклар күрсәтәләр.*

*Быел май аенда гражданнар сугышы герое матрос-комиссар Н. Маркинның тууына 75 ел, октябрь аенда Пьяный Бор (хәзерге Красный Бор) пристане янында каты сугышта батырларча һәлак булуына 50 ел тула. Шул уңай белән журналыбызның бу санында язучы С. Сабировның Казанны азат итү күренешләрен сурәтләгән түбәндәге очеркын урнаштырабыз.*

## I


Бу төнне комиссар Маркинның черем итеп алырга да вакыты булмады.

Кичә көндез флотилия штабында утырыш булган иде. Анда иртәгә башланачак зур һөҗүм планын раслау һәм аны армия штабы вәкилләре белән килештерү, разведчиклар алып кайткан соңгы мәгълүматларны аныклау озакка сузылды.

Аннары кич җитәрәк ул, катерга утырып, рейдны әйләнеп кайтырга, һәр корабның яуга әзерлеген үзе тикшерергә, командалар белән сөйләшеп чыгарга кереште. Штабтан приказ әле яңа гына җиткерелгән булса да, корабларга корал һәм ягулык төйи башлаганнар, тупларны һәм механизмнары соңгы кабат тикшерәләр, иртәгә башланачак штурмга һәркайда зур күтәренкелек белән әзерләнәләр иде.

Шәһәрнең дошман кулында булуын Николай Григорьевич үзе дә авыр кичерә һәм Зөягә килгәннән бирле тизрәк һөҗүмгә күчәргә ашкынып яши, ару-талуны белмичә флотилияне шуңар әзерли иде. Менә әле корабларда митинглар үткәреп йөргәндә командаларның җиңүгә омтылып януын күреп тә эчке канәгатьләнү кичерде: «Мондый арсланнар белән теләсәң нинди дошманның муенын сындырырга мөмкин», — дип үз алдына елмаеп куйды ул.

Ниһаять, күп төрле мәшәкатьләрдән арынып, үзе урнашкан «Ваня» корабына кайтып кергәндә, төн инде үтеп бара, шәһәр ягыннан беленер-



Гражданнар сугышы герое Н. Г. Маркин.

беленмәс кенә таң атып килә иде. Башка кораблардагы кебек, монда да беркем дә йокламый, приказ булу белән кораб кузгалып китәргә әзер тора иде.

Николай Григорьевич палубадагы матросларның сәламенә:

— Исәнмесез, хәерле кич, иптәшләр! — дип җавап бирде дә шундук үзеннән-үзе көлеп җибәрде: — Хәер, кич түгел, иртә икән инде, әнә таң атып килә ич... Димәк, тиздән кузгалырга вакыт.

Көндезләрен кояшлы, жылы булса да, хәзер таң атканда күз сулышы су өстендә үзен сиздерә, матрослар хәзинәдә булган кадәр җылырак киенергә тырышкан иде. Николай Григорьевич моны күреп ихтыярсыз гаҗәпкә калды. Матросларның кайчандыр чем-кара постау бушлатлары уңып көрән төскә кергән, машинист Михаил Куликның бескозыркасы берничә җирдән тишелеп (дошман пулясы эзләре) һәм таушалып беткән. Кайберәүләрнен өсләрендә иске соры шинель, аякларында солдат обмоткасы, хәрби дингезчегә аз гына да охшашы юк. Шуңа да карамастан, барысының да күңелләре күтәренке, һәркемнең йөзендә яуга омтылу күренә иде.

Комендор Шәрипов үзенең тубы янында басып торган җиреннән:

— Николай Григорьевич, үзәктән хат-хәбәр юкмы? — дип сорау бирде. — Безнең Ильичның хәле ничек икән анда? Шуны беләсе иде...

Барсы да кинәт тынып калдылар. Маркинга бу сорауны бүген башка корабларда да биргәннәр иде. Күптән түгел генә юлбашчының революция дошманнары тарафыннан яралануын солдатлар, матрослар авыр кичерәләр һәм аның хәлен әледән-әле сораштырып торалар; аның сәламәтләнүен теләп телеграмма да җибәргәннәр иде.

Маркин сорауга җавап бирергә өлгермәде, түбәнге рейд ягыннан моторын шаулатып менеп килгән кечерәк кенә катерга борылып карады. Матрослар да шунда карап хәрәкәтсез калдылар. Менә катер тын су өстендә бөтерчек дулкыннар кузгатып кораб янына килеп туктады. Штабтан ашыгыч пакет җибәргәннәр икән. Аны тиз генә күздән кичерүгә, Николай Григорьевичның йөзе яктырып китте.

— Дуслар, безнең телеграммага Ильичтан җавап килгән! Тыңлагыз, укыйм. Менә ул:

«Рәхмәт. Сәламәтләнүем бик әйбәт бара. Казанда чехларны һәм акгвардеецларны, шулай ук аларга булышлык итүче канәчкеч кулакларны бастыру үрнәк булырлык аяусыз үткәрелер дип ышанам.

Чын күңелдән сәлам. Ленин».

Комиссар телеграмманы укып бетергәч, барсы да җиңел сулап куйдылар һәм елмаеп бер-берсенә карашып алдылар. Шәрипов күтәренке тавыш белән:

— Алайса, бик әйбәт, тизрәк савыга күрсен, — диде. — Ә без монда бу кәнтәйләрнең артсабакларын укытырбыз...

— Бик дөрес әйтәсең, туганкай, молодец... Нәкъ шул вакыт житте. — Маркин гадәтенчә кызып китеп, безкозыркасын кулына алды һәм шәһәр ягына күрсәтә-күрсәтә сөйләргә тотынды: — Иптәшләр, хәзер кузгалабыз. Һөҗүм менә болай планлаштырыла: безгә көтмәгәндә Казан пристанена десант төшереп, аннан дошманны бәреп чыгару, иртәгә транспортларга төялеп Идел аша киләчәк гаскәри көчләргә плацдарм әзерләү бурычы йөкләтелә... Дуслар, бу бик җаваплы операция, десантка иң тәвәккәл егетләр генә, үзләре барырга теләүчеләр генә алыначак. Куркаклар комачаулап йөрисе булмасын. Менә шул!.. Ә хәзер, иптәшләр, барыгыз да үз постларыгызга таралыгыз. Кызыл матрослар ничек сугыша белгәнен тагын бер күрсәтик, Ильичны Казан шәһәрен азат итү белән шатландырыйк әле...

Тиздән кораблар якорьдан кузгалып агым уңаена борылыша башладылар һәм «Ваня» артыннан бер-бер артлы сафка тезелешеп юлга чыктылар.

Су өстендә сөт кебек ак куе томан. Кораблар бер-берсен көч-хәл белән генә күздән югалтмыйча баралар.

Штурвал көпчәге янында торучы киң маңгайлы, куе сакаллы лоцман Овчинников әйләнә-тирәгә бер мәл борчулы карап барганнан соң:

— Бу томанда ярга барып бәреләсенне көт тә тор, — дип сукрана башлады. — Николай Григорьевич, алдан әйтеп куям: сайга утырсакнитсәк, мине гаепләмә... Мондый томанда адәм рәтле кеше йөрми, чынлап әгәр...

— И сакалбай, юкка гына мыгырданасың, бу томан безгә бик кулай. — Комиссарның күңеле күтәренке, йөзе ачык иде. — Һич тә борчылма, адашмабыз. Томан тагын бераз шулай торса, дошман безнең килеп төшкәнне сизми дә калачак.

Әйләнә-тирә тып-тын. Түбәндә көпчәкләр кузгаткан йөгерек дулкыннар гына бер-бер артлы тәгәриләр һәм куе томан эчендә эреп югалалар иде. Корабның туплары һәм пулеметлары алга төбәлгән. Палубада десантчылар отряды.

Маркиз атавы буйлап байтак баргач, Маркин рубкадан ачык мостикка чыкты һәм бинокльдән сул як ярга таба игътибар белән карап бара башлады. Менә томан сыеграк булган бер арада ул яр буенда дебаркадер, складлар күреп алды һәм кулы белән изәп рульне сулга салырга кушты. «Ваня» артыннан шунда ук башка кораблар да борылдылар һәм зур тизлектә пристаньга юнәлделәр.

Тиздән «Ваня» килеп туктауга, десантчылар, чалка бәйләгәнне дә көтмәстән, дәррәү сикереп дебаркадерга төштеләр һәм сыгылмалы такта басмалардан яр өстенә ыргылдылар. Маркин да, тупчыларга, пулеметчыларга үз постларында әзер торырга кушты да, пристаньга чапты. Шул арада килеп туктаган бүтән корабларның матрослары да аның артыннан йөгерделәр.

Разведчиклар мәгълүматына караганда, пристаньда дошман көчләре күп тупланган булырга тиеш иде. Бактың исә, беркем дә юк, причал буп-буш. Десантчылар хәтта аптырап калдылар. Бары тик складлар артына барып чыккач кына әрдәнәләп өелгән утын һәм төрле ящиклар арасында җай гына яшеренгән эре калибрлы туплар батареясын һәм пулеметларны күреп алдылар.

Акгвардеецлар мондый куе томанда һәм болай иртүк кызыллар килеп төшәр дип уйламаган, күрәсең. Кайдадыр якын тирәдә ял итәләр булса кирәк, туплары янында бары бер солдат кына сакта тора иде. Ул мылтыктан атып тавыш күтәрүгә каяндыр башкалар да килеп чыктылар һәм иләмсез акырышып контратакага ташландылар.

Ул арада мондагы хәлне аклар командованиесе дә абайлап өлгерде булса кирәк: каяндыр еракта авыр туплардан ата башладылар. Снарядлар баш очыннан гына выжылдап үтеп яр буеннан еракка су

өстенә явалар. Алар төшкән турыда елга төбеннән әле анда, әле монда ком катнаш су фонтаннары бәреп чыга иде.

Маркин бер мәл снарядларның кай яктан очып килгәнен белми торган иде. Әмма бик тиз күреп алды: һаваны тетрәтеп туп тавышы гөрелдәп үткән саен кремль өстенә саргылт куе дары төтене бөркелеп күтәрелә һәм җил уңаена акрын гына тузгып тарала иде. Николай Григорьевич ул төтеннең хәтта тончыктыргыч ачы исен дә тойган кебек булды һәм эчке борчылу белән: «Ә, кремльдән икән... Бигрәк тә якыннан бәрәләр», — дип пошына башлады.

Ә моңарчы Идел өстен каплап торган куе томан инде тарала төшкән, кремльдән дошман батареясы Устьега төзәп ата башлаган иде. Аның авыр снарядлары якында гына гөрселдәп шартлаган саен причал буендагы кораблар, кинәт сискәнеп киткәндәй, бөтен корпуслары белән янтаеп ала иде.

Маркин Югары Ослан ягына тиз генә борчулы карап алды. Ләкин анда су өстендә берни дә юк, коры җир гаскәрләрен төягән транспортлар килгәне әле һаман никтер күренми иде. Димәк, хәзер монда торып десантны да, корабларны да харап иттерергә ярамый. Маркин бу фикергә килү белән, десантчыларга дошман тупларыннан тиз генә йозакларын алырга да, чигенергә приказ бирде.

Шул чак ярдәм килеп җиткәч, яр буенда аклар отыры кыюлана төштеләр һәм матрослар отрядын тагын да катырак кысрыклый башладылар. Ә «Ваня» мостигыннан Всеволод Вишневский белән Володя Реаторский икесе ике пулемет янында моны күреп торсалар да, үз иптәшләрен кырудан куркып әлегә хәтле ут ача алмыйлар иде. Менә десантчыларны куып килүче дошман яр өстенә ябырылып килеп чыгуга, алар бер-берсенә:

— Әйдә, күрмәгәннәрен күрсәтик әле! — дип тиз генә карашып алдылар да иптәшләре баш өстеннән дошманга аяусыз ут яудырырга тотындылар.

Аклар кинәт куәтле давылга очрагандай тукталып калдылар һәм причалда бик күп үле гәүдәләр калдырып тәртипсез рәвештә кире чигенә башладылар... Ә кремльдән атучыларның снарядлары корабларга чак кына тими кала, янәшә генә төшеп шартлый иде. Шул арада инде «Ваня» рубкасына менеп өлгергән Маркин корабларга тизрәк кузгалып китәргә команда бирде. Пристаньда бик күп үле гәүдәләр, яуга яраксыз туплар, дөрләп янган складлар торып калды. Кораблар барлык тупларыннан һәм пулеметларыннан ата-ата кузгалып кире киттеләр.

## II

Иртәгесен 10 сентябрьдә Казан шәһәрен һәрьяклап камау һәм штурмлау башланды.

Коры җир гаскәрләренең бер группасы Иделнең сул як яры буйлап иртән иртүк һөҗүмгә күчте: ул дошманны әзәрлекләп барып шәһәргә Ягодный һәм Кәҗә бистәләре аша бәреп керергә тиеш. Елганың уң ягындагы көчләр — пехота, кавалерия һәм артеллерия частьлары, — барлык кораллары белән пароходларга төялеп беткәннәр һәм пристаньга килеп төшү белән Бишбалта һәм Яңа бистә дамбалары буйлап барып шәһәрне штурмларга әзер торалар иде. Ә хәрби флотилия корабларының бер төркеменә тагын шул кичәге бурыч — Аргы Устьега беренче десант төшереп коры җир гаскәрләре килергә плацдарм әзерләү максаты куелган иде.

Кораблар тавышсыз-тынсыз гына якорьдан кузгалып юлга чыкканда, таң беленеп кенә килә иде әле. Башлап «Ваня», аның артыннан бер-бер артлы тезелешеп «Добрый», «Ольга», «Коновод», «Олень» һәм «Пересвет» бара. Палубаларында десантчылар әзер.

Су өстендә томан булгач, Маркин пристаньга бүген дә искәрмәстән килеп төшәргә уйлаган иде. Әмма кичә бер мәртәбә авызы пешкәч, дошман бүген бик уяу булып чыкты. Кораблар Маркиз атавы буеннан үтеп сулга, пристаньга таба борылуга, кремль һәм Жылан тавында урнашкан авыр батареялардан котырынып ата башладылар. Шулай да томан төзәп атарга комачаулый, күрәсең, снарядлары югарыдан ачы сызгырып очып үтәләр дә кайдадыр еракта суга төшеп шартлыйлар иде.

Менә пристань. «Ваня» кичәге дебаркадерга килеп туктауга Маркин рубкадан тиз генә йөгереп төште дә алгы палубадагы десантчыларга:

— Әйдәгез, дуслар, Казан өчен алга!..— дип команда бирде һәм кулындагы наганын болгый-болгый дебаркадерга сикерде.

Десантчылар көчле ташкындай аның артыннан причалга ташландылар. Бу вакытта инде «Ретивый» миноносецы белән йөзмә форт «Сережа» туплардан, пулеметлардан ата-ата пристаньга якынаеп киләләр һәм дошманга яр буендагы складлар, каралтылар арасыннан күтәрелеп чыгарга ирек бирмиләр иде. Көтелмәгән куәтле атакага дошман солдатлары каршылык күрсәтә алмадылар, тупларын, пулеметларын ташлап, трамвай юлы буйлап тәртипсез рәвештә Бишбалтага таба чигенә башладылар.

Аргы Устье өчен сугыш озак бармады. Транспортларга төялгән кавалерия, артиллерия частьлары килеп житкәндә, пристаньнан дошман куып чыгарылган, төп көчләрне кабул итәргә ныклы плацдарм әзерләп куелган иде инде.

Ә кызыл матрослар чигенүче дошманның үкчәсенә басып диярлек эзәрлекләп бара бирделәр. Иң алда комиссар Маркин.

— Алга, иптәшләр, алга!.. Дошманга тын алырга да бирмәскә! — дип ашыктырды һәм әледән-әле наганыннан ата-ата отрядны әйдәп һаман алга йөгерде.

Бистә чиркәвендә дошманның оборона пункты икән. Шунда килеп житкәндә, кинәт пулеметтан ата башладылар. Бу жылан оясын ничек тә бастырырга кирәк, югыйсә төп көчләрнең юлында тоткарлык туачак. Ләкин күрәләтә утка кереп кешеләрне һәлак итәргә дә ярамый иде.

Маркин отрядка жиргә ятарга, якындагы йортлар артына ышыкланырга ым какты. Вишневский белән бер төркем матроска, гранаталар алып, күршедәге бакчалар аша дошман тылына үтәргә команда бирде. Һәм аларны озак көтәргә туры килмәде: берничә минуттан чиркәү эчендә рәттән ике-өч граната шартлауга дошман уты бастырылды, ишектән кулларын күтәреп исән калган солдатлар чыга башлады.

Ләкин хәзер алар белән маташырга вакыт юк. Маркин беренче әсирләрне штабка озатырга команда бирде дә:

— Алга, иптәшләр, әйдәгез алга! — дип тагын башлап кузгалды һәм отряд бердәм күтәрелеп алга ыргылды.

Кайдадыр күк күкрәгәндәй бөтен шәһәрне тетрәтеп туп аталар, әле анда, әле монда пулемет такылдый, кайберәүләр яраланып егылып калалар.

Дамбаны үтеп шәһәргә кергәндә, пристаньда транспортлардан төшкән кызыл атлылар десантчылар артыннан килеп життеләр һәм чигенүче акгвардеецларны һәм фетнәче акчехларны аяусыз эзәрлекләп куа киттеләр.

Отряд Проломный урамына барып житкәч, халык арасыннан житез хәрәкәтле, жирән сакаллы чандыр гына гәүдәле бер карт чыгып аклар штабы урнашкан йортны күрсәтте. Бинаны тиз генә һәрьяклап камап алып шундук эченә бәреп керделәр. Хужалары качып китәргә дә өлгермәгән икән әле. Хәтта ишек алдында тиз атышлы ике өр-яңа тупларын да алып китә алмаганнар иде.

Аклар башта ачык тәрәзәләрдән атып бер мәл каршылык күрсәтмәкче дә булганнар иде. Әмма сарай кебек зур залга гранаталар белән коралланган арсландай матрослар белән Маркин бәреп килеп кергә, ак офицерлар тындылар һәм, приказ биргәнне дә көтмәстән, калтыранып кулларын күтәрә башладылар.

Аларны коралсызландырып озаткач, комиссар әһәмиятле документларны, печать һәм штампларны үзе белән алды. Ә ишек алдындагы тупларны, снарядларны игътибар белән карап чыкты да:

— Карташев, боларны корабка озатыгыз... Бик әйбәт, төзек туплар. Әйдә, безгә дә хезмәт итсеннәр әле, — дип кәефле елмайды.

Шул чак Маркин каршына тупчы Шәрипов килеп басты.

— Иптәш комиссар, әнә тегендә карагыз әле, — диде ул, капка артындагы кирпеч сарайга күрсәтеп. — Аракы складды икән, кайберәүләр авыз итеп тә өлгергән инде.

Склад ишеге төбендә чынлап та инде битләре кызарып өлгергән кешеләр кайнаша, эчтән кемнәрнеңдер исерек тавышлары ишетелә иде.

— Хәзер үк бөтен аракыны юк итәргә, исерекләрне куып чыгарып складны бикләргә һәм кораллы сакчы куярга! — дип боерды Маркин. — Тагын менә нәрсә, иптәшләр!.. Безнең үз арабыздан шундыйлар була күрмәсен, һәркайда да революцион тәртип саклыйк.

Ул арада инде кызыл полклар да Казанга өч яклап бәреп кергән һәм паникага бирелгән дошман зур ашыгычлык белән тәртипсез рәвештә Лаеш тракты буйлап чигенә башлаган иде. Бары тик кремль эченә оялаган кара көчләр генә, бирелергә теләмичә, әле һаман каршылык күрсәтә, анда каты сугыш дәвам итә иде. Озакламыйча матрослар отряды да шунда барып житте һәм килеп төшкән шәпкә сугышның иң кызу участогында шундук бердәм яуга ташланды, штурм яңа дәрт белән кызып китте.

Каты сугыш озак дәвам итмәде. Һәр яктан утлы боҗра белән камап алынган һәм һәлакәткә дучар ителгән дошманның соңгы өере аяусыз бастырылды. Данлы җиңүне бөтен шәһәргә хәбәр итеп кремль манарасы очында азатлык һәм җиңү байрагы — кызыл байрак җилфердәде.

Һәм бик тиз арада бөтен шәһәргә бәйрәм төсе керде. Акгвардеецлар, фетнәче акчехлар газабыннан азат ителгән Казан хезмәт халкы, яз көннәрендә ярларыннан ашып аккан Идел сулары кебек, мәйданнарга, урамнарга чыкты, азатлык алып килүче кызыл сугышчыларны гаять зур күтәренкелек белән каршылады. Халык тантанасы төн уртасына кадәр сузылды...

Кич белән, десант отряды пристаньга кайткач, причалда митинг булды. Флотилия командующие Раскольников Казанны азат итүдә күрсәткән батырлыклары өчен десантчыларга рәхмәт белдерде, «Ваня» корабына Бөтенроссия Үзәк Башкарма комитетының Кызыл Байрагын тапшырды. Казан өчен батырларча сугышкан корабларга яңа исемнәр куштылар. «Ваня» корабына Маркин тәкъдиме буенча «Ваня-коммунист» исеме бирелде.

— Минемчә, бик лаеклы исем, бу кораб диңгезчеләре бүген чын коммунистларча сугыштылар, — диде комиссар.

Шамил Бикчурин

# КАТЫ ТОКЫМ

ОЧЕРК

I

Күңелле, шаулы яңа ел бәйрәме дә узды. Шундый тиз үтте, шундый кыска булды ул — чыршыларына эленгән бизәкләре кебек ялтырап кына калды. Бүген инде әнә җирдән себерә торган кар кичәге эзләрне дә күмеп ташлаган. 1959 ел эзләрен. Һәм бөтенләйгә. Күрәсең, шушы эзләр кебек, үткәннәр дә мәңге кайтмый торгандыр...

Иске елны озаткан саен, Анатолий үзендә нигәдер бушлык сизә. Ул нәрсәнедер югалткан, нидер эшләп, өлгертеп җиткермәгән, онытып калдырган кебегрәк бер хис кичерә башлый. Әллә, чыннан да, былтыргы ел бөтенләй мәгънәсез уздымы?

Киез итекләре белән яңа карны ера-ера, Анатолий тауга күтәрелде, конторага таба борылды. Бүген тагын буровойга, ә шәһәр өстендәге бихисап иллюминацияләр бер сүнеп, бер кабынып һаман җемелдәшәләр. Боларны бит буровойдагыларның бөтенләй күрми калулары да мөмкин...

Йокыдан уянганнан бирле күкрәген тырнап килгән кәефсезлекнең әле генә серенә төшенде Анатолий. Яңа елга каршы ул шәһәргә кайтып кергәндә, бораулаучылар буровойда, ачык кырда, буран астында эшләп калдылар. Төнге уникедә бөтен илгә ишеттереп Кремль курантлары сукканда, кешеләр якты, җылы өйдә, өстәл янында яңа ел, яңа бәхетләр хөрмәтенә тост күтәргәндә нинди уйлар кичерделәр икән алар?

Декабрь азакларында гына Анатолий Павловны, катлаулы эшләр мастеры буларак, Шөгер мәйданындагы шушы буровойга авария бетерү өчен җибәргәннәр иде. Коточкыч хәл иде 38 нче буровойда. 1760 метр тирәнлектә бораулау инструменты кысылып калган. Нефть катламына нибары җитмеш-сиксән метр дигәндә...

Бригадага килгәч, Павловка кешеләр зур өмет белән карадылар. Юк шул, алай тиз генә булырлык түгел иде. Анатолий инструментны әйләндерергә, йолкытырга маташып карады — барып чыкмады. Инструмент аска да төшми, өскә дә күтәрелми иде...

Күңелен авыр уйлар баскан хәлдә, Анатолий контора капкасыннан керде, ишек алдындагы иртәнге шау-шуга чумды.

4 нче разведка-бораулау конторасы Лениногорскида беренчеләрдән булып уяна. Дөресен әйткәндә, ул тәүлек буена бөтенләй йокламый. Камышлы елгасы буенда, биек тау итәгендә урнашкан бу предприятие, шәһәргә карап, көнен дә, төнен дә гел шаулап тора. Төннең теләсә кайсы вакытында аның тәрәзәләрендә ут булыр, бүлмәләрендә кешеләр утырыр, биек койма белән әйләндереп алган ишек алдында станоклар, агрегатлар гөрләр.

Ике ягына зур-зур электр фонарьлары эленгән тимер капканың да ябылганы юк. Сәгать саен, минут саен кешеләр утырган автобуслар чыгып тора, буровойдан эшчеләр кайта, төрле бораулау җиһазлары төялгән зур-зур машиналар ерак юлларга китә.

Шундый ыгы-зыгы астында, машиналарның кайсына юл биреп, кайсының юлын бүлеп, ашыга-ашыга бригада кешеләрен эзләп йөргәндә, Анатолийның артыннан кемдер кычкырды:

— Павлов, сине конторага чакыралар!

## II

Партбюро секретаре Әдип Зәкиев өстәленә туздырып ташлаган кәгазьләрне озак актарып утырды. Павлов турында шактый күп мәгълүматлар бар иде, тик бу конторага яңа килгән секретарьны алар гына канәгатьләндереп бетерә алмый шул.

Менә Павловның ярты биттән генә торган автобиографиясе. Бик дикъкатьләп, укучы почеркы белән язылган. «1932 елда Ставрополь крае, Кусаевский районы, Султанское авылында туганмын, — дигән. — Җиденче классны тәмамлау белән Краснодар нефть техникумына укырга кердем һәм аны 1952 елда бетереп чыктым».

Шуннан соң биредә Павлов Анатолий Викторович исеменә өр-яңа хезмәт кенәгәсе ачыла. Тау техникы дипломы алган егетне «Татбурнефть» трестына бораулаучы итеп куялар.

Монысы Зәкиевне гаҗәпләндерми, ә менә аның өч айдан соң бораулау мастеры итеп билгеләнүе сәеррәк.

Язуның дөреслегенә шикләнгәндәй, Зәкиев кенәгәне әйләндереп, аның тышына карап куйды.

— Егерме яшьтә бораулау мастеры... Иртә җитлеккән, бик иртә...

Дөрестән дә, хәзер ул яшьтәге мастерларны Татарстан нефтьчеләре арасыннан да эзләп табарлык түгел бит. Институт бетереп килгән инженерларның да берничә еллар буена бораулаучы булып, мастер урынын ала алмыйча йөргәннәрен белә Зәкиев. Павловның шулай бик тиз күтәрелеп китү сәбәбен ул чакта кадрлар җитешмәүдән генә күрде ул.

Шул ук көзне Павловны армиягә алганнар. Анда өч ел хезмәт итеп, демобилизацияләнгәч, яңадан элек эшләгән конторасына кайткан, бораулаучы булып кергән. Өч айдан кабат мастер. Бу юлы инде катлаулы эшләр буенча...

«Билгеле, катлаулы эшләр мастеры бер селтәнү белән могҗиза тудыручы тылсымчы түгел, шулай да тәвәккәлләргә», — дип уйлады Зәкиев һәм контора директоры Лисов бүлмәсенә кереп китте.

Павлов анда иде инде. Лисов, читләтеп кенә Анатолийдан буровой хәлләрен сораша, мастерның кылларын тартып карый иде.

Анатолий, бүреген салып, бер почмакта утыра, директорның сорауларына бик саран гына җавап бирә. Соң, Иван Игнатьевич буровойдагы хәлләрнең аяныч икәнен, бригаданың нык утырганын үзе белмимени? Авариянең сәбәбе дә директорга яхшы таныш — бораулый торган балчык измәсен дөрес кулланмауда. Гомумән, мастерларның күбесе измәгә бәя биреп бетерми. Су белән бораулый башлаганнан бирле аның, ни өчендер, абруен төшерделәр. Билгеле, су белән бораулау яңа нәрсә, арзанлы, прогрессив алым. Кирәкле катламда гына кулланганда су ифрат яхшы нәтиҗәләр бирә. Тора-бара бораулаучылар измәне онытып куя яздылар, тоташ су белән генә бораулауга күчтеләр. Шуның аркасында җирнең йомшак катламы юылып, забой ишелеп төшү, инструмент кысылу кебек хәлләр ешайды.

Кайбер токымнарны тишеп үткәндә измәдән башка бөтенләй эшләп булмый. Измә борауны әйләндерә, шул ук вакытта скважина көпшәсен сылап, ныгытып баручы бердәнбер арзанлы материал да.

Мастер Горшенин белән бораулаучы Әмир Билалов измәнең әнә шул кыйммәтле сыйфатларын онытканнар, аны әзерләгәндә чагыштырма үлчәвенә дә, суга каршы торучанлыгына да, башка параметрларына да игътибар бирмәгәннәр. Нәтиҗәдә җир астына кудырылган балчык измәсе көпшәк катламны тотып тора алмаган, токым ишелгән, 38 нче скважинада ике километрга якын трубалар колоннасын кыскан. Бу һәркем өчен ачык.

Үзенең ни өчен чакырылуын Анатолий соңыннан гына белде. «Кабул итеп ал син Горшенин бригадасын», — диделәр аңа.

Кинәт әйтелгән бу тәкъдимнән Павлов каушабрак калды:

— Өметсез ул скважина...

— Булдырсаң син генә булдырасың, — диде кисеп Иван Игнатьевич. — Тәҗрибәң җитәрлек...

«Тәҗрибәгә килгәндә, кирәгеннән артыграк, — дип уйлады Анатолий, үзен үчекләп. — Эшне беренче көннән аварияле скважинада башлаган идем, күрәсең, исән буровойда эшләргә язмагандыр...»

Һәм ул техникум эскәмиясеннән чыгу белән Ягупов бригадасына бораулаучы булып килгән кенен искә төшереп алды. Бригада аварияда утыра иде. Өч айдан мастер булды. Вахаев бригадасын кабул итеп алды. Анда да баш чыккысыз авария иде... Катлаулы эшләр мастеры итеп куелгач, кеше ватканны төзәтүче, кеше бозганны турылаучы булып китте. Инде килеп, тагын җимерелгән бер бригадага китереп тыгалар.

Бу бригадага карата Анатолийның директорга ниндидер сораулары, дәгъвалары һәм әйтәсе килгән күп кенә сүзләре дә бар иде, тик Иван Игнатьевичның тәкъдиме шулкадәр кинәт булды, алар барысы да, ничектер, югалып калдылар. Әнә Иван Игнатьевич, торып баскан да, Анатолийга таба омтылып, бөркет кебек карап тора. Юк, ул үз фикереннән чигенмәячәк, каршы килсәң, өстеңә бөркет булып куначак, барыбер ычкындырмаячак. Анатолий аның холкын белә инде...

— Әгәр бәладән коткаручыны мин генә дип табасыз икән, киттем алайса бригадага, — диде Павлов. Ашыгып бүреген, бияләйләрен киде.

— Без барып җитәрбез, — диде директор, Павлов чыгып киткәндә.

Зәкиев өчен бу көтелмәгән хәл иде. Павлов бармас, ялындырыр, киреләнер, аяк терәп каршы торыр кебек иде аңа. Соң, кайсы җүләр инде берсүзсез андый хәтәр бригадага риза булсын! Моңа баш кирәк ич, тәвәккәллек кирәк, батырлык кирәк!

— Аның чыннан да китүеме? — дип сорады ул Иван Игнатьевичтан.

— Бездә ике сөйләшүне яратмыйлар, — диде Лисов горурлык белән.

Моны инде яңа секретарь үзенчә аңлады. «Киләчәктә син дә искә ал, сүз куертма, конкретрак бул», — димәкче директор. Һәм, шуны раслагандай, Иван Игнатьевич сөйләп китте:

— Молодец алар, разведчиклар, күп сөйләп тормыйлар! Берәү булса: «Тәҗрибәм дә юк, тазалыгым да начар, бригадасы да бик бозык, булдыра алмам», — дип зарланырга, җыларга керешер иде. Ә менә, уйлап кара, күпме эшлим, андыйларны күргән юк!

— Димәк, анысы сезнең бәхетегез, — дип куйды Зәкиев, директорның сүзен бүлеп.

— Бәхеттән түгел. Әгәр без разведкага кешеләрне эшкә алабыз икән, алдан кисәтеп куябыз: разведка уен түгел, түзәрлек, чыдарлык булса гына керсен. Һәм шундыйлар гына килә дә. Ул кеше инде белә: тәүлекнең теләсә кайсы вакытында эшкә торып китәргә тиеш, вакытында кайта алмый, җылы аш, җылы өй күрмәскә, шуңар түзәргә тиеш. Ул теләгән киносын, театрын да карый алмый, концертына да бара алмый. Ул, дөресен әйткәндә, хатынының җылы кочагыннан да мәхрүм!

Бу урында инде Зәкиев тә елмаймый булдыра алмады:

— Димәк, разведчик дөнья рәхәтләреннән ваз кичәргә тиеш, дисең инде...

— Шунсыз разведчик та була алмый!

— Шулай да разведчикларга тормыш шартлары тудыру турында уйларга кирәк булыр, Иван Игнатьевич, — диде Зәкиев. — Иң беренче чиратта!

## III

Инде барысы да тынды, үз урынына утырды кебек. Бригада җыелышы тәмамланды, авария өчен ачуланырга тиешлә кешеләр ачуланылды, чара күрергә тиешләренә җәза бирелде. Әйе, мондый эшләр өчен гаепләрне башларыннан сыйпамыйлар шул. Мастер Николай Горшенин бригадасы айның аена бораулау планын үтәмәгән, хезмәт дисциплинасын, бораулау технологиясен бозган, аварияләр ясаган. Күп тапкырлар тәнкыйтьләүгә, кисәтүгә карамастан, мастер эленке-салынкы йөргән, үз белдегә белән эшләгән, коллектив фикеренә колак салмаган.

Лисов җыелышта һәрвакыттагыча кызып, ярсынып сөйләде. Горшенинны эшеннән алып бораулаучы итеп калдырырга, ә бораулаучы Әмир Билаловны эшеннән куарга дигән тәкъдим кертте.

Горшенин аварияда үзенең гаебе юклыгын исбат итәргә теләп карады, түбән урынга риза булмыйча: «Китәм!» — дип куркытып маташты. «Китсәң кит!» — диделәр аңа, ялынмадылар. Ә менә Билаловны яклап бораулаучылар стена булып бастылар. Бер адым да артка юк: «Калсын, эшләсен, гаебен юсын!» Алып калдылар Әмирне.

Гыйбрәтле булды бу җыелыш. Конторада сөйләп күрсәткәнчә, бу бригада кеше-

ләре әле дөньяга бик үк битараф түгелләр икән...

Инде барысы да тынды, контора житәкчеләре кайтып китте, буровой тормышы үз урынына утырды кебек.

Хәзер инде, Павлов, син бригаданың башында, эшлә генә! Көн саен бер вахтаң белән утырып буровоеңа кит, эшчеләреңнең бораулаганын күзәт, ялгышларын төзәт, контораңа шалтыратып трубалар, башка җиһазлар даула. Кич житсә, кайт та, план бүлегенә кереп, ничә метр бораулаганың турында сводка бир, инженерга бораулауның барышы турында отчет яса. Синнән инде хәзер барысын да сорарлар, бөтенесен дә төпченерләр. Буровойга килеп стена газеталарын тикшерерләр, агитмасса эшләре белән кызыксынырлар, бораулау графикларын карарлар. Профсоюз эшлекләләре бораулаучылар түләмәгән взнос өчен тиргәп китәрләр, комсомолецлар үзешчән түгәрәкләрдә катнашмаган өчен тәнкыйть итәрләр. Син инде, иптәш мастер, хәзер барысы өчен дә җавап бирә торган кеше!

Шушы уйлар белән ул беренче мәртәбә бригаданың хуҗасы булып буровойга чыкты.

Элек, катлаулы эшләр мастеры булып эшләгәндә, болай дулкынланмый иде Павлов. Киресенчә, бораулаучылардан ояла, читенсенә иде ул. Эшем кешеседәй буровойга килү, аварияның сәбәпләрен төпченеп йөрү, зур белдекледәй, тәҗрибәле мастер яки бораулаучы кулыннан идарә рычагларын үз кулыңа алу бик кыен иде. Ничектер шунда «йомырка тавыкны өйрәтә» кебегрәк булып чыга иде.

Мастер сәгатьләр буенча азапланды. Инструментны чыгыр белән тарттырып карады, ротор белән әйләндермәкче булып маташты — җир астындагы колонна кымшанырга да уйламады. Аннан эшчеләрне буровойдан куып чыгарды да инструментны йолкытырга кереште. Кырык биш метрлы вышка ыңгырашып сыгылды, трубаның башын эләктергән корыч баулар өзелердәй булып тартылдылар, ләкин җир токымы үз корбанын җибәрмәде.

— Әкренрәк, әкренрәк! — дип кычкырдылар читтә котлары алынып карап торучы эшчеләр. Алар мондый тәвәккәллекнең нинди фаҗигаләргә китергәнен, күргәннәре булмаса да, ишеткәннәре бар иде. Бер елны тали блогы өзелеп төшеп, Әлмәтнең иң яхшы мастеры Белоглазовны да һәлак итте бит.

Чатлама суык булуга карамастан, Павловның бүрек астыннан, яка эченнән пар күтәрелде, ул ак бәс булып кашларына, керфекләренә сарылды. Тирләгән куллары бияләйләрне өнәми башлады, мастер аларны салып ыргытты.

Авариядән авариягә йөри торгач, Павловның гадәтенә бер нәрсә сеңеп калган: ничек кенә булса да, буровойны бәладән коткарырга, бригаданы авыр хәлдән чыгарырга. Ә бу скважина гел өметсез. Скважинаны ташлап, икенче урыннан бораулый башларгамы? Бу кадәр тирәнлеккә житкәч, шушы хәтле озынлыктагы металл колоннаны җир астына күмеп калдырудан да кызганычрак, үкенечрәк нәрсә бармы? Аңа күпме көч куелган, күпме тир түгелгән? Бәлки электәге берәр алым ярап куяр дип, үзе моңа кадәр эшләгән буровойларны, андагы аварияләрне күңеленнән үткәрде, ләкин бер авария икенчесенә, икенчесе өченчесенә охшамый. Бу ысул тегесенә, тегесе монысына ярамый.

Бердәнбер юл — инструментны җир астында өзеп чыгару, шул урыннан читкә таба бораулый башлау иде.

Директор белән инженер бу фикер белән килештеләр. Күп азаплангач, 1300 метр тирәнлектә инструмент өзелеп калды һәм мастер Павловның бу бригададагы беренче метрлары шуннан башланды.

Берничә көн эчендә шактый гына тирәнлеккә төштеләр. Су күрмәгән кешегә су тамчысы да кадерле, дигәндәй, бораулаучылар аңа куанып бетә алмадылар. Үтелгән шушы берничә дистә метрлар моңарчы булдыксызлар исемен алган эшчеләргә дәрт кертеп, аларның күңелләрен күтәреп җибәрергә житә калды.

— Бораулыйбыз бит, төшәбез!

— Мотор тавышын ишетер көннәр дә бар икән! — дип сөйләнәләр иде алар.

Бу метрлар яңа мастер өчен дә бик кыйммәт иде. Шушы метрлар аркасында ул үзе өчен әлегә ятрак күренгән бригада членнары белән азмы-күпме танышырга, сөйләшергә, аларның уй-фикерләрен белешергә өлгерде. Бер-берең белән яхшы таныш булмау — ул тоташ киеренкелектән, сынаулы карашлардан, хәтта шикләрдән дә тора икән.

Тәбәнәк, калын гәүдәле, алма кебек кызыл битле бораулаучы Ибраһим Садриев кирәгеннән артык салмак. Эштә дә әкрен кыймылдыйдыр төсле иде ул Павловка. Әмма смена азагында килсәң, барысыннан

да күбрәк аның вахтасы бораулаган булып чыга. Трубаларны күтәргәндә-төшергәндә, бораy алыштырганда, бу эшләрне аңардан тиз башкаручы юк.

Бораулаучы Николай Трошихин яшьтә дә, эштә дә арада иң өлкәне, ул егерме еллык стаж җыеп килә инде. Йөргәндә һәр адымын үлчәп, чамалап кына атлый торган бу кеше эшендә дә шулай икән. Буровойда кирәксез бер хәрәкәт ясамас, артык бер сүз сөйләшмәс. Идарә пультына килеп бастымы — үз вахтасындагыларны сихерләгәндәй итеп йөртә. Аның ни әйтергә теләгәнен күз карашыннан аңлыйлар.

Иң тырышы, иң тыңлаучаны — Әмир Билалов. Арып егылганчы эшләр, анда да туктауны, ялны белмәс, сер бирмәс. Шушы кадәр уңган кешене теге вакытта директор ни өчен эшеннән куарга исәпләгәндер — анысы аңлаешсыз. Аның ялгышын Павлов шул кергәннән артык карусыз булуыннан күрә. Мастер кушкан, ул үтәгән. Яраса-ярамаса да үтәгән. Күрәсең, мастер сүзе аның өчен законга әверелеп киткән. Әле хәзер дә ул, бичара, күбрәк гаебен юу, үзен аклау өчен тырыша иде, ахры.

Буровойдагы бөтен эшне берүзе эшләп бетерердәй булып йөргән ярдәмче бораулаучы Алексей Курочкин, һәрвакыт үзенең насослары, дизельләре белән мактанырга яратучы Сергей Волковлар да Павловның якын дуслары булып киттеләр.

Катлаулы эшләр мастеры булып буровойдан-буровойга йөргәндә кешеләргә бер дә игътибар итмәгән икән Анатолий. Вакытлы кеше, кунак кына булган икән ул. Аңа нәрсә: аварияне бетердең — хуш, сау бул, икенчесенә кит... Хәзер исә син аларны аңларга, төшенергә тырышасың. Чөнки алар синекеләр. Синең белән һәр көн бер машинада эшкә барасы, бер буровойда көч түгәсе, бер кашыктан ашыйсы кешеләр. Алар хәзер синнән умырып эшләрдәй эшен дә, куандырырлык хезмәт хакын да, вакытында ялын да таләп итәргә хаклылар.

Ә Анатолийның бригада кешеләрен нәрсә белән булса да куандырасы килә, бик килә иде.

Тик боларның берсе дә насыйп булмады. Җитмеш метр тирәнлеккә җиткәч, җир өстыннан фонтан булып су бәреп чыкты. Кешеләр утыз градуслы суыкта сифон астында калдылар. Бозлы су, верховой сәндерәсенә кадәр күтәрелеп, өскә явып торды. Буровой шторм вакытындагы корабльне хәтерләтә иде. Ул да булмады, котырынып буран кузгалды...

## IV

— Әй, юл бир, борыла!

— Артка чиген, артка!

— Читкәрәк ал!

Ярты чакрым буена тезелгән машиналар колоннасы ике ягын кар каплаган тар юлга бөке булып кереп утырган да алга да, артка да китә алмый. Шоферлар берберсенә кычкыралар, тиргәшәләр, кабиналарыннан чыгып көрәкләр белән юл кырыйларын, тәгәрмәч асларын казыйлар, тик берни чыкмый. Күз ачырмаслык буран бөтерелеп һавада уйный, өеме-өеме белән куптарып кар китереп сала, юл ярырга килгән бульдозерларның да тырышлыкларын минуты белән юкка чыгарып ташлый. Олы юл буендагы көрт өеме инде машиналар биеклегә булган.

Артта машиналар артканнан арта, алдагыларын кар эченә тирәнрәк кыса бара. Сигнал, акыру, сүгенү тавышлары күбәйгәннән күбәя.

— Чигенегез, чигенl

— Артка ал, диләр сиңа!

— Бәрдерәм, үпкәләмә!

Урталыкта машиналар арасына килеп кысылган «газик», төрле маневрлар ясап, алга үтәргә азаплана, корсагыннан көрткә бата, тәгәрмәчләре белән кар туздыра.

— Булмый дип әйттем бит, — ди шофер, янында утырган Зәкиевкә.

— Яхшы чакта борылу ягын карыйк...

— Тырышып кара, бәлки үтәрбез...

— Кызык соң бу яңа секретарь, — дип куя эченнән генә шофер, — күреп тора: атна буена буран котыра, буровой өчен кирәк-ярак төяп чыккан машиналар да, вахта автобуслары да, бара алмыйча, кире әйләнеп кайттылар. Ә ул: тырышып кара!

— Мөмкин түгел! — диде шофер, өмет калдырмаслык итеп, һәм тычкан тозагыннан машинасын ничек тә булса чыгару ягын чамалый башлады.

— Их, шушы чакта вертолет булса икән! — дип көрсенде Зәкиев, баш өстендәге давыл җилбердәткән брезент түбәгә карап.

«Чын хыялый кеше икән бу, — дип уйлап алды шофер, — әле буровойларга телевизорлар сатып алу турында сүз кузгата, әле күчмә вагоннарда кызыл почмаклар, кием киптерү өчен сушилкалар, ап-ак җәймәле койкалар булдыру турында сөйләнә башлый. Инде килеп вертолет! Булмый ул безнең разведкада һәм гомергә буласы

да юк! Күрдек инде сезнең кебек секретарьларны! Берне түгел, бишне күрдек! Хыялланудан ары китә алмадылар».

Бу Зәкиевнең генә хыялы түгел иде. Күптән инде бораулаучылар елның теләсә кай вакытында, теләсә нинди һава шартларында буровойга бара ала торган уңайлы транспорт турында хыялланалар. Вездеходлар «теләсә кая йөрер» исемен күтәрсәләр дә, күчәреннән пычрак, түбәсеннән кәрт булган буровой юлларыннан үтә алмыйлар. Кайчакта нефтьчеләр чылбырлы кечкенә танклардан да файдаланалар. Тик алар да җитешле түгел. Аның өстенә бу авыр машиналар тирән карда баталар, кешеләрне аз сыйдыралар, әкрен йөриләр. Ә нефть эзләү чикләре елдан-ел киңәя, үсә.

Разведчиклар хәзер төп базадан 40—60 километр булсалар, киләсе бер-ике ел эчендә Яңа Елховой, Ямаш, Бөгелмә, Баулы мәйданнары бораулана башлаячак һәм ара 100 километрга кадәр артачак. Димәк, эшкә бару-кайту өчен генә дә биш-алты сәгать вакыт китә. Кышкы, язгы, көзге көннәрне исәпләгәндә, бу санны икегә тапкырларга кирәк. Әйе, 4 нче разведка-бораулау конторасының киләчәктә тагын да ераграк чикләргә — Оренбург далаларына китеп эшләү перспективалары барлыгын да сөйләп торалар. Шулай булгач, разведчиклар өчен хәзер вертолетлар да, хәтта җиңел типтагы самолетлар да кирәк.

Буровойга киткән машиналарның әйләнеп кайтулары директорны тәмам пошаманга төшерде. Телефоннан сөйләшеп, вахталарның бүген ничек булса да барып җитәчәкләренә ышандырган, берничә смена тоташ эшләгән бораулаучыларны алыштырырга, аларга ял бирергә вәгъдә иткән иде.

Менә, кар-буранга батып, Зәкиев тә кайтып керде.

— Һич тә үтәргә мөмкин түгелме? — дип, ышанмагандай, каршы алды аны Лисов.

— Мөмкин түгел, Иван Игнатьевич.

— Ә бульдозерлар? Алар нәрсә карый?

— Эшлиләр. Сөреп китәләр дә, артларыннан ук юлны кар баса. Үзләре дә чыга алмый яталар...

Зәкиев, бүреген башыннан салып, эрегән карны идәнгә селки. Иван Игнатьевич йөренә, әле бер тәрәзәгә, әле икенчесенә килеп, тышка карый. Буранның туктарга исәбе юк.

— Болай булса, бик нык утырабыз бит, беләсеңме шуны? — ди ул, Зәкиевкә янагандай. Әйтерсең, буран өчен партбюро секретаре гаепле. — Мастер Җәләлетдинов бригадасында җир асты куышлыгына очраганнар. Никулин бригадасы буровой тезгәнне күтәп ята—вышкачылар килә алмыйлар. Подберезныйныкылар тагын авыр хәлдә, — дип санап китте Лисов. — Ә Павловны әйтеп тә торасы юк...

Павловның буровойдан хәбәр итүенә караганда, скважинада бүгенге көнгә кадәр фонтан ату дәвам итә икән. Өскә ургыган су ташкынын бастыру өчен балчык измәсен авырайтырга — аңа барит кушып җибәрергә киңәш ителгән иде. Шулай эшләп караганнар, ләкин 3—4 көн буена әзерләнгән измә 5—10 метр борауларга да җитмәгән — җир асты упкыны йотып бетергән. Коллектив атна буенча кайта алмыйча буровойда куныл эшли, кешеләр эт урынына арганнар икән.

— Әйе, Павловка җайсыз туры килде,— диде Зәкиев, уйланып торганнан соң. — Бригадага яхшы ният белән китте, ә эше бармый да бармый...

Яңа мастерның хәлен Иван Игнатьевич та яхшы төшенә иде. Павловны коллектив сөенеп каршы алды. Ике ел буена планны үти алмыйча, тариф акчасына гына яшәп килгән эшчеләр җыелышта да: «Җитәр, безнең дә башкалар кебек метрлар бирәсебез, макталасыбыз килә, кешеләр кебек премияләр алып, ял итеп, күңел ачып яшисебез килә!» дигәннәр иде бит. Аларның хакы юкмыни моңа?

Зәкиевнең дә хәлен бик яхшы аңлый Лисов. Бригаданы мораль яктан да, материаль яктан да күтәрмәкче партбюро секретаре. Тик, әлегә булмый шул, җаным. Производствоның бик каты законы бар: продукция бир син аңа, метрлар бир, эшеңне күрсәт!..

## V

Көннәр утырып, язгы кояш карый башлаганда, борау забойга — проект тирәнлегенә якынлашты. Эш җырлап бара, аста, девон катламында, борау чакма ташларны кимереп һаман түбәнгә, нефть горизонтына төшә. Ләкин табигать көче белән сугышып үткән көннәр Анатолийның һич тә күңеленнән чыкмый, торып-торып уйланырга мәҗбүр итә.

Январь азакларында һәм февраль башларында дулап алган бураннар вакытында бораулаучылар буровойда яшәп, өчәр-дүртәр смена рәттән эшләделәр. Түзмәсләр,

буровойны ташлап китәрләр, эш туктап калыр, дип курыккан иде Павлов. Бригаданы Горшениннан кабул итеп алганда, коллектив таркау, бораулаучылар ваемсыз, өметләрен җуйганнар иде бит.

Авырлык килгән чакта кешеләр үзгәрүчән булалар икән. Ничектер, ягымлыланып, яхшырып киттеләр төсле. Бер-берләренә карата кинәт игътибарлары арта, сизгерлекләре көчәя башлады. Син җитди дип йөргән кеше көтмәгәндә шаянлана башлый, җор сүзләр ычкындыра. Моңа кадәр мәзәклегә белән дан алганнары басыла, җитди кыяфәткә керә. Кызык бу кеше дигәнең.

Буровойда өскә явып торган сифон астында да бораулаучылар төшенкелеккә бирелмәделәр, эшне ташламадылар.

**Яңгыр, яу, яу,**
**Майлы ботка казанда,**
**Тәти кашык базарда!**

— дип җырлап та җибәрәләр иде. «Эх, хәзер майлы ботка булса икән!» дип тә куялар. Ничә көннәр җылы аш күрмәгән кешеләр иреннәрен ялап алалар.

Моңа кадәр үтә салмак, сүзгә саран бораулаучы Ибраһим Садриев та алыштырып куйгандай булды.

— Ничава, егетләр, курыкмагыз! Яңгыр файдалы ул. Яңгыр икмәкләрне генә түгел, кешеләрне дә үстерә, — дип, шаяргалап та сөйләнә.

Һәр хәрәкәте үлчәүле булган Николай Трошихин гына һаман бер көенчә калды. Ул эш вакытында шаярганны яратмый. Син аңа гына дикъкать итәргә, аның нәрсә талап иткәнен ымыннан аңларга тиеш.

Бораулаучы Әмир Билаловның кичерешләрен барысы да яхшы аңлыйлар. Авариядән чыгып, яңадан шушы хәлгә төшүне дә ул әле һаман үзенең гаебе дип саный иде булса кирәк. Шуңа күрә кешеләр белән будкага җылынырга да керми. Төнлекләр буена яуган сифон астында, тормоз рычагы янында торып, аның киемнәре бозланып катты, өсте пыяла кебек елтырап калды.

— Әйдә, җылынырга! Нәрсә, киемнәреңнең модасы үзгәрүдән куркасыңмы әллә! — дип, аны иптәшләре будкага мәҗбүри алып керәләр. Аның күңелен күтәрергә теләп, төрлечә шаярталар:

— Бүреген кызгана ул! Кара, ничек бизәлгән!

— Мондый бүрек Монамахның да төшенә кермәгән!

Эшчеләр ардылар, ялыктылар, ләкин бораулау бер генә минутка да туктап тормады. Бораулаучы арыса, аны беренче ярдәмчесе алыштырды, ул ял иткәндә, аның урынына верховой басты. Верховойга өченче ярдәмче алмашка килде. Дизельче бер генә иде — аңа да ял бирделәр. Дизельләрне сүндермичә, моторлар янында чиратлап дежур тордылар.

Анатолий үзе дә буровойдан ике атна кайтмады. Катлаулы зоналарны ничек бораулап үтү, кайсы катламда тормозга ничек басым ясау ысулларын өйрәтә-өйрәтә, көн-төн салкын буровой платформасында басып торды, тәмам хәлдән тайган, чыланган бораулаучыны ял итәргә, йокларга куып кертеп, рычагларны үз кулына алды. Буровойдагылар бу вакытта иркенләп, хәвефсез эшлиләр иде. Бораулаучыларның аңа ирелеп, ышанып китүләре мастерны бераз куркытты да. Җир асты деньясын белеп булмый: кинәт кенә үзе авария ясап куйса?

Тик яңадан андый хәлләргә юлыкмадылар. Инде борау забойда.

Борау забойда. Яшь ананың куркып, хәвефләнеп, шул ук вакытта эчке бер куаныч белән бала көткән кебек, бораулаучылар да яңа урында, яңа нефть чыганагы ачылу минутларын борчылу, шатлык, киеренкелек белән көтәләр.

Павловка калса, нефть чыккан бер җирне ул я бер завод, я бер фабрика салыначак урын дип күз алдына китерә. Скважина тирәсендә берәр авыл-мазар да утырса, ул инде булачак шәһәр дип карый. Янында урман булса — парк.

Лениногорск шәһәре Анатолий килгәндә әле Иске Писмән авылы гына иде. Салам түбәле йортлар, тар, пычрак урамнар, зурзур бәрәңге бакчалары...

Беренче көннәрдә Анатолий шул авыл уртасындагы тау башында, урам эчендә эшләде.

Күз алдында үсте шәһәр. Эшкә баргандә карый: авыл читендә солы үсеп утырган басу уртасында йорт нигезе салалар. Ә тирә-якта колхозчылар тизрәк игенне урып калу өчен ашыгалар. Кайтканда карый — иген егып салынган, йорт инде ике кат булып күтәрелгән, түбәсен ябасы гына калган.

Һәр көн шулай. Бара, кайта, ә солы кырында һаман йортлар калкып чыга, урамнар, проспектлар барлыкка килә...

Бераздан Анатолийны армиягә алдылар. Өч ел хезмәт итеп кайтуына инде Иске

Писмәнне бөтенләй танырлык та түгел иде. Ул чын шәһәр булган. Һәркайда өчәр-дүртәр катлы йортлар, мәктәпләр, клублар... Ул эшкә йөргән урман да урман түгел инде — аны искиткеч матур паркка әверелдергәннәр.

Кем белә, шушы скважинадан нефть чыкса, өнә теге тау буендагы Урдалы авылы да, кечкенә генә булса да, шәһәр булып куяр, янындагы куе урманы паркка әйләнер...

Шуларны күз алдына китергән саен, Анатолий авырлыкларны онытып җибәрә, үзе белән, разведчиклары белән горурлану хисе кичерә. Бөтен эшнең башы разведчикларда бит. Алар килгәнче, исеме-аты ишетелмәгән кыр, тау, елга яки урман гына була. Менә килеп, разведчиклар беренче палаткаларны корып җибәрәләр. Нәкъ Иске Писмән тавы буендагы кебек. Палаткалар янында беренче учаклар ягыла, беренче җыр җырлана, өшеп-туңып беренче төн кунылa. Шуннан беренче буровойлар, тактадан әтмәлләп куелган будкалар, өйләр, конторалар, складлар... Такта өйләрне таш йортлар алыштыра, алар янына мәктәпләр, клублар, башка биналар салына, юлларга асфальт җәелә. Поселок яки шәһәр туа. Вакыт үтү белән, яңа урында нефть табып, буровойлар һаман ераккарак, арырак күчәнә баралар. Ә шәһәр үз урынында. Ул, разведчикларның һәйкәле булып, мәңгегә шунда төпләнеп кала. Йортлары, культуракөнкүреш биналары, завод-фабрикалары белән кешеләргә хезмәт итә.

Разведчикларның эзе мәңгелек, ул кабызып киткән факеллар бер вакытта да сүнми дә, сүрелми дә.

Берничә сәгатьләр инде буровойда команда юк, кычкыру, сөйләшү юк. Эшчеләрнең күзләре бораулаучы Садриевта — ул ни әйтер? Ибраһим, тормоз рычагын бер күтәреп, бер төшереп, әкрен генә девон төбен капшый. Унике ел эшләп, ул шушы рычагларның калтыравы аша да ике мең метр тирәнлектә җир токымын сизәргә, аңа бәя бирергә өйрәнеп беткән. Борау каты доломит катламын үтеп, продуктлы горизонтка — йомшак комташка килеп керде. Менә-менә нефть бәреп чыгарга тиеш. Мондый чакта бөтенесе: мастердан, бораулаучылардан алып аның ярдәмчеләренә, дизельчеләргә, машинистларга кадәр аяк өстендә.

Мастер, сүзсез генә Ибраһим янында басып тора да, аның йөзендә үзгәреш күрмәгәч, улаклар янына китеп, скважина төбеннән юдырылып чыккан җир токымын тикшереп карый. Бу ни хәл: тирәннән «кара алтын» сеңгән комташ килә, ә нефть юк.

— Күренмиме? — дип сорый аннан Ибраһим һәм мастерның күзләренә чекрәеп карый.

— Юк.

— Әллә югыйсә... Скважина кысырмы?

— Кызганычка каршы...

Разведчикларның ничә айлар буе интегүләре бер селтәнү белән җилгә очты. Бу радиуста нефть табылмады. Моңа бик нык кәефләре киткән бригада кешеләрен Яңа Елховой мәйданына күчерделәр.

## VI

Йөз илле километрдан артык юл йөреп, Лисов Павлов буровоена әйләнеп килде, ләкин күңелсезлектән башка бернәрсә дә алып кайта алмады. Беренче скважиналар салынган Яңа Елховой мәйданында тоташ җир асты капризлары. Ямаш мәйданында, карт мастер Сергей Егоян буровоенда су фонтаны атуын дәвам итә. Ул утыз метр биеклеккә күтәрелеп, ике атнага якын инде вышканы коендырып тора. Буровой вышкасы, барлык бораулау инструментлары, дизель моторлары, насослар боз астында күмелеп калган.

Павлов бригадасының хәле тагын да мөшкелрәк. Бер кирегә китсә китә икән: беренче метрларны да борауларга өлгермәделәр — буровой астындагы җир убыла башлады, вышка аву куркынычы туды. Күпме эшләп, Лисов мондый хәлне очратканы юк иде әле. Буровой астын цемент белән ныгытмакчы булдылар, ләкин җир куышы шулкадәрле зур булып чыкты — әкияттәге аждаһа кебек, цементны йотып кына тора. Хәзер инде цемент белән бергә таш, агач, пычкы чүбе — ни туры килсә шуны тутыралар.

Зәкиев тә буровойда иде. Әдип Карипович башкаларга караганда бу бригаданы үз итә төшә, күбрәк биредә булырга ярата, бораулаучыларның һәр адымын күзәтеп, кызыксынып тора.

— Үзгәреш юкмы? — диде Лисов, партбюро секретарен күрү белән.

— Юк. Илле тоннага якын цемент китте инде...

Кай вакытларда Иван Игнатьевич, мастер Павловтан битәр, партбюро секретаре Зәкиевнең үзен кызганып куя иде. Яңа кеше бит, эшен дә күрсәтәсе киләдер... Һич кенә дә син дигәнчә бармый бу дөнья...

Зәкиевнең әле нефть өлкәсендәге белеме дә ишетеп һәм газеталардан укып өйрәнгән берничә сүздән генә тора иде. Гаҗәпләнәсе юк, конторага белгеч булып килмәгән. Кайчандыр ул, комсомол яшендә, туган ягы Тымытыкның ВЛКСМ райкомында оештыру бүлеге мөдире булып эшләгән. Шунда кичке урта мәктәпне тәмамлаган, ике еллык юридик мәктәпкә укырга киткән. Аннан кайткач, Шөгердә прокурор ярдәмчесе, читтән торып юридик институтны бетергәч, прокурор булган.

Бик тә интеллигент кеше инде үзе. Ачулана белмәс, кычкыра белмәс, кешенең җаена гына ятыр — прокурор булган димәссең. Ә бит нефть эшендә, бигрәк тә разведкада гел кеше уңаена гына торып булмый. Кайчагында кешене ачуланырга да, административ җәза бирергә дә, хәтта эшеннән алырга да туры килә.

Зәкиевкә барысы да гаҗәп, сәер тоела: оршышу да, аварияләр дә, вакытында партия җыелышлары уздырылмый калу да, буровойда кешегә нормаль шартлар җитеп бетмәү дә — бөтенесе дә.

Лисов күрә: Зәкиев буровойга барса да үзенә урын таба алмый йөри. Будкага керсә, озак кына бораулау графигына, социалистик ярыш нәтиҗәләренә карап тора, үзе алып килеп тә, әлегә кадәр бераү дә укый алмаган газета-журналларны актаргалый, үзенең тәкъдиме белән яңа гына сатып алган радиоалгычны боргалый башлый.

Аннан буровойга чыга, бик белергә, төшенергә тырышып, бораулаучыларның скважина авызына ничек итеп таш, цемент, агач тутырганнарын карап тора. Күз алдында гына инде өч машина агач, унбиш машина таш, әллә никадәр цемент китте, ә скважинаның бирән тамагы туймый да туймый.

Бораулауны көйләп җибәреп, яхшы гына эшли башласалар, җыелыш уздырырга да, стена газетасын чыгарырга да, лекция-мазарын үткәрергә дә мөмкин булыр иде. Бу хәлдә, кешеләр тир сөртеп алырга да вакыт тапмаган чакта, тәрбия турында нинди сүз булсын? «Әллә инде бу Лисов юри Павловны шундый урынга җибәрдеме?» — дип тә уйлап куя иде Зәкиев.

Шулай да Зәкиевнең бүген бер нәрсәгә күңеле булды. Павлов бригадасын, һич кенә дә кетмәгәндә, шәһәр газетасына мактап язганнар. Шуңа күрә бораулаучылар да бүген, башка көннәргә караганда, дәртләрәк эшләп йөриләр төсле. Күрәсең, кешеләрнең рухын күтәреп җибәрү өчен күп тә кирәкми торгандыр...

Скважинага инструмент төшерелеп, буровойда яңадан бораулау эшләре башлангач, Лисов белән Зәкиев кайтырга чыктылар.

Лисов ялыккан иде, машина утыргычына уңайлырак авышып, ул бер селкенми алга, фаралар белән яктыртылган язгы пычрак юлга карап барды. Вакыт-вакыт папирос алу өчен кесәсенә тыгылуыннан гына, Зәкиев аның нәрсәдер уйлануын сизә иде. «Инде монысын юлга салдык, иртәгә безне нинди сюрпризлар көтә икән?» — дип бара торгандыр, әлбәттә.

Упкын кебек җир асты куышын томалый алмасалар да, буровой нигезен ныгыттылар, вышканы авудан коткарып калдылар. Аннан скважинага юан-юан трубалар төшерделәр. Зәкиевнең моны әле беренче күрүе иде. Скважинаны шул техник колонналар эченнән бораулаячаклар икән. Катлам ишелеп, инструментны кысмасын өчен шулай эшләнә икән. Димәк, ике эш. Бораулау бригадалары арасында иң артта калган мастер Павлов тагын икеләтә артта калачак.

— Павлов кайчан булса да алга чыга алырмы, юкмы? — дип тынычлыкны бүлеп сорады Зәкиев. — Син ничек уйлыйсың, Иван Игнатьевич?

Лисов дәшмәде, һаман алга карап баруында дәвам итте.

— Яңа мәйданда, әйтик, тиздән бораулыйсы Баулы, Бөгелмә мәйданнарында.

— Анда тирәндә нәрсә бардыр бит әле, тамугмы, оҗмахмы...

— Геологик шартлар яхшы булгандa?

— Чыга алыр иде... Күрдең, ничек эшлиләр!

— Әйдә алайса, бу скважинаны бетергәч күчереп карыйк.

— Бетерсен, карарбыз.

— Хәл алсыннар иде бераз. Кешеләргә гел тәмуг кына димәгән...

## VII

Вахта алышыну вакыты буровойда үзенә бер төрле бәйрәм төсен алып куя. Смена килергә ярты сәгатьләр вакыт калгач, вахта җитәкчесе эшне туктатырга команда бирә. Моторлар колак тондыргыч гүләү-

ләреннән тыналар. Бораулаучылар, кулларына кайсы кирәк, кайсы себерке, кайсы су сиптерә торган шланг алып, буровойны җыештыра башлыйлар. Бу тәртип буровойда закон булып кергән — арыгансыңмы син, туңгансыңмы, чылангансыңмы — үзеңне алыштырасы иптәшләреңә эш урыныңны чиста, инструментларыңны тизәк итеп тапшырырга тиешсең.

Машиналарың, агрегатларың карыйсы карала, майлыйсы майлана. Буровой идәне дә сап-сары булып юыла, инструментлар да ялт итеп кала. Инде күзләр буровой юлында. Шуннан соң инде арада берсе — билгеле, бик ачыкканы, я арыганы — кычкырып җибәрә:

— Киләләр!

Еракта үрләр артында таныш автобусның түбәсе, бераздан борыны, аннан бөтен гәүдәсе күренә башлый.

— Киләләр!

Эшчеләр, туй каршылагандай, кулларын болгый-болгый, кычкыра-тавышлана буровойдан чыгалар, машинаның каршысына йөгерәләр.

Автобус ашыкмый гына бер кырыйга килеп туктый. Аннан шулай ук шау-гөр килеп бораулаучылар коелалар. Ни дәверләр күрешми торганнар диярсең — китә күрешү, җилкәгә сугышу, юк-бар сүзләр әйтешү:

— Нихәл, туган, анда ниләр бар? Шәһәр урынындамы?

— Әбиең сәлам әйтте, бабаң утырмага килсен диде!

— Кая, җылы кабартма алып килмәдеңме?

Павлов аз сүзле, үтә тыйнак кеше. Бер хәсрәтсез балалар кебек көлешкән бораулаучыларга гаҗәпләнеп тә, көнләшеп тә карап тора да:

— Ярый, егетләр, уен-уен белән... Бораулау ничек барды? — дип сорый.

Анда да шаяру:

— Күңелсез бу буровойда! Муеннан суга чумып, башыңнан бозга катып эшләмәгәч эшмени ул!

— Ярар, — ди Анатолий, җитди генә итеп, — бик симерсәгез, күчерүне сорап карармын!

Бүген ул, чыннан да, Бөгелмә мәйданыннан Оренбург далаларына күчену турында приказ алып килгән иде.

Егетләрнең кәефләре күтәренке, күңелләре көр. Бөгелмә мәйданына күчкәннән бирле бригада конторада беренчелекне алып бара. Бораулаучылар 1962 елда беренче мәртәбә планны 18 ноябрьга ук үтәделәр, ә декабрь башларына инде, 11750 метр бораулап, йөкләмәләрен дә тутырдылар, ел азагына кадәр планнан тыш тагын 300 метр җир тиштеләр. Бөтен 1963 ел буена бригада кешеләре почет тактасында торды.

Әмма Яңа Елховой мәйданыннан соң бригадага хәл алу өчен бирелгән Бөгелмә мәйданы да бораулаучыларны кочагын җәеп каршы алмады. Биредә дә, Яңа Елховой мәйданындагы кебек, су бәреп чыгулар, җир асты куышлары, скважина ишелүләр адым саен булып кына торды. Аның өстенә алмаз борауларның да теше үтмәс каты токымга юлыктылар. Ярты метр төшкән саен, ике километр тирәнлектәге трубаларны күтәреп, борау алыштырырга туры килә иде монда. Барлык операцияләрне дә төгәл, тиз, оста башкардылар егетләр.

Хәзер аларны тагы да ераграк урынга, катлаулырак мәйданга, авыррак эшкә җибәрәләр. Бүген мастер бригада членнарын будкага җыеп, шул турыда хәбәр итәргә тиеш.

Барысы да утырып беткәч, Анатолий бер мәлгә каушап калды. Ничек башларга?

Разведка тормышын «чегән тормышы» дип бораулаучылар тикмәгә генә әйтмиләр. Эш гомер буе күченеп йөрү, урын алыштыру белән бәйләнгән.

Буровой — кечкенә завод, диләр. Барлык булган буровой хуҗалыгын: алтмыш тонналы вышкаң, бер-берсе унар тонналы бишалты дизель моторларың, насосларың, тәгәрмәч өстендә йөреп какшап беткән будкаң, машиналарың, бораулау станокларыңны әйләндерүдән алып чәеңә кадәр җылытучы электр станцияң һәм эреле-ваклы башка җиһазларың белән яңа урынга килеп туктыйсың. Урнашасың, мең бәлаләр белән эшне көйләп җибәрәсең, бораулый башлыйсың. Көннәрдән бер көнне скважинаң тәмам. Күчәргә, диләр. Китәсе килми, нәрсәдер кызганыч сыман. Шушы сине интектергән буровоеңа, каһәрләнгән скважинаңа, каргалган мәйданыңа күнегелгән, барысы да сиңа якын. Моны мастер гына түгел, һәр бораулаучы кичерә.

Ниһаять, Анатолий үзенең дулкынлануын басып:

— Беләсезме, егетләр, нәрсә өчен җыйдым? — дип сорый.

Будкада тынлык урнаша. Нәрсә өчен икән?

Мондый җыелышлар, гадәттә, берәрсе гаепле эш эшләсә, я бригада артта кала

башласа, я алдынгы урынга чыгып, аңа күчмә Кызыл Байрак бирелгән очракларда була. Әлегә бригадада тәртипсезлекләр булганы юк, коллектив моңача һич кайчан күрелмәгән тизлек белән бораулый, конторада беренче урынны тота.

— Без инде, мастер, премия көтәбез, — диләр бораулаучылар.

— Юк, белмисез, — ди берсе, — профсоюз взносы түләнмәгән, менә ни өчен җыйган!

Павловны алай килделе-киттеле сүзләр белән генә көлдереп булмый. Көлмәсә дә, чама белән генә шаярып алганга каршы да түгел үзе. Бу юлы да Павлов шаяруга шаяру беләнрәк җавап бирде:

— Күңелсез монда. Муеннан суга, башыңнан бозга катып эшләмәгәч, нинди эш инде. Күчәбез, егетләр!

— Күчәбез? Кая?

— Нәрсәсе ярамаган бу мәйданның?

— Әле бит бораулыйсы урыннар күп!

Будкада шау-шу кузгалды.

— Менә шулай, — диде Павлов һәм зәңгәр күзләрен кыса төшеп елмайды да сөйләп китте: — Оренбург далаларына, яңа мәйдан ачарга китәбез.

— Оренбург далаларына? Еракмы соң ул?

— Үрелеп тә җитәсең! Лениногорскидан автобус белән Бөгелмәгә. Тимер юл белән Чишмә станциясенә. Аннан тиз йөри торган поездлар белән генә Кинель шәһәренә, Куйбышев өлкәсенә...

— Сызгыра беләсеңме, әби!

— Килеп җитмәдек әле. Кинельдән, йомшак вагоннарга гына утырып, Бозаулык шәһәренә барып төшәсең...

— Җир читендә ич!

— Тукта әле, барып җитмәдек. Бозаулык шәһәрендә сине комфортабельле автобуслар көтеп торалар. Ягъни мәсәлән, без хәзер утырып вахтага йөри торган автобуслар. Аннан ерак калмый инде. 70—80 километрлар үтсәң, без бораулыйсы Каликин мәйданы булыр.

— Я аллам! Бөтенләй күченергәме?

— Юк, барып-кайтып эшләячәкбез. Менә шулай туганнар. Бездән үрнәк өчен бер тирән скважина бораулап күрсәтүне сорыйлар, өч мең, өч ярым мең метрга...

— Өч мең ярым!? Җир шарын тишеп чыкмабызмы соң?

Бораулаучылар тып-тын калдылар. Һәркем үзенчә уйлый, үзенчә фикер йөртә, мөмкинлекләрен үлчәп, чамалап карый. Бу кадәр ерак урыннарга барып, Татарстан бораулаучылары тарихында беренче тапкыр тирән скважиналар салу көчтән килерме? Бу мәйданның холкын өйрәнеп беттек, иң зур тизлекләр белән бораулый башладык дигәндә генә тагын яңа мәйдан, билгесез тирәнлекләр, мәгълүм булмаган токымнар... Анда аларны нинди күңелсезлекләр, җәфалар, нинди шатлыклар көтә икән?

Мастер күзләрен бораулаучыларга төкәгән. Әнә бригаданың иң уңган бораулаучысы Ибраһим Садриев, кызарып, бүртенеп, бер почмакта утыра. Тегә салкыннарда су эчендә эшләп, радикулит чире алды, билен тота-тота гына утыра. Бәлки шуңа да дәшми торгандыр?

Тагын бер вахтаның башлыгы, Ромашкино, Шөгер, Яңа Елховой мәйданнарында дан тоткан бораулаучы Иван Трошихин да: «Бу елларда какшадым», — дип йөри. Ул нәрсә әйтер? Ә яңа мәйдан, тирән скважина өчен аның тәҗрибәсе, сизгерлеге, оста куллары бик кирәк булачак.

Аның янәшәсендә — буровой җиһазларының ун ел буена алышынмас хуҗасы Сергей Волков. Аңа ышана инде Анатолий. Бригаданың парторгы, бетмәс-төкәнмәс энергияле кеше, үз машиналары кебек, туктаусыз, ватылусыз эшли. Вакытында ашамау аркасында ашказаны авырту белән интексә дә, әле аның бирешергә исәбе юк.

Тагын бер төркем уңган, таза яшьләр үсә. Шөгер, Яңа Елховой кышында үзен чын егет итеп күрсәткән, тимер кебек нык Фәтелгаен Кашапов, дүрт ел Әфганстан буровойларында эшләп кайткан Петр Голдобин, бөтен эшне берүзе генә кочаклап алырдай булып йөрүче Алексей Курочкиннар бар. Бу егетләр белән Оренбург далаларына гына түгел, җир читенә барырга була.

— Ну, егетләр, булдыра алырбызмы?

Тавышлар бердәм яңгырады:

— Эшләргә икән, эшләргә!..

## VIII

Павлов бригадасының Оренбург якларыннан кайтуын Лисов ике еллап көтте. Башта совнархоздан: «Бер генә скважинаны бораулап күрсәтсеннәр дә кайтырлар», — диделәр. Күрсәттеләр. 3400 метр тирәнлектәге 1 нче номерлы скважинаны егетләр гадәттә булмаган тизлек белән үтеп, совнархоз заданиесен срогыннан алда тәгәл-

ләделәр. Элек икешәр ел бораулаган тирәнлек тугыз ай ярымда яуланды.

Башка өлкә бораулаучыларын шаккатырып, кайтырга җыендылар. Җибәрмиләр. Тагын бер генә скважинаны бораулап күрсәтегез инде, янәсе, очраклы хәл түгел микән?

Күз алларында кабат бер скважинаны тиштеләр. Анысы да срогыннан элек. Тизлек тагы да артык: станок-айга — 1470 метр. Янә сорыйлар: «Тагын берне генә». Шулай итеп рәттән алты тирән скважина бораулапды.

Татарстан бораулаучылары оренбурглыларга ошап китте күрәсең, соңыннан бер бригаданы гына түгел, алты бригадасы, вышка-монтаж участогы һәм барлык хуҗалыгы белән бөтен контораны сорый башладылар. Үзләренекен иттеләр дә. Элек «Татнефтегазразведка» тресты каршында булган 4 нче разведка-бораулау конторасы хәзер «Оренбургнефть» берләшмәсенә буйсына.

Яңа урынга күчүне, ничектер, авыр кичерде директор. Юк, Иван Игнатьевич эгоист та, индивидуалист та түгел, тар ведомство карашлары белән дә яшәми. Эш анда түгел. Мәсьәлә озак еллар буена бер урында эшләүдә, күнегүдә.

Иван Игнатьевич Лисов 45 еллык гомеренең төгәл яртысын нефть эшенә бирде. Аның да уналты елын Лениногорскида, шушы 4 нче разведка-бораулау конторасында тоташтан директор булып үткәрде.

Контора Татарстан җирлегендә туды, шунда кадрлар туплады, үсте, ныгыды. Хәзер инде, әзергә бәзер дигәндәй, кинәт кенә аны оренбурглылар ала. Моны озак вакытлар башына сыйдыра алмыйча йөрде Лисов.

Контораны Оренбург далаларына күчерсәләр, кешеләр шәһәрдәге уңайлы квартираларын яңадан вагоннарга, палаткаларга алыштырырга риза булырлармы? Бораулаучылар анда барудан баш тартсалар, барганнары да, кыр шартларына түзә алмыйча, качып бетсәләр, ни эшләрсең?

Бу көннәрне мең төрле уйлар, кичерешләр белән яшәде директор.

Директордан бигрәк бораулаучыларның семьялары борчылды. Алар хаклы. Тәпләнеп, кешеләрчә яшәрбез дип, ничәмәничә еллар буена баракларда тордылар, шәһәр салынуын, йортлар өлгерүен өметләнеп көттеләр. Ниһаять, тилмереп көткән йортлар өлгерде, бораулаучылар капиталь квартираларга күчтеләр. Бала-чагалары иркен мәктәпләргә, бакчаларга, яслеләргә йөри башлады. Хәзер Оренбург далаларына китеп, яңадан элеккегә хәлгә кайтсалар ни булып бетәр?

Ләкин Министрлыкта бу проблеманы акыллы хәл иттеләр. Бернинди күченү, урыннан кузгалу булмаячак, йөреп эшләргә, диделәр. Ә вахтага бару-кайту өчен бердәнбер җайлы транспорт булган вертолет тәкъдим ителде.

## IX

Вертолет, винт-канатларын җилпи-җилпи, шәһәр өстенә күтәрелде, аз гына авыша төшеп, көньякка борылды.

Бер-берләренә нык сыенып утырган бораулаучылар тәрәзәгә иелделәр. Аста таныш кырлар, бормалы юллар, яфраклары коелган урманнар, игене урып алынган, сөрелгән басулар ачылды. Күп урыннарда уйдык-уйдык кар ята.

Вахта буровойга бара. Һәр көн шушыннан — бер үк кырлар, юллар, урманнар, иген басулары өстеннән очсалар да, бораулаучылар һаман тәрәзәләргә иеләләр, аска карыйлар. Гүя вертолет аларны, дөньяны биеклектән күрсеннәр дип, гыйбрәт өчен алып менгән.

Кайсы гына тәрәзәгә күз ташласаң да, узган хатирәләргә килеп чуаласың. Ел фасылына карап кырлар үзгәрә, урманнар төрләнә, басулар яңа төс ала, әмма үз эзләрең җирдән дә, күңелдән дә җуелмыйлар икән.

Алдагы урыннарның берсендә Павлов утыра, ул вертолет борылган саен, каерылып-каерылып шәһәргә, шәһәр яныннан ук башланып киткән урманнарга карый.

— Нәрсә, Толя, әллә балаларың кул болгыйлармы? — ди янәшәсендә утырган Садриев.

— Яшь чаклар искә төшеп китте.

Шушы урман өстендә генә Анатолий беренче тапкыр буровойда эшли башлаган иде. Бер урыннан ике игезәк скважина тиштеләр. 1700 метр тирәнлектә инструмент кысылып калды. Бик озак маташтылар скважинада. Трубаларны борып чыгаруга гына егерме көнләп вакыт китте. Яңа гына парта артыннан чыккан, куллары моңарчы салкын тимер, битләре ачы җил күрмәгән кичәге студент өчен чыдап булмаслык авыр тоелды буровой эше.

— Гел шушылаймы? — дип сорады ул бер көнне бораулаучылардан.

— Гел түгелен түгел, әмма аралаш! — дип келделәр тегеләр.

Уенын-чынын кушып әйткән бу сүзләрдә дөреслек булган икән.

— Беләсеңме, Ибраһим, — диде Павлов, елмаеп Садриевка карады да: — Әнә, Зәй-Каратай мәйданы.

Армиядән кайткач, белдекләнәнеп, Егоян, Тулышев кебек Баку, Грозный мастерларын ничек итеп бораулмаска өйрәтеп йөргән урыннар...

— Җәмәгать, әнә теге урман артында 38 нче буровой түгелме? — Садриев урыныннан сикереп торырдай булды. — Шул! Әнә вышкасы да күренеп тора!

— Нәрсә юкны сөйлисең! Аннан нефть чыкмады ич!

— Аның каравы менә диген саф су чыкты! Әмирнең гөнаһларын шундый итеп юды — судан ак, сөттән пакь булып калды егетең!

Бораулаучылар вертолет тавышын күмеп көлештеләр.

Шул арада инде вертолет Бәгелмә мәйданы өстеннән оча, тимер юлны кисеп, Татарстан чиген үтә, Оренбург өлкәсенә керә, хатирәләрне тагын яңартып җибәрә. Автомашиналардан поездга, поездан автобусларга күчә-күчә, икешәр тәүлек эшкә барган чаклар, салкын вагоннарда яшәп, беренче тапкыр тирән скважиналар салган вакытлар искә төшә.

Бозаулык шәһәре янындагы Каликин мәйданы совнархозның тәҗрибә участогы иде. Башкортстаннан да, Куйбышевтан да, Оренбургның үзеннән дә бар иде бораулаучылар.

Үзара көч сынашу башланды. Кем бригадасы станок-айга 1000 метр тизлек белән җир тишә — ул рекордчы, совнархоздан аңа беренче бүләк бирелачәк, диделәр.

Алар куйган тизлекне бригада Бәгелмә якларында эшләгәндә үк узган булса да, Павлов шикләнә калды: җир таныш түгел, скважина тирән булачак, кешеләр ерактан килеп эшлиләр, яңа шартларга күнмәгәннәр. Оренбурглылар үзләре дә станок-айга 600—800 метр гына бораулыйлар икән.

— Башкалардан уздырмасак, Татарстан бораулаучылары исемен дә күтәреп йөрмибез! — диделәр Павловнныкылар.

Татарстан бораулаучылары! Каликин мәйданына командировка белән эшкә килгән башка бораулаучылар бу сүзне әеручә ихтирам белән әйтәләр, безнең егетләргә үтә ышаныч һәм хөрмәт белән карыйлар иде. Аларның һәммәсе дә яхшы белә: нефть чыгару буенча карт Бакуны ун ел эчендә узып киткән, илебездә алына торган «кара алтын»ның дүрттән бер өлешен бирүче Татарстан нефтьчеләренә тиңдәш юк. Советлар Союзында беренче буларак тирән девон катламын ачкан, роторлы станокны алыштырып, беренче тапкыр турбина белән, балчык измәсе урынына су белән бораулый башлаган Татарстан егетләре һәркайда мәгълүм иде, мактала иде. Татарстан бораулаучыларының елга 40 мең метрдан артык җир тишеп үтүләре, вышкачыларының 6—7 сәгать эчендә буровой корып куюлары башка республикаларда, бездән читтәге нефть чыганакларында эшләүче бораулаучылар арасында легенда итеп сөйләнә иде. Менә шул легенда батырлары алар белән күзгә-күз очраштылар, алар белән кулга-кул тотынып эшли башладылар.

Һәм сер бирмәделәр дә егетләр. Берсеннән-берсе тирән, катлаулы булган алты скважинаны срогыннан элек тәмамлап, разведка тарихында күрелмәгән рекордлар бирделәр, үзләрен данга күмделәр.

— Артыграк тырышып куйдык, ахры, — дип уйлады Павлов. — Юкса, безне монда алмаган да булырлар иде...

Хәзер инде көн саен вертолет Оренбург кырларына оча.

— Бу чикерткәгә утырып йөри башлаганнан бирле, йокы туймый башлады әле,— диләр бораулаучылар. — Күзне йомарга да өлгермисең — буровой!

Ләкин аларның берсе дә йокымсырарга уйламый, үзләре узган җирләрнең һәр адымын, үзләре бораулаган һәр скважинаны калдырмый, дикъкать белән күзәтеп баралар. Хәтта хыяллары вертолеттан күренмәгән еклардагы буровойларда да булырга өлгерә.

— Әнә тегендә сөтле буровой булырга тиеш!

Ул буровойның ни өчен сөтле икәнен дә яхшы белә Павлов. Алексей Курочкин вахтасы газга исергән иде. Шул көннән эшчеләргә сөт бирә башладылар...

Кечкенә конторада Лениногорск разведчикларының еллык бораулау заданиеләрен үтәүләре уңае белән тантаналы җыелыш булды. Разведчиклар 14 ноябрьдан башлап 1968 ел өчен эшлиләр.

Бригада адресына, Павловка, аның бораулаучыларына карата җылы, матур сүз-

ләр әйтелде җыелышта. Бригадада оештыру эшләре яхшырган, тик торулар кимегән, хезмәт дисциплинасы күтәрелгән. Контора коллективының тырышлыгы нәтиҗәсендә, хәзер бораулау тизлеге 10 процентка күтәрелгән, бораулау бригадаларында файдасыз вакыт шактый кимегән. 10 ай эчендә оештыруга киткән тик торулар 1183 сәгатькә кыскарган. Бу уңышларны ишетү бөтен бригада бораулаучыларының уртак шатлыгы иде.

Нефть эзләүчеләр тагын яңа үрләр билгеләделәр — ел ахырына кадәр планнан тыш 6 мең ярым метр җир катламын тишеп үтәргә йөкләмә алдылар.

Бер уйлаганда бик күп бу. Бу — илебезгә өстәмә рәвештә ун меңләгән сум акча, йөзләрчә мең тонна нефть бирү дигән сүз.

Егетләрнең кәефләре күтәренке. Алар нык ышаныч, зур дәрт белән яңа биеклекләрне штурмларга баралар.

Вертолет буровойга килеп җитте. Менә күрегез, элек ничек идек тә, хәзер ничек булдык, дигән төсле, ул нәкъ буровой естендә асылынып тора. Ә аста, кечкенә бер шәһәрчекне хәтерләтеп, ялтырап торган металл вагоннар тезелгән. Берничәсе йоклар өчен. Эчендә ак җәймәләр җәелгән икешәр катлы койкалар. Берсе — киемнәр киптерү вагоны. Икенчесе — буровойның «конторасы» — мастер бүлмәсе. Салкын ашларны да күптән оныттылар инде бораулаучылар. Газы, суыткычы белән бөтен бер вагон-ашханәләре дә бар. Ә тегендә, тышкы ягы төрле плакатларга, лозунгларга төренгәне — вагон-кызыл почмак. Ял вакытында китаплар, газета-журналлар укырга, радио тыңларга, өч каналдан телевизор карарга була. Шәп яшиләр егетләр.

Аста, буровойның кечкенә «аэродромында», инде кешеләр җыелган, кул болгыйлар, баш киемнәре болгыйлар, кычкыралар:

— Нәрсә карап каттыгыз, тизрәк төшегез!

— Аш суына, аш!

— Юк, буровой суына!

Вахта алмашыну хәзер дә үзенә бер төрле бәйрәм.

◇ П ◇

**Мирсәй Әмир**

# ИҖАТ ДӘРТЕ[1]

Иптәшләр! Бүген сезнең алдыгызда хисап бирергә җыелган идарәнең сайлануына биш ел тулып узды. Язучылар союзының уставы буенча, без бу съездны үткән елның январь аенда чакырырга тиеш идек. Ләкин ул елда Совет властеның 50 еллык юбилее уңае белән уздырылган төрле чаралар болай да бик күп булу сәбәпле, безгә аны бераз кичектерергә туры килде. Чираттан тыш чакырылган алтынчы съезд булганга әле өч кенә ел узуы да безгә чираттагы бу съездыбызны ашыктырмаска мөмкинлек бирде.

VI нчы съездны чираттан тыш чакыру РСФСР язучыларының II съездына делегатлар сайлау өчен кирәк булды. Устав срогы әле үтмәгән булганлыктан, анда идарә яңадан сайланмады, ләкин аның хисап доклады тыңланды. Шуңа күрә мин бүген VI нчы съездга кадәр булган чорга артык тукталмыйча, нигездә соңгы өч еллык эшебезне, шул чордагы иҗат практикабызны күздә тотып фикер йөртү дөрес булыр дип уйлыйм. Билгеле, искә төшерү тәртибендә генә булса да, VI нчы, хәтта V нче съездыбызга кадәр булган кайбер эшләр турында да берничә сүз әйтергә туры килер. Чөнки әдәби иҗат турында сүз барганда календарь сроклары белән генә эш итү мөмкин түгел.

V нче съездда без, партиянең XX нче съездыннан соңгы чорда, җитәкчелек һәм ил белән идарә итү эшләрендә шәхес культы тудырган хата һәм кимчелекләр фаш ителеп, ленинчыл демократия урнаштырылу нәтиҗәсендә туган уңай шартларда язучыларыбызның иҗат активлыгы күтәрелү турында әйткән идек. Аеруча проза жанрында, моңарчы татар әдәбияты тарихында күрелмәгән дәрәҗәдә күп санда яңа әсәрләр — романнар, повестьлар язылуы, ул елларда иҗат ителгән әсәрләребезнең сыйфат ягыннан да яңаруы, эчтәлекләре белән халык тормышына якынрак килүләре, чынбарлыкның катлаулы мәсьәләләренә тирәнрәк үтеп керүләре турында сөйләгән идек. Ул уңышларыбызның конкрет мисаллары төсендә Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» романына, Ф. Хөснинең «Утызынчы ел», Г. Әпсәләмовның «Мәңгелек кеше», Гариф Ахуновның «Хәзинә» романнарына, Р. Төхфәтуллинның «Йолдызым», Эдуард Касыймовның «Кояш көн дә чыга» повестьларына һәм башка күп әсәрләргә тукталган идек.

Аннан соңгы иҗат практикабыз алган юнәлешебезнең дөрес булуын күрсәтте. VI нчы съездга без яңа уңышлар белән килдек. Атилла Расихның «Язгы авазлар» һәм «Ике буйдак» романнары, Н. Фәттахның «Бала күңеле даладa»сы, Эдуард Касыймовның «Гомер ике килми» романы, татар совет әдәбияты өчен әле яңалык булган мемуар яки истәлекләр жанрында язылган әсәрләр: Ф. Хөснинең «Минем тәрәзәләрем», М. Максудның «Сагынылган минутлар» китаплары, драматургиядән Риза Ишморатның «Давылны каршылап», Нәкый Исәнбәтнең «Гөлҗамал» драмалары; поэзия буенча Хәсән Туфан, С. Хәким шигырьләре игътибар үзәгендә булдылар. Шулай ук өлкән буын һәм яшь язучылардан бик күп иптәшләрнең яңа әсәрләре турында әйтелгән уңай фикерләр һәм тәнкыйть сүзләре ул съездның эчтәлеген тәшкил иттеләр.

Алтынчы съездан соң үткән өч ел вакыт эчендә дә язучыларыбызның иҗат активлыгы кимемәде. һәм гомумән республикабызда әдәби хәрәкәт бу чорда аеруча җанлы төс алды. Шулай булуы табигый да: чөнки бу еллар әһәмиятле тарихи вакыйгаларга, зур юбилейларга бай булдылар.

РСФСР язучыларының II нче съезды, СССР язучыларының IV нче съезды шушы чорга туры килеп, әдәби хуҗалыгыбызны кат-кат барларга этәргеч булдылар һәм безгә алдыбызда торган проблемаларны дөньякүләм югарылыктан карап ачыкларга, якындагы бурычларны конкретлаштырырга ярдәм иттеләр.

Илебезнең экономика һәм культура үсешенә аеруча көчле йогынты ясаган, аларга билгеле юнәлеш биргән зур тарихи вакыйгалардан партиянең XXIII съезды белән Совет хөкүмәтенең 50 еллык юбилеена багышланган сессия дә шушы елларга туры килделәр.

XXIII нче съезд һәм юбилей сессиясе материаллары яктылыгында без Советлар Сою-

[1] Татарстан язучыларының VII нче съездында сөйләнгән доклад.

зының, җир шары күләмендә беренче булып фәнни социалистик нигезгә баскан, шул нигездә гөрләп үсеп баручы буларак, заман рухына җавап бирү ягыннан карaганда иң алдынгы, иң прогрессив ил булганлыгын тагын да ачыграк күрдек.

Күңелләребездә шундый илнең гражданнары булу белән горурлану хисе тагын да көчәйде. Һәм бу бөек тойгы барлык совет кешеләрен үз өлкәләрендә тагын да дәртләнебрәк эшләргә, каләм ияләребезне тагын да илһамланыбрак иҗат итәргә рухландырды.

## ӘДӘБИ ТАРИХ

Язучыларыбыз бу соңгы өч ел эчендә укучыларыбызны нинди яңа әсәрләр белән куандырды соң?

Бөек Октябрьның 50 еллыгы — аңа хәзерлек чоры һәм юбилей елы үзе — Союзның оештыру эшләренә генә түгел, язучыларның иҗатларына да уңай йогынты ясады. Аларга билгеле бер юнәлеш бирде. Узган съездларыбызда без бүгенге әдәбиятыбызның җитди кимчелекләреннән берсе итеп, тарихи-революцион темага язылган әсәрләребез юк дәрәҗәсендә аз икәнлеген әйткән идек. «Казан утлары» журналының үткән елгы саннарында без Атилла Расихның «Ямашев» романын укыдык. Россиядә Октябрь җиңешенә китергән данлы революцион көрәшнең художестволы тарихын язган, шул көрәшләрдә катнашкан, җитәкчелек иткән тарихи шәхесләрне үз исемнәре белән гәүдәләндергән әдәби әсәрләргә безнең татар совет әдәбияты соң дәрәҗәдә мохтаҗ.

Шушы ихтыяҗны үтәү юлында Атилла Расих зур һәм батырларча кыю адым ясады. Кыю дим, — чөнки Казандагы һәм Татарстандагы революцион көрәш тарихы ифрат дәрәҗәдә катлаулы һәм әдәби планда хәл кылу өчен зур талант һәм белем өстенә, батырлык та сорый торган авыр чорлар аша үтеп килә. Аның өстенә, дөресен әйткәндә, безнең татар әдәбиятында туры мәгънәсендә тарихи роман туып җиткәне дә юк бит әле. Бу юлда беренче җитди адым итеп каралган «Тукай» романына да тәгәлләнү насыйп булмады. Талантлы шагыйребез һәм драматургыбыз Әхмәт Фәйзи, үзенең проза өлкәсендә дә көчле каләм иясе икәнлеген күрсәтеп өлгерсә дә, Тукай гомеренең иң катлаулы революцион көрәш чорларына туры килгән чагын язып өлгермичә арабыздан китте. Бу җөмләгә тагы Ш. Маннурның «Муса» романын өстәргә булыр иде. Тик хәзергә бу әсәр әле тулы килеш чыгып укучы кулына барып җитмәгән булганлыктан, аның турында тулырак фикер әйтүне алдагы көннәргә калдырып торырга туры килә.

Бездә шартлы рәвештә тарихи дип атарга мөмкин булган, ягъни билгеле бер тарихи чорны алып та, аны конкрет тарихи шәхесләргә бәйләп түгел, бәлки язучы уйлап чыгарган образлар аша сурәтләгән шактый көчле әсәрләр бар. Галимҗан Ибраһимовның «Безнең көннәр», Кави Нәҗминең «Язгы җилләр» романнарын, Г. Бәшировның «Сиваш» повестен һәм соңрак елларда язылган кайбер әсәрләрне санарга мөмкин.

Ә менә тарихыбыз күренекле шәхесләргә шактый бай булса да, шулар турында туры мәгънәсендә тарихи романнарыбыз юк диярлек. Шуңа күрә беренче рус революциясе елларында Казан большевикларының татар группасына уңышлы җитәкчелек иткән, татар телендә беренче революцион прокламацияләр тараткан, беренче большевистик газета чыгарган, Тукай тарафыннан дөньядагы иң гүзәл кеше итеп бәяләнгән һәм татар әдәбиятында революцион-демократик агымның туууына, үсүенә зур йогынты ясаган профессиональ революционер-большевик Хөсәен Ямашев һәм аның көрәштәшләре турында роман язуны мин аеруча әһәмиятле эш дип карыйм. Дөрес, без әле Расих романының да беренче китабын гына күрдек, хәзер инде без аның Казандагы революцион хәрәкәт һәм әдәбият тарихы өчен тагын да катлаулырак чорны эченә алган икенче китабын көтәбез. Язучының беренче китапта ирешкән уңышлары безне өметләндерә. Дөрес, анда әле әдәби яктан күзгә бәрелеп торган кимчелекләр бар. Исемнәре телгә алынган тарихи шәхесләр бары да әдәби образ дәрәҗәсенә күтәреләалмаганнар, җанлы сурәтләрен бирү урынына, автор аларга күбрәк сүз белән генә характеристика биреп китә. Ул чорны яхшы өйрәнгән белгечләр, бәлки, тарихи яктан да төгәлсезлекләр табарлар. Ләкин иң әһәмиятлесе: әсәрдә Хөсәен образы бар. Хөсәен яшәгән замандагы Казан тормышы бар. Революция дулкыны белән урамнарга ташып чыккан киескен көрәш картиналары бар. Әсәрнең эчтәлеге Казан урамнары, андагы халыкның төрле катламын эченә алган бай һәм ярлы өй эчләре, завод-фабрика цехлары белән генә чикләнми, ул Чистайга да, авылларга да чыгып китә. 1905 нче елдагы Әлмәт ярминкәсе күренеше үзе генә дә ни тора! Әлмәт бүген, зур промышленность һәм җитди культура үзәге буларак, Татарстанда гына түгел, бөтен Союзда дан тота торган шәһәр. Хәзер аның исеме хәтта бик күп чит илләргә дә билгеле. Шуңа күрә укучы Ямашев заманындагы Әлмәтне сурәтләгән юлларны укыганда ихтыярсыз аны бүгенге Әлмәт белән чагыштыра.

Язучы тарихи шәхесләр белән берргәттән, үз әсәрендә шартлы, ягъни уйлап чыгарылган образларга да урын бирә. Авылда яшәргә рәт калмагач, шәһәргә килеп, ихтыярсыз революция дулкыннарына эләгеп киткән Фәрхетдин, вак буржуа бунтарыннан милләтчегә әйләнеп киткән Җагъфәр, ярлы тол хатын — эшче Тәгъзимә образлары шундыйлар. Әдәби яктан шактый тулы канлы эшләнгән бу образлар тарихи шәхесләрне калкурак итеп күрсәтергә, аларның эчке дөньяларын тулырак ачарга, заман рухын тирәнрәк сиздерергә ярдәм итәләр.

Кыскасы, «Ямашев» романының идея эчтәлеге ягыннан да, әдәби кыйммәте ягыннан да җитди әһәмиятле әсәр икәнен күрсәткән мисалларны күп китерергә мөмкин. Шуның белән бергә аның әле кимчелекле

яклары да юк түгел. Аларга киңрәк тукталуны хәзергә тәнкыйтьче иптәшләргә калдырып, шуны гына әйтәсе килә: Расих үзенең бөтен көчен һәм осталыгын бу әһәмиятле романның икенче китабын тагын да яхшырак итеп язып бетерүгә тупласын иде дә без аны тизрәк тулы килеш күрсәк иде.

Күптән түгел без Татар дәүләт академия театры сәхнәсендә «Шамил Усманов» драмасын карадык. Соңгы елларда күбрәк мораль темалар — тормыш-көнкүреш, гаилә, мәхәббәт мәҗаралары белән мавыгуга бирелгән театрыбыз һәм драматургиябез өчен сәхнәдә революцион-героик традицияләрне терелтергә омтылу факты бик куанычлы хәл. Дөрес, әсәрнең дә, спектакльнең дә кимчелекле яклары бар. Без әле анда Шамил образын бер яклырак, аны бары комиссар итеп кенә күрәбез. Ә бит Шамил Усманов халык каршында язучы булып танылган һәм әдәбиятыбыз тарихында күренекле урын алган кеше. Әсәрдә Шамилнең бу ягы бөтенләй чагылмавы әдәби образ буларак аның әһәмиятен киметә. Икенчедән, авторларның, шулай ук режиссер һәм башка сәхнә осталарының ул чордагы легендарь сугышчыларны артык примитивлаштырып күрүләре һәм аларны шарж планындарак сурәтләүләре бәхәс тудыра. Ул чорны үзләре кичергән буын кешеләре моның белән бигрәк тә килешә алмыйлар. Шулай да бүгенге көннең үз стиленә тапкыр килгән драма тудыру проблемасы өстендә җитди эзләнүләр алып баручы Аяз Гыйләҗев һәм аның белән бергә әле беренче җитди адымын ясаган Альберт Яхин иптәшләрне, шулай ук яшь буын сәхнә көчләребезне тарихи революцион темага кыю рәвештә тотынулары белән котларга кирәк. Шуның белән бергә аларга мондый җаваплы темаларны хәл иткәндә тирәнрәк уйларга киңәш бирәсе килә.

Тарихи шәхесләр образын иҗат итүдә безнең сәхнә әдәбиятыбыз прозага караганда алдарак икәнен дә онытырга ярамый. «Тукай», «Мулланур Вахитов», «Каюм Насыйри», «Гөлҗамал», «Мылтыклы кеше», «Муса» драмаларын уйнаган театр бит ул! Әйбәт традицияләрне истә тотарга кирәк.

Бу чорда бездә тагын, бая әйткәнемчә, туры мәгънәсендә тарихи дип атап булмый торган яки шартлы рәвештә тарихи диярга мөмкин булган әсәрләр дә байтак язылды. Бу төр әсәрләрдән аеруча күзгә бәрелгәне һәм җитди әһәмияткә ия булганы, безнеңчә, Ибраһим Газиның «Онытылмас еллар» трилогиясе. Бу әсәр турында без үткән съездларда да әйттек. Ул вакытта аның беренче һәм икенче китаплары турында сүз барган иде. Хәзер инде аның «Канатланыр чак» исеме астында өченче китабы да басылды һәм шуның белән трилогия тамамланды. Һәм бу китап турында 66 нчы әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышта җитәрлек уңай фикерләр дә әйтелде. Әдәби яктан кимчелек итеп каралган яки бәхәсле урыннары турында да искә алынды. Ибраһим Гази үз-үзенә гаять таләпчән булу өстенә, иптәшләрчә тәнкыйть фикеренә дә чынлап колак сала белә торган язучы. Ихтимал, төрлесе төрле елларда язылган бу өч китапны бер итеп яңадан карап чыкканда, ул аның өстендә тагын бер кадәр каләм йөртер. Һәрхәлдә, «Онытылмас еллар» трилогиясе Татарстанда революция елларын башыннан башлап азагына кадәр шактый киң полотнода гәүдәләндергән һәм чын язучы каләме белән язылган, совет әдәбияты киштәсендә дәрәҗәле урын алган җитди әсәр. Аның Бөек Октябрьның 50 еллыгына тәгаенләнүе — олы юбилейга язучының зур бүләге булды диярга кирәк. Шуны истә тотып, Язучылар союзы идарәсе быел бу әсәрне Тукай премиясенә тәкъдим итәргә лаек тапты.

Юбилейга багышлап Салих Баттал «Чирмешән буйларында» романын язды. Революциягә кадәрге авыл тормышын, аның төрле катлам һәм төрле сыйныф кешеләрен, ниһаять, авылны Октябрьга алып килгән сыйнфый бәрелешләр һәм революцион көрәш күренешләрен поэтик образларда сурәтләүгә багышланган бу әсәр идея эчтәлеге белән дә, татар поэзиясендә беренче буларак, шигырь белән язылган роман булуы белән дә игътибарга лаеклы. Баттал поэзиясенә хас үзенчәлекләр дә, оригиналь чагыштырулар, уңышлы риторик фигуралар, мавыктыргыч сюжет алымнары да бар анда. Шулай да ни өчендер безнең тәнкыйтьчеләребез бу әсәргә карата җитәрлек кызыксыну күрсәтмәде шикелле. Ихтимал, роман, шигырь белән язылган булса да, азагына кадәр тулы мәгънәсендә шигъри әсәр булып очлана алмагандыр. Чынлап та, баштагы бүлекләрендә чын поэзия булып, стиле, лирик чигенешләре, полемик алымнары, фәлсәфи афоризмнары белән бүгенге заман рухына да аваздаш булып яңгыраган әсәр азакка таба, сюжет-фабуласы ягыннан куера төшсә дә, поэзия әсәре буларак сыеклана бара, ничектер кафияләштерелгән прозаны хәтерләтә башлый.

Шулай да, «Чирмешән буйларында» җитди әсәр. Поэзия белгечләребез моңа тиешенчә игътибар итәрләр әле, дип ышанам. Шул ук вакытта авторга да бу хезмәте турында уйланудан туктамаска кирәктер: ул аны тизрәк очларга кабаланып бераз эшне бозмаган микән?

Соңгы елларда әдәбиятыбызның тагын да җитлегә төшүен күрсәткән мемуар жанры туды, диган идек. Бу жанрда язылган әсәрләр дә турыдан-туры Бөек Октябрьның 50 еллыгына баглы буларак дөньяга килделәр дисәк, хата булмас.

Билгеле булганча, өлкән яшьтәге язучыларыбыз күбесе татар хезмәт ияләренең үзәгеннән чыккан һәм гаять бай, катлаулы тормыш юлы үткән кешеләр. Алар үткән юл — ул капитализм чорындагы сыйнфый һәм милли каршылыклар тудырган көрәш һәм вакыйгаларны да, даннлы революция һәм гражданнар сугышы елларын да, иске заман калдыкларының котырынкы каршылык күрсәтүләрен җимереп, илдә Совет власте урнаштыру һәм аны ныгыту өчен барган көрәш дәверен дә, тарихи бишьел-

лыклар, Бөек Ватан сугышы чорларын да эченә ала.

Чын художникка хас үткен, нечкә күзәтүчәнлек белән озак еллар буенча җыелган тормыш материалына, аның өстенә инде зур әдәби тәҗрибә туплаган талантлы каләмгә дә хуҗа булган язучының, яшь буынны күздә тотып, үзе һәм замандашлары турында язарга теләве бик табигый, шуның белән бергә әдәбиятыбыз өчен мәҗбүри дәрәҗәдә кирәкле эш.

Татар совет әдәбияты гаять дәрәҗәдә кискенләшкән сыйнфый көрәш шартларында тәрәккый итте. Шуңа күрә безнең иң яхшы диган әсәрләребездә дә сыйнфый тенденциялелек үзен шактый ачык сиздерә килде. Без моны кимчелек итеп тә санамадык. Һәм хәзер дә сыйныфлы җәмгыять логикасына буйсынган ул чорлар әдәбиятына карата кимчелек итеп санамыйбыз. Чөнки заман рухы шуны таләп итә иде. Хәзер исә, илебездә социализмның җиңүе, сыйныфсыз җәмгыять төзелү шартларында әдәбиятыбызның стиле дә үзгәрде. Хәзерге әдәбият өчен чынбарлыкны, катлаулы тормыш картиналарын, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне һәм аларның катлаулы эчке дөньяларын, шулай ук тарихи үткәнне тынычрак тонда зур объективлык белән сурәтләргә омтылу характерлы. Бу безнең өчен генә түгел, гомумән күп милләтле зур совет әдәбияты өчен дә шулай. Яңа коммунистик җәмгыять төзү процессында һәрбер милли әдәбият, уртак культурага лаеклы өлеш кертү өчен, үз халкының рухи байлыкларын барлый. Шушы яктан караганда, халык эченнән чыккан каләм остасының үз башыннан кичкәннәрне, ягъни үзе күреп һәм танып белгән тормыш күренешләрен язуы аеруча әһәмиятле.

Узган елда без «Казан утлары» журналында Гомәр Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» дип исемләнгән автобиографик әсәрен укыдык. Баштарак, бигрәк тә беренче бүлекләрен укыганда бу әсәр беркадәр сәеррәк тә тоелган иде. Автор этнографик детальләр белән артык мавыга кебек, татар әдәбиятында инде булган күренешләрне кабатлый, халык тормышындагы социаль моментларны читләтеп үтә кебек күренде. Ләкин аны тулы килеш укып чыккач күңелдә әйбәт тойгылар уяна. Җитди уйланасың. Язучы тормышта булган һәм үзе әнәсеннән җебенә кадәр белгән вакыйгалар һәм кешеләр турында яза. Ягъни укучыга чын тормышның үзен күрсәтә. Ләкин ул әдәби талымсыз түгел, күзенә ни күренсә, шуңа тукталып, теләнә ни килсә, шуны сөйләүдән ерак тора. Нәтиҗәдә без бу әсәр аша халкыбызның бик матур сыйфатларын, аның рухи яктан никадәр байлыгын күрәбез. Кешеләргә мөнәсәбәттә гаделлек, гуманизм, һәр эштә дөреслек-турылык сөю, азатлыкка, яктылыкка, мәгърифәткә омтылу, тыйнаклык һәм шуның белән бергә кеше буларак горурлык саклау, оятсызлыкка, комсызлыкка, гаделсезлеккә, кешелексезлеккә каршы нәфрәт тойгысы — шундый матур сыйфатлар татар халкының олысында, кечесендә, ирендә, хатын-кызында элек-электән бар һәм булып килгәннәр.

Шул сыйфатларга бай булу аны үз культурасы, үзенә хас гореф-гадәтләре, үз теле булган, ихтирамга лаек халык сыйфатында яшәтеп килә дә. Дөрес, бу әйбәт сыйфатлар бер татар халкы өчен генә түгел, бик күп бүтән халыкларга да хас. Татар халкын кемнән дә булса өстен итеп күрсәтергә теләү турында сүз бармый. Аның берәүдән дә ким түгеллеген, үзен ихтирам иткән барлык халыклар кебек үк, игътибарга һәм хөрмәткә лаек халык икәнен тулырак күрсәтә белергә, шуңа омтылырга кирәк безгә.

«Туган ягым — яшел бишек» әсәрендә без халкыбызның тарих тарафыннан зур сынауларга дучар ителгән, тираннар изүе астында калганда да, ак патшалар тарафыннан туракланып, туган туфрагыннан төрле тарафларга туздырылган чагында да үзенең бөтенлеген саклап килә алган, ниһаять, бөек рус халкы белән бергә революция ясашкан һәм бүгенге көндә яңа — коммунистик җәмгыять төзүчеләрнең алгы сафларында барган татар халкының кечкенә, ләкин характерлы бер кисәген күрәбез. Язучы аны, бернинди ялган пафоска — ясалма ялтырату яки каралтуларга бирелмичә, чын тормыш дөреслеген әдәби дөреслек дәрәҗәсенә күтәреп сурәтли.

Ибраһим Гази Гомәргә караганда яшьрәк. Аның хәтер көче ныгып җиткән чагы революция алды һәм революция елларына туры килә. «Малайлыкта кунакта» повестен укыганда без, язучының үзе белән бергә, аның малай чагына кунакка барып кайткан кебек булабыз. Хәзерге вакытта инде пенсия яшендәге меңнәрчә кешеләребез үткән юлның бер өлешен Ибраһим үзенә генә хас стильдә гаять кыска, тапкыр сүзләр белән җанлы итеп күз алдына китереп бастыра. Уйнап-шаярып кына ул безне кайвакыт җан тетрәткеч күренешләр алдына китереп чыгара. Ихтыярсыз бүгенге көндә яшәвеңә шөкер итеп куясың. Ибраһим үткәннәр турында бүгенге заманнан торып яза. Үтелгән юлның дәһшәтле күренешләрен сурәтләү белән бергә, ул авырлыкларны җиңеп үтүнең романтик матурлыгын да тойдыра белә. Шул ук вакытта, ул ямьсез еллар артта калды инде, хәзер бары да әйбәтләнде дип, укучыны тынычландыру юлына басудан да ерак тора. Бүгенге көнебезнең безне борчый торган якларын да күрә, киләчәккә дә күз ташлап куйгалый. Бу әсәрдә без халык тормышының «Туган ягым — яшел бишек»тә булмаган икенче бер кисәген, бөтенләй бүтән, үзенчә стильдә сурәтләнгән, ләкин шулай ук тарихи үткән булган өлешен күрәбез.

Гүзәл хезмәтләре белән халкының олы мәхәббәтен казанган өлкән буын язучыларыбыз киң Советлар иленең төрле почмакларында туып-үскән кешеләр. Димәк, һәркайсы үзләре үткән тормыш юлын язсалар да бер-берсен кабатлау куркынычы юк. Хәтта бер үк авыл яки шәһәрдә туып-үскән ике язучы булса да, әгәр алар чын язучы икән, әдәбиятта үз стильләрен, үз

тавышларын тапкан кешеләр икән, анда да бер-берсен кабатламаячаклар, бары тик икесе бергәләп бер үк тормышның, бер үк халыкның төрле якларын тулырак ачуга гына ирешәчәкләр. Шуңа күрә андый әсәрләр бездә әле тагы язылыр һәм язылырга тиеш тә. Тик мондый характердагы әсәрләргә карата шуны әйтәсе килә: революциягә кадәрге тормышны яки революция һәм гражданнар сугышы елларын язу белән генә канәгатьләнмәскә иде. Совет властеның беренче ун еллары, хәтта Бөек Ватан сугышы чоры үзе дә хәзер инде безнең яшь буын өчен генә түгел, урта буын өчен дә шактый еракта калган тарих.

Мемуар характерындагы әсәрләр югарыда саналган исемнәр белән генә бетми. Кайбер язучылар үзләре үткән тормыш юлында очраган эпизодларны аерым-аерым хикәяләр формасында, кайберәүләр исә аны теге яки бу тарихи вакыйгага яки шәхескә бәйләп, истәлекләр рәвешендә язалар. Арабызда яше ягыннан да, дәрәҗәсе ягыннан да иң өлкән шагыйребез Хәсән ага Туфанның Галимҗан Ибраһимов, Һади Такташ, Зыя Камали, Мохтар Мутиннар турындагы искиткеч гүзәл шигъри истәлекләрен дә мин әдәби хәзинәбезнең шушы бүлегенә кертер идем. Мондый әсәрләр, әлбәттә, безнең әдәбиятыбызны баетырга, тарихыбызны тулыландырырга ярдәм итәләр. Шуның белән бергә алар арасында факт дөреслеге принципыннан гына чыгып язылган, бүгенге заман өчен тарихи әһәмияте булмаган, хәтта кайберләрендә революцион чынбарлыкны ялгыш аңлауга хезмәт итә торган язмалар да күренгәли. Тәнкыйть моңа игътибар итәргә тиеш. Редакция һәм нәшриятларыбызга да бу төр әдәбиятка карата талымсызлык күрсәтергә, таләпчәнлекне йомшартырга ярамас.

Әдәбият белеме өлкәсендә эшләүче галимнәребез дә бу чорда үзебезнең татар әдәбияты һәм культурасы өчен куанычлы уңыш булу белән бергә, күп милләтле зур совет әдәбиятының уртак фондына да кыйммәтле өлеш булып керерлек хезмәтләр иҗат итүгә ирештеләр: «Татар совет әдәбияты тарихы», Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләүче язучы-галимнәребез тарафыннан рус телендә язылып, Мәскәүнең «Наука» нәшриятында басылып чыкты. Бу әсәр үзенең гыйльми нигездә язылуы, татар әдәбиятының үсү юлындагы үзенчәлекләрен гомум совет әдәбияты үсешендәге проблемалар белән бәйләнештә яңача ача белүе белән үзәк матбугатта югары бәя алды. Бүгенге рус әдәбияты галимнәреннән В. Пискунов һәм Н. Гельфанд иптәшләрнең әдәби хәрәкәт һәм аны өйрәнү мәсьәләләренә багышлап язылган һәм «Дружба народов» журналында басылып чыккан мәкаләләрендә галимнәребезнең бу хезмәте турында болай диелә: «История татарской литературы» — один из примеров удачного изложения на конкретном материале проблемы национальной литературы как явления особого и общего».

Бу әһәмиятле хезмәтне уңышлы итеп чыгаруда язучы-галимнәребездән Гали Халит, Хәсән Хәйри, Баян Гыйззәт, Нур Гыйззәтуллин, Хәй Хисмәтуллин, мәрхүм Рөстәм Башкуров иптәшләр зур активлык күрсәттеләр. Моның өстенә Г. Халитның Г. Тукай иҗаты турында татар телендә дә, рус телендә дә җитди хезмәтләре басылып чыкты.

Мөхәммәт Гайнуллин ага үзенең «Татарская литература и публицистика начала XX века» дигән китабын чыгарды. Бу хезмәтләр — татар халкының рухи байлыкларын, аның әдәбиятын бөтен союз күләменә күтәрү, аларны барлык совет халыкларының уртак байлыклары фондына кертү юлында җитди адымнар. Бу чорда әдәбият гыйльме буенча тагын бер докторыбыз артты: ул Ибраһим Нуруллин. Аның «XX йөз башы татар әдәбияты» дигән хезмәте, әдәбият тарихыбызның иң әһәмиятле бер чоры турында вуз студентлары өчен кыйммәтле кулланма булу белән бергә, киң катлам укучы өчен дә яратып укырлык әһәмиятле әсәр. Әдәби мирасны өйрәнүгә багышланган җитди хезмәтләрдән профессор Хатип Госманның Идел буе Гөлстаны турындагы «Ерак гасырларның шигъри авазы»н һәм башка мәкаләләрен искә алырга кирәк.

Халкыбызның авыз иҗатын өйрәнү буенча да әдәбиятыбыз өчен тарихи вакыйгага дип әйтерлек зур уңышка ирештек: арабызда иң өлкән күренекле язучыбыз һәм галимебез Нәкый ага Исәнбәт татар халык мәкальләрен җыю һәм классификацияләү буенча үзенең өч томлык уникаль хезмәтен тәмамлап, бастырып чыгарды. Халкыбызның чиксез зур рухи байлыгы хәзинәсен туплаган һәм язучы-галимнең тирән эчтәлекле кереш хезмәте белән тәэмин ителгән бу әсәр дә быел Язучылар союзы һәм тагын берничә коллектив исеменнән Тукай премиясенә тәкъдим ителде.

Безнең бу тәкъдимнәребез җәмәгатьчелек һәм киң катлам укучылар массасы тарафыннан хуплап каршы алыныр дип ышанабыз.

Хәмит Ярминең «Татар халкының поэтик иҗаты» дигән монографиясе, Тел, әдәбият һәм тарих институты галимнәре хәзерләп бастырган җырлар — укучылар өчен дә, язучылар өчен дә әһәмиятле хезмәтләр.

Данлы 50 еллыкка һәм даһи Ленинның тууына 100 ел якынлашуга атап төрле жанрда язылган әсәрләр күп булды. Г. Минскийның Астрахань өлкәсендә яшәүче татарлар тормышын, аларның этнографик үзенчәлекләре белән бергә революцион көрәш юлларын гәүдәләндергән, шул яклары белән әдәбиятыбызга яңа образлар алып килгән «Яшенле яңгыр» повесте; Гариф Галиевнең яңа хикәяләре, Җәвад Тәрҗемановның Лобачевский турындагы китабы, Сибгат Хәким, Әнвәр Давыдов, Нури Арсланов, Зәки Нури, Хисам Камал, Нәби Дәүли, Галимҗан Латыйп, Әдип Маликов, Саҗидә Сөләйманова, Мөхәммәт Садри һәм башка иптәшләрнең шигырь, хикәяләре, очерк һәм мәкаләләре, Совет властен яулап алу һәм аны ныгыту өчен көрәш тарихының, шулай ук әдәбиятыбыз үткән юлның данлы сәхифәләрен бүгенге укучыга ачып күрсәттеләр.

## КЕШЕ РУХЫ ӨЧЕН КӨРӘШ

VI нчы съездан соңгы чорның үзенчәлеген игътибарга алып, иң башта күбрәк тарихи үткәнебезгә багышланган әсәрләргә тукталганбыз икән, моңардан ялгыш фикер тумасын, ягъни бу чорда бүгенге көн темасы икенче планга калган икән дип уйланмасын. Узган съездларга кадәр булган кебек, бу чорда да иҗат эшебезнең үзәгендә бүгенге көн темасына багышланган яңа әсәрләр язу мәсьәләсе торды. Һәм без һәрбер уңышлы яңа әсәрне, кайсы заман темасына багышланган булуына карамастан, Совет властеның 50 еллык тантанасына язучы керткән өлеш дип карадык һәм карыйбыз.

Заман темасына язылган әсәрләребезнең идея-эстетик эчтәлеге җәмгыятебезнең бүгенге характерыннан чыгып билгеләнә. Илебез коммунизмның материаль-техник базасын төзү буенча елдан елга яңа уңышларга ирешә бара. Тынычлык шартларында узган һәр көн безне төп максатыбызга якынлаштыра.

Капитал дөньясы моның белән ничек тә килешә алмый. Үзенә үлем китерүче коммунизмның җиңүенә һич юл куясы килми аның. Һәм дөнья күләм коммунизм идеясенә каршы, беренче чиратта ул идеяне үз практикасында гамәлгә ашырып баручы Советлар Союзындагы тәртипләргә каршы, көрәштә ул үз кулында булган бөтен коралларны, бөтен чараларны, барлык хәйләмәкерләрне ходка җибәрә. Ә аның кулында нинди генә чаралар юк! Ләкин капитал дөньясы хәзер үзе дә аңларга һәм таныргa мәҗбүр булган тарихи факторлар бар: экономик өстенлек белән дә, хәрби техника һәм фән ягыннан булган өстенлекләр белән дә капитализмның социализмны җиңү мөмкинлекләре беткәннән бетә бара. Эш хәзер экономик байлыкта яки коралда гына түгел, кешелек дөньясының аң дәрәҗәсе хәзер бу мәсьәләдә хәл кылгыч факторга әйләнә. Кешеләрнең дөньяга карашлары ничек, аларның рухи көчләре кая таба юнәлгән? Планетаның бөтен нокталарында хәзер кеше рухы өчен аяусыз һәм катлаулы көрәш бара.

Матур әдәбият исә бу көрәштә иң зур урын тота торган коралларның берсе.

Безнең татар әдәбияты да, күп милләтле зур совет әдәбиятының бер өлеше булarak, ул көрәштә үзенә тиешле әһәмиятле урынны алып тора. Бүгенге Татарстан республикасы үзенең экономик торышы һәм культурасы белән дөнья күләм әһәмияткә ия булган бер үзәк дәрәҗәсенә күтәрелгән икән, аның әдәбияты алдында торган бурычлар да шул югарылыктан карап билгеләнә.

Үз әсәрләре белән татар әдәбиятының данын дөнья күләм мәйданга чыгарган Муса Җәлил, Тукай, Галимҗан Ибраһимов, Такташ, Кутуйлар истәлеге дә алдыбызга куйган бурычны шуннан да түбәнәйтергә рөхсәт итми.

Ләкин дөнья күләм әһәмияткә ия булган әдәби әсәр иҗат итү, ул мотлак халыкара күләмдәге мәсьәләләр турында язу дигән сүз түгел әле.

Һәр әдәбиятның һәм язучының үзенең беренче планда торган проблемалары була. Безгә барыннан да элек үз иманыбызга үз укучыларыбызны ышандырырлык әсәрләр язарга кирәк. Моның төп шарты: үз җирлегебездә, үз кешеләребез үрнәгендә бүгенге чынбарлыкның рухын реалистик дөрес картиналарда чагылдырган, яңа җәмгыять төзүчеләрнең тулы канлы образларын сәнгатьчә дөрес гәүдәләнгән әсәрләр иҗат итү. Шул шарт үтәлсә, безнең геройларыбыз да, Григорий Мелеховлар, Василий Теркиннар, Танабайлар, Җәмиләләр, үзебезнең Шүрәлебез, Галиябез, Нәфисәләребез кебек, дөнья укучысына юлны үзләре табарлар.

Соңгы өч ел эчендә безнең әдипләребез, шагыйрь һәм драматургларыбыз, шулай ук тәнкыйтьчеләребез һәм әдәбият галимнәребез укучылар массасының һәм язучылар җәмәгатьчелегенең игътибарын җәлеп иткән күп әсәрләр яздылар. Аларның барына да бер докладта тукталып бетү, әлбәттә, мөмкин түгел. Һәм бу съездда моңа ул кадәр мохтаҗлык та юк дип беләм. Чөнки без идарәнең Казандагы барлык язучылар һәм журналистлар җәмәгатьчелеге катнашы белән уздырыла торган киңәйтелгән утырышларында һәр өч ай саен «Казан утлары» журналында басылган әсәрләр турында фикер алышулар уздырып киләбез. Аның өстенә тагын да әһәмиятлерәге: 1965 нче ел өчен дә, 1966 нчы ел өчен дә, республикадагы бөтен язучыларыбызны чакырып, һәр ике еллык әдәби иҗат эшебезгә йомгак ясадык.

Ул елларда дөнья күргән проза әсәрләреннән «Кукчәтау далалары» турында күп кенә уңай фикерләр әйтелде анда. Ибраһим Салахов бу романда гасырлар буенча хәрәкәтсез яткан казакъ далаларын иген кырларына әверелдерүче төрле милләт кешеләренең катлаулы язмышлары, алар арасындагы интернациональ дуслык, кешелек мөнәсәбәтләре турында сөйли. Җанлы образлар теле белән, укучыны мавыктырырлык итеп, ышандырырлык итеп сөйли.

Гариф Ахуновның «Хыялый Хәйруш егетләре», Рафаил Төхфәтуллинның «Тамчылар ни сөйли» повестьлары турында шактый тулы итеп сөйләнде ул җыелышларда. Аларга нигездә уңай бәя бирелде. Шуның белән бергә, «Хәзинә», «Йолдызым», «Авылдашым Нәби» авторлары өчен аларның бик үк алга китеш түгел икәнлеге дә әйтелде. Моның белән килешергә туры килә.

Фатих Хөснинең әледән-әле диярлек чыгып торган яңа хикәяләре, бу елларда күп кенә кызыклы хикәяләр язган Газиз Мөхәммәтшин әсәрләре, Аяз Гыйләҗевның «Берәү» повесте, «Үги ана яфраклары» һәм башка хикәяләре, Әмирхан Еникинең яңа әсәрләре, Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар»ы күп җыелышларның игътибар үзәгендә булдылар.

Габдрахман Әпсәләмовның «Ак чәчәкләре» турында да сөйләнде ул җыелышларда,

Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар» романы хакында да күп кенә җылы сүзләр әйтелде. Сөббух Рафиковның «Авыл иртәсе» ни өчендер бөтенләй читләтеп узылды шикелле.

Бу романнар уңае белән принципиаль характерда берничә сүз әйтәсе килә. «Ак чәчәкләр» романы хәзерге көндә халык арасында иң популяр әсәрләрнең берсе. Чөнки язучы, гомумән аның иҗатына хас булганча, бу әсәрендә дә бүгенге көннең актуаль мәсьәләләрен күтәрә. Җәмгыятебезнең моралена хас булган гуманизм, кешеләргә карата гаделлек, хезмәт сөю, барыннан да элек халык мәнфәгатен өстен кую идеяләрен яклый. Галимҗан Ибраһимов, Шәриф Камал кебек классикларыбыздан килгән яхшы традицияләрне дәвам иттерә.

Шуңа әзлекле буларак, өлкән буын белән яшь буын арасындагы мөнәсәбәтне дә романында уңай планда хәл итә. Үзенең бөтен гомерен халыкка хезмәт итүгә багышлаган олы намуслы, саф йөрәкле, хезмәт сөючән Әбүзәр образының яшь буынга күчкән сурәтен без Гөлшәһидә образында күрәбез.

Әсәрнең медицина өлкәсендә эшләүчеләр тормышын гәүдәләндерүгә багышланган булуын да мин очраклы хәл димәс идем. Кешегә игътибар, кешегә мәхәббәт идеясен гәүдәләндерү өчен уңайлы материал буларак, бу тема язучының күңелен үзенә тарткан. Һәм ул табиплар тормышын, шул өлкәдә эшләүче төрле кешеләр дөньясын моңарчы әле безнең әдәбиятта булмаган дәрәҗәдә киң күләмдә яктырта алган.

Гомумән алганда соңгы елларда язылган әсәрләребезнең уңышлары җөмләсенә кергән бу романга карата язучылар җәмәгатьчелеге эчендә шактый кискен тәнкыйть белән чыгучы иптәшләр дә булды.

Ләкин бу очракта сүз бер «Ак чәчәкләр» романы турында гына түгел, гомумән иҗат принциплары, аеруча уңай герой проблемасы турында бара. Кайбер иптәшләрдә героик планда язылган әсәрләрне кире кагу тенденциясе бар. Андый тәнкыйтьчеләр романтик планда алынган, Г. Әпсәләмовча әйтсәк, «кирәк икән, пьедесталга да бастырылган» геройны кабул итә алмыйлар. Мондый алым геройны тормыштан аеруга алып бара дип карыйлар. Ләкин бит матур әдәбиятта һәм гомумән сәнгать әсәрләрендә тормышның гади кеше күреп бетә алмый торган аерым детальләрен яки кешеләрнең характерындагы үзенчәлекләрне тормышта булгандагыдан арттырыбрак сурәтләү, аны калкурак итеп күрсәтү эстетика кануннарына каршы килми. Юмор, сатира әсәрләре, комедия яки карикатура турында сүз барганда, кире образларны күпертеп бирүне без танныйбыз гына түгел, хәтта котылгысыз чара дип карыйбыз. Моңа бераү дә каршы килми. Ә инде бөтенләй икенче пландагы әсәрдә язучы тормышның уңай күренешләрен, геройның характерындагы яхшы якларны калкурак итеп бирә икән, кайбер тәнкыйтьчеләр моны ялтырату дип, фальш дип бәяләргә торалар. Моның белән килешеп булмый. Әгәр без бу позициягә бассак һәм аны үз логикасы буенча дәвам иттерсәк, Гомәр Бәширов, Атилла Расих, Гариф Ахунов, Гариф Гобәй, хәтта Шәриф Камал, Галимҗан Ибраһимов кебек язучыларыбызның әдәбиятыбыз киштәсендә хөрмәтле урын алган күп кенә әсәрләрен дә шик астына куя башлар идек.

Дөрес, «Ак чәчәкләр» романында күзгә бәрелеп торган кимчелекләр барлыгын да инкарь итмибез. Гомуми культура дәрәҗәсе шактый үскән бүгенге укучы өчен бик гади һәм күптән ачык булган хакыйкатьләрне тафсиллауга артыграк урын бирү, инде әдәбиятта булган эпизодларны кабатлау, авторның идея позициясен декларатив характердагы сүзләр аркылы әйтү кебек моментлар романның әдәби көчен билгеле дәрәҗәдә киметәләр. Анысын, әлбәттә, әйтергә кирәк. Ләкин болар бит Әпсәләмов иҗатында принципиаль характердагы үзенчәлекләр түгел. Безнең өчен мәсьәләнең әһәмиятле ягы шунда: мондый, бүгенге тормышыбызның алгы сызыгында торып, мораль проблемаларны хезмәт белән тыгыз һәм тирән бәйләнештә алып язылган һәм андагы уңай тенденцияләрне, алдынгы кешеләрне раслау, безнең җәмгыятькә ят тискәре элементларга нәфрәт тудыру позициясеннән торып иҗат ителгән әсәрләр безгә кирәк. Мондый темаларны күтәрү өчен язучыдан табигать биргән талант өстенә зур фидакарь хезмәт тә сорала. Шуңа күрә андый әсәрләргә мөнәсәбәттә безнең тәнкыйть объектив караштa булырга, ягъни аларның кимчелекләрен күрсәтү белән бергә, уңышлы, файдалы якларын ачуда укучыга да, язучыга да ярдәм итәргә тиеш.

Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар», Сөббух Рафиковның «Авыл иртәсе» романнары да халык тарафыннан яратып укылалар. Алар буенча бик күп урыннарда конференцияләр уздырыла. Авторлары исеменә яхшы сүзләр әйтелә. Чөнки бу әсәрләрдә чын халык тормышы, читтән күзәтеп кенә түгел, аның эчендә торып язылган. Аларның эчтәлеге чиксез бай катлаулы тормыш материалы, җанлы кеше образлары, кызыклы һәм гыйбрәтле язмышлар белән тулы.

Мәхмүт Хәсәнов безгә республикабызның даны булган нефть районнарында асфальт юллар, сазлыклар аша дамбалар, күперләр салучы кешеләрнең авыр, катлаулы, шуның белән бергә мәгънәле гүзәл хезмәтләре турында сөйли. Без ул кешеләр салган мәһабәт юлларны гына түгел, аларны төзүче геройларның үзләре үткән тормыш юлларын да күрәбез. Менә Варис Исламов образы. Ул безнең заманның алдынгы кешесе. Ләкин аның тормыш юлы тигез генә түгел. Ул катлаулы көрәш һәм җиңүләр юлы. Менә Хәйрүш образы. Ул үткән тормыш юлы тагы да авыррак һәм катлаулырак. Ләкин ул бөтенләй үзенчә: җинаятьләр, алардан арынулар юлы. Мөбәрәков Тимер, Рәис Яруллин, Сария юллары һәм аларның язмышлары, алар бары

да укучыны уйландыралар, аңа тормышта үз юлын табарга булышалар.

Тау кадәр «Маз»ны үзенә бик җиңел буйсындыра белгән батыр, ярсу йөрәкле шофер Әбрар белән асфальт җәяүче кыз — автор теле белән әйтсәк, гәүдәгә «тун төймәсе кадәр генә» Галимә арасында хезмәт процессында булган бәрелеш эпизодына һәм аларның соңгы язмышына багышланган юллар романда күп дигәндә бер бит чамасы урын ала торгандыр. Ләкин юмор планында юл уңаенда гына чагылып калган шул эпизод безнең күңелләрнең характерлы бер детале сыйфатында онытылмаслык булып истә кала. Романда гомумән матур күзәтү һәм ачышлар, халыкчан чагыштырулар, тапкыр сүзләр аз түгел. Чорыбыз өчен характерлы булган тип яки персонажлар, заман рухына тапкыр килгән деталь яки эпизодлар уңай яктан да, кире яктан да җитәрлек. Хәтта артыгы белән диясе килә. Ләкин сәнгать әсәре артып киткәнне дә яратмый бит. Артыгы бишенче тәгәрмәчне яки алтынчы бармакны хәтерләтә башлавы мөмкин.

Әгәр дә хәзер бер тәнкыйтьче «Юллар, юллар» романын алып, андагы артыкка киткән риториканы, артыкка киткән эпизодларны, урынсыз кулланылган сүзләрне, уңышсыз җөмләләрне җыеп, санап чыкса, образлар аркылы бирелергә тиешле фикер һәм идеяләрне ялангач фразалар белән генә әйтеп үткән урыннарны күрсәтсә, композицион яктан булган кимчелекләренә дә игътибар итсә, һәм шулардан чыгып, бу китапны әдәби әсәр буларак бөтенләй кире какса, бу, әлбәттә, дөрес нәтиҗә булмас иде. Шул ук вакытта ул тәнкыйтьченең үзен кире кагу да шактый читен булыр иде. Чөнки романда чынлап та шундый характердагы эч пошыргыч кимчелекләр бар. Алар, әлбәттә, идея чатаклыгыннан килгән кимчелекләр түгел, өлешчә, әдәби осталык яки тәҗрибә җитмәүдән, күбрәге авторның үзенә карата таләпчәнлекне йомшартуыннан, ашыгуыннан килгән кимчелекләр. Шулар өстенә тагын, авторның һәм укучының бәхетсезлекләренә каршы, әсәрнең тиешенчә редактор каләме аша узмаганлыгын да китереп өстәргә кирәк. Әгәр дә әсәр үз һөнәрен яхшы белүче, үз эшенә җитәрлек җаваплы караучы, чын мәгънәсендә таләпчән һәм әдәби зәвыклы редактор каләме аркылы үткән булса, һич икеләнүсез әйтергә мөмкин: андагы кимчелекләрнең бик күбе укучы күзенә барып җитмәгән булыр иде.

Сөббух Рафиковның «Авыл иртәсе» романына карата да нәкъ шундый фикерләрне әйтергә мөмкин. Бу роман бүгенге колхоз авылын гәүдәләндерә. Илгә икмәк һәм башка төр азык-төлек бирү эшендә елдан-ел яңа уңышларга ирешә баручы авыл кешеләре тормышын алар арасындагы нечкә, катлаулы мөнәсәбәтләр, хезмәткә һәм көнкүрешкә бәйле тормышчан вакыйгалар, җанлы характерлар аркылы сурәтли. Шулары белән укучыны мавыктыра, аңа җан азыгы бирә, аны тормыш турында уйландыра. Шул ук вакытта «Юллар, юллар»га хас булган кимчелекләр дә җитәрлек анда. Алар өстенә тагын бу әсәрдә стиль ягыннан искегә тартымлык, заман рухына туры килеп бетми торган алымнар да бар иде. Мондый кимчелекләр, әлбәттә, бу әсәрләрнең әдәби кыйммәтен киметәләр. Ихтимал, алар бу хәлләрендә кырыс заман сынавын үтеп, бик еракка да китә алмаслар. Коммунистик төзелешнең алдынгы сафындагылар турында яңа, яхшырак әсәрләр язылып, боларны онытуы да мөмкин. Шулай да, әдәби практикабызның хәзерге хәленнән чыгып, мин аларны игътибарга лаек, бүгенге укучы өчен кирәкле, файдалы әсәрләр җөмләсенә кертәм. Авторларга исә аларны озын гомерле итү турында җитди уйланырга эш бар.

Бу еллардагы әдәби хәрәкәтебезнең куандыра торган бер ягы итеп, тема һәм алымнардагы төрлелеккә игътибар итәсе килә. Гариф Гобәйнең «Коръән серләре» татар прозасы өчен бөтенләй яңа булган әдәби публицистика жанрында язылган әсәр. Гаять җанлы әдәби тел һәм сатирик алым белән, гасырлар буенча бик күпләр каршында изге китап саналып, миллионнарның миен томалап килгән коръәннең реакцион эчтәлеген ачып биргән бу китап укучы тарафыннан зур кызыксыну белән каршы алынды. Советлар Союзының бөтен почмакларыннан язучы исеменә, аңа рәхмәт әйтеп тә, аны каһәрләп тә, (соңгылары дингә фанатикларча ышанучылардан) йөзләрчә хатлар килә. Атеистик тәрбия эшендә, һичшиксез, зур роль уйнаган бу китап бик тиз таралып бетте. Язучы хәзер аның яңа — тулыландырылган икенче басмасын хәзерли.

Татар әдәбиятының тематик диапазонын киңәйтү ягыннан да, идея эчтәлеге һәм әдәби алымы белән дә Нәби Дәүлинең «Җимерелгән бастион» романы әдәбиятыбыз өчен бер яңалык булды. «Үлем белән яшәү арасында» повесте белән Союз күләмендәге укучының игътибарын казанган язучы бу әсәрендә дә фашист әсирлегендә калган якташларыбыз, аларның коточкыч авыр шартларда дошманга каршы аяусыз көрәш алып барулары турында яза.

1967 нче елда басылган әсәрләрнең җитди игътибарга лаеклыларыннан тагын берсе — Нурихан Фәттахның «Мәдир Сәҗидә» повесте.

Шушы уңай белән татар әдәбиятында безнең заманның яшь кешесе образы мәсьәләсенә карата берничә сүз әйтәсе килә. Бу проблема безнең бик күп әсәрләргә кагыла. Кайбер авторлар моны яшьләрне картларга каршы кую планында чишәргә тырышалар. Ягъни, өлкән буын кешеләре өчен шәхси мәнфәгатьне өстен кую, үз рәхәте өчен мораль принциплар белән хисаплашмау хас булса, яшьләр өчен барыннан да элек кешегә карата гаделлек, йөрәк кушуына каршы бармау, мәхәббәт, намус иреклелегә характерлы димәкче булалар. Яки, яшьләр арасында да мораль гарип кешеләр бар икән, моңа да картлар гаепле, ул кешеләрне алар шулай имгәткән дияргә телиләр. Хәзерге көндә өлкән яшь-

Төге кешеләребез шәхес культы чорындагы башбаштаклыклар белән килешеп яшәгәннәр, аңдагы гаделсезлекләргә каршы тавыш күтәрергә батырлыклары җитмәгән, дип гаепләү тенденциясе сизелә. Без моны Әхсән Баянның «Яшьлегемне эзлим» повесте, Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы» комедиясе кебек әсәрләрдә сизәбез. Шулай ук Аяз Гыйләҗевнең «Берәү» повестенда һәм кайбер хикәяләрендә күрәбез. Монда, әлбәттә, логика юк түгел. Өлкән кешеләребездә очрый торган кимчелекләрне без, гадәттә, капитализм калдыгы дип кенә бәяләргә гадәтләнгәнбез. Ләкин эш анда гынамыни? Бүгенге көндә өлкән буын кешеләре дигәнебезнең дә яшь гомерләре социалистик ил шартларында узган бит. Бүгенге яшь кешенең үзенчәлекләрен ачу өчен аны карт кеше янына куеп карамаска, ә бүгенге көндә карт булган кешеләрнең яшь чаклары белән янәшә куеп карарга кирәк. һәм билгеле чордагы совет тормышының үз каршылыкларын да игътибарга алырга кирәк. Бер яктан, хәзерге кебек үк коммунистик мораль алга сөрелә иде ул елларда, икенче яктан, социализмга әле бик ерак булган экономик ярлылык, материаль кысынкылык көчле иде. «Книга о вкусной и здоровой пище» дигән китап безнең өчен бөтенләй дөньяда ук юк кебек иде. Ничек итеп тамак туйдыру проблема иде. Купшы киенү түгел, ә бөтенәйтү турында сүз бара иде. Кешеләр ванналы-газлы, җылы санузеллы квартира турында хыялланмыйлар, кыш көннәрендә туңмый чыгар өчен утын табу хәстәрен күрәләр иде. Шулай ук бөтен кешене урта белемле итү турында да сүз бармый иде әле ул елларда. Алда бөтенләй укый-яза белмәүчелекне бетерү проблемасы тора иде. Шундый шартларда да яшьләр арасында производствода ударник, мораль яктан хәзерге алдынгы яшьләр кебек үк саф күңелле кешеләр җитәрлек иде. Мондый булу өчен ул елларда кешеләрдән билгеле дәрәҗәдә фанатик булу да сорала иде. Шуңа күрә бер кадәр догматик булу да гаҗәп түгел иде.

Моны аңларга кирәк. Бүгенге яшь кешенең образын яктырак итеп күрсәтүне үткән буын кешеләрен каралту исәбенә эшләргә ярамый.

Нурихан Фәттах үзенең соңгы повестенда бүгенге көннең яшь кешесе образын иҗат итүдә бик дөрес юл сайлаган. Сәҗидә образында ул үзебезнең җирлектә бүгенге заманның яшь бер кызын тормышчан, реалистик буяуларда сурәтли. Барыннан да элек ул рухи яктан ирекле кеше; аның һөнәре бар, белеме бар, саф намусы бар. Шуңа күрә ул үзенең һәръяктан тигез хокуклы икәнен тоеп, шуңа горурланып яши. Ул үзен рәнҗетергә, кимсетергә бирәүгә дә юл куймый. Бу мәсьәләдә олылар белән дә исәпләшергә теләми һәм аны гафу итсәң. Өйе. Олылар да хәзерге яшьләрнең кем икәнен аңлап эш итәргә, аларның заман биргән өстенлекләрен каприз дип аңламаска, алар белән исәпләшергә тиеш!

Сәҗидә ялгыз үзе генә шундый булса, бәлки аның укучыны ышандыру көче кимрәк булыр иде. Юк, ул ялгыз түгел. Хәтта авыл яшьләре белән аралашырга теләми йөргәндә дә, баштарак аларны яратмый йөргәндә дә ялгыз түгел, ул барыбер алар белән. Чөнки тегеләре дә — Зөһрәсе дә, Танясы да, Тимерҗаны да, Равиле дә — бары да, һәркайсы үз характерына хуҗа булган хәлдә, аның кебек үк азат рухлы, һөнәрле, тигез хокуклы, тормыш сөюче, шуның белән бергә горур йөрәкле кешеләр. Хезмәт сөючәннәр алар, шат күңелләр, кешене — яшен-картын — хөрмәт итә беләләр. Шундый җанлы кеше булганга да укучы аларның һәр адымын кызыксынып, яратып күзәтә.

«Мөдир Сәҗидә» повесте бүгенге яшьләребез турында шундый матур тәэсир калдыра. Өлкән буын кешеләрен дә җитди уйландыра.

Бу яктан, укучы өчен әле яңарак исем булган Хәсән Сәрьянның «Өткәм һөнәре» повесте дә характерлы. Бу әсәрдә балта осталары турында сүз бара. Яшь авторның, хәзерге көндә балта тавышы да машина тавышы белән бер дәрәҗәдә яшәргә хаклы, дигән тезисы ни дәрәҗәдә заман рухына туры килә торгандыр, анысы турында бәхәсләшергә мөмкин. Мәгәр әсәрдә бүгенге авыл тормышы, аның кешеләре җанлы итеп сурәтләнә. Монда да үзәк урында яшь кеше — армия сафыннан кайткан егет — Гаяз образы. Аңа да шул ук Сәҗидәләрдә булган сыйфатлар хас. Ул дөрес сайланган. Реалистик планда дөрес сурәтләнгән. Шуңа күрә әсәрдәге башка образлар да, уңайлары һәм киреләре дә ышандыра. Бу әсәр әдәбиятыбызга тел үзенчәлекләре һәм яңа пейзажлар алып килүе белән дә яхшы тәэсир калдыра.

Яшь кеше образы безнең шагыйрьләребез иҗатында да үзәк урында торган проблемаларның берсе. Монда ул күбрәк яшьләр иҗатында лирик «мин» образы рәвешендә чагыла.

## ҮРЛӘР АША

Поэзия темасына кагылгач, бу мәсьәлә белән генә чикләнеп булмый. Үткән съездларда без роман, повестьлар жанрында уңышларыбыз зур булуын әйткән идек. Бу чорда да без аларны байтак санадык шикелле. Шулай да хәзер бездә, бүгенге әдәби хәрәкәтебез турында сүз йөрткәндә, еш кына, поэзия активлашты, аның диапазоны киңәйде, эчтәлеге тирәнәйде, дигән сүзләр ишетергә туры килә. Чынлап та монда дөреслек бар.

Бүгенге поэзиябез турында сүз кузгалса, Шәүкәт Галиевнең «Күңелләргә сәяхәт»еннән сигез юллык бер шигырь хәтергә килә:

Текә кыяларның кәрнизеннән —
Упкын кырыеннан юл бара.
Бормаланып бара-бара да ул
Болытларга кереп югала.
Аска карыйм — биек дигән таулар
Нинди нәни булып калганнар.
Мин үтәргә куркам бу юллардан,
Ә кемнәрдер шуны салганнар!..

һәркемгә диярлек таныш гади табигать күренеше. һәркемгә таныш тойгы. Тик һәркем аңа игътибар итмәгән. Ә менә шагыйрь тертеп күрсәткәч, шул гади табигать күренешенә бәйле буларак һәркемдә туа торган гади тойгыга карата үзенең фәлсәфи фикерен әйтеп биргәч, ул картина искиткеч, тирән мәгънәле шигъри образга әверелә.

Мин үтәргә куркам бу юллардан...

Әйе, безгә тормышта, бигрәк тә безнеке шикелле тарихта беренче булып яңа җәмгыять төзүчеләргә хас катлаулы тормышта бик куркыныч юллардан, коточкыч упкын кырыйларыннан үтәргә кирәк булган чаклар еш очрый. Кайвакыт кыенлыклардан, хәвефләрдән куркып, алга атларга шомланасың... Хәтәр күренә. Шунда шигырь синең исеңә төшерә:

Ә кемнәрдер шуны салганнар...

Чынлап та ул юлны салучыларга тагы да хәтәррәк булган бит! Җиңеләеп китәсең. Күңелеңә ташкын булып рухи көч килеп керә...

Кешелек дөньясын таңга калдырган әллә кайчангы каһарманнар, башларын, тормышларын корбан итеп, тарихта яңа юллар салган Джордано Брунолар, Галилейлар, Маркс, Энгельслар, бишенче ел батырлары, даһи Ленин, Октябрь революциясе еллары күңелеңнән кичә. Ниһаять, үз күзләрең белән күреп, үз кулларың белән тырмашып, үз аякларың белән атлап үткән юллар!.. Әле кайчан гына тиңсез гигант булып күренгән Днепрогэслар... безнең бүгенге югарылыктан, илебез күтәрелгән космик биеклекләрдән торып караганда,

Нинди нәни булып калганнар...

Шушы кичкенә шигырьдән күңелдә уянган уй-тойгыларны, күз алдына килгән картиналарны сөйләп китсәң, аларның очына чыгып булмас иде кебек. Шигъри образның көче дә шунда. Соңгы еллардагы поэзия әсәрләребез өчен бу бик характерлы.

һаман алга, югарыга омтылу, шул ук вакытта үтелгән юлга да борылып карау — яулап алынган биеклекләрне раслап, аларны поэзиядә мәңгеләштерергә тырышу тенденциясе безнең хәзерге шигырьләр өчен гомумән хас сыйфат. Моның иң характерлы матур үрнәген без Сибгат Хәкимнең «Үрләр аша» поэмасында күрәбез. Әлмәттән Европаның үзәгенә, бик күп үрләр аша, Карпат таулары аша үтеп, Германиягә хәтле дуслык юлы салына. Иң башлап бу юлдан Бөек Ватан сугышы елларында, кешелек дөньясына килгән фашизм афәтен җиңеп, совет солдатлары — Янар Яруллалар узa. Икенче кат, инде тыныч шартларда, сугыш тудырган экономик авырлыкларны җиңеп, Халидәләр — хезмәт кешеләре нефть торбасы салып узалар. Өченче катка менә шигырь уза бу юлдан. Шигырь белән бергә күп меңләгән укучылар уза.

Халкым юлда күтәрелгән үрләр —
Алар бар да минем үрләрем...—

ди шагыйрь. Болай дип горурланырга аның икелата хакы бар. Әйе:

Уз әле син сират күпереннән,
Дуга аша исән уз әле!..

Сибгат Хәким илебезгә тарихи җиңү китергән Курск дугасы җәһәннәме аша узып исән калган кеше. Каләм түгел, кулына корал тотып, Татарстаннан Европа үзәгенә туры юл ачучыларның берсе.

Халидә шул эзләр буйлап бара,
Бер сыналган юлдан йөрисең,
Салмый тормыш аерым трассалар,
Трассалар салмый җыр өчен...

Халык белән бергә, бер юлдан бара бездә шигырь. Ул шуның белән көчле дә. Бар иде шундый вакытлар, безнең нәшриятларыбыз шигырь китабы күтәреп килгән автордан куркалар иде. Акрын үтә иде шигырь китабы. Аз укыла иде шигырь. Чөнки чын поэзия дәрәҗәсенә ирешкән шигырь аз иде. Поэма дип, көйле хикәяләр языла иде, көйле мәкаләләр, рифмалаштырылган хәбәрләр күп иде. Дөрес, алар әле дә бетеп җиткәне юк. Шулай да хәзер безнең поэзиядә чын мәгънәсендә шигъри образларда гәүдәләнгән сәнгать дереслеге өстенлек итә. Шигырь-поэмаларыбыз бүгенге көн рухы белән сулый. Күп төрле формаларда, һәр шагыйрьнең үзенә хас алымда язылган, һәркайсы үзенчә булган хәлдә, заман стилендә иҗат ителгән йөзләрчә шигырьләрдә бүгенге совет кешесе образы гәүдәләнә. Хәсән Туфан, Сибгат Хәким, Әхмәт Исхак, Салих Баттал кебек, шигырьгә күптән килгән өлкән буын шагыйрьләребез иҗатларында картаймыйлар: заман рухын тоеп, халык белән бергә атлау аларны яшәртә. Иҗат активлыклары кимеми, әдәби осталык дәрәҗәләре арта бара... Галимҗан Латыйп, Мөхәммәт Садри, Нури Арслан иптәшләрнең күп еллык иҗатларын чагылдырган шактый бай эчтәлекле яңа җыентыклары чыкты. Әхмәт Юнысның «Туган җирем, сиңа җырым» җыентыгында совет кешесенең олы язмышын гәүдәләндергән шигъри образлар күңелне куандыралар. Вакытсыз мәрхүм булган Гали Хуҗи, Зыя Мансур дусларыбыз бүген безнең арада юк, ләкин аларның язып калдырган әсәрләре, поэмалары, җыентыклары яши, алар бу съездда да катнашалар.

Әдәбиятка сугыш чорында һәм аннан соңгы елларда килгән шагыйрьләр бүгенге поэзиябезнең төп эчтәлеген, аның идея-эстетик рухын билгели торган үзәк көчләр булып әверелә баралар. Илдар Юзеев, Әнвәр Давыдов, Шәүкәт Галиев кебек шагыйрьләр, фольклордан, классикларыбыздан һәм өлкән буын шагыйрьләрдән килгән традицияләрне дәвам иттерү белән бергә, заманга хас яңа стиль һәм образлар алып киләләр һәм бу яктан хәтта кайбер елкәннәргә дә уңай йогынты ясыйлар дияргә була. Алар белән бергә ярышып иҗат итүче Гамил Афзал, Хисам Камал, Әдип Маликов, Зәки Нури, Саҗидә Сөләйманова, Нәби Дәүли, Марс Шабаев, Әхсән Баян кебек шагыйрьләребез һәркайсы үзенә хас алымнарда, идея эчтәлекләре ягыннан да үзләренчә формалашкан күп яңа әсәрләр

белән шигъри хәзинәбезне тулыландырдылар.

Тагын шунысы куанычлы: поэзия кырларына яшен яшьнәтеп, күк күкрәтеп, талантлы, белемле, хәзергә кыска булса да, катлаулы тормыш юлы үтәргә өлгергән кыю яшьләр төркеме килә. «Ирләр булыйк» дип, «Тик кагылма романтикама» дип, «Мин дәресен сөйлим» дип, исән чагында җиргә кайгы орлыгы чәчмәскә «вәгъдә» биреп, Рәдиф Гатауллин килеп керде безнең сафка. «Гадиләргә гимн» җырлап, Равил Фәйзуллин килде.

> «Башыма кайгы килде дип,
> Тормыштан суынма син!» —

дип, һәм үзенең яшәү үрнәге белән дә, оптимистик шигырьләре белән дә шуны раслап, Фәнис Яруллин килде. Әнә:

> «Пәк тоягын машина кебек барам,
> Кешелек, каршыла мине!» —

дип, Рөстәм Мингалимов килә. Аның белән янәшә үз кредолары белән Ренат Харисов, Шамил Мәхмүдовлар, инде укучы күзенә исемнәре шактый еш чалына торган Камил Мостафин, Гәрәй Рәхим, Раил Шакиров, Зәһирә Гомәрова, Рәшит Әхмәтҗанов, Ренат Рәхимовлар иҗатларында бүгенге заман сулышын алып киләләр. Әнә, поэзиябез күгенә бер юлы бөркелеп, ундүрт яшь каләмнең «Беренче карлыгач»лары килеп чыкты. Бу «карлыгачлар» уңае белән Равил Фәйзуллинның бик борчылып язган мәкаләсен укыдык. Әйе, яшьләребез озаграк өлгерә. Бу уйландыра торган хәл. Ләкин шигырь турында сөйләгәндә салкын статистик саннарга нигезләп кенә фикер йөртү урынлы микән? Минемчә, бу урында төшенкелеккә бирелергә урын юк. «Осталыкка төп кыйбла — абсолют камиллек, шигъриятлелек булырга тиеш» дигән фикер белән дә килешәсе килми. Нинди «абсолют камиллек» ди ул? Әйтик, син аңа ирештең дә, ди. Ә аннары? Үсү тукталдымы? — Болар турында бәхәсләшергә мөмкин. Шулай да яшь шагыйрьнең гомумән алганда шактый тирән эчтәлекле, әдәбиятыбыз турында борчылу һәм кайгырту белән язылган мәкаләсе чыгу факты үзе мине ифрат куандырды. Бу безнең хәзерге шагыйрьләрдә сирәк очрый торган бик кадерле сыйфат. Әйе, поэзиябез бу чорда җитди уңышларга иреште дибез икән, аның якын киләчәге тагын да өметлерәк.

Ләкин әле бу шигырь жанрында безнең йомшак якларыбыз, кимчелекләребез юк дигән сүз түгел. Күзгә бәрелеп торган ике төрле кимчелек күңелне борчый. Беренчесе — форма белән артык мавыгучы иптәшләр бар. Әдәбиятка беренче адымнарын ясаучы яшьләргә карата мин моны билгеле дәрәҗәдә аңлашыла торган хәл дип карыйм. Шигырьдә үз тавышын табарга өлгермәгән, үзенең уй һәм тойгыларын ничек итеп үзенчә әйтергә әле өйрәнмәгән яшь автор, укучының (аның да, әлбәттә, беренче чиратта әдәби җәмәгатьчелекне төшенкил итә торган өлешенең) игътибарын тизрәк үзенә җәлеп итү өчен, ничек тә башкалардан аерылырга тырыша. Әгәр дә ул чынлап та талант иясе булса, күңелендә халкына әйтерлек олы хис һәм фикерләре булса, җәмәгатьчелек аңа игътибар итә һәм андый шагыйрь бик тиз үз тавышын да табып ала.

Күбесенчә «Татарстан яшьләре» битләрендә мондый тәҗрибәләр ясаучы Айдар Хәлим, Ренат Харисов һәм башка кайбер яшьләр бу өзләү чорын исән-сау үткәреп җибәрерләр дип ышанам. Ә менә Роберт Әхмәтҗановта форма белән мавыгу чире озакка сузылды. Аның шул ук «Татарстан яшьләре» битләрендә басылып чыккан «Тәңге монолог» дигән кыланышларын бернинди киртәгә дә сыйдырып булмый. Юк, эзләнү түгел бу. Коллективтан, җәмәгатьчелектән, халыктан аерылу, тормыштан гел ансат бирелә торган арзанлы рәхәтлек кенә эзләп йөрү бәласе.

Форма белән кирәгеннән артык мавыгу уены чын-чынлап формализм чиренә әйләнеп китмәсен өчен, тәнкыйтьчеләребезгә генә түгел, редакторларга да таләпчәнрәк була белергә кирәк.

Шул ук таләпчәнлек җитмәү аркасында нәшрият практикасында күзгә бәрелә торган икенче кимчелек: юл саннары гадәттән тыш күп, поэтик эчтәлеге юк дәрәҗәсендә аз булган примитив шигырь җыентыклары. Бу яктан аеруча характерлы мисал итеп, Абдулла Сәләхетдинов белән Касыйм Фәсәхов иптәшләрнең китапларын китерергә мөмкин. Аларның икәү бергәләп язган «Миша җыры»н карагыз. Тугыз йөз юлдан артыкка сузылган бу әсәрдән мин сәнгать дәрәслеге дәрәҗәсенә ирешкән бер генә куплет та таба алмадым, диярга мөмкин. Әдәбиятның төрле жанрында төрле авторлар тарафыннан инде әллә кай заманнардан бирле әйтелә килгән хакыйкатьне, ягъни «коры шиккә таянып, тормыш иптәшеңне көнләргә ашыкма» дигән дидактик фикерне әйтү ни өчен кирәк булгандыр? Әйтергә ниятләнгәнсең икән инде, нигә аны бу кадәр озын итеп язарга кирәк булгандыр? Бу җыентыкка кергән шундый ук озын-озын күләмле башка әсәрләрдә дә бернинди шигъри ачыш, бернинди хәзерге заман рухы юк. Фәсәхов иптәшнең «Пәрвез» поэмасы да шундый ук күңелсез тәэсир калдыра. Биш йөз юлга якын күләмгә сузылган әсәрнең идея эчтәлеге мондый примитив фикергә кайтып кала: «Надан карчыклар сүзенә карап, балагызны сөннәткә бирмәгез, каны агулanып үләр, баласыз калырсыз». Бу иптәшләрнең мин әйбәт кенә очеркларын укыганым бар. Кыска шигырьләре арасында уңышлылары да юк түгел. Сәләхетдиновның кызыклы гына мәсәлләре дә күренә. Ләкин алар әнә шундый юллар саны артыннан куып язылган сай эчтәлекле примитив әсәрләр астында күмелеп калалар. Бу турыда аларга җитди уйларга кирәк.

Идея-эстетик эчтәлекләре гаять примитив, сәнгатьчә эшләнү ягыннан бик түбән сыйфатлы әсәрләр бер шигырь буенча гына түгел, хикәя, драма жанрында да һаман чыга торалар. Без күп вакытта классикларыбызны басарга, тугандаш әдәбият-

ларның күренекле әсәрләрен чыгарырга кәгазь җитми дип зарланабыз. Ә нәшрият практикабызда әнә шундый чын әдәбият булмаган әсәрләргә никадәр кәгазебез исраф була. Гонорар фондыбыз югала. Үз әсәрләренә җавапсыз караучы авторлар нәшриятының үз аппаратында эшләүчеләр арасында да булуы халтурага каршы көрәшне читенләштерә.

Яшьләр күбрәк әдәбиятка шигырь язып киләләр. Ләкин тарих шуны күрсәтә: вакыты белән алар арасыннан бик әйбәт прозаиклар да, драматурглар да, тәнкыйтьчеләр дә чыга. Бер үк вакытта төрле жанрда каләм сынаучы, шулай ук турыдан-туры хикәя, повесть яки сәхнә әсәрләре язып килүче Радик Фәизов, Мәдинә Маликова, Вахит Монасыйпов, Туфан Миңнуллин, Фаил Шәфигуллин, Гәрәй Рәхим, Альберт Хәсәнов кебек өметле каләм ияләре дә укучы күзенә күренә киләләр. Шулай да, прозага килә торган яшьләрдән киң катлам укучының да, язучылар җәмәгатьчелегенең дә игътибарын җәлеп итәрлек чын мәгънәсендә талантлы, тирән эчтәлекле әсәрләр тудырган язучы күренми әле дисәк, күңелсез булса да, ялгыш булмас. Бу мәсьәләгә безнең әдәби ел йомгакларына багышланган җыелышларда игътибар ителгәне бар. Яшьләрнең аеруча проза өлкәсендә нормаль үсүенә тоткарлык иткән җитди сәбәпләрнең берсе итеп, алар өчен махсус журнал булмау һаман әйтелә килә. Бу турыда без кирәкле урыннарга да җитәрлек ишеттердек инде. Шәт иншалла дигәндәй, мин үзем киләсе съездда яшьләр өчен журнал юк дип зарлану урынына, инде барлыкка килгән ул журналның уңышлары һәм кимчелекләре турында фикер йөртербез дип ышанам.

## БАРЫБЫЗНЫҢ ДА ИГЪТИБАРЫНА МОХТАҖ ЖАНРЛАР

Ә хәзергә журнал булмау җитешсезлеген каплау эшен китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторы өлешчә үз өстенә алып килә. Ягъни яшь һәм башлап язучы авторларның әсәрләре, кагыйдә буларак, шул секторда басылалар. Нәтиҗәдә китап итеп аерым басып чыгару өчен әдәби яктан җитлекмәгән әсәрләр дә күбрәк шул сектор аркылы үтеп китәләр. Шулай да яшьләр секторы соңгы елларда балалар әдәбиятын бастыруны оештыру буенча нәтиҗәле эшләп килә. Балалар әдәбиятының торышын да без, башлыча, шул сектор чыгарган китапларга карап билгелибез. Үзләренең иҗатларын тулысы белән диярлек балалар әдәбиятына багышлаган Гариф Гобәй, Җәвад Тәрҗеманов, Ләбибә Ихсанова, Әминә Бикчәнтәева, Госман Бакиров кебек язучыларыбызны без бу елларда гы хезмәтләре өчен дә хөрмәт белән телгә алып китәбез. Ләкин балалар әдәбияты алар белән генә канәгатьләнми, ул бөтен язучыларның да үзенә игътибар итүен сорый. Һәм безнең мондый, балаларга игътибарлы, язучыларыбыз да әз түгел. Шәүкәт Галиевнең соңгы елларда балалар өчен бик нык күңел биреп, җиңел юмор планында язылган шигырьләре мәктәп балалары һәм нәниләр өчен язылган әдәбиятыбызны баеталар.

Әдип Маликовның мәктәп яшендәге балалар өчен махсус язылган «Кембригә юл салучылар» китабы әйбәт, җанлы тел, мавыктыргыч картина һәм вакыйгалар аркылы укучыны тайга күренешләре, Лена елгасы буенда яшәүче кешеләр тормышы, андагы кыйммәтле җир асты байлыкларына безнең якташларыбызның ничек итеп юл ачулары белән таныштыра.

Гариф Ахуновның «Канатлар кая илтә» исемле китабы да шулай ук язучыга хас җанлы телдә балаларны үз республикабыз һәм аның алдынгы кешеләре белән таныштыра. Шамил Ракипов «Чәчәкләр сөйли белә» дип аталган документаль повестенда Александр Матросов батырлыгын кабатлаган якташыбызның героик тормышын сурәтли. Самат Шакирның «Легенда егетләре» китабы да балалар өчен дә, зурлар өчен дә кызыксынып укырлык файдалы хезмәт.

Яшь буынны тәрбияләү эшендә мондый характердагы әсәрләрнең роле аеруча зур дип карыйм мин. Кызганычка каршы, безнең язучылар арасында мондый күп хезмәт сорый торган эшкә алынучылар сирәгрәк шул әле.

Шушы арада гына без Гомәр Бәшировның «Ата каз белән ана каз һәм аларның унике бәбкәсе» дигән хикәясен укыдык. Хәтерем ялгыштырмаса, бу аның нәниләр өчен язылган беренче әсәре. Бик гади тема. Ләкин тәҗрибәле художник каләме белән язылган чын сәнгать әсәре буларак, яшь укучыларыбыз өчен никадәр зур бүләк.

Сибгат Хәким, Габдрахман Әпсәләмов, Әмирхан Еники кебек язучыларыбыз да бу өлкәдә каләмнәрен сынап карасалар, мәгаен, нәни укучыларыбызны чынлап куандырырлык күп кенә яңа әсәрләр дөньяга килер иде.

Барлык язучылар ярдәменә мохтаҗ булган тагы ике жанр бар бездә: драматургия һәм әдәби тәнкыйть.

Иҗатларын тулысы белән драматургиягә генә багышлаган язучылар саны бездә ярты дистәдән артмый. Театрларыбызны репертуар белән тәэмин итү эше башлыча икенче жанрда эшләүче авторлар ярдәме белән алып барыла. Андыйлар да күп түгел. Шулай да сәхнә әсәрләре аз языла дип булмый. Рәшидә ханым Җиһаншинаның әйтүенә караганда, бер аларның театрына гына да елына алтмыш-җитмешләп кулъязма китерәләр икән. Ләкин шулар арасыннан әдәби кыйммәтләре ягыннан Татар дәүләт академия театры сәхнәсенә куярлык дәрәҗәдә булганнары биш-алтыдан артмый, ди.

Сәхнәгә куярлык дәрәҗәдә язу!

Бу бит әле таләпнең иң кечкенәсе. Заман үзенә тиң әсәрне сәхнәгә чыккан пьесалар арасыннан сайлый. Уңышлар юк түгел, әлбәттә. «Шамил Усманов» драмасының җитди игътибарга лаек спектакль булуы турында баштарак әйтеп киткән идек инде. Соңгы өч ел өчендә сәхнәгә чыккан әсәрләрдән Шәриф Хөсәеновның «Зөбәйдә — адәм баласы», кайбер бәхәсле яклары бу-

лу белән бергә, тамашачы күңелендә җитди, тирән эз калдырды. Сәнгатьчә эшләнгән җанлы образлары, жанрына күрә тормышчан ситуацияләре белән, яшь буынны тәрбияләү, кешеләргә мөнәсәбәт мәсьәләләрендә ул безне бик кирәкле юнәлештә уйландыра торган әсәр. Хәй Вахитның «Соңгы хат», «Күк капусы ачылса», Риза Ишморатның «Шаулыйлар дулкыннар» комедияләре үз жанрлары күләмендә нигездә уңышлы хәл кылынган әсәрләр буларак, менә берничә сезон буенча тамашачыны тотып киләләр. Тәрҗемә әсәрләрдән «Фатыйма Сабри», «Бәйрәм кичендә», «Кол» спектакльләре яхшы тәэсир калдыралар. Ә шулардан башкалары? Заман сулышын тоеп, киеренке һәм җиңүләргә бай чорыбызны чагылдыруда бүгенге көн таләпләренә җавап бирерлек итеп язылган әсәрләребез кайда? Халкыбызның батырлыгына, фидакарь хезмәтенә, мораль югарылыгына лаек булырлык тулы образлар иҗат итә алдыкмы? Драматургларыбыз бу мәсьәләдә тамашачы һәм театрларыбыз каршында бик зур бурычлылар, дияргә генә туры килә. Ләкин шунысы бар: заман таләп иткән зур масштаблы әсәрләр тудыру мәсьәләсе турыдан-туры театрга, аның идея-эстетик таләпләре ни дәрәҗәдә булуына да бәйләнгән. Авыр булса да, дөресен әйтергә туры килә, бу яктан Академия театрыбыз әле драматургларны идея йөкләмәсе җиңел булган, күбрәк кассага хезмәт итә торган әсәрләр язуга ориентацияли.

Үз драматургларыбыз тарафыннан бүгенге чынбарлыктагы теге яки бу кимчелекләрне тәнкыйтьләргә тырышып язылган, ләкин күбесенчә тар гаилә конфликтларыннан яки интим мәхәббәт маҗараларыннан ары китә алмаган әсәрләр буенча куелган зәгыйфь спектакльләр шактый булды.

— Шулардан яхшырак бүтән әсәрләрегез булмагач, театр нәрсә куйсын соң? — диюләре мөмкин.

Ә менә «Инде китмә!» спектакле нәрсә аңлата соң? Дистәләрчә зур сәхнәләрдә сыналган йөзләрчә әсәрләре булган бүгенге рус драматургиясеннән, хәтта мин әйтер идем, күп милләтле совет драматургиясеннән безнең театрыбыз Валерий Турның татар театры сәхнәсенә ят, аның мораль сафлык традицияләренә хилаф порнографик күренешләрне эченә алган, идея позициясе дә томанлы булган «Инде китмә!» драмасын сайлап алып сәхнәгә куя! Бу хәл театрыбызның художество җитәкчелеге, аның эстетик принциплары турында безне борчуга төшерә.

Күптән түгел без «Миләүшәнең туган көне» спектаклен карадык. Мин бу спектакль өчен Туфан Миңнуллинны гаепләргә җыенмыйм. Яшь автор сәхнәбез өчен яңа булган тормыш материалы алып килә. Иҗат интеллигенциясе арасында конъюнктурага карап эш итүче, карьера артыннан куучы типларны фаш итү, чын иҗат атмосферасы өчен көрәш проблемаларын куярга тели. Ләкин аны сәхнәгә куючы иптәшләр авторга тиешенчә ярдәм итә алмаганнар. Нәтиҗәдә, театр кире образ итеп күрсәтергә тырышкан Шәһит — уңай образ булып гәүдәләнә диярлек. Ә уңай образлар киресенчә тәэсир калдыра. Чынлыкта Шәһитнең гаебе нәрсәдә соң? Өч бүлмәле яхшы квартирасы булу белән битәрлиләр аны. Кайчандыр үзе белән бер торакта яшәгән, хәзерге көндә берсе уңмаган шагыйрь, икенчесе уңмаган композитор хәлендә йөрүче иптәшләреннән аерылуда, алар белән бергә аракы эчеп, юк-бар сөйләп утырырга теләмәүдә гаеплиләр. Ниһаять, иң зуры: имештер, ул явыз ният белән икенче бер художникның эшен тәнкыйтьләгән: геройны болай мескен итеп күрсәтү дөрес түгел, дигән. Сәхнәдә без ул геройны да күрәбез. Һәм монда да кире образ хаклы, дигән тәэсир кала.

Бу турыларда барыбызга да җитди уйланырга кирәк. Бу мәсьәләдә театрыбызның да, драматургларыбызның да әдәби тәнкыйтьтән эффектлы ярдәм көтәргә хаклары бар.

## ТӘНКЫЙТЬКӘ МОХТАҖ УРЫННАР

Әдәби тәнкыйть буенча да язучыларыбыз бу съездга шактый җитди уңышлар белән килделәр.

Узган съездларда без һаман тәнкыйтьне бүгенге әдәбият алдында торган проблемалардан читтә калуда, хәрәкәттәге әдәбият турында аз язуда гаепли килә идек. Бу чорда хәлләр яхшы якка таба сизелерлек үзгәрде. Моңа Язучылар союзы һәм редакцияләр тарафыннан уздырылган оештыру чаралары да ярдәм итте. «Хәзерге поэзиядә Г. Тукай, М. Җәлил традицияләре» дигән темага «Социалистик Татарстан» битләрендә алып барылган дискуссиядә тәнкыйтьчеләр генә түгел, бик күп күренекле шагыйрь һәм язучыларыбыз да, шулай ук укучылар да актив катнашты. Дискуссия барышында поэзиядә халыкчанлык, патриотизм, гуманизм, заман белән тыгыз бәйләнеш традицияләрен яклап һәм шигырьдә новаторлыкны формадан гына эзләргә тырышу тенденцияләрен тәнкыйтьләп, бик күп җитди дәлилле фикерләр әйтелде.

Башта әйткәнемчә, һәр әдәби елны күмәкләшеп йомгаклау мәҗлесләре уздыру, «Казан утлары»нда басылган әсәрләр турында өч ай саен фикер алышу практикасы хәрәкәттәге әдәбиятка тәнкыйтьне активлаштыру эшенә бик зур уңай йогынты ясадылар. Шундый фикер алышулар нәтиҗәсе буларак, журнал һәм газета битләрендә Хатип Госман, Ибраһим Нуруллин, Рафаэль Мостафин, Фәрваз Миңнуллин, Гариф Ахунов һәм башка иптәшләрнең җитди мәкаләләре басылды. Шулар арасында хәзер инде үзе мәрхүм булган Рөстәм Башкуровның бүгенге поэзия турында тирән эчтәлекле, бай фикерле мәкаләсен аеруча искә алып китәсе килә. Зәет Мәҗитов, Флүн Мусин, Баян Гыйззәт иптәшләрнең шундый характердагы чыгышлары аларның әле күптән түгел басылып чыккан «Заман сулышын тоеп» исемле китапларына нигез булды. Шулай ук Нил Юзиевнең «Традицияләр яңарганда» дигән җыентыгы да шул

фикер алышулар нәтиҗәсендә дөньяга килгән хезмәт.

Рафаэль Мостафинның «Әдәби портретлар» китабы, Гали Халитнең «Романтизм һәм реализмны яклап», «Бәхәсле һәм бәхәссез хакыйкатьләр» дигән теоретик характердагы мәкаләләре, Нил Юзиевнең «Музалар туганлыгы» дигән хезмәте, Гази Кашшаф, Роберт Бикмөхәммәтов, Мансур Хәсәнов, Азат Әхмәдуллин һәм башка күп иптәшләрнең Муса Җәлил, Галимҗан Ибраһимов, Габдулла Тукай, Фатхи Бурнаш, Кәрим Тинчурин һәм бүгенге көндә үзләре исән булган күренекле язучыларыбызның юбилейлары уңае белән язылган дистәләрчә китап һәм мәкаләләре — болар бары да шушы, VI нчы съезддан соңгы, чорда иҗат ителгән хезмәтләр.

Әйе, әдәби тәнкыйть жанры сизелерлек активлашты. Шулай да ул язучыларыбызның өзлексез хәрәкәттә булган иҗат эшчәнлеге артыннан, бүгенге әдәбият алдында туып торган яңадан-яңа проблемалар артыннан куып өлгерә алмый әле. Поэзия дөньясында әледән-әле ялтырап китә торган кыйммәтле асыл ташлар гына түгел, хәтта зурзур китаплар, романнар, повестьлар да, сәхнә әсәрләре дә тәнкыйть игътибарыннан читтә кала бирәләр. Бу яктан балалар әдәбияты әсәрләре аеруча бәхетсез. Танылган тәнкыйтьчеләребез аны бар дип тә белмиләр диярсең. Шушы уңай белән балалар әдәбиятының патриоты Җәвад Тәрҗемановның иптәшнең кызыклы тәҗрибәсен искә төшерү урынлы булыр дип уйлыйм. «Ян йолдызым, ян» дигән китабында ул үзенең балалар әдәбиятына кагылышлы мәсьәләләр буенча көндәлек практикада әйткән фикерләрен, җыелышларда ясаган чыгышларын, вакытлы матбугатта игълан ителгән мәкаләләрен басып чыгарды. Әлбәттә, аның эчтәлегендә бәхәсле урыннары да булуы мөмкин, һәрхәлдә, балалар әдәбиятына кагылышлы проблемалар буенча фикер кузгату ягыннан ул җыентыкның әһәмияте зур, ләкин тәнкыйтьчеләребез аны да игътибарсыз үткәрделәр шикелле. Игътибар итәргә әле дә соң түгел дип уйлыйм.

Соңгы елларда шактый авырлык белән бара торгач сатира-юмор жанры, кыска хикәяләр проблемасы һәм практик һәм теоретик характердагы тәнкыйть ярдәменә бик каты мохтаҗлар.

Әйе, тәнкыйтьнең азлыгы, күп әсәрләребезгә карата аның бөтенләй юклыгы әле һаман да бу өлкәдәге җитди кимчелекләребезнең берсе булып кала.

Тәнкыйтьнең булган кадәресенә нәрсә җитми? Кайвакыт бездә принципиальлек җитеп бетми. Бигрәк тә дискуссион мәкаләләрдә. Тукайның 80 еллыгы уңае белән Ибраһим Нуруллинның «Шагыйрьне өйрәнү юлында» дигән мәкаләсе чыкты. «Казан утлары» редакциясе бу бәхәсле характердагы мәкаләне басу белән Тукай иҗатының һәм тормышының әле ачыкланып бетмәгән мөһим якларын ачыкландыруга ярдәм итүне максат итеп куйгандыр. Ләкин шундый зур юбилей тантанасына хәзерлек көннәрендә укучыда: «Тукай без уйлаганча ук зур түгел икән» дигән фикер уяту рухында язылган ул мәкалә яхшы нәтиҗә бирмәде. Бу дискуссиягә катнашучылар мөһим мәсьәлә турында җитди сөйләшү урынына күбрәк Тукай иҗатының кулэгәле якларын урынсыз һәм вакытсыз күперткән мәкаләгә отпор бирү рухында язарга мәҗбүр булдылар.

Бәхәсле әсәрләрне басу һәм алар турында бәхәс алып баруны оештыру эшендә безгә тәҗрибә җитми әле.

Бәхәсле дип әдәбиятта без нинди әсәрләрне атыйбыз? Тормыш өзлексез хәрәкәттә. Ул үзенең алга бару юлында төрле каршылыкларга очрый. Ул каршылыклар аерым кешеләрнең яки төркемнәрнең күңелендә төрле настроениеләр тудыра. Ул настроениеләрнең заман рухына хас килгәннәре булган кебек, кайвакыт, аның табигый үсешенә, алга барышына кире килә торганнары да була. Кайвакыт бөтенләй читтән, коммунизмга каршы лагерьдан җибәрелгән настроениеләр дә безнең яшьләр арасына килеп кергәли.

Шуннан теге яки бу тарихи чорга төрлечә мөнәсәбәтләр килеп чыга. Язучы үзенең әсәрләрендә халык арасында булган төрле настроениеләрне чагылдыра. Дөньяга карашы нык, идеология фронтында көрәш тәҗрибәсе белән яхшы таныш язучы, ул настроениеләрне чагылдыру белән бергә, аларга карата үзенең нинди позициядә булуын да сиздерә: заман рухына хас булган, үсәргә тиеш булган настроениеләрне раслый, кирегә өстери торганнарын хөкем итә. Асылда безнең әдәбиятыбыз шундый әсәрләрдән тора. Без аларны бәхәсле димибез.

Ләкин безнең бүгенге катлаулы чорда, ягъни без бер яктан, экономик мәсьәләләрдә капиталистик илләр белән янәшә тыныч яшәү политикасын якласак, икенче яктан, идеологик мәсьәләләр буенча ике дөнья арасында аяусыз көрәш алып барган заманда яшьләр арасында туып торган төрле настроениеләрнең кайсы яхшы, кайсы начар икәнен чамалау да ансат кына түгел.

Әнә шундый бераүләр өчен яшәргә хаклы булып тоелган, икенче бераүләргә очраклы күренгән настроениеләр кайбер әдәби әсәрләргә дә килеп керә. Аны бераүләр хуплый, бераүләр кире кага. Мондый әсәрләрне без бәхәсле дибез. Андый әсәрләрне басып чыгаруга без каршы килмибез. Алар безгә тормышның томанлы якларын җәмәгатьчелек белән бергәләп ачыкларга уңайлы сылтау булалар. Әмирхан Еникинең «Рәшә» повесте, «Әйтелмәгән васыять» хикәясе, Аяз Гыйләҗевнең кайбер хикәяләре, Нурихан Фәттахның «Артта калган юллар»ы бездә шундый бәхәсләр тудырдылар. Бәхәсле әйбер басылып чыга һәм аның турында матбугат битләрендә җитди һәм нәтиҗәле бәхәс алып барыла икән — бу бик әйбәт. Ләкин бездә еш кына болай да була: бәхәсле әйбер басылып чыга, аның турында кулуарларда төрле сүзләр йөри, ләкин матбугат битләрендә берни дә язылмый кала. Бусы инде әйбәт түгел. Узган ел «Казан утлары»нда Әхсән Баянның «Яшьлегем-

не эзлим» повесте басылды һәм аның турында укучылар фикеренә дә журнал битләрендә урын бирелде. Ләкин бәхәскә йомгак ясалмады һәм укучыларда журналда соңгы булып басылган фикер — Аяз Гыйләҗевнең: «Укучы, син үзең кем?» дигән мәкаләсе — редакция фикере дигән уй калды. «Социалистик Татарстан» газетасында басылган, нигездә журналның уңай һәм кимчелекле якларын дөрес ачкан күзәтүдә дә бу мәкаләгә шулай бәя бирелә. Хәлбуки, бу редакциянең йомгаклау мәкаләсе түгел әле. Һәрхәлдә, Әхсән Баянның сугыш еллары яшь буынны бары рухи яктан имгәтте генә, аларны яшьлек рәхәтеннән мәхрүм итү белән бергә, килачәкләрен дә канатсыз калдырды, дигән характердагы тезислары белән килешеп булмый. Шулай ук аның бу әсәрендә дә, «Күзләре нинди иде» дигән пьесасында да, кайбер җитәкчеләрнең хуҗалык буенча бер урында уңышка ирешү өчен икенче урында урлашуларын уңганлыкка, хәтта фидакарьлеккә санавын кабул итеп булмый. «Яшьлегемне эзлим»не тәнкыйть итеп язган укучыларны гаепләгән мәкаләсендә Аяз Гыйләҗев, Әхсән Баян әсәрләрендә бөтенләй булмаган фикерләрне үзе уйлап чыгарып, аны яклау юлына баса.

Соңга калып булса да, әлбәттә, редакция бу турыда үз фикерен әйтергә тиеш булыр. Бу бәхәсле әсәрләрне басу белән бергә, алар турында фикер алышуны да тиешенчә оештыру чарасын күрергә кирәк. Хәзергә бездә бу җитми әле.

Тәнкыйтьнең әйдәп баручылык роле йомшак булу, әдәби практикабыздагы уңыш һәм кимчелекләрне гомумиләштерү көче җитмәү нәтиҗәсендә, кайвакыт язучыларыбыз иҗатында бер тема тирәсендә озак таптану, инде үтелгән баскычларны кабатлау күренешләре килеп чыга. Шәхес культы чорындагы башбаштаклыкларның һәм антидемократик тәртипләрнең кеше рухын имгәтүен һәм аның аянычлы нәтиҗәләрен сурәтләүгә багышланган әсәрләр бездә артык күпкә китә башлады. Әйтик, Атилла Расихның «Ике буйдак» романындагы Заһид образыннан соң, Әмирхан Еникинең «Тәнге тамчылар»ы да, Ф. Хәсниның «Язмыш шуклыгы» да әдәбиятыбызга әллә ни яңалык алып килмәделәр. Әсәрләребездә ире төрмәгә китеп тол калган хатыннар, әтисе кулга алынып ятим калган кызлар, егетләр күбәеп китте.

Шәхес культын партиянең Үзәк Комитеты үзе шулай фаш иткәннән соң, бу темага рус әдәбиятында да, башка халыклар әдәбиятында һәм үзебезнең әдәбиятыбызда да инде дистәләрчә генә түгел, йөзләрчә әсәрләр язылганнан соң, һаман шул мәсьәлә тирәсендә әйләнү яңалык та түгел, бернинди кыюлык та түгел.

Шәхес культы чорындагы аянычлы хәлләрне онытырга кирәк дип әйтәсем килми. Аның яңа шартларда кабатлану ихтималы булган аерым күренешләренә карата игътибарсыз булырга ярамый.

Тагын Мәхмүт Хәсәновның «Юллар, юллар» романыннан бер өзек искә төшә. Анда бер җыелышта эшчеләр үзләренең җитәкчеләренә каршы бик каты тәнкыйть белән чыгалар. Масса тәнкыйтьтән кысарга теләүче, иске стиль белән эш итүче партком секретаре Яруллин бу хәл өчен ачуланып, башлангыч партоешма секретарен — заман рухын тоеп эш итүче Варис Исламовны бюрога чакыртып тирги: «Сез анда забастовка оештырып ятасызмы?» — ди. Варис аңа тиешенчә җавап бирә алмый да урамга чыккач үкенә. Уртак сөйләм алымы белән автор үзе дә кушыла аның үкенүенә.

«Их, Варисның үзендә дә гаеп бар...— ди ул. — Ә бит аңар, кабаланмыйча, кызмыйча, вакыйганың асылын, чынын төшендереп бирергә була иде.

Ә мин, диясе иде аңар, халыкның шулай канәгатьсезлек күрсәтүенә, ризасызлык белдерүенә куанам гына. Кеше хәзер үз дәрәҗәсен белә, аңы үскән, кимчелекләр белән килешә алмый. Ә менә алар тарафыннан куелган таләпләрне тиз генә тормышка ашыра алмавыбыз аянычлы, диясе иде...»

Монда мин язучының җитәкчелек эшендә культ чоры стилен дәвам иттерергә азапланучыларга каршы тавыш күтәрүен ишетәм. Аны укучы да, үзенә тигән җитәкче работниклар да ишетә торгандыр. Мондый тавышларны тәнкыйть тә ишетергә тиеш дип уйлыйм.

Шулай ук, өлешчә булса да, тәнкыйть күзе җитмәү аркасындадыр дип беләм, әдәби осталыкка кагылышлы мәсьәләләрдә дә күзгә бәрелеп торган кимчелекләр яшәп килә. Вакыйгалар, образ аша әйтелергә тиешле идеяне сөйләп бирү, бүгенге укучының интеллектуаль үсеш дәрәҗәсен искә алмыйча, бик гади хакыйкатьләрне яңалык сыйфатында китерү һәм аларны энәсеннән җебенә кадәр төшендереп бирергә, әйтеләсе фикерне чәйнәп каптырырга тырышу характерындагы күптән искергән алымнар бездә һаман очрый әле. Ситуацияләр, сюжет алымнары кабатлану күренешләре бар. Әйтик, ирсез йөри торган берәр чибәр, акыллы кызга яки тол хатынга кияү кирәк була да, авторлар аңа һәрьяктан лаек булган бер яшь кенә ирнең хатынын үтерәләр. Шуннан яңа мәхәббәт сызыгы туа. Бу ситуацияне без «Ике буйдак»та да, «Ак чәчәкләрдә»дә, «Юллар, юллар»да да, «Авыл иртәсе»ндә дә очратабыз. Ул китапларның һәркайсын аерым-аерым укыганда сизелми. Ә барысын бергә җыеп, янәшә куеп карый башласаң, ничектер күңелсез булып китә. Язучыларыбыз фантазиягә ярлы булып күренә башлый. Мондый мәсьәләләрдә безнең тәнкыйть күзе бик үткен булырга тиеш.

---

Бездә шактый куәтле рус язучылары секциясе эшли. Рус телендә язучыларның саны хәзер 18 гә җитте. Тагы шул чамада яшьләр, аерым китапларын чыгарган яки вакытлы матбугатта басылып килүче каләм ияләре бар.

Тихон Журавлев, Константин Лебедев, Рөстәм Кутуй, Геннадий Паушкин иптәшләрнең әсәрләре, үзәк матбугатларда басылып,

союз күләм әдәбият орбитасына чыктылар.

Софья Борисовна Радзиевская, инде 75 яшьтә булса да, яшьләрчә дәрт белән эшләп килә. Балалар өчен аның яңадан-яңа китаплары ел саен чыгып тора.

Алексей Иванович Салминга да күптән түгел 75 тулды. «Идел буенда давыл» трилогиясеннән соң ул яңа әсәр өстендә эшли.

Валерий Синев, Ян Винецкий, Александр Булгаков, Илгиз Калимуллин, Бабенко, Елизарова иптәшләр актив эшләп киләләр.

Узган ел «Щелья» дигән диңгез көймәсендә зур сәяхәт итеп, союз күләмендә дан алган якташыбыз Михаил Скороходов та хәзер Казанга кайтты, шул данлы сәяхәт турында ул яңа повесть язды.

Русча язучылар сафына да актив яшьләр тәркемә килә. Шушы елларда гына Иван Данилов, Николай Беляев, Алексей Королев, Виктор Костригин, Нонна Орешина, Гани Бикушев иптәшләрнең китаплары басылды. Съездга «Радуга» исеме астында яшьләрнең шигырьләр җыентыгы чыкты. Марсель Зарипов һәм Дмитрий Сычев иптәшләрнең китаплары чыгып килә.

Рус телендә язучылар турында өстәмә доклад буласын истә тотып, мин аларның иҗатларына туктала алмыйм. Тик шуны әйтәсем килә: аларга карата РСФСР Язучылары союзының игътибары җитми. Аларны Татарстан язучылары союзының бер секциясе итеп кенә карала. Ә алар үзләренең саннары белән дә, иҗат активлыклары белән дә, башка өлкәләрдә аерым бүлекләре булган бик күп оешмалар белән ярыша алалар. Татарстандагы рус язучылары өчен үз штаты булган махсус җитәкче кирәклеге бик нык сизелә. РСФСР Язучылары союзы җитәкчелеге бу турыда җитди уйларга тиеш.

---

Иптәшләр!

Олы юбилей билгесе астында узган бу чорда язучылар тарафыннан башкарылган эшләр, алда торган проблемалар, әлбәттә, бүген искә алынган әсәрләр һәм аларга бәйле мәсьәләләр белән генә бетми. Бу чорда бездә узган ярты гасыр эчендә иҗат ителгән уңышларыбыз да искә алынды. Классикларыбызның һәм үзләре исән булган күп кенә язучыларыбызның өчәр томлык, икешәр, яки берәр томлык сайланма җыентыклары чыгарылды. Якын киләчәктә тагын да зуррак җыелмалар планлаштырыла. Практикабызда тәрҗемә эшләре елдан-ел зур урын ала бара. Ләкин бер докладта барына да туктальп бетү бик читен. Өстәмә докладлар һәм фикер алышуларда катнашучы иптәшләр аларга туктальрлар, хисап докладыбызны тулыландырырлар дип ышанам.

Совет властеның 50 еллыгы тудырган рух күтәренкелеге, кайнар иҗат дәрте язучыларыбыз күңелендә сүрелгәне юк. Ул дәвам итә. Алда Бөек Октябрь революциясен оештыручы һәм аны гамәлгә ашыручы даһи Ленинның тууына 100 ел, Ленин партиясе байрагы астында барлыкка килгән һәм бүгенге дәрәҗәсенә ирешкән Татарстаныбызга 50 ел тулу бәйрәмнәре көтә. Бу тарихи көннәрне без, узган ярты гасырда иҗат ителгән рухи байлыкларыбызны тагын да җентекләбрәк барлау белән бергә, заманыбыз таләпләренә һәрьяктан җавап бирерлек чын мәгънәсендә сәнгать югарылыгына ирешкән яңа әдәби әсәрләр белән каршылау өчен көрәшәбез.

Партиябезнең, моңа кадәр булган кебек, таләпчән һәм аталарча кайгыртучан җитәкчелеге һәм ярдәме белән бу көрәштә тагы яңа уңышларга ирешербез дип ышанабыз.

# СЕРЛЕ ЙОМГАК ЭЗЕННӘН

*(Берлинда табылган яңа материаллар хакында)*


1968 елның 15 февралендә, Муса Җәлилнең тууына 62 ел тулган көне, Германия Демократик Республикасының башкаласы Берлинда чит ил һәм совет журналистлары өчен матбугат конференциясе уздырыла. Кыскача кереш сүз сөйләп, конференцияне герман-совет дуслыгы җәмгыяте председателе Курт Тимме ача. Аннан соң трибунага җәмгыятьнең идарә әгъзасы, танылган публицист һәм тәрҗемәче Леон Небенцаль күтәрелә. Ул журналистларны Берлинда табылган гаять әһәмиятле яңа документлар белән таныштыра. Алар — җәлилчеләр турында.

Л. Небенцаль Җәлилнең Моабит шигырьләре белән беренче тапкыр 1955 елда «Советлар Союзы матбугаты» исемле журналның редакторы булып эшләгәндә таныша. Җәлил шигырьләрен беренче укуда ук ярата ул. Ул шигырьләр, ничектер, бик үз, якын тоелалар аңа. Небенцальне, барыннан да бигрәк, фашистлар зинданында күп җәфа чиккән бер шагыйрьнең немец халкына карата дустанә мөнәсәбәттә булуы гаҗәпләндерә. Европа күген фашизмның кара шәүләсе каплап алган бер чорда шагыйрь мәгърифәт, хөрлек һәм тигезлек Германиясе, Маркс һәм Гейне Германиясе турында хыяллана.

«Советская литература» журналында Юрий Корольковның махсус мәкаләсе чыккач, Небенцаль Муса Җәлил язмышы белән тагын да якыннанрак таныша. Мәкаләдә Җәлилнең соңгы көннәре хакында бик аз нәрсә билгеле булуы, аның шигырьләр дәфтәрен коткарып калган Бельгия патриоты Андре Тиммермансның һаман әле табылмавы турында да әйтелгән була. Бу — Небенцальне дә кызыксындыра. Әнә шулай, җәлилчеләрнең тиңдәшсез көрәшен өйрәнүчеләр сафына тагын бер кеше өстәлә.

Л. Небенцаль Брюссель шәһәрендә фашизмга каршы көрәштә катнашкан сугышчыларның махсус оешмасы булуын, анда немец тоткынлыгына эләккән кешеләрнең исемлеге саклануын белә. Әлеге оешма ярдәме белән, ул А. Тиммермансның адресын эзләп таба һәм, Муса турында сорашып, аңа хат яза. Андре Тиммерманс нәкъ менә эзләгән кеше — Муса белән бер камерада утырган, аның шигырьләр дәфтәрен саклап калган тоткын булып чыга.

Бу хакта Небенцаль Берлиндагы Совет илчесе вәкилләренә сөйли һәм Ю. Корольковка хат яза. Корольков, билгеле, бик шатлана. Шул ук вакытта ышанып та җитми. Ай-һай, ул кеше микән, ди, ялгышмыйсызмы икән? ди. Алар шулай үзара хат язышкан арада, Тиммермансны икенче тапкыр эзләп табалар. Бу юлы инде, Бельгия шагыйре Роже Бодар ярдәме белән, күренекле совет язучысы Константин Симонов



*Дрезден төрмәсе, 1945 ел. И. Зәбиров фоторепродукциясе.*

эзләп таба. 1956 елның көзендә ул Бельгиядә уздырылган Халыкара поэзия фестивалендә катнаша һәм шунда Андре Тиммерманс белән очраша [1]. Бүген бельгияле дустыбыз Андре Тиммерманс исеме безнең илдәге һәр мәктәп баласына таныш. Ул сөйләгән истәлекләргә нигезләнеп, Җәлил турында поэмалар, пьесалар, киносценарийлар, хәтта бөтен бер роман язылды. Шагыйрь тормышына багышланган бер генә хезмәттә дә аның истәлекләрен читләтеп үтеп булмый.

Бераз соңрак, безнең галимнәрнең үтенече буенча, Леон Небенцаль элекке фашист төрмәләренең архивларын өйрәнә башлый. Моабит төрмәсенә сугыш бетәр алдыннан гына бомба эләккән. Нәтиҗәдә төрмә архивында саклана торган документларның бер өлеше янып юкка чыккан. Исән калганын Көнбатыш Берлиндагы Плетцензее төрмәсенә тапшырганнар икән. Небенцаль, җәлилчеләр турындагы материалларны сорап, төрмә идарәсенә үтенеч яза. Әмма көткән җавап килми. «Сез сораган кешеләрнең ябылуда булулары хакында берни дә табылмады... Җәзага тартылган кешеләр исемлегендә Җәлил яисә Җәлилов шулай ук күренми», диләр аңа. Күпмедер вакыттан соң Небенцаль төрмә идарәсенә кабат мөрәҗәгать итә. Муса төрмә документларына «Гумеров» яки «Һаумерофф» дигән фамилия белән теркәлмәде микән, дип сорый. Тагын шундый ук җавап килә.

А. Тиммерманс җәлилчеләрне судка Дрезден шәһәренә алып киттеләр, ди. Моны белүгә, Небенцаль Дрезден шәһәренең хөкүмәт прокурорына хат җибәрә. Прокурорның җавап хатыннан шул нәрсәләр ачыклана: политик тоткыннар турындагы документлар Пилльнитцер-штрассе урамында, империянең Верховный суды урнашкан бинада саклана торган булган. 1945 елда, 12 февральдән 13 февральгә каршы төндә, америка летчиклары ташлаган бомбаларның берсе әлеге бинага эләгә, йорт бөтенләй җимерелә, архив юкка чыга.

«Политик җинаятьчеләр» өстеннән чыгарылган гаепләү актларының бер өлеше Мюнхнер мәйданында, Дрезден шәһәр суды урнашкан бинада да саклана торган була. Бу бина исән кала. Әмма совет гаскәрләре якынлаша башлагач, гестапочылар бөтен документларны, ишек алдына алып чыгып, яндыралар. Дрездендагы башка төрмә архивлары да шундый ук язмышка очрый. Җәлил утырган яки күпмедер вакыт утырган булырга тиеш дип уйланылган башка төрмә архивларында эзләнү дә көткән

---

[1] «Литературная газета»ның 1956 елгы 13 октябрь санын карагыз.

нәтиҗәне бирми. Германия Демократик Республикасының юстиция министрлыгында, мәсәлән, гитлерчылар кулыннан һәлак булган корбаннар исемлеге бар. Небенцаль үтенече буенча, меңнәрчә битлек шул исемлекне тагын бер тапкыр барлап-тикшереп чыгалар. Җәлил үзе дә, иптәшләре дә очрамый.

Небенцаль эзләнүләрне төрле юнәлештә алып бара. Һәм ул сайлаган юлларның берсе шактый нәтиҗәле булып чыга. Хәзер шул турыда берничә сүз.

Сугыш бетеп күп тә үтми, Берлинда Плетцензее төрмәсенең элекке рухание Гарольд Пельхауның «Соңгы сәгатьләрдә» исемле истәлекләр китабы басылып чыга. Китапта фашизмга каршы актив көрәш алып барган күренекле патриотларның соңгы сәгатьләрдәге тормышы сурәтләнгән. Небенцаль әлеге кешегә хат язып карарга була. Кызганычка каршы, җәлилчеләр турында Пельхау үзе берни дә белми икән. Небенцальнең хатын ул башка руханиларга җибәрә. Озакламый Шпандау төрмәсенең элекке рухание Георгий Юрыткодан хәбәр килә. Ул Муса Җәлилне дә, аның иптәшләрен дә яхшы хәтерли икән. Юрытко ярдәме белән шагыйрьнең соңгы көннәрен белүче тагын бер кеше — итальян антифашисты Рениеро Ланфредини табыла. Ланфредини Муса белән бер камерада утырган, татар патриотларының соңгы көннәрен күреп белгән бердәнбер кеше иде. Аның «Казан утлары» журналында (3 сан) басылган истәлекләре җәлилчеләр тормышының моңарчы без белмәгән күп кенә якларын ачыкларга ярдәм итте.

Эзләнүләр дәвам итә. Тикшеренә торгач, Небенцаль тагын бер әһәмиятле нәрсә ачыклый. Кагыйдә буенча, җәзалап үтерелгән кешеләрне төрмә кайсы район территориясенә урнашкан булса, шул районның ЗАГСында терки торган булганнар. Плетцензее төрмәсендә җәзаланган кешеләрне, мәсәлән, Шарлоттенбург округының ЗАГС бүлегендә теркәгәннәр икән. Небенцаль әлеге ЗАГС архивын (бәхеткә каршы, ул Көнчыгыш Берлинда) тикшерә башлый һәм, ниһаять, бу юлы уңышка ирешә: бөтенесе бер үк көнне, бер үк сәгатьтә җәзаланган татар патриотларыннан унбер кешенең таныклыгын таба. Үзләренең җинаять эзләрен яшерү өчен, фашистлар, гадәттә, тоткыннарның килектән үлгәнен дөрес күрсәтмәгәннәр. Бу юлы хәтта алдашып та маташмаганнар.



*Фашизмның политик корбаннарына Дрездендагы һәйкәл. И. Зәбиров фоторепродукциясе.*

Шарлоттенбург архивында табылган ул материалларны Л. Небенцаль Казанга, Татарстан язучылар союзына җибәрде. Түбәндә Муса Җәлилгә тутырылган таныклыкның сүзгә-сүз тәрҗемәсе китерелә[1]:

№ 2970 C³

*Берлин Шарлоттенбург 1944 елның 26 августы*

*Муса Гумеров-Җәлил, язучы, мөселман, торган урыны Берлин, Шарлоттенбург, Хафельштрассе 9, үлде 1944 елның 25 августында, 12 сәгать 18 минутта, Берлинда, Шарлоттенбург, Кёнигсдамм 7.*

*Мәрхүмнең туган елы 1906 елның 2 феврале, Мостафа (Оренбург).*

*ЗАГС таныклыгының номеры (тутырылмаган—Р. М.).*

*Атасы — Гумеров-Җәлил Мостафа, соңгы яшәгән урыны билгесез.*

*Анасы — Гумерова-Җәлил Рәхинә (Рәхимә — Р. М.), кыз чактагы фамилиясе Сәйфуллина, башка мәгълүматлары юк.*

*Мәрхүмнең хатыны — Гумерова-Җәлил Әминә, кыз чактагы фамилиясе Сәйфуллина.*

*Таныклык Берлинда Мантейфельштрассе 10 яшәүче надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэрның телдән биргән күрсәтмәләренә таянып тутырылды.*

*Бу мәгълүматларны хәбәр итүче—мәгълүм кеше һәм мәрхүмнең үлемен үз күзләрем белән күрдем дип раслады.*

*Кычкырып укылды, дөреслеге расланды һәм кул куелды Пауль Дюррхауэр.*

*Кенәгәнең төп нөсхәсе белән дөреслеге расланды.*

*Берлин, Шарлоттенбург, 1944 елның 26 августы.*

*ЗАГС эшчесе хезмәтләрен башкаручы: Глюк.*

*Үлүнең сәбәбе: башы киселде.*

Күрәсез, бу коточкыч документ вәхшиләргә генә хас пехтәлек белән тутырылган. Аерым орфография хаталарын исәпләмәгәндә, шагыйрь хакындагы бөтен мәгълүматлар искиткеч дөрес һәм төгәл теркәлгән. Нибары әнисенең кыз чактагы фамилиясе хатыны Әминә Җәлилнең кыз чактагы фамилиясе белән буталган. Таныклыкта Җәлилнең туган көне иске стиль белән күрсәтелгән. Леон Небенцаль сүзләре белән әйткәндә, бу — фашист хәрби юстиция аппаратының никадәр төгәл һәм никадәр кабахәт булуы турында сөйли торган бер факт.


Муса Җәлил белән бергә җәзаланган сигез кеше безгә моңарчы да билгеле иде. Алар түбәндәгеләр: танылган балалар язучысы Абдулла Алиш, инженер Фоат Булатов, укытучы Гайнан Курмаш (үлү турындагы таныклыкка ул «Григорий Курмаш» дип теркәлгән), Ташкентта яшәгән финанс хезмәткәре Гариф Шабаев, Мәскәү журналисты Әхмәт Симаев, Совет армиясе офицеры Габдулла Баттал һәм сәүдә эшчесе Зиннәт Хәсәнов.

Яшерен группаның тугызынчы әгъзасы Фоат Сәйфелмөлековның да исем-фамилиясе электән таныш иде. Әмма аның хакында башка берни дә белми идек. Фашистлар тутырган таныклыкта кайбер өстәмә мәгълүматлар бар. Таныклыктагы язмаларга караганда, ул 1916 елның 16 июлендә Ташкент шәһәрендә туган, сугыш башланыр алдыннан Сталинабад шәһәрендә яшәгән, һөнәре буенча бухгалтер (А. Алиш үз язмасында аның Үзбәкстан сәүдә халык комиссарының урынбасары булып эшләвен әйтә). Әтисенең исеме «Хаджарахим» дип укыла. Әнисе — Сәйфелмөлекова Нәгыймә, кыз чактагы фамилиясе Шафиева, Гиждуван дигән җирдә туган. Таныклыкка карaганда, Фоат Сәйфелмөлеков өйләнмәгән була.

Безнеңчә, хәзер Фоат Сәйфелмөлековның язмышын ачыклау юнәлешендә дә эзләнү эшләре башлап җибәрергә мөмкин. Фашистлар калдырган мәгълүматлар моңа нигез бирәләр төсле. Бәлки, укучылар ярдәме белән аның туганнарын яки якыннарын табып булыр?..

---

[1] Разбивка белән бирелгән сүзләр типографиядә басылган, калган өлешләре машинкада язылган, имзаларны һәр кеше кулдан үзе куйган.



Nr. 2970 C¹

Berlin – Charlottenburg – –, den 26. August 19 44.

Der Schriftsteller Musa Gumerow-Djalil,

mohammedanisch

wohnhaft in Berlin – Charlottenburg, Havelstraße 9

ist am 25. August 1944 – – um 12 Uhr 18 Minuten

in Berlin –Charlottenburg, Königsdamm 7 – – – – – verstorben.

Der Verstorbene war geboren am 2. Februar 1906 – – – –

in Mustafina (Orenburg)

(Standesamt Nr. )

Vater: Mustafa Gumerow-Djalil, letzter Wohnort unbekannt

Mutter: Rachina Gumerow-Djalil, geborene Seifulima, weitere Angaben fehlen

Der Verstorbene war ~~nicht~~ – verheiratet mit Amina Gumerow-Djalil, geborenen Seifulima.

Eingetragen auf mündliche ~~schriftliche~~ – Anzeige des Hilfsaufsehers Paul Dürrhauer, Berlin, Manteuffelstraße 10.

Der Anzeigende ist bekannt und erklärte, daß er vom Tode aus eigener Wissenschaft unterrichtet sei.

Vorgelesen, genehmigt und unterschrieben

Paul Dürrhauer

Die Übereinstimmung mit dem Erstbuch wird beglaubigt

Berlin Charlottenburg

den 26. August 1944

Der Standesbeamte

In Vertretung [signature]

Der Standesbeamte

In Vertretung Gluck.

V 122

Todesursache: Enthauptung.

Eheschließung der Verstorbenen am ___ in ___

(Standesamt ___ Nr. ___)

Муса Җәлилнең үleme турында таныклык. Фотокопия.



*Фоат Булатов. Бу рәсем беренче мәртәбә басыла.*

Ике патриотның исем-фамилияләре белән без беренче тапкыр әлеге таныклыкларда очрашабыз. Аларның берсе — повар Әхәт Аднашев. Ул 1918 елның 12 декабрендә Петропавловск шәһәрендә туган, сугышка кадәр ниндидер Штецнайк (?) дигән җирдә яшәгән. Әтисе — Мәхмүт Аднашев. Әнисе — Өммекамал Аднашева, кыз чактагы фамилиясе Билялова, икесе дә әлеге Штецнайк дигән җирдә яшәгәннәр.

Патриотларның икенчесе — гади эшче Сәлим Бухаров. 1915 елның 15 июнендә ниндидер Заргей (?) дигән җирдә (Уфа, Россия) туган. Сугышка кадәр Уфада (Башкортстан күздә тотыла — Р. М.) Дортсагай (?) дигән җирдә яшәгән. Әтисе — Гыйматов-Бухаров (?). Әнисе — Сабира Бухарова, кыз чактагы фамилиясе Фариза (?). Мәрхүмнең хатыны — Бухарова Мария, кыз чактагы фамилиясе Качи (?).

Тәртип санына караганда, Бухаров таныклыгы иң соңыннан тутырылган булса кирәк. Фашистлар ашыкканнар, күрәсең, язганда бик күп хата җибәргәннәр [1]. Тагын шулкадәресен истә тотарга кирәк: «Бухаров» аның чын фамилиясе дә булмаска мөмкин. Кем белә, бәлки, әтисенең исеме язылган графада батырның дөрес, чын фамилиясенә ишарә бардыр?

Аннан соң, нигә унбер генә таныклык табылды икән? Ланфредини дә, Юрытко да татарлар группасында уникe кеше иде, дип сөйләделәр ич... Бу да — бик мөһим һәм ачыклауны сорый торган деталь. Кызганычка каршы, Ланфредини бу эштә ярдәм итә алмый инде. Ул вафат булды. Юрытко исә күп нәрсәләрне оныткан. Әхмәт Симаевның Дрезден төрмәсе стенасында калдырган язмасын хәтергә төшерик. Ул: «Без Россиядән унбер кеше идек», дип язган. Шпандау төрмәсенең элекке тоткыны Василий Иванович Чебон шулай ук татарлар унберәү иде, дип тәкрарлады. Уникенче кеше, бәлки, чыннан да, Ланфредини әйткән немец сержанты булгандыр? Шулай булырга да мөмкин...

Яшерен группаны саткан хыянәтче өстеннән алып барылган тикшерү материалларыннан чыгып хөкем йөрткәндә, фашистлар, Гитлер рейхына каршы эшчәнлек алып баруда гаепләп, 70—80 гә якын кешене кулга алалар. Аларның бик азы гына туган илгә кайта алды. Шулар арасыннан Р. Хисаметдиновны, Г. Фәхретдиновны, Ф. Солтанбековны, Ш. Гарифҗановны (Җәлил блок-нотында — «җырчы Әмиров») һәм тагын берничә кешене күрсәтергә мөмкин. Калганнары фашист зинданнарында һәлак булды һәм без аларның күбесенең хәтта исемнәрен дә белмибез. Плетцензее төрмәсендә, күрәсең, яшерен группаның җитәкчеләрен генә җәзалаганнардыр. Л. Небенцаль фикеренчә, татар патриотларының тагын бер төркемен Цухтхауз Бранденбургта җәзага тартканнар.

Төрмә рухание Юрытко сүзләренә таянып, Ланфредини татарлар 1944 елның 25 августында иртәнге сәгать унда үлделәр, дигән иде. Хәзер һәр кешенең кайчан үтерелүе минутына кадәр билгеле. Таныклыклардан күренгәнчә, җәлилчеләрне 1944 елның 25 августында уникe сәгать алты минуттан уникe сәгать 36 минутка кадәр, ягъни ярты сәгать вакыт эчендә җәзага тарталар. Һәр өч минут саен бер кешенең башы киселгән, дигән сүз бу. Беренче булып Җәлилнең иң якын ярдәмчесен — Гайнан Курмашны җәзалыйлар. Аның артыннан уникe сәгать тугыз минутта Фоат Сәйфелмөлековны, аннан Абдулла Алиш белән Фоат Булатовны. Муса бишенче булып җәзалана. Мусадан соң бер-бер артлы Гариф Шабаев, Әхмәт Симаев, Габдулла Баттал, Зиннәт Хәсәнов, Әхәт Аднашев һәм Сәлим Бухаровларның башын кисәләр.

---

[1] Моның икенче сәбәбе булуы да ихтимал. Таныклыкта Бухаровның профессиясе «кара эшче» дип язылган. Бәлки, бу аның белеме җитәрлек дәрәҗәдә булмавының нәтиҗәседер. Немец телен белмәсә, кайбер сорауларны аңлап җитмәве дә бик ихтимал.



*Гариф Шабаев хатыны белән. И. Зәбиров фоторепродукциясе.*

Җәлилчеләрнең ничек үтерелүләре хакында да моңарчы төрле караш яшәп килде. Георгий Юрытко: «Хәтеремә ышанып бетә алмыйм, шулай да, минем уемча, татарларны аттылар бугай», ди. Әмма шул ук Юрытко Ланфрединига татарларны астылар дип сөйләгән булган. 1944 елда, августның икенче яртысында, фашистларның гильотиналары сафтан чыккан булуын исәпкә алганда, соңгы караш, чыннан да, акылга сыярлык күренгән иде. Ләкин 1944 елның нәкъ 25 августында гильотинаны өлешчә төзәткән булырга да мөмкиннәр бит әле. Күрәсең, бу мәсьәләдә рәсми документларга таяну ышанычлырак булыр. Фашистлар тутырган таныклыкларда татарларның «б а ш ы к и с е л д е» диелгән. Мәсьәләгә надзиратель ярдәмчесе Пауль Дюррхауэр тулы ачыклык кертә алыр иде: ул карап торган булырга тиеш. Ләкин аны ничек табарга? «Комсомольская Правда» газетасының үз хәбәрчесе Г. Гурков, «Известия» газетасы хәбәрчесе белән бергә, әлеге таныклыкларда күрсәтелгән адрес буенча Көнбатыш Берлинда була, Пауль Дюррхауэрны эзләп карый. Ул сугыш беткәнче үк каядыр күчеп китте, диләр күршеләре. Аларга якындагы бер икмәк кибетенә барырга кушалар. Дюррхауэрның яңа адресын белсәләр, шунда белерләр, янәсе. Анда хәбәрчеләрне ак алъяпкыч кигән чал чәчле бер карт каршылый. Кунакларның нинди эш белән йөрүләрен белгәч, кибет хуҗасы сөйләшеп тә тормый. Андый кеше барлыгын ишеткәнем үк юк, дип кырт кисә. Ләкин эзләнүләр дәвам итәчәк. Әгәр кайчан да булса ул кешене тапсак, шик юк, совет патриотларының соңгы минутлары турында нинди дә булса яңа мәгълүматлар бирми кала алмас иде.

Берлинда табылган документларның кыйммәте Муса Җәлилнең һәм иптәшләренең биографияләренә ачыклык кертү белән генә чикләнми. Алар — Гитлер Германиясенең вәхши йөзен фаш итә, фашистлар хөкүмәте кешелек дөньясына китергән бәла-казаларны ачып сала торган материаллар. Моны Көнбатыш Германиядә яңадан баш күтәрергә азапланган реваншистларга каты итеп, ныклап әйтергә бурычлыбыз. Үзенең матбугат конференциясендәге чыгышын Леон Небенцаль түбәндәге сүзләр белән тәмамлаган:

«Без, Германия Демократик Республикасы гражданнары, Муса Җәлилне фашизмга каршы көрәшкән өчен генә түгел, ә бәлки ялкынлы интернационалист булган өчен дә хөрмәтлибез. Хәтта үлем камерасында утырганда да, ул Германиядәге милитаризм һәм кара көчләр белән немец халкы арасындагы аерманы ачык аңлый алды: милитаризмны дошман күрде, соңгы сулышына кадәр аңа каршы көрәште, ә немец халкын хөрмәт итте, аның Маркс һәм Тельман, Гете һәм Гейне, Бах һәм Бетховен кебек бөек улларын чын күңелдән яратты, якын итте. Шагыйрьнең Моабит төрмәсендә язган иң

# Das Schicksal der Dshalil-Gruppe



Mussa-Dshalil-Denkmal von W. J. Zigal in Kasan

Sowjetische und deutsche Genossen haben seit 1955 Nachforschungen nach dem Schicksal des tatarischen Dichters Mussa Dshalil angestellt, der 1944 von den deutschen Faschisten ermordet wurde. Die sowjetische und die DDR-Presse berichteten laufend über diese Bemühungen. Auch wir haben wiederholt Beiträge über das Wirken und den heldenhaften Kampf des Dichters gebracht (vergl. z. B. „Die Presse der Sowjetunion" Nr. 15 und Nr. 55 – 1966).

Verdienste um die Dshalil-Forschung in der DDR erwarb sich Leon Nebenzahl, der auch mit einer Delegation des Deutschen Schriftstellerverbandes an den Feierlichkeiten zum 60. Geburtstag des Patrioten teilnahm und im Rahmen einer wissenschaftlichen Konferenz an der Moskauer Lomonossow-Universität referierte.

Den Lesern in unserer Republik wurde der tatarische Lyriker auch durch das „Moabiter Heft" bekannt, eine Auswahl seiner Gedichte, die er während seiner Kerkerhaft schrieb und die uns durch den mutigen Einsatz antifaschistischer Kämpfer erhalten geblieben sind. Mussa Dshalils Werke sind in viele Sprachen übersetzt worden. Seine Heimat ehrte ihn durch die Auszeichnung als „Held der Sowjetunion" und mit dem Leninpreis.

Am 15. Februar 1968, dem 62. Geburtstag des Dichters, veranstaltete der Zentralvorstand der Gesellschaft für Deutsch-Sowjetische Freundschaft ein Pressegespräch, bei dem weitere Einzelheiten über das Schicksal Mussa Dshalils mitgeteilt wurden. Wir bringen nachstehend auszugsweise die Ausführungen Leon Nebenzahls, in denen er über die neuesten Ergebnisse der Dshalil-Forschung in der DDR informierte.

Red. PdSU

*Көнчыгыш Берлинда чыга торган «Советлар Союзы матбугаты» исемле атналык газетаның Муса Җәлилгә багышланган бите.*

соңгы әсәрләреннән берсе — «Алман илендә» исемле шигыре шул турыда сөйли. Бу шигырендә Җәлил фашист җәлладларын кискен гаепли, немец халкының алдынгы көчләренә мөрәҗәгать итә һәм аларга тирән ышаныч баглый.

Саф-саф булып тагын унтугызынчы
Елгы төсле җырлап килегез.
Һәм, күтәреп өскә уң йодрыкны,
«Рот-фронт» дип җавап бирегез.

Борыгыз муйнын комсыз карчыганың,
Кояш чыксын Алман җиренә.
Күтәрелсен Тельман трибунага,
Маркс, Гейне кайтсын иленә.

Җәлил хыяллары тормышка ашкан һәм Тельман трибунага күтәрелгән, Маркс белән Гейне яңадан гражданлык хокукы алган немец дәүләтендә Муса Җәлил һәм аның иптәшләре кебек көрәшчеләр тирән хөрмәт һәм дан казандылар. Без алар алдында баш иябез».

Рафаэль **МОСТАФИН.**

**АВТОРДАН.** Бу материал басылып ятканда, Уфадан, укучыбыз М. Габдрахмановтан хат килде. Ул Әхәт Аднашевны белә икән.

Әхәтнең әтисе, Мәхмүт Әхмәтша улы Аднашев, элекке Казан губернасы, Мамадыш өязе, Өскебаш авылында туган. Аднашевлар гаиләсе революциягә кадәр ук Петропавловск шәһәренә күчкән. 1918 елның 12 декабрендә Әхәт исемле уллары туган. Соңыннан алар Степняк поселогында яшәгәннәр. Әхәтнең әнисе Өммекамал сугышка кадәр үк үлгән. Әхәтнең Хәмит, Җәлил, Мәхмүт һәм Рокыя исемле туганнары хәзерге көндә дә исән булырга тиеш. Әмма әлегә аларны таба алганыбыз юк.

**Гази Кашшаф**

# ХАТИП ГОСМАН



Иртә белән Казан урамнары аеруча җанлы була. Эшлеләр эшкә ашыга, балалар мәктәпкә йөгерәләр, кайсылары иреннеп кенә сумкасын болгый-болгый бара. Уйланып йөрүче картларның да үз мәшәкате күчле. Сезон белән бик үк исәпләшми торган чуар киемле студентлар арасында егетләрчә җитез хәрәкәтле бер профессор күренә. Аның йөзе бераз уйчан, үзе дә шул уйлар басымы астында бераз иеләрәк төшкән сыман, ләкин коңгырт күзләре алга төбәлгән һәм үтәли карыйлар. Аның кулында гадәттә газетага төрелгән китап яки бик нәхтә юка папка яисә портфеленә көчкә сыйган калын кулъязма күренә, анысы кемнеңдер диссертациясе булса кирәк.

Йөгерә-атлап баручы студентлар төркеме данлы университетның ак колонналары арасыннан кереп китәләр, ә профессор университетның икенче бинасына — химкорпуска таба юнәлә. Ләкин ул химик түгел. Бу — филология фәннәре докторы, профессор, язучы Хатип Госман. Ул инде утызынчы ел буе университетта татар әдәбияты кафедрасын җитәкли. Бу кафедра дистәләрчә яшь белгечләр — фән кандидатлары хәзерләде, ике доктор җитештерде, югары квалификацияле йөзләрчә педагоглар бирде, яшь каләм көчләренә, аеруча шагыйрьләргә иҗат юлы күрсәтте.

Профессор Хатип Госманның эше бик күп. Бүген аның кафедра утырышы уздырасы бар. Төрле институтларда башкарылган диссертацияләрне тикшереп — алар Татарстаннан да, Башкортстаннан да килеп торалар — бәя бирергә, алдагы язмышын хәл итәргә кирәк. Аның өстенә кафедраның эчке эшләре дә җитәрлек.

Кафедра членнары соңга калып килергә ярамаганлыкны яхшы беләләр, соңга калсаң — профессордан шәфкать көтмә, аның кашы җимереләчәк һәм каныңа тоз сала торган сүзе дә ишетеләчәк. Профессор үзе дә соңга калмый, башкаларның да соңгаруын кичерми, чөнки вакыт исәпле һәм аның кадерен белергә кирәк.

Кафедра утырышына ике сәгать вакыт бирелә. Вакытны тыгыз итеп файдалана белү аркасында, каралачак мәсьәләләр икенче утырышка калмыйлар. Фән каршында торган проблема да тикшерелә, гыйльми хезмәт турында да һәркем үз фикерен әйтергә өлгерә, башка көндәлек мәсьәләләр дә хәл ителеп бетә.

Хатип Госманның, фән җитәкчесе буларак, тагын бер сыйфатын әйтеп китәргә кирәк. Ул, үзе зур фәнни проблемалар өстендә эшләргә яраткан кебек, кафедра членнарының да зур проблемалар өстендә эзләнүләрен таләп итә һәм аларга шул мәсьәләне чишү өчен кирәкле шартлар тудыра белә. Без — башка кафедра членнары — Хатип Госманның «фәнне оештыра» белүен сокланып сөйлибез.

Ә сезнең ул укыган лекцияләрне тыңлаганыгыз бармы? Юк, алайса — мин әйтеп бирим.

Университетта бер лекция сәгать тә егерме минут дәвам итә. Сөйли белмәгән кеше өчен, әлбәттә, бу бик озак вакыт. Күңелсез итеп сөйләсәң, студентларың йоклап бетәргә мөмкин. Ләкин Хатип Госманның лекцияләрендә вакыт узганы сизелми, ул фәннең төп моментына тукталa, матбугатта булган материалларны искә төшереп, аларны укуны студентларның үзләренә калдыра. Иң мөһиме — проблеманы билгеләү һәм студентларга шул проблеманы ачу юлларын өйрәтү. 80 минут! Шул вакыт эчендә фәннең бер почмагы ачылырга тиеш! Шул вакыт эчендә студентның белеменә байлык, фикеренә юнәлеш бирелергә тиеш!

Хатип Госманда әнә шул галим-педагог осталыгы көчле.

Каян кила соң ул кеч? Без моны Хатипның үз эшенә гаять таләпчән булуы һәм җаваплылык хисе тоюы белән аңлатыр идек. Фәннең бер тармагын алып еллар буе лекция укырга мөмкин. Ләкин үзенә таләпчән галим ул лекцияләрне кабаттан сөйләгәндә, фәнгә нәрсәдер өсти, яңа ачышлары белән бизи. Хатип Госман фәнне үстерүче, баетучы лекторларның берсе. Ләкин бездә татар әдәбияты фәне барлык тармаклары буенча, барлык проблемалары буенча әле эшләнеп бетмәгән. Киресенчә, хәтта әле яңа керешелгән дияргә мөмкин. Шуңа күрә галимнәр-педагоглар каршында мавыктыргыч проблемалар ята. Һәркем фәнгә үзеннән өлеш кертә ала!

Хатип Госман татар әдәбияты фәне проблемаларына үзенчәлекле юл белән килде. Ул Казан дәүләт педагогия институтында Көнбатыш Европа әдәбияты буенча лекцияләр укый иде. Әйтергә кирәк, Көнбатыш Европа әдәбияты кайда гына укытылмый, нинди генә дәреслекләр, хрестоматияләр, махсус тикшеренүләр юк бу өлкәдә! Китапханәдә А. В. Луначарский, П. С. Коган кебек совет галимнәренең махсус лекцияләре бар, дөнья әдәбияты классикларының кыйммәтле һәм уйландыра торган фикерләре тулып ята. Гомумән, Көнбатыш Европа әдәбияты Хатип Госман өчен гаять бай мәктәп булды. Эш монда өйрәнелгән, системага салынган Көнбатыш Европа әдәбияты тарихын үзләштерүдә генә түгел, барыннан да элек, зур тарихи гомумиләштерү ысуллары белән танышу, образлар системасына килү юлларын, сәнгатьне сәнгать иткән чараларны күрсәтү алымнарын аңлау — Хатипның алдагы хезмәтләре өчен гаять бәрәкәтле, илһамлы булдылар.

Хатип Госман үзенең кандидатлык диссертациясе итеп Такташ поэзиясен сайлады һәм аны оригиналь төстә, шагыйрьнең эстетик карашларына басым ясап, башкарып чыкты. Бу хезмәт Такташ иҗатын тикшерүдәге иллюстративлыктан, дорфа социологизмнан котылу үрнәге булды.

Шул хезмәт башкарылган арада Хатип Госман X класслар өчен әдәбият дәреслеген төзүдә катнашты (1947). Ул еллардагы программа Көнбатыш Европа әдәбияты үрнәкләрен дә эченә ала иде һәм Хатип Госман «Яңарыш чоры. Шекспир һәм Гете» исемле бүлекне язды. Хәзерге көндә дә Хатип дәреслекләр язуда, методик әдәбият тудыруда актив эшләп килә.

Хатип Госман Казан дәүләт университетына марксизм-ленинизм методологиясен үзләштергән югары квалификацияле белгеч булып килде. Ләкин әле аңа бик күп авырлыкларны җиңәргә кирәк иде. Беренче чиратта күп гасырлы татар әдәбияты тарихын иңләп алырга кирәк иде. Һәм ул шул эшкә җиң сызганып кереште дә.

Инде байтак еллар узды. Хатип та берничә курс һәм специаль курс буенча лекцияләр укырга, аларның программаларын төзергә өлгерде. Менә минем алдымда «Татар шигыре» исемле специаль курс программасы. Хатип Госманга кадәр бу курсны беркем дә укыганы юк иде.

Дөрес, татар шигырь төзелеше бөтенләй тикшерелмәгән өлкә түгел, элек-электән үк бу мәсьәлә рус тюркологларын һәм татар галимнәрен, шагыйрьләрен кызыксындырып, борчып килә. X. Госман ул карашларны бүгенге фәннең торышыннан чыгып бәяли һәм «элек ирешелгән казанышларга таянып», төгәлләнгән гыйльми хезмәт бирә. Без аның 1964 елда аерым китап булып басылган «Татар шигыре» исемле китабын истә тотабыз. Хатип Госман татар шигыренең үз табигатен, үзенең милли сыйфатын билгеләү өчен ерак тарихка, халыкның үз авыз иҗатына, татар шигыре казанышлары булып танылган классиклар тәҗрибәсенә таяна. Һәм ул татар шигыре төзелеше гарәпләрдән һәм фарсылардан күчерелмәгәнлеген катгый рәвештә раслый. X. Госман гаруз, бәхер, газәлләр, касыйдәләр, мәснәвиләргә дә туктала, татар шигырен кардәш халыкларның шигъри практикасы белән дә чагыштыра һәм татар шигыре төзелеше нигезендә буынара ачыклыклар системасы һәм ритмик ачык иҗекләр системасы ятканын билгели.

Хатип Госманның бу ачышы әдәбият белеме дөньясында шактый җанлы бәхәс уятты. Шул җөмләдән, татар шигыре дөньясында да үзгә фикерләр чагылып китте. Без шагыйрь Әхмәт Исхакның «Тукайның шигъри осталыгы» исемле кызыклы хезмәтендәге кайбер фикерләрнең X. Госман фикерләренә капма-каршы булуын истә тотабыз.

Хатип Госманның капиталь хезмәте «Социалистик революция һәм татар поэзиясе» дип атала. Шушы теманы ул үзенең докторлык диссертациясенә сайлады һәм аны 1962 елда уңышлы яклады. Бу хезмәтне тулысынча өч китаптан укырга мөмкин: югарыда искә алынган «Татар шигыре» (1964), «Бөек Октябрь революциясе һәм гражданнар сугышы чорында татар поэзиясе» (1960) һәм «Егерменче елларда татар поэзиясе» (1964).

Хатип Госман үзенә генә хас эзлеклелек белән социалистик революция тудырган татар поэзиясен 30 нчы елларга кадәр бик җентекләп өйрәнгән. Аның игътибарыннан бер генә шигырь дә читтә калмаган, күрәсең. Гражданнар сугышы елларында кечкенә өяз шәһәрләрендә чыгып килгән газеталарда басылган шигырьләрне дә Хатип бөртекләп җыйган. Ләкин бу эш гомуми күзәтү ясау өчен генә башкарылмый, бәлки зур гомумиләштерү өчен эшләнә, үсеш закончалыкларын ачар өчен табыла.

Матбугатның турыдан-туры үзенә мөрәҗәгать итү аркасында, Хатип Госман бик күп онытылган исемнәрне әдәбиятка, фәнгә кайтара, заманында теге я бу рәвештә ярлык тагылып, тарихи урынын ала алмый калган шигъри әсәрләргә бүгенге көн әдәбият фәне күзлегеннән чыгып, объектив гыйльми бәя бирелә. Шулай да ул чуар шигъри диңгез уртасында, төп кыйбласын югалтып, югалып калмый, революция еллары тудырган, революцион көрәш пафосы тәрбияләгән зур шигъри маякка — Һади Такташка карап юнәлеш ала. Хатип Госман татар шигыре дөньясында бик иркен йөзә һәм колачын бер чор рамкаларында гына чикләп калдырмый. Шуңа күрә ул үз-үзенә кыен сораулар биреп, мәсьәләне катлауландыра, киңәйтә бара.

Шундый авыр сорауларга җавап эзләп, галим әдәби процессның тирән агымнарына төшә, татар поэзиясенә генә түгел, рус һәм башка кардәш халыклар поэзиясенә дә күз сала.

Галим революция тудырган поэзиянең үзенчәлекләренә киң туктала. Шуларның берсе — антитеза алымы. Хатип Госман моны да бик җентекләп тикшерә, реакцион вазифалы һәм прогрессив рухлы антитезаның өч тип чагылышын да бай мисаллар белән аңлатып бирә.

Кыскасы, «Социалистик революция һәм татар поэзиясе» исемле хезмәт татар әдәбиятының мөһим бер чорын һәм иң өлкән жанрларының берсен тикшерүгә багышланган. 30 нчы еллар яки сугыштан соңгы чор поэзиясен тикшерергә ниятләнгән галим дә, революция еллары әдәбиятының башка аспектларын тикшерүче дә Хатип Госманның бу хезмәтен читләтеп уза алмаячак. Ул татар әдәбияты фәненә зур өлеш керткән хезмәт булып калачак.

Хатип Госман әдәбиятка башта ук галим булып килмәде, билгеле. Аның иҗаты шигырь язу белән башланып китте һәм беренче җыентыгы «Кырлар лирикасы» (1931) дип атала иде. Бераздан ул прозага күчте һәм берничә хикәя, повесть бастырды. «Кан тавышы» (1934), «Юсыф» (1937), «Мин күккә күтәреләм» (1937) кебек әсәрләре сугышка чаклы яшьләр арасында популярлык казандылар. Болардан тыш Хатип Госман газета-журналларда хикәя, очерк, тәнкыйть, публицистик мәкалә белән актив чыгыш ясап торды.

Бөек Ватан сугышы башланды. Халык уллары белән бергә Хатип та илбасарларга каршы сугышка китте. Авыр һәм мактаулы солдат хезмәтен үтәп, совет офицеры булып, орденнар һәм медальләр белән бүләкләнеп, җиңү тантанасын каршылады.

Фронттагы язучы солдат хезмәтен генә башкармады. Бу турыда мәрхүм Фатих Кәрим бик матур итеп язган иде. Язучы өлешенә, солдат хезмәтеннән тыш, замандашларының кан тибешен билгеләп, аны сугыш вакыйгалары яктылыгында күрү бурычы төште. Ул ерткычлык һәм гуманизм, җинаять һәм шәфкать, котырган милли эгоизм һәм пролетар интернационализмның якага яка килеп канлы бәрелешләрен күзәтүче генә түгел, бәлки бөек тарихны үзе тудыручы һәм аның елъязмасын теркәүче дә булды. Совет кешесендәге ачыныш һәм гамь, сагыш һәм якты өмет, нәфрәт һәм мәхәббәт тойгылары үскәннән үсә, тирәнәйгәннән тирәнәя барган чакта, совет язучысы үзенең тарихи миссиясен уңышлы башкарып чыкты. Алар арасында Хатип Госман алгы сафларның берсендә торды. Аның очерклары, хикәяләре алгы ут сызыгыннан алып язылдылар һәм аларда совет солдаты образы мәһабәт бөеклеге белән басып торды. Төньяк-көнбатыш фронтта язылган һәм күләме белән ул еллар өчен зур булган «Ялкынлы йөрәк» повестен алып карыйк.

Язучы, солдат массасының уртасында кайнавына карамастан, төбендә бер образга күз ташлый. Яшь солдат Рөстәмнең сугыш биографиясендәге берничә калку моментка гына игътибар итә. Рөстәм фронтка килә, абыйсы Мәрдәнне очрата һәм абыйсы аны үз янында калдыра. Рөстәм башта, билгеле, тәҗрибәсез сугышчы, ләкин булдыклы һәм үч алу хисе белән янган сәләтле сугышчы, тиз вакыт эчендә тәҗрибә ала һәм разведчик булып китә. Яралану, госпиталь, фашизм җинаяте турында уйлану, дошман өстенә ябырылып куну хисләре белән яну... һәм яңадан фронт. Үз частена кайткан көнне үк Рөстәм разведкага ашкына, уңышка ирешә һәм һәлакәткә очрый.

Бу повестьта Хатип Госманның алдагы (сугыштан соңгы) иҗаты өчен характерлы моментлар бар. Язучы алда үзенең иҗтимагый карашларына ятыша торган ярсу йөрәкле герой сайлаган. Рөстәм — ул Хатип хыялларында яшәгән яңа тип галим, киләчәге зур булган, фәнне алга илтәчәк галим. Рөстәмнең фәлсәфи карашларында, сугыш вакыйгалары тәэсирендә ясалган нәтиҗәләрендә алда үсәчәк галим яралгылары салынган. Беренче сугыш тәэсиреннән соң Рөстәм үзенең көндәлегенә болай дип яза: «Сугышның эчтәлеге ике төп моменттан тора: героик момент, һәлакәтле момент... һәлакәтне бетерү өчен, сугышны бетерергә кирәк, сугышны бетерер өчен, аны башлаучыларны бетерергә кирәк...» Повестьта герой һәлак була, ләкин ул авторның күңелендә үлемсез яши һәм миңа, ничектер, Рөстәмнең дәвамы — Хатип үзе кебек тоела. Рөстәмдәге аналитик аңны Хатип үзенең гыйльми хезмәтләрендә бик матур күрсәтте.

Еллар буе эзләнү, тикшеренү гаять нәтиҗәле булды. Хатип Госман югары гыйльми дәрәҗә алды, фән дөньясында танылып өлгерде. Бәлки хәзер бераз туктап, тын алырга кирәктер?.. Ләкин Хатип Госманда мондый тынычлану, ирешелгән уңыш белән канәгатьләнеп калу гадәте юк. Капиталь хезмәтен башкарганда ук инде ул параллель рәвештә башка проблемалар өстендә эшли башлады. Чыннан да, безнең әдәбият тарихыбыз бик бай, ул XIII йөзнең башыннан ук килә. Җиде ярым гасыр эчендә мәйданга бик күп талантлар чыккан. Алар халыкның рухи һәйкәле булып яшәрлек поэтик энҗе бөртекләре калдырып киткәннәр. Шул кадәр байлык бездә тиешенчә өйрәнелмәгән һәм тупланмаган. Хатип Госман «Социалистик революция һәм татар поэзиясе» проблемаларын өйрәнгәндә, борынгы әдәбиятны да игътибар үзәгеннән читкә җибәрми. Ул татар поэзиясе антологиясен төзүдә актив катнаша, антологиягә сүз башы яза (1956), Габделҗаббар Кандалый шигырьләрен беренче тапкыр туплап бастыру эшенә җитәкчелек итә һәм сүз башы яза. Бүгенге көндә ул борынгы әдәбиятны өйрәнү эшен дәвам итә, бу өлкәдә яңадан-яңа материаллар таба. Бу — шулай ук ачыш. Узган ел гына әле тикшеренүләренең нәтиҗәсе итеп, Хатип Госман борынгы әдәбиятның тарихы буенча тезисларын бастырган иде. Анда, мәсәлән, бик оригиналь һәм бик җитди фикер алга сөрелә. Профессор татар халкының язма әдәбияты үсешен шәһәрләр төзелешенә китереп бәйли. Бу — бик кыю гыйльми нәтиҗә!

Хатип Госманның гыйльми авторитеты бик зур. Югары Аттестация Комиссиясе (ВАК) әледән-әле аңа рецензиягә төрле галимнәрнең диссертацияләрен җибәреп тора. Ул университетның Зур гыйльми советы, факультет гыйльми советы, Фәннәр Академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге тел, әдәбият һәм тарих институты гыйльми советы члены. Шуның өстенә Хатип Госман гыйльми дәрәҗәләр бирү советының председателе урынбасары. Монда тагын шуны да әйтергә кирәк, 1967 елда Финляндиянең Хельсинки университеты чакыруы буенча, Хатип Госман һәм Мөхәммәт Гайнуллин иптәшләр Финляндиядә булып кайттылар. Алар яшь фин галимнәренә консультация бирү өчен чакырылганнар иде!

Коммунист-галимнең болардан тыш та җәмәгать эше бик күп. Ул университетның партком составына да сайланып эшләде, берничә тапкыр аны Казанның Совет районы хезмәт ияләре үзләренең депутатлары итеп сайладылар. Хатип Госман Татарстан язучылары союзы идарәсе члены булып та эшли... Аңа галимнәр, яшьләр киңәшкә киләләр... Гомумән, Хатип Госманның көне тыгыз эштә, файдалы хезмәттә үтә...

Инде кич, университетның актлар залында партия җыелышы башланырга тора. Җыелышка беренче булып килүчеләр арасында Хатип Госманны очратам.

Исәнлек-саулык сорашкач та, Хатип:

— Әйдә әле, бергә утырыйк әле, — дип мине алга алып китә. — Күптән сөйләшкән юк...

Ләкин безгә сөйләшергә туры килми. Тикшерелә торган мәсьәлә бик мөһим һәм без игътибар белән тыңлап утырабыз. Ара-тирә мин Хатипның уйчан йөзенә һәм чем кара чәчләренә карап алам.

— Чыннан да 60 яшь туламы бу тынгысыз егеткә? — дип уйланам мин. Моңа ышанасы килми! Хәер, хезмәт кешене яшәртә дә бит. Әйдә, яшьлек дәрте белән эшеңне дәвам иттер, Хатип. Фәннең яңа серләрен ач, укучыларыңны куандыр. Озын гомер һәм яңадан-яңа иҗади уңышлар телим мин сиңа! Дөресе — мин генә түгел...

◇ II ◇

**Хатип Госман,**

филология фәннәре докторы,
профессор

# АНТИТЕЗАЛЫ ТАСВИР КАЙЛАРДАН КИЛӘ

*(Бер уйлану)*

Тукай шигъриятенең бер үзенчәлеге һәрбер укучының күзенә ташланып тора: бу аның нинди дә булса күренешне тасвирлаганда капма-каршы куюлардан файдалануы. Әдәбият фәнендә мондый каршы кую антитеза дип йөртелә. Мисалын күрик:

Керләнә өс, өстенә рух, һич хозур вөҗданга юк,
Ни сәбәптән җир йөзендә тәнгә — мунча, җанга — юк?!

Мондый каршы кую шигырьдә тойгыны көчәйтә, мәгънәне тирәнәйтә, әйтергә яраса, хискең күз алга килеп басарлык гәүдәле сурәтен үк тудыра.

Антитеза Тукайның бөтен иҗатын тирәнтен сугарып алган. Нечкәләбрәк карасаң, хәтта аның шигырь һәм поэмаларындагы образлар, персонажлар да антитеза белән алынган: Кеше — Шүрәле; күңел нуры сүнгән чытык чырайлы Хәлфә—алтырап тормас Таз; дәп-дәү гәүдәле ахмак Абзый — сыңар учка йомып алырлык кечкенә генә хәйләкәр Чыпчык («Өч хакыйкать»)... Каршы кую рәвешләре аңарда хисаплап бетергесез күп төрле. Ул бу алымның тиңсез остасы. Шагыйрьнең замандаш язучылары арасында зур талант ияләре бар: Г. Камал, С. Рәми, Ф. Әмирхан, Дәрдмәнд, Г. Ибраһимов, М. Гафури... Болар да үз тасвирларында күренешләрне контраст китерү алымына еш мөрәҗәгать итәләр. Ф. Әмирханның «Фәтхулла хәзрәт», «Хәят» әсәрләрен искә төшерегез. Шулай да антитезалы тасвирда боларның берсе дә Тукайга тиңләшә алмый. Бу өлкәдә шул заман татар әдәбиятында Тукай бер үзе даһи. Аның бу үзенчәлеге ниләргә бәйләнгән! Аларны күзәтеп, өйрәнеп булмыймы! Шул сораулар уңае белән без биредә, мәсьәләне кую тәртибендә генә булса да, кайбер нәрсәләргә тукталып китмәкче булабыз. Әлбәттә, барыннан да элек өч мәгълүм нәрсә алга килә: Тукай талантының тумышыннан ук килгән индивидуаль үзенчәлеге, Тукай яшәгән һәм иҗат иткән тарихи чорның бу үзенчәлеккә мохтаҗ булуы һәм, ниһаять, Тукайга хәтле килеп киткән татар шагыйрьләренең антитезалы тасвир өлкәсендә туплаган иҗат тәҗрибәсе, моны Тукайның, традиция буларак, үзләштерүе, үстерүе.

## I

Шактый озын гомерле татар әдәбиятының тарихы буйлап килә-килә, үз иҗатында антитезалы тасвир кулланган шагыйрьләрне билгеләп чыксак, аларның берсе дә Тукай дәрәҗәсенә күтәрелә алмаган булуын күрербез. Дөресен әйткәндә, Тукайдан

соң үткән чорда да асылда эш шулай. Әлбәттә, арада Ш. Бабич аерылып тора торуын, ләкин ул да Тукай түгел. Ни өчен бу шулай! Әллә Тукайга кадәр яки аңардан соң табигатенә, сәләтенә антитезалы тасвирга кирәкле талант орлыгы салынган балалар дөньяга тумаганнармы! Юк, алай түгел. Мәсьәлә теге яки бу сабыйның, теге яки бу талант иясе булып тууында гына түгел, бәлки ул үскән, ул эшчәнлек иткән тарихи заманның бу талантка мохтаҗлыгы бармы, юкмы икәнендә дә. Һәр заманда талантлар күпләп туа торган, ләкин тормыш аларның һәммәсенә дә юл бирмәгән. Монда иҗтимагый шартлар хәлиткеч роль уйнаган: реакция талантларны гомумән эшчәнлек мәйданыннан мәхрүм иткән. Шуңа күрә алар, әрәм булып, билгесез югалганнар.

Тарихи үсеш тудырган прогрессив һәм революцион хәрәкәтләр һәрвакыт үз идеаллары өчен көрәшә алырлык зур талантларга, көчле характер ияләренә мохтаҗ булалар. Алар талантларны, үз идеаллары белән коралландырып, искелекне җимерү һәм яңаны яклау, үстерү, иҗат итү эшенә кушалар. Шушында һәр талантның аңа гына хас индивидуаль үзенчәлеге, характер көче ахырынача тирән ачыла. Тукай белән дә шулай булган, күрәсең. Аңа тумыштан ук искиткеч зирәклек, үткен күз, тапкыр тел бирелгән. Һәр күргән, һәр ишеткәнне аның зиһене йотып алырга һәрвакыт әзер торган. Тирә-юньдәге кешеләрнең килешсез кыланышларын ул тиз эләктереп алып, сабыйларга гына хас турылык белән шунда ук кискен нәтиҗә чыгара һәм зурларны аптырашта калдыра торган булган. «Исемдә калганнар» әсәрендә ул үзе шундый эпизод турында яза: «...бер заман Бәдри абзыйларга килгәч, минем иңә күрешергә Ситдикъ исемле авылыбызның шактый могътәбәр кешесе килде, үзе исерек иде.

Миңа килеп сәлам бирде — сәламен кайтармадым, кулын сузды — кулын алмадым.

Сәбәбен сорадылар. Мин шул вакыт «Бәдәвам»ның:

Исереккә сәлам бирмә,
Ул бирсә һәм, син алма...

дигән бәетен ярдым да салдым. Моңар бөтен Бәдри абзый гаиләсе»[1] гаҗәпләнде.

Монда ук инде Тукайның үзенә күрә антитеза куллануы күренә. Уральскида рус телен дә өйрәнгәч, аның тарихтан, әдәбияттан, гомумән дөньяда барган хәлләрдән мәгълүмат алу мөмкинлекләре бик киңәя. Бу вакытта Россиядә реакция белән иҗтимагый прогресс көчләре арасында каршылык һаман кискенләшә бара. Яшь Апушның да күңеле, тойгысы, фикер дөньясы шушы хәлләрдән азык ала. Шәкертлегенең соңгы елларына таба Мотыйгулла хәзрәткә дәрес тыңлатканда, ул үз укытучысы белән бәхәскә дә кергәли башлый: «мәсәлән, ул капитал тугрусында, миңа хилаф [каршы — Х. Г.] китүб, аның зарарлыгын исбатка тырыша иде»[2], — дип яза Мотыйгулла хәзрәт үзе. Соңрак, 1905 ел революциясе кызып барган чакларда, Тукайның «Царь-голод яхут ачлык падишаһ» кебек әсәрләрне русчадан татарчага тәрҗемә итүе дә аның сәләте, талант орлыгы үсүенә азык бирми калмагандыр дияргә кирәк. Болар бигрәк тә Тукайның антитезалы фикерләвенә социаль-политик эчтәлек кертүдә зур роль уйнаганнар булса кирәк: «Берәүләр кан тирләргә батып эшлиләр, берәүләр бернәрсә дә эшләмиләр; берәүләр ачыгалар, үләләр; икенчеләре... алтын-көмеш савытлардан гына ашыйлар»[3] кебек юллар белән соңрак язылган «Көзге җилләр»дәге: «Куйса монда корткалар тәшкән тешен алтын белән, бер телем икмәк дип, анда назлы нечкә бил җылый!» юллары арасында тирән эчке бәйләныш юк микән!

Кыскасы, революция кузгаткан яңалык хәрәкәтендә Тукай үзенең иҗтимагый кыйблосын тапса, яңалык хәрәкәте исә, үз нәүбәтендә, Тукайда үзенә кирәкле бер сәләт иясен, талант һәм характер иясен тапкан. Шулай да Тукай башланып киткән революциянең үзенә, үз вакыйгалары эченә бик яшьләй, безнең хәзерге тормыш фактларына чагыштырып әйткәндә, әлерәк кенә 10 классны тәмамлаган, югары уку йорты бусагасын атлап керер-кермәс, үсмерлек белән егетлек арасындагы яшендә аяк

---

[1] Г. Тукай. Академик басма. II том. 1948 ел. 21 бит.
[2] Г. Тукай. Мәҗмугаи әсәры. 1914 ел. 26 бит.
[3] Г. Тукай. Академик басма. II том. Казан. 1948 ел. 99 бит.

баса. Бу яшьтә кешенең рухи сыйфатлары инде тәмам ачыкланып, утырып җитә, чыныгу алган була дип әйтүе кыен. Әмма революция бер башланып киткәч, күтеп тора алмый, үз ташкынына килеп кергән кешеләрне кичектерелмәс практик эшкә куша, ә аларның җитлегергә өлгермәгән якларын вакыйгалар барышында, «эш арасында» җитлектерә. Мондый чорларда һәр аерым эшлекле шәхеснең эчке, рухи үсеше үтә дә киеренке, дөрләп янулы, бөтенесен иң кыска вакыт аралыгында кичерү шартларында бара, кичерешнең үзе кискен бәрелешле драматизм төсмерен ала, антитезага әверелә. Боларны революциянең күтәрелә баруы белән бәйләп карау гына җитми әле. Революциянең җиңелүе, аннан соң кара реакция өстенлек алуы, илдә төрмәләр, палач балталары, дар элмәкләре тантана итүе, аннан соң яңадан революция рухы терелә башлавы — Тукай чоры турында сүз йөрткәндә без боларның барысын да бер-берсеннән аерып калдырмыйча, тарихи эзлеклелектә күз алдында тотарга тиешбез. Революция ташкыны үзенә суырып алып, иҗтимагый прогресс өчен көрәш юлына бастырылган кешеләр бәрысы да үз рухи үсешләрендә шушы катлаулы һәм авыр юлны үткәннәр. Башта кеше күңелендәге каршылык төбендә иске карашлар белән революция китереп керткән яңа карашлар арасында туган булса, реакция елларында яңа карашлары әле чыныгып җитмәгән кеше күңеленә реакция вәсвәсәсе басым ясарга керешә, ул кеше күңелендә мәеткә әверелгән искелекне яңадан терелтергә тырыша. Бу хәлләр чорның яңа кешесе формалашуын гаять дәрәҗәдә катлауландырган, аның җан язмышын бик әһәмиятле проблемага әверелдергән, җанның үзендә барган хәрәкәтләрне һич күздән ычкындырмыйча, күреп, белеп торуны җитди иҗтимагый-политик мәгънәсе булган эш иткән, алдынгы иҗтимагый көчләр бу хәлнең сәнгать көзгесендә тулы һәм чынлыклы чагылуына мохтаҗ булганнар. Бу ихтыяҗга шигырь өлкәсендә барыннан да элек Тукай җавап биргән. Ул үз чорының алдынгы кешесе җанында барган көрәшне, бу җанның хәрәкәтен һәм язмышын үзенең лирикасында күрсәткән.

## II

Тормыштагы иҗтимагый антагонизмнарны күрү, аңлау, үзеңнең эчке хисләр-тойгылар көрәшен кичерүең, Тукай әйткәнчә, «яшерен яну»ың бер нәрсә, ләкин шуларның сурәтен сүз ярдәмендә кәгазьгә күчерүең бөтенләй икенче нәрсә. Монда акылзиһен, хис-тойгы иясе булуың гына җитми, монда художник булуың кирәк, ягъни үзеңнең — күзеңне йомыпмы яки йоммыйча укмы — хыялыңа китергән сурәтләрне башка кеше күңелендә дә нәкъ шундый итеп кабат тудыра ала торган сүзләр табарга кирәк.

Тукай талантының антитезалы каршылык өчен кирәкле үзенчәлеге, моның орлыгы аңа тумыштан ук бирелгән булырга тиеш, дидек. Ул сабыйның үз тирә-юнендәге кешеләр сөйләгәнне аңлый башлагач ук үсәргә керешкән дип уйларга мөмкин. Аның халык авыз иҗатына ихласы да җитди роль уйнамый калмаган. Ул җырлар, әкиятләр тыңлау гына түгел, мәкальләрне дә еш ишеткән. Ә соңгылары инде — антитезалы фикерләүнең искиткеч үрнәкләре, өлгеләре. Акны-караны аера башлагачтыр, ахры, укырга-язарга өйрәнеп, китапка тиенгәч, ул татар һәм гомумән төрки шагыйрьләренең әсәрләре белән дә танышырга, үз талант орлыгын алардан алган ләззәт белән азыкландырырга керешкән. Ул кеше күңелендәге хисләр көрәшен антитезалы формада тасвирлауның беренче үрнәкләрен, әйтергә кирәк, шул борынгы шагыйрьләрдән күргәндер, беренче өлге һәм үрнәкне шулардан алгандыр. Чөнки борынгы татар һәм төрки поэзиясендә мондый тасвир киң кулланылган, аның алымнары, формасы шактый эшләнгән, чарланган булган. Бу бигрәк тә суфи шагыйрьләрдә шулай. Борын заманда алар иҗатында илаһи идея белән дөньяви идея бер-берсенә кискен каршы куелган. Алар шушы ике дошманның кеше күңеленә кереп, аның җаны өчен көрәшүләрен күрсәтергә омтылганнар. Тасвирда антитеза кулланганнар, җанны илаһият ягы билап алса, ул әллә нинди биеклекләргә оча, дөньяви як биләсә, гади тормыш ыгы-зыгылары базына тәгәри, дигәннәр. XV йөздә иҗат иткән суфи шагыйрь Өмми Камалның үз күңеленә дәшеп язган шигырен алыйк:

И гаһи шәмс, гаһи зәррә, гаһи маһ мөнир,
И гаһи бәхр, гаһи катрә, гаһи маһи күңел.
Бер нәфәс җәһлилә нә кәндүни, нә гайри билән,
Бер нәфәс гыйльмилә һәр нәснәнең агаһи күңел! [1]

Бу юлларны хәзергечә язсак, менә ничек килеп чыга: и әле кояштай, әле тузан, әле айның шәүләсе кебек кенә күңел; әле океан, әле тамчы, әле айның үзе кебек күңел; бер мизгелендә наданлыгыннан ни үзеңне, ни башканы танымаган, әмма икенче мизгелендә белем көче белән һәрнәрсәне күреп торган күңел!

Күрәсез, шагыйрьнең күңел дулкыннары бер мизгел арасында нинди искитәрлек амплитудалар ясый.

XVI йөзнең урталарында иҗат иткән Казан шагыйре Мөхәммәдъярны алыйк. Аныңча да, җан алладан бирелгән. Ул, үз вакыты җитеп тәнкән аерылгач, алла хөкеме каршына кайтырга тиеш. Мөхәммәдъяр күңел дигәннән күбрәк «нәфсе»не күздә тота, моның белән ул кешенең дөньяви, реаль теләкләрен белдерә.

«Җан» үзенең алла каршысында сафлыгын сакларга тели, әмма «күңел» (нәфсе) дөнья һәм тормыш вакыйгаларына омтыла, алардан азык, мәгънә һәм ләззәт алырга тели. Шушы урында «җан» белән «күңел» арасына өченче нәрсә — «язмыш» («фәләк») килеп керә һәм, күңелгә ачу итеп, җанны газапларга керешә. Шагыйрь моның өчен фәләккә ризасызлыгын белдерә:

Бер кешенең ике булса дошманы,
Кайда тынгай ул фәкыйрьнең бер җаны?
...Бер заман мең төрлүк утка якмагыз!

Күренә ки, шагыйрь язмышны да, күңелне дә җанга дошман саный. Ул диннән, суфичылыктан азат булмаса да, аңарда дөньявилык көчлерәк.

Борынгы шагыйрьләр кешенең рухи дөньясында дөньявилык белән диниlек арасындагы капма-каршылыкны, кискен тартышны күз алдына бастыра торган антитезалы сурәт чараларын да эшләгәннәр. Тойгы-хисне шигырьгә күчерүдә алар, күбесенчә, шартлы сурәтләр кулланганнар, кеше җанының давыллы хәлләрен — диңгез; балкулы чакларын — кояш, ай; илһампану вакытын — күңел күзе ачылу кебек метафораларда күрсәткәннәр, шигырьнең ритмик төзелешен чарлаганнар, аның нәфисләү чараларын үстергәннәр.

Г. Тукай борынгы төрки һәм татар шагыйрьләренең әсәрләре белән кечкенәдән үк таныша башлаган. Уральскида мәдрәсәдә шигырь төзелеше фәнен өйрәнгәндә, шигырь үлчәмнәрен үзләштерү өчен, «Мөхәммәдия», «Бакырган» кебек китапларны укый. Тукайның күп шигырьләре «Мөхәммәдия»гә яки «Бакырган»га пародия итеп язылуы шуның өчен дә гаҗәп булмаска тиеш. Ләкин борынгы поэзиядән ул тик көләрлек, тик мәсхәрә итәрлек нәрсәләр генә алган дисәк, бу бер яклы караш булыр иде. Ул аннан уңай мәгънәдә дә күп нәрсә өйрәнгән, ләкин аларны революция заманының тәнкыйте аша алган. Лирикага килгәндә, ул борынгы поэзиядән кеше күңелендә каршылыклы хисләр көрәшен тасвирлау традициясен, антитезаны үзләштергән, бу көрәшне тасвирлаудагы күп кенә шартлы сурәтләрне үз иткән, ниһаять, шигырь төзелешенең барлык казанышларын үзләштергән. Тукай борынгы антитезаның бер ягын — дини ягын — ташлап калдырды, аның тик дөньяви ягын гына алды һәм аңа иҗтимагый дифференциация кертте: халык дөньявилыгы белән эксплуататорлар дөньявилыгын ике якка кискен аерып ташлады, антитезаны шушында ачты һәм аның ярдәмендә иҗтимагый көчләр арасындагы капма-каршылыкларны гәүдәләндерде. Кайберәүләр, бәлки, ул бит динчеләр турында да язды лабаса, диярләр. Ләкин ул динчеләрне дә инде илаһи көч итеп түгел, бәлки иҗтимагый көчләрнең бер төркеме итеп, социаль яктан дифференциацияләнгән дөньяви күренеш буларак тасвирлады, аларны антитезаның халыкка каршы ягына куйды. Кешенең үз эчке дөньясындагы капма-каршы уйхисләр көрәшендә дә ул дөньяви идея белән дини идеяне түгел, бер як дөньяви иҗтимагый идея, хис, тойгы белән икенче як дөньяви иҗтимагый идея, хис, тойгыны куйды. Шушының белән ул бөтен татар поэзиясе тарихында яңа эпоха ачты. Шушында

[1] Өмми Камал. Казан. 1884 ел. 98 бит.

аның борынгы әдәби традицияләрне үзләштерүдәге концепциясе аерата ачык күренде.

Тукайның күп кенә лирик шигырьләренең төп картинасын өч шартлы образ оештыра: төн, күңел газабы, кояш яки ай. Боларның даими мәгънәсе бар: т ө н — котелмәгән дәһшәтле хәлләргә килеп керү нәтиҗәсендә күңелдә туган аптырау, юлсыз калу, хәтта идеалны да күздән ычкындыру. Г а з а п л ы к и ч е р е ш — көтмәгәндә килеп туган хәлне алдан күрә белмәгәнең өчен сызлану, тормыш һәм кеше тануда үзеңнең өлгереп җитмәгән ягың булуын кинәт аңлап, кимсенү, үкенү, өзгәләнү, уйлану, кискен хәрәкәтле анализга керешү, әзләнү. К о я ш, ф и к е р к о я ш ы я к и Й о л д ы з, У т — кичерү, эзләнү барышында газаплы хисләр җиңелә бара; төн, томан акрын-акрын тарала, офык яктыра һәм кояш чыга яки, төнне болыт, томан каплаган булып, ул таралса, саф аяз күктә йолдыз балкып күренә башлый. Шушында эчке көрәш чишелә, чөнки «кояш», «йолдыз» яки «ут» төсендә идеал табыла. Тукай бу шартлы сурәтләрне бик яратып куллана, еш кына шушы өч элемент аның лирик шигыренә камилләшкән сәнгатьчә бөтенлек бирә. Менә аның «Даһига» шигыре:

> Күз карашыңда синең дөнья күренде мәңге төн.
> Киттең эзләп син аны яктыртмага идеал утын.
> Гайрәт иттең, армый-талмый йөрдең ушбу юлда син.
> ...Артка бакма, даһием, идеал һаман да алда ул;
> Алга барганнарга тик табыла табылса: алла ул.

«Иһтида» шигырендә дә без төбендә шул ук хәлне күрәбез. «Сөюнең мәгънәсе бигүк гали, бигүк нечкә. Сөю идеалдыр ул», — дип инанган шагыйрь берәүгә гашыйк була һәм соңрак, бик нык ялгышканын төшенеп, үзенең «җиңел уй, йөз кызарткыч төрле хисләре» өчен оялa, күңеленнән газаплана. Чишелештә без шул ук шартлы сурәт белән очрашабыз: «Килеп чыкты хәзер фикрем кояшы золмәт (төн — Х. Г.) артыннан», — ди инде ул тантана белән.

«Өмет» шигырендә антитеза аеруча кискенлек белән кулланыла. Монда бер-берсенә «фикер кояшы» белән «болыт» капма-каршы куелган. Ф и к е р к о я ш ы (идеал) — шагыйрьнең вөҗданына тереклек көче биреп торучы. Б о л ы т (хата, бозык, реакцион тойгы һәм фикерләр символы), ике арага кереп, шагыйрьнең вөҗданын үлемгә дучар итә. Үлек вөҗданлы кешегә әверелү — бу коточкыч трагедия, һәлакәт! Шагыйрьнең котылу, үз кешелеген саклап калу әмәле тик бер генә нәрсәдә: болыт китеп, яңадан фикер кояшы чыгуында. Шагыйрь явыз «болыт» астында калган җанның газабын тасвирлый: «вөҗдан үлгән», шагыйрь «тугры юлдан адашкан», «бетү чокырына» егылган, «караңгыда калган... уңны-сулны күрми, асны-өсне белми». Аның ышанычы тик «фикер кояшы»нда гына: «нәрсә ул дөнья кояшы, син миңа нур бирмәсәң!» — ди ул. Чишелеш кискен сикереш төсендә бирелгән:

> Юк, кояшым, мин беләм, син батмагансың мәңгегә;
> Син дә, вөҗдан, бер торырсың, ятмагансың мәңгегә.
> Юк! Түбән калмас бу җан: фитратта гали булган ул...

Кайвакытта Тукай үз шигырен эчке рухи көрәшнең чишелешеннән башлап китә. «Газаптан соң» шигыре шулай язылган. Башта ук шагыйрь тантана белән: «Мин бәхетле бәндә!» дип белдерә:

> Тормыш инде яктырадыр, кузгала һәм җанлана.
>
> Таң атып, чәчсә кояш нурлар, шулай ук кузгала,
> Яктыра, шаулый ерак җирдән күренгән зур кала.
>
> Үземә сөенеч бирәм инде бәхет, гыйззәт белән;
> Уйлыймын үткән газапларны хәзер ләззәт белән.
>
> Булмадымы шул газаплар бәхтемең ачкычлары!..

Монда шагыйрь карашының бик мөһим яклары ачыла: күңелдәге газап вакытын ул башка килгән бер бәла итеп кенә карамый. Бу газап — көрәш. Монда «бәхет ач-

кычы»н әзләүчә актив көч хәрәкәт итә. Шуңа күрә дә бу көрәштә үзенә аерым ләззәт бар. Шагыйрьнең бу сүзләреннән эчке рухи көрәшнә үсү, яңару процессы итеп карады, художник буларак, асылда «җан диалектикасы»на үтүе аңлашыла.

Шагыйрь күңеленә ут кабыну, рухи дәрләү, эчке көрәш нинди дә булса тышкы нәрсәдән көчле тәэсир алу белән башлана. Бу хәл «Гыйлвәә» шигырендә ачык күрсәтелгән. Ул һәр җанлы бер туташнымы, ханымнымы күреп, тирән әсәрләнгән:

Булмадың ярым вә булмассың, беләм, җефтем минем,
Әмма булдың янмага күңелемдә син нефтем минем, —

ди ул. Аның эчке януын үз рухи дөньясының тышкы дөнья белән өзлексез бәйләнештә булуы нәтиҗәсе дип карарга кирәк. Монда объектив дөнья вакыйгаларына шагыйрьнең субъектив мөнәсәбәте гәүдәләнә, объектив чынлыктагы матурлык, гүзәллек шагыйрьнең күркәм рухи омтылышлары белән бергә кушылып, зур эстетик көчкә әйләнә, аның шәхси кичерешә иҗтимагый эчтәлек ала һәм, шигырьгә әверелеп, җәмгыять хәзинәсенә күчә.

Тукайның демократик, революцион идеалы, әлбәттә, ул яшәгән җәмгыять төзелеше белән килешми. Иҗтимагый төзелеш белән аның идеалы арасында кискен дошманлык бар. Иҗтимагый строй аның идеалын сүндерергә һәм шуның белән шагыйрьнең кешелек намусына үлем җәрәхәте салырга омтыла. Шагыйрь үз идеалы өчен өзлексез көрәшергә мәҗбүр. Аңардан дөнья һәр минут саен күңел җимешләре биреп торуны сорый. Моның өчен өзлексез яну кирәк. Шунсыз күңелнең үзен дә «төрле тап-тутлар өртелдерә», шуның өчен дә: «Ян, күңел, сызлан, күңел!» — ди шагыйрь. Теләгәнең шундый бөек — аңа ирешер өчен мең җан бирсәң дә урынлы! Очарга теләсәң, канатың ач, вакыт җитте! Яхшы аңла: кешелегеңне югалтмасаң, бу дөньяда рәхәтлек, кәеф-сафа юк.

И шуны саклау юлында күп газапланган күңел!

Үз иманына кул тидермәс өчен, үз идеалын саф килеш саклар өчен бу кадәр дә ут атып торган күңел булыр икән! — дибез без дә сокланып.

Шагыйрьнең идеалы гел хыялый нәрсә генә түгел, ул конкрет, гәүдәле дә булып алга баса. Шагыйрь үз идеалының конкрет чынлыгын бөек кешеләрдә күрә: Пушкин һәм Лермонтов — Кояш, Хәсәен Ямашев — язда елмайган Кояш, өстән Йолдыз һ. б. Яшь буынга үгет-нәсихәт биргәндә дә шагыйрь чын кешене Кояшка тиңли:

Син Кояштан үрнәк алсаң, иҗтиһат итсәң һаман,
Күп арасында кояш күк ялтырарсың бер заман.

Вакыты белән шагыйрь үз идеалы — Кояш белән органик берләшергә ук ашкына. Мәсәлән, 1912 елда язылган «Ваксынмыйм» шигырендә шулай. 1905 елгы революциядә юлаучы булып, шапырынып йөргән кайберәүләр бу вакытта инде мөртәт булганнар, революция идеалларына кул селтәп, азу-тузу, талаш-ызгыш юлына басканнар. Тукайның үз сүзләре белән әйткәндә, «бер-берен чәйни Бишенче елдагы күп әүлия» («Мөхәрриргә»). Алар Тукайны да үз яннарына ымлыйлар, әйдә, диләр, «син үзеңне дөньяда безнеңчә йөрт, безнеңчә тот!» Шагыйрь моңа антитезалы сурәт белән җавап кайтара: юк, бу мөртәтләргә, бу хаиннәргә кушылса, аларга баш иссә, ул үзенең олы җаны, саф вөҗданы каршында зур җинаять эшләгән булыр иде. Юк, ул моны эшләмәс; идеалына хыянәт итмәс:

Ашкынамын мин әбәт бетмәс урынга, мәңгегә,
Мәңгелеккә — мәңге рухлы, мәңге нурлы ямьлегә!

Анда мин мәңге көләч һәм мәңге яшь булмак телим,
Бу кояш сүнсен, җиренә мин кояш булмак телим.

Сатлык җаннар, мещаннар сазлыгы белән кешелек күгендә балкып торган кояш — шигырьдәге шушы доминант сурәт, шушы антитеза, күз алдында искиткеч предметлы һәм җанлы картина тудырып, зур һәм тирән иҗтимагый идеяне, хис-тойгылар дулкыны белән ярсытып, әчә дә ташлый. Тукай лирикасындагы антитезалы тасвирның төп

чыганагы, шулай итеп, шагыйрь яшәгән һәм иҗат иткән тарихи чорның иҗтимагый тормышында — мондагы антагонистик көчләр арасында барган рәхимсез көрәштә. Тукай лирик герое кичергән рухи көрәшнең дә тарихи эчтәлеге шушы хәл белән бәйләнә. Бу лирикада яңа заманның алдынгы яңа кешесе нинди эчке һәм тышкы каршылыкларны җиңә-җиңә үсеп килүе күренә.

## III

Безнең уебызча, сәнгатьнең төп законнарыннан берсе зурдан да зуррак күренешләрне мөмкин хәтле кечерәк мәйданга сыйдыру, эчтәлекнең мөмкин хәтле зуррагын, ә аны урнаштырыр мәйданның мөмкин хәтле кечерәген табу. Даһиның тарихны тотырып торган бөеклеген сынчы зур шәһәрләр уртасында бер табан басарлык кечкенә мәйданчыкта терелтеп күрсәтергә хыяллана, заманның бөтен кешелекне куз-гаткан бөек диңгез һәм давылларын язучы култыгыңа кыстырып китәрлек китапка сыйдырмакчы була. Тукай да кечкенә бер бит кәгазь мәйданында революция диңгезенең кеше күңеленнән кичкән ярсулы көчен һәм кодрәтен кабат ашкындыртып уздырырга тели, ул да мөмкин хәтле зурданрак алып, мөмкин хәтле кечерәк мәйданга сыйдыру юлын эзли. Әйтергә кирәк, мәйдан кечерәйтүдә антитезалы тасвирга хуш килеп тора торган тагын бер нәрсә бар: ул — афоризм. Чыннан да Тукайның иҗаты антитезалы афоризмнар белән типчелгән. Бу да, бер яктан, борынгы көнчыгыш һәм төрки поэзиясенә, икенче яктан исә, халык иҗатына барып тоташа. Тукай поэзиясенең халык иҗатына бәйләнешен бездә күбрәк әкият һәм җыр белән бәйлиләр. Ләкин ул мәкаль дөньясы белән дә тирән бәйләнгән. Һәм бу турыда сүз йөрткәндә Тукайның үзе яшәгән якын арадагы заман үлчәме белән генә эш итү аз булыр. Монда сүзне тамырлары мең елларга һәм күп халыкларның иҗатларына кереп югалган күренешләр, бәйланышлар турында йөртергә кирәк.

Борынгы заманда Түбән һәм Урта Идел ярлары Европа белән Азия, Урта Көнчыгыш белән Төньяктагы илләр арасында барган зур сәүдә юлларының бергә очраша торган урыны булган. Сәүдәгәрләрнең янчыкларында, кулларында тәңкә булса, башларында, телләрендә мәкаль булган, үткен сүз булган. Дөньяның һәр дүрт тараф кешеләре арасында мал алмашу барышында, әлбәттә, кызыклы фикерләр уртаклашу да, шул исәптән мәкальләр алмашу да барган. Идел буе төрки дөньясы ул мәкальләрнең байтагысын, төрки теленә күчереп, мондагы тормыш, мондагы фикер-зиһен ихтыяҗларына яраштырып, үзенә дә калдырган, аларны үзе иҗат иткән байлыкларга кушкан. Югыйсә Мәхмүт Кашгарый 1073 елда ук үз китабына теркәгән:

> Ут төтенсез булмас,
> Егет языксыз булмас [1],—

дигән мәкальне төньяктагы немец та:

> Kein Feuer ohne Rauch.
> Kluge Leute fehlen auch [2],—

дип, ничек нәкъ шундый ук сүзләр белән әйтер иде. Мондый мисалларны бик күп китерергә мөмкин. Без татар халкы телендә йөргән мәкальләрне хәзерге көндә бездән көнчыгышта һәм көнбатышта, төньякта һәм көньякта яшәгән халыкларның мәкальләре белән чагыштырып, тикшереп карадык. Бездә, үз илебез халыклары турында әйтеп тә тормастан, япон, кытай, вьетнам, һинд, гарәп, фарсы, Африка, Европа халыклары белән уртак мәкальләр бик күп икән. Урын тар булганга гына аларны биредә китереп булмый.

Мәкаль аша халык аңы, халык культурасы, ул үзе бу турыда уйламаса да, күп илләр, мең еллар белән бәйләнә. Шуңа күрә дә үз иҗаты барышында халык мәкаль-

---

[1] М. Кашгарый. Диване лөгатит төрк. Ташкент. 1960 ел. I том. 380 бит.

[2] А. Гердт. Русские и немецкие пословицы и поговорки. 1965 ел. 41 бит. (Алга таба Г. диелер).

ләренә мөрәҗәгать иткән, үзенең иҗат ителмәктәге әсәренә мәкальләрдәге идея һәм сәнгать матурлыгын органик төстә кушып җибәргән шагыйрь мең еллык традицияләр белән дә котылгысыз бәйләнә. Мәкальне һәм аңарда җыйналган халык тәҗрибәсен Тукай да үз иҗат концепциясенең нигез ташларыннан итеп алган. Бу аның лирикасында да, башка төрдәге шигырьләрендә дә ярылып ята. Аның иҗат процессында, күзгә күренмәс булып, күп халыклар, күп заманнар, күп мең еллар катнаша. Бераз мисаллар китерик.

«Син бүген бай, бәлки, шайтаннан да ярлы иртәгә!» — ди шагыйрь «Нәсыйхәт» шигырендә. Вьетнам мәкале дә шуны ук әйтә: «Син бүген кич — бай, иртә таңда — ярлы»[1]. «Һәр ялтыраган алтын түгел», — ди шагыйрь: «Es ist nicht alles Gold, was glänzt», — ди немец мәкале [Г. 38], иран мәкале дә нәкъ шулай әйтә [В. 425].

Үз төбенә төшми, ди, шәм-лампаның һичбер нуры,
Шул мәкаль монда дөрес шул, ах, аны җен оргыры! —

ди шагыйрь ачынып «Казан вә Казан арты» шигырендә. Бу афоризм күп халыкларда булган икән: һиндта [В. 6], ассириялеләрдә [В. 97], грузинда [В. 202], фарсыда [В. 430]. Японда: «Маяк төбендә һәрвакыт караңгы», — диелә [В. 633].

Батарсың, дим — йөгермә Нилгә каршы,
Кире кайтыр, — төкермә җилгә каршы.

Бусы «Бер маңгы тәрәкъкыйга» шигыреннән. Көрд халкы: «Җилгә каршы төкергәннең төкерөге үз битенә төшәр», — ди [В. 334], грузин шуны ук кабатлый [В. 195], кореяле [В. 317], малайя [В. 369], таиланд халкы [В. 466], бенгалияле [В. 134], япон [В. 633]... Тукай шигыренең үзәге, күзгә күренмәс күп җепләр белән, башка халыкларның тарихи һәм акыл-зиһен эшчәнлегенә бәйләнеп беткән. Аның тавышына кушылып, аның шигыреннән асылда күп халыкларның, күп заманнарның авазы яңгырый.

Борынгы һинд афоризмнарын тикшергән А. Е. Сыркин болай ди: «Афоризм... әйтеп бирү рәвеше ягыннан караганда сәнгать иҗаты белән, эчтәлеге ягыннан фәнни иҗат белән кардәшлек итә. Афоризм сәнгать белән фәннең ике урталыгындагы чиктә тора, үзенең форма һәм мәгънәне аерылмас бер бөтенгә бәйләве белән ул культураның төп ике сферасын тоташтыручы буын хезмәтен үти»[2]. Фәнгә дә, сәнгатькә дә бер үк дәрәҗәдә ялкынлы мәхәббәт асраган Тукайга мәкальләрнең мондый табигатe үтә дә үз булмыйча калмаган. Фәнгә бәйләнешле буларак, мәкальләр билгеле бер идеянең диалектик асылын каршылыклар бирлегендә, антитеза ярдәмендә ачалар. Әлбәттә, Тукайга аларның шушы ягы аерата якын. Без тагын мисалларга мөрәҗәгать итик. Борынгы һинд афоризмы әйтә: «Көн кояш бату белән бетә, төн — кояш чыгу белән; шатлык хәсрәт белән, хәсрәт шатлык белән тәмамлана. Бәхеттән соң бәхетсезлек, бәхетсезлектән соң бәхет килә. Гел генә бәхетсезлек яисә гел генә бәхет булып тормый» [ДА. 74]. Бенгалия халкы: «Бәхет белән бәхетсезлек алмаш-тилмәш килә» [В. 126], суахили: «Хәсрәттән соң шатлык килә», ди [В. 450]. Японнар: «Шатлыкта хәсрәт орлыгы, хәсрәттә шатлык орлыгы бар», диләр [В. 618].

Күрәсең: бу болыт бирлә гомерлеккә кояш бергә,
Шулай бергә, бугай, шатлык та хәсрәт, канлы яшь бирлә,—

ди безнең шагыйрь дә «Шатлык вә хәсрәт» шигырендә.

Тукай бу афоризмнарны шигыренә китаплардан күчереп алып куйган дип уйлау үтә дә беркатлылык булыр иде. Шигырен иҗат иткәндә, алар аның уй һәм кичерешләренә китап битләреннән килеп кермәгәннәр, бәлки күңеленең иң тирән түреннән күтәрелеп чыгып, аның бәгырь канының җылысы белән бергә килеп кергәннәр. Ул аларны кече-кечедән күп ишеткән, күп хәтерләгән, алар аның талантын азыкландырып,

---

[1] Пословицы и поговорки народов Востока. 1961 ел. 450 бит. (Алга таба бу китап В. дип әйтелер һәм бите генә күрсәтелер.)

[2] Древнеиндийские афоризмы. Мәскәү. 1966 ел. 70 бит. (Алга таба ДА. диелер.)

нәкъ үзенең күңел хәзинәсенә әверелеп, уйлау, кичерүендә субъектив сыйфатына әйләнгәннәр. Аның үз уйлау барышы шул мәкальләрдәге, шул афоризмнардагы антитезалы рәвеш белән хәрәкәт итә торган формада җитлеккән. Антитезалы фикерләү аның индивидуаль табигатенә әйләнгән. Шуңа күрә дә халык мәкале, борынгы афоризм аның шигыренә читтән, чит гәүдә кисәге булып түгел, органик үзенеке булып кереп китә. Гомумән, фикерләү шундый ташкын белән барганга, аның илһамы элек бөтенләй беркайда да булмаган афоризмнарны да китереп чыгара: «Бармыни бездә гомумән чын кеше кадерен белү!! Без аны кайдан белик, мескен үлеп аңлатмагач!!» («Хөрмәтле Хөсәен ядкяре»), «һич кайгысыз кеше булса, адәм түгел» («Серләүхәсез»), «Керләнеп беттем үзем, дөньяны пакьли алмадым» («Кыйтга») һ. б.

Антитеза, сурәтле фикерләвенең хас үзенчәлеге буларак, гомумән Тукайның бөтен шигъри сөйләменә үз тәсмерен бирә: аның чагыштырулары, эпитет һәм метафоралары — бөтен тасвир чараларын кискен контрастларга, антитезаларга, каршылыкларның көтелмәгән берлеген табуга корылган. Тукай, ике чакма ташны бер-берсенә кинәт бәрелдереп, аларда дөнья яратылганнан бирле сизелми яткан очкыннарны шулай ук кинәт кабызган шикелле, бер-берсенә һич тә якын килә алырлык дип уйламаган сүзләрне көтелмәгәндә бер-берсе белән очраштыра һәм шулай ук һич тә көтелмәгән хикмәтле мәгънә тудыра. Бу инде аның гына бәхетенә чыккан талант үзенчәлеге. Бу үзенчәлекнең үсеп, ачылып китү шартларын исә революция заманы, искелек белән яңалык арасындагы капма-каршылыкның ачыктан-ачык революцион конфликт булып ачылып китүе тудырган. Шулай булмаса, Тукай таланты да дөньядан бәлки эзсез-юлсыз, үзен күрсәтә алмыйча үтеп китәр иде.

Без мәсьәләне борынгылыктан ук алып күзәтергә тырыштык. В. И. Ленин болай ди: «...культураны җимерүләр нинди генә булмасыннар — аны тарихи тормыштан сызып ташларга мөмкин түгел, аны яңарту кыен булыр, ләкин һичкайчан һичнинди җимерү дә бу культураны бөтенләй юкка чыгуга хәтле илтеп җиткермәс. Үзенең теге яки бу өлешләрендә, теге яки бу материаль калдыкларында бу культура — бетерелгесез, кыенлыклар тик аны яңартуда гына булачак...» [1].

Культураларны яңадан торгызу шартларын социаль революцияләр китерә. Тукай иҗаты — гасыр башындагы халык революциясе нәтиҗәсе. Шуңа күрә аның иҗатында элегрәк заманнарда туып та, царизм хакимлеге нәтиҗәсендә җимерелгән, еллар-гасырлар астында калган культура казанышларының яңадан торгызыла башлавы һәм яңартылуы табигый иде. Шушы ноктадан без бөек шагыйрь иҗатындагы традиция һәм новаторлык мәсьәләләренә якын килүдә бер тәҗрибә ясап карарга гына тырыштык.

---

[1] В. И. Ленин, Сочинения, 4 издание. Том 27, стр. 105, Рус телендә.

# УСАЛ ТЕЛЛЕ ДРАМАТУРГ

Әлмәттә дә юбилейлар башлана! Әлмәт юбилейлар капкасын драматург Сәет Кальметов ачып җибәрә һәм шуннан соң бар туктатып кара син: ел аралаш бер юбилей булып торачак!

Усал телле, берәүгә дә охшамаган сәеррәк холыклы, беркайчан да алга сикереп чыгарга, исемлеккә эләгергә тырышмаучы Сәет Кальметов турында журналга уч төбе чаклы гына язу язып бирү кирәк булгач, күңелдә нигәдер әнә шундый уенчак, шаян тойгылар уянды.

Сәет Кальметов Башкортстанның Яңавыл поселогында тимер юлчы семьясында туган. Җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң ул Ташкентта, «Үзбәкфильм» каршында оештырылган ике еллык сәнгать студиясендә укый, реклама мастерскоенда һәм Урта Азия театрларында художник булып эшләп йөри. 1938—41 елларны Чиләбе татар театрында художник була, театр ябылгач, Орджоникидзе заводына художник булып эшкә керә, агитплакатлар яза. 1943 елдан сугыш беткәнгә кадәр Сәет Кальметов фронтта. Беренче Украина фронты сугышчылары белән ул, танкист булып, Прагадан Берлинга кадәр барып җитә. Сугышчан медальләр белән бүләкләнә.

Сугыштан соң, 1945 елны, Сәет Кальметов Буа театрына кайта: ике ел буена режиссер, бер үк вакытта артист та була. «Безнең кияү» исемле бер пәрдәле пьеса әнә шунда, Буада иҗат ителә һәм яшь авторда иҗат дәрте уята. «Йолдызлар балкый» исемле күп пәрдәле икенче комедия Буа, Минзәлә, Республика күчмә театрларында уйнала.

Драматургны тамашачыларга аеруча таныткан әсәре «Тын алан шаулый» драмасы булды. Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, режиссер Габдулла ага Юсупов сәхнәгә куйган бу әсәр Татар дәүләт академия театрында өч сезон уйналды. Колхоз авылы механизаторларының көндәлек тормышын, үзара бәхәсләрен һәм яшьлек-мәхәббәт тойгыларын кайнар итеп, үткен итеп чагылдыруы белән драма тамашачылар күңелен яулап алды.

Сәет Кальметов 1955 елны Әлмәткә күчеп килә. Шуннан соң ул драматурглык язмышын Әлмәт театры белән бәйли. Бу театр аның «Йолдызлар балкый» (яңа варианты), «Нуриянең дуслары», «Ышанычлы юлдаш», «Үкенерсең, кодагый», «Тамгалы йорт» комедияләрен, «Соңгы очрашу» һәм «Зәкия» драмаларын тамашачыларга икешәр-өчәр йөз мәртәбә күрсәтте. Күрәсең, моңа Сәет Кальметов драматургиясендәге үзенчәлекле сыйфат — вакыйгаларның кискенлеге, персонажлар теленең борычтай ачы булуы, юмор һәм сатира ярдәм иткәндер. Икенчедән, әсәрләрне сәхнәгә куйган режиссерларның, театр коллективының да бик теләп, яратып эшләүләре булышкандыр.

Сәхнәдә сүлпәнлекне, озаклап аңлатып торуны, «прозаизмны» яратмый драматург. Аның әсәрләре динамика-тизлек, контрастлар таләп итә. Холкында да шулай безнең дустыбыз: бер карыйсың — үз эченә бикләнгән, икенче карыйсың — иң шәп артистларыңны да уздырырлык итеп, шаулап, тавышланып күрешә синең белән.

Сәет Кальметов илле яшь тулыр алдыннан Әлмәт театрына берьюлы ике әсәр: «Тайгак тау» драмасын һәм «Тозлы шикәр» комедиясен тапшырды.

Илле яшьне иң җитлеккән, иҗатының чәчәк аткан чоры дип санап, каләмдәш дустыбызга алга таба, алтынчы дистәне ваклый башлаганда, зур уңышлар телибез.

Гариф АХУНОВ.

**Рәфикъ Нәфиков,**

тарих фәннәре докторы, профессор.

# ТАТАР РЕВОЛЮЦИОНЕРЛАРЫның РАЗНОЧИНЕЦ-ДЕМОКРАТИК ХӘРӘКӘТКӘ КАТНАШУЛАРЫ ТУРЫНДА

Революцион демократлар калдырган мираста, бигрәк тә Россиядәге революцион хәрәкәтнен разночинецлар чорына караган мираста, рус булмаган вак милләт вәкилләренең азатлык хәрәкәтенә катнашу мәсьәләләре әлегә кадәр бөтенләй диярлек өйрәнелмәгән.

Дөрес, патша Россиясендә күп халыкларның тормыш хәлләре бик авыр, үсеш дәрәҗәләре бик артта булганга, алар арасыннан революцион-демократик юнәлештә фикер йөртә торган укымышлыларның киң күләмдә чыгуы турында сүз алып барырга да мөмкин түгел.

Әмма, гомумән алганда, К. Маркс һәм Ф. Энгельс әйткәнчә, Россия рус булмаган милләтләр өчен, өлешчә Идел буе халыклары татарлар, башкортларның цивилизациясе өчен уңай роль уйнады.

Бөек революцион демократлар Россия тарихындагы милли моментка игътибар юнәлттеләр һәм аны үзләренчә чишәргә дә тырыштылар. Башка халыкларга һәм милләтләргә карата ихтирам, Польшадагы революцион хәрәкәткә теләктәшлек белдерү, ялган патриотизмны, панисламизмны, славянофилларның Бакунин һәм либераллар алга сөргән юнәлешләрен тәнкыйтьләү — милли мәсьәлә буенча алар алга куйган «программа» әнә шулар булды. Шул ук вакытта алар рус булмаган халыкларны патша хөкүмәтенә, изүгә каршы социаль көрәш агымына тартырга тырыштылар.

1862 елның 13 октябрендә күренекле революционер М. Д. Муравский, төрмәдә утырганда, болай дип язды: «Соңгы өч-дүрт ел эчендә мин шундый ныклы карашка килдем: рус хөкүмәтеннән... аңа буйсынган милләтләр азмы-күпме файдалы үзгәртеп корулар көтмәскә тиешләр..., минем уемча, хәзерге тәртипләрне үзгәртү өчен бердәнбер ысул — ул революция ясау юлы»[1]. Ул алтмышынчы елларда Казан университеты студентларын үзләренең туган якларында рус булмаган халыклар арасында культура таратырга, диннән арынырга ярдәм итәргә, рус тарихын Щапов идеяләре рухында укытырга чакыра, башкортларның руслар белән якынлашуын яклап чыга[2].

Архив документларыннан күренгәнчә, алар үзләренең бу омтылышларын конкрет эшләре белән дә ныгыталар. Узган гасырның 60—80 елларында Идел буенда һәм Уралда, патша хөкүмәтенең каты эзәрлекләвенә карамастан, разночинецларның эшчәнлегендә прогрессив, гуманистик һәм революцион традицияләр дәвам итә, алар буыннан буынга күчеп, һәр этапта үсәләр, яңа сыйфатлар белән байыйлар. Идел буенда һәм Уралда яшәгән халыклар һәм милләтләр арасында ул елларда ук, үзләренең рус туганнары белән бер сафка басып, азатлык өчен көрәшчеләр үсеп чыга.

---

[1] М. Лемке. «Алтмышынчы еллар»дагы азатлык хәрәкәте очерклары. Икенче басма. С. Петербург. 1908. 301 бит.

[2] Шунда ук.

Житмешенче елларда народниклык хәрәкәтендә яңа этап башлана: аның күренекле вәкилләре үзләренең эшчәнлеген башында Карл Маркс белән Фридрих Энгельс торган Халыкара пролетар оешма белән бәйлиләр. Беренче интернационалның атаклы рус секциясе Россия белән, крестьяннар һәм кайбер эшчеләр арасында практик революцион эш алып барган народниклар белән даими бәйләнештә тора. Париж коммунасы, Маркс һәм Энгельс хезмәтләре, Беренче интернационал эшчәнлеге Россиядә иҗтимагый фикернең үсешенә, яшьләрнең формалашуына зур йогынты ясый.

Үз чиратында Идел буендагы һәм Урал тирәсендәге народниклар Мәскәүдәге үзәк белән, И. Мышкин типографиясе белән тыгыз бәйләнештә булалар. Аитов фамилияле берәү, татар теле буенча имтихан тоту өчен, 1873 елда Мәскәүгә бара. Ул, укытучы булып, татарлар арасында революцион эш алып бару максатын күз алдында тота. 1873 елның 13 июлендә бер татар ямщигы Оренбургтагы яшерен яшьләр түгәрәге членнарына Мәскәүдән, Аитовтан, Беренче интернационалның программа басмаларын, француз телендә язылган берничә бит прокламация һәм башка материаллар алып кайта [1].

Аитов үзе дә революцион китаплар, шулар арасында Щаповның «Рус халкының үсешендә педагогик шартлар тарихы» хезмәтен алып кайтырга тиеш була.

Давыт һәм Ильяс Аитовлар «халыкка йөрү»гә әзерлек эшләренә актив катнашалар, 70 еллардагы Мәскәү, Петербург революционерлары, «Зур пропаганда җәмгыяте» членнары белән бәйләнеш тоталар; яшерен оешманың башка членнары кебек үк, Карл Маркс һәм Фридрих Энгельсның кайбер хезмәтләрен, Беренче интернационал, аның рус секциясе материаллары белән таныш булалар, икесе дә кулга алыналар һәм төрмәдә утырып чыгалар.

Давыт Аитов, 1878 елда төрмәдән чыккач, Оренбург шәһәрендә торып кала һәм, рәсми документта күрсәтелгәнчә, «җирле халык арасында хөкүмәткә каршы идеяләр таратып, үзенең җинаять эшен дәвам итә». Властьларның әзәрлекләве нәтиҗәсендә ул чит илгә китәргә мәҗбүр була һәм эмиграциядә дә революцион эшчәнлеген дәвам итерә [2].

Народникларның житмешенче еллардагы пропаганда эшчәнлеге, бер дә арттырмыйча әйтергә була, хезмәт ияләре аңында билгеле бер эз калдырды, укучы яшьләргә шактый йогынты ясады. Бу йогынты сиксәненче елларда аеруча күренде. Патша чиновниклары да моны танырга мәҗбүр булдылар.

Казан уку-укыту округы попечителе, реакционер П. Шестаков үзенең яшерен язмаларында бу турыда хәзерге көн өчен бик әһәмиятле хәбәр язып калдырган:

«Усал ниятле пропаганда, зыянлы идеяләрне әзлекле рәвештә таратып, күренгәнчә, көчле тәэсир ясый. Политик агитаторлар хөкүмәткә һәм дингә каршы идеяләрне ике юл белән: земство врачлары, земство акушеркалары... һәм авыл укытучылары аша халык массаларына җиткерәләр булса кирәк» [3].

Аны алыштырган икенче бер попечитель, ун ел үткәч, 1885 елда, Саратов губернасында яшәгән халыкны характерлап, министр Деляновка болай дип яза: «...Күптән түгел генә пропагандистлар массасы монда халыкка зарарлы йогынты ясаган...» Ул бу тирәдә миссионер мәктәпләре ачарга, аларда православие рухында дәресләр бирергә чакыра, «рус булмаган халыкларның христианча тәрбия күрмәве» турында чирканып яза [4].

1879—1881 елларда революцион ситуацияләр феодаль-крепостной дәүләт эчендәге каршылыкларны тагы да тирәнәйтте. Илдә капитализмның үсеше яңа социаль көч — пролетариат барлыкка килүне тәэмин итте. Буржуаз җитештерү мөнәсәбәтләренең милли өлкәләргә дә җәелүе, Россиядә яшәгән барлык халыкларның диярлек капиталистик мөнәсәбәтләргә тартылуы болай да катлаулы сыйнфый каршылыкларны тагы да кискенәйтте.

Революционерларга каршы репрессияләр көчәюенә, илдә хакимлек иткән ерткычларча реакциягә карамастан, сиксәненче елларда азатлык хәрәкәте тагы да киңрәк колач алды, бер-бер артлы марксистик түгәрәкләр, группалар барлыкка килә торды, рус булмаган милләтләр эченнән дә яңадан-яңа көрәшчеләр сафка басты.

Сиксәненче елларның беренче яртысында революцион демократлар милли мәсьәләдә яңа тенденцияләр күрделәр. 1881 елда Женевада белорус телендә «Байлык һәм ярлылык турында» дигән бер брошюра басылды. Аннары ул украин һәм молдаван телләрендә дә чыкты. Шул ук елны народник И. Н. Присецкийның хатына каршы П. Б. Аксельродның «Барысы да халык өчен, халыкның үз көче белән» дип исемләнгән җавабы дөнья күрде. Анда: Народниклар «милли бердәмлек» иллюзияләренә каршы бөтен көчне биреп көрәшергә һәм барлык иҗтимагый мәсьәләләрдә, политик реформа мәсьәләләрендә дә, иҗтимагый сыйныфлар арасындагы антагонизм турындагы фикерләрне истә тотып, тайпылышсыз рәвештә эш итәргә тиешләр, дип ачык әйтелгән иде.

Үзенең бу брошюрасында П. Б. Аксельрод төрле милләт кешеләрен көчләп чукындыру, мәктәпләрдә милли телдә сөйләшүне тыю фактларын китерә, изелгән милләтләр арасында революцион эш алып бару кирәк-

[1] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы. 89 ф. 1608 эш. 85 бит.

[2] ТАССРның Үзәк дәүләт архивы. 1 ф. 3 оп. 8250 эш. Ильяс Аитовның язмышы билгеле түгел. Мөгаен, аның токымнары, аларның туганнары бардыр. Аларның сүзләрен ишетәсе иде. (Автор.)

[3] Казан университеты китапханәсенең сирәк китаплар һәм кульязмалар фонды, 8150 эш. 47 бит.

[4] ТАССРның ҮДА. 92 ф. 1 оп. 16208 эш. 8 бит.

леген нигезли. Ул абсолютизмга каршы бергәләп көрәшүне яклап чыга һәм федератив республика, Россиядәге халыкларның тулы автономиясен булдыру идеяләрен пропагандаларга тәкъдим итә.

Шул ук вакытта ул бүтән милләт халыкларын наданлыкта гаепләүчеләргә, самодержавиегә каршы бергәләп көрәш мөмкинлеген инкарь итүчеләргә каршы чыга, политик һәм экономик таләпләр куйганда, урыннарда халыкның милли составына хас булган үзенчәлекләрне, аның хәлен истә тотарга чакыра. «Украинлыларга инде прокламацияләр белән мөрәҗәгать иттеләр, — ди ул, — ләкин Казан тирәсендәге татарлар да күптән түгел баш күтәрделәр»[1].

Аксельрод тарафыннан куелган милли мәсьәләләр, әлбәттә, революцион түгәрәкләрдә һәм марксистик «Хезмәтне азат итү» группасы членнары арасында тикшерелә. Бу брошюра Россиядә киң таралган була. Аның гектографта басылган данәләре революционерларны кулга алганда Казанда да табыла[2].

Казан университеты студентлары Петербургта яшерен рәвештә чыга торган «Студенчество» журналын даими укып баралар, бу журналга үзләре дә язалар. 1883 елда журнал редакциясе үзенең укучыларына «Коммунистлар партиясе манифесты»н һәм «Франциядә гражданнар сугышы» китабын укырга тәкъдим итә.

Журналда Казан студентларының хәлләре, Казан губернасындагы крестьяннар тормышы, Спасс өязеннән Себергә күчеп китәргә мәҗбүр булган крестьяннар турындагы материаллар басылып чыга.

1882—83 елларда Казанда танылган революционер Феофан Крылов (Алексей Воскресенский) яши. Тентү вакытында анардан Марк Кавказский дигән авторның патша хөкүмәтенең Урта Азиядә, Украинада, Польшада, Грузиядә, Әфганстанда үткәрә торган колониаль политикасын фаш иткән кульязмасын табалар[3].

Идел буенда һәм Уралда яшәүче халыкларга караган милли мәсьәләләр Казан университеты профессоры Н. Загоскин чыгара торган «Волжский Вестник» газетасында да еш яктыртыла. Бу газета яшерен революцион оешма белән тыгыз бәйләнештә була.

«Волжский Вестник» газетасының студентларга һәм урта уку йортларында укучыларга йогынтысы зур була. Аны Ульяновлар семьясы да алдыра, атаклы революционер Н. Е. Федосеев, пекарня эшчесе А. М. Пешков укый. Бу газета редакциясендә 70—80 елларның күренекле революционеры, Н. Е. Федосеевның дусты П. А. Голубев[4] эшли. Шулай ук А. П. Досенова да газетаның актив хезмәткәре була. Архив документларыннан күренгәнчә, шушы газета хезмәткәре буларак, ул Польша революционерлары, «Пролетариат» группасы членнары белән элемтәдә тора[5]. Җирле властьлар аның укучы яшьләргә «зыянлы» йогынтысы турында язалар, Казаннан куылуын таләп итәләр.

«Волжский Вестник» тирәсенә Казандагы студентлар активы туплана. 1887 елның 4 декабрендә университет студентлары сходкасында катнашкан Вышенский, Дударь һ. б. лар редакция белән тыгыз бәйләнештә булалар. Редакция шулай ук сходкада катнашканнары өчен университеттан куылган студентларга материаль һәм мораль ярдәм күрсәтә, аларның әдәби әсәрләрен бастырып чыгара.

«Волжский Вестник»ка актив катнашучы студентлар «Социаль-революцион җәмгыять» дигән түгәрәккә дә йөриләр. Бу түгәрәк Россиядәге күп кенә революцион группалар белән бәйләнештә тора.

Шунысы да кызыклы, Александр Ильич Ульяновның классташы һәм фикердәше В. М. Бурлаков та бу түгәрәкнең члены була. Түгәрәктә В. И. Ленинның туганнан туган абыйсы М. А. Пономарев та аның белән бергә эш алып бара. Казан губерна жандарм идарәсенең таләбе буенча, ул 1885 елның январенда Пермьдә кулга алына.

Бертуган Н. һәм В. Кларклар, татар студенты С. Моратов, егерме яшьлек татар кызы Гөлсем Алкина да түгәрәк членнары булалар. 1882 елда ук сходкаларга актив катнашканы өчен Мәскәү университетыннан куылган С. Моратов К. Маркс һәм Ф. Энгельсның дусты, күренекле революционер Герман Лопатин белән якын бәйләнештә була.

С. Моратов, яшерен түгәрәкнең икенче бер члены Н. Каташ белән бергә, 1884 елның 24 октябрендә кулга алына һәм бер айга якын төрмәдә утырып чыга.

Гөлсем Алкина булачак бөек язучы Алексей Пешков белән дә дусларча мөнәсәбәттә була.

1889 елда Н. Новгородта А. М. Горькийны кулга алу вакытында төзелгән танышлары исемлегендә Гөлсем Алкина фамилиясе дә күрсәтелгән. Алексей Максимовичка соңыннан аның фоторәсеме кайтарып бирелми[6].

В. И. Ленинның туганнан туган апасы врач Анна Ивановна Веретенникова турында «Волжский Вестник» болай дип яза: «Ул барлык ярлыларны да түләүсез дәвалый, алай гына да түгел, үзенең материаль

---

[1] Гайнетдинов Хөснетдин һәм Гыйсмәтуллин Фәйзулла дигән крестьяннар 1878 елда авылдашларын котырту, властька буйсынмаулары һәм салымнарын түләмәүләре өчен туган җирләреннән куыла. Казан губернасында мондый куылган крестьяннар күп була. Биредә сүз шулар турында бара.

[2] ТАССРның УДА. 51 ф. 8 оп. 108 эш.

[3] Шунда ук. 199 ф. 1 оп. 3725 эш.

[4] ТАССР УДА. 92. 1 оп. 17297 эш. 11 бит. П. А. Голубев элегрәк Четвергова белән бер түгәрәктә була. Соңыннан Четвергова белән В. И. Ленин бик озаклап Казандагы яшерен оешманың эше турында сөйләшеп утыра.

[5] Шунда ук. 199 ф. 1 оп. 3726 эш. 52, 72 битләр.

[6] «Былое». 1921 ел. № 16, 182, 184 битләр.

хәле бик чамалы булуга карамастан, хәтта үзе дә аларга ярдәм итә иде... Казан шәһәрендә татар ярлылары да үзләрен дәвалаган, укырга-язарга өйрәткән Анна Ивановнаны озак вакытлар исләрендә саклардар»[1].

Моңа өстәп шуны да әйтергә кирәк: А. И. Веретенникова сиксәненче еллар башында Уфа губернасының Бәләбәй өязендә дә татарлар һәм башкортлар арасында эшли һәм анда да хезмәт ияләренең мәхәббәтен казана. Өч ай эчендә ул татар телен шундый өйрәнеп җиткерә, сөйләшү генә түгел, хәтта укый һәм яза да ала[2]. Замандашлары аның татарлар һәм башкортлар арасындагы эшчәнлеге турында түбәндәгечә язып калдырганнар: «...Татар һәм башкорт халыклары арасында ул медицина өлкәсендәге иң популяр акыл ияләре дә ирешмәгән зур хөрмәт яулап алды... Ул аларның һәрберсе өендә кадерле кунак иде. Аңардан авыл кешеләре юл йөрткән өчен, азык-төлек өчен акча алуны да гөнаһ санадылар... Аның квартирасы һәрвакыт татар, башкорт хатын-кызлары, ирләре белән тулы була иде. Авырганга гына түгел, кайгы-хәсрәтләрен бүлешергә дә аның янына киләләр иде, чөнки алар үз врачларының кешелеклегенә чын күңелләреннән ышанганнар иде»[3].

Ул Земство җыелышларында, утырышларында гел ярлылар интересын яклый торган булган, шуңа күрә аңа алпавытлар, кулаклар үч саклап йөргәннәр.

Билгеле булганча, А. И. Веретенникова белән И. Н. Ульянов та гәпләшеп утырырга бик яраткан. В. И. Ленинның абыйсы Александр Ильич та аны бик хөрмәт иткән. Әлбәттә, В. И. Ленин да аның татарлар һәм башкортлар арасындагы эше турында сөйләгәннәрен тыңлагандыр. Чөнки А. И. Веретенникова авырып ятканда 1888 елда Владимир Ильич та Кокушкинода була.

Документаль материалларда, архив чыганакларында халыкларның патша хөкүмәтенә каршы бергәләп көрәшүе турында бик кызыклы фактлар табылып тора. Алар барысы да Россиядәге азатлык хәрәкәтенең зур традицияләрен яктырталар.

Әлек кул тимәгән чыганакларны, «Волжский Вестник» газетасының цензура гранкаларын җентекләп тикшерү, — моңа нык ышанып әйтергә була, — Н. И. Ульяновның, А. И. Веретенникованың иҗади хезмәтләрен, татар хезмәт ияләре арасындагы эшчәнлекләрен, А. М. Горькийның узган гасырның сиксәненче елларында ук татар эшлекләре белән бәйләнешен тагы да киңрәк өйрәнергә мөмкинлек бирәчәк.

[1] «Волжский Вестник». № 191. 1888 ел. 31 июль.

[2] «Русское богатство». 1888 ел, август саны. 190 бит.

[3] Шунда ук.

П ◇ П

# ӘЛИШЕР НӘВОИНЫҢ ТУУЫНА 525 ЕЛ



*Үзбәк халкының бөек шагыйре Әлишер Нәвоиның туусына быел 525 ел тула. Татар укучылары аның «Фәрһад һәм Ширин», «Ләйлә һәм Мәҗнүн» кебек поэмалары, күп санлы газәлләре белән борынгы заманнардан бирле якыннан таныш. Аның «Фәрһад һәм Ширин» поэмасы 1948 елда татарчага тәрҗемә ителеп, аерым китап булып басылып чыккан иде. Журналыбызның бу санында без Әлишер Нәвоиның шагыйрь Әхмәт Исхак тарафыннан тәрҗемә ителгән кайбер газәл һәм шигырьләрен урнаштырабыз.*

●

Бик күп аһ орсам, булыр бик тиз йөрәкнең каны фаш,
Уйлагач сине, гаҗәпме, акса күздән канлы яшь?

И гүзәл, бу ташны син, сабыйлар аткан таш, димә,
Яудыра һәр көнне язмыш мин юләргә шундый таш.

Күктәге кояш чагылгандай суда, нурлы йөзең
Чагыла су төсле күктә, и чибәр, булып кояш.

Син җыенмыйсың икән ауларга күңлемнең кошын,
Ник колач ачкан, алайса, ике якка ике каш?

Баш иясең нигә ул потка, диләр, исәм сиңа,
Кыйблага башым ияргә миндә юк бит ике баш!

Мин явыз күк төсле, дөньяны йотарга уйламыйм,
Пешмәгән бер ярма да булыр миңа тәүлеклек аш.

Күңлен ауларга Нәвоиның талаша күп гүзәл,
Җир өчен шаһлар алып барган кебек сугыш-талаш.

●

Дусларым яшерен яга торган яланы нишләтим?
Күп кеше шуңар инана, бу бәлане нишләтим?

Йөз җәфа илдән күреп тә, ул — җәфалаучы, диеп,
Илдә мин алдым үзем ат, бу җәфаны нишләтим?

Һәр минут канымны фаш итә хыянәтче күзем,
Әйтче, күңлем, инде ул йөзе караны нишләтим?

Булса күңлендә яра, бик тиз дәвалый яр, диләр,
Юк минем ярым, дәвасыз ул яраны нишләтим?

Йөз вәфа күрсәтсәм илгә, күрсәтә ул мең җәфа,
Тәңремә әйтми бу хәлне, ялгыз аны нишләтим?

Әй Навои, һәр сулыш күрсәң илеңнән тик җәза,
Китмичә ташлап ул илне, бу җәзаны нишләтим?

●

Гыйшыкта кемгә дә сердәш була алмас падишаһлар,
Алар йөз елда да чөнки бу дәртне аңлый алмаслар.

Тик аңлаудан ни файда бар? Гыйшык илендә тиң чөнки
Тузанда аунаган ярлы белән тиңсез бөек шаһлар.

Гаҗәпме, шаһ гыйшыкта миннән артыграк газап чиксә?
Аның бәхте — тәхет, байлык, минем бәхтем — газап, аһ-зар.

Ни дәхле бар мәхәббәт һәм гыйшык урамына шаһның?
Түгә канлы яшь анда сап-сары йөзләр, орып аһлар.

Сөйгәнен кол итәргә уйласа шаһ, бу — гыйшык булмас,
Гашыйклар үзләре коллык итәр ярга, иеп башлар...

Навои, зарлана күрмә, гыйшыкта ярлы булсаң син,
Биреп тәхтен дә шаһлар мондый байлык алмаслар.

●

Ярдан аерылса әгәр гашыйк, елар зар, дусларым,
Зар елыйм, чөнки янымда юк минем яр, дусларым.

Бирмәгез үгет, ярыңны әйтмә, дип, беркемгә дә,
Аһ, ник әйтим булмаганны, ул, диеп, бар, дусларым!

Шул минем гыйшкым, диеп, юкны сөйләп ант итмиләр,
Кем ышаныр, бирсә бер кем шундый антлар, дусларым?

Хурламагыз, беркемең юк, дип, минем дә бар иде
Назлы ярым, атта җилгән дәртле чаклар, дусларым.

Яшь түгәм ялгыз хәрабәдә, ә сез ярлар белән
Уйнагыз гөлбакчада назлы уеннар, дусларым.

Аһ-зарым чиктән ашып, кан егъласам, гаеп итмәгез,
Ихтыярсыздан ага күздән бу каннар, дусларым.

Җаныма кулын суза еш-еш гыйшыкның махмыры,
Яр белән чөкәшегез сез тулы җамнар, дусларым.

Эчегез мәй, бу җиһанда күпме эзләп тапмадым,
Биргән антын бозмый торган тугры ярлар, дусларым.

Каушуның кадрен белегез, аһ, Нәвои бичара
Ялгыз үлә, шундый каушуга булып зар, дусларым.

●

Тиле күңлем минем бичара булды,
Бәлаләр чүленә әүвара булды.

Шушы чүлдә явып таш өстенә таш,
Бөтен җирендә канлы яра булды.

Ора торгач башымны шунда ташка,
Сөякләр бар да парә-парә булды.

Еәла тавында мин ятканда һушсыз,
Акыл баштан очып, шул тауга кунды.

Кара кылса бу дөнья язмышымны,
Аның үз язмышы да кара булды.

Касәмә кем салыр ширбәт, дигәндә,
Күземнең яшьләре касәмә тулды.

Чара эзләмә хәсрәттән, Нәвои,
Сиңа шул чарасызлык чара булды!

●

Горурлыгың ташытма, мин матур, диеп,
Кыйммәтле тире һәм ефәк кием киеп.
Каурый һәм йоны матурлык аркасында
Һәлак булды ауда күпме кош һәм киек!

●

Юлдан язды күпме хезмәткәр, күзең йомганга син,
Шаһмы син, я ярлымы, моннан зыян күрде эшең.
Күпме оста юлчыларның чыкты юлдан арбасы,
Бер минутка онтылып, юлдан күзен алган өчен!
Күпме җәнлек килде аһ-ваһ, күрмичә ауга кереп,
Аһ ора бик еш кеше дә шундый җәнлекләр кебек.

●

Тәмуг белән куркытма син, суфи, мине әрләп,
Миңа — җәннәт, сиңа — тәмуг, димә, мине җәлләп.
Ярымны уйласам, җәннәткә әйләнер тәмуг,
Сине күрү белән, тәмугка әйләнер җәннәт!

●

Каннан артык сөям, газиз гомер, сине,
Җаннан артык сөям, газиз гомер, сине,
Бар нәрсәдән артык сөеп булса нине,
Аннан артык сөям, газиз гомер, сине.

# «КАРА ЧӘЧКӘЛӘР»

Китапны кулга алу белән, гадәттә, аның кем әсәре булуы белән кызыксынасың. Бу юлы да шулай «Кара чәчәкләр»[1] романын күргәч, моны кем язды икән дип, авторның исеменә күз төшердем. Сахиб Җамал. Бу исем, ничектер, таныш тоелды. Каян беләм соң әле мин аны? Уйлый торгач, үзебезнең академия театрында куелган «Фатыйма Сабри» искә төште. Шул көчле драманың авторы бит әле ул Сахиб Җамал! Менә хәзер татар телендә аның «Кара чәчәкләр» романы басылып чыккан.

Әсәрнең беренче юллары, беренче битләре кай ягы беләндер гүзәл әкиятләрне хәтерләтә. «Әфганстан — биек таулар, шау чәчәкле бакчалар, кара чатыр корып яшәүче күчмә кабиләләр иле ул», дип ашыкмыйча, җай гына хикәяли башлый автор. Һәм укучы күкләргә ашып утырган таулар арасында, камыш курайлар уйнап, күченеп баручы бәдәвиләр кәрваны артыннан ияреп китүен сизми дә кала. Менә алар, бер җирдә туктап, чатырларын корып җибәрәләр. Шунда ук учаклар ягыла, казаннар асыла...

Әнә шул кара чатырларның берсендә моннан егерме ел элек бер малай дөньяга килгән. Әтисе Динмөхәммәт үзенең бердәнбер баласына, зур өмет баглап, Надир[2] дип исем кушкан. Малай таза-сәламәт, кыю булып, тау чәчәгедәй чыдам булып үсә. Байлыклары булмаса да, барына канәгать булып, бәхетле генә яшәгәндә, гаилә өстенә авыр кайгы килә: Надирның әтисен агулы елан чага. Романдагы вакыйгалар әнә шул фаҗигале үлемнән башланып китә.

Карты үлгәннән соң, малайның әнисе Биби чит-ят ир-ат белән күченеп йөрүне яхшысынмый, туып үскән авылы Ләгманга кайтырга була. Әмма туган авылың булу гына җитми, анда сагынып көткән туган-тумачаң яисә ачык чырай белән каршы алырдай дус-ишең булсын икән. Ләгман урамына килеп кергәч үк, Биби белән Надир шул ачы хакыйкатьне аңлыйлар. Ярый әле: Динмөхәммәт белән Бибинең яшьлек дуслары Сәет исән икән. Ул Бибиләрне үз куышының бер почмагына сыендыра, аларның икесенә дә эш табуда булыша.

Тик иркендә үскән Надир гына авыл тормышына күнегә алмый. Ул, бер генә көн дә тормас, яңадан бәдәвиләр янына китәр иде. Ләкин ана хәтере дигән нәрсә бар. Аннан соң, беренче күрүдән диярлек, ул Сәет бабаның сукыр кызы Җамалга гашыйк була. Нинди генә каршылыкларга очрамый, нинди генә сынаулар үтми ике яшь йөрәкнең керсез, саф мәхәббәте!..

Романның тәрҗемәсе дә әйбәт эшләнгән. Т. Нурмөхәммәтов моңарчы басылып чыккан тәрҗемәләре (А. Рыбаковның «Хәнҗәр», «Бакыр кош» повестьлары, Ю. Томинның «Алмаз сукмаклар» дигән хикәяләре һ. б.) белән үк бу өлкәдә эзләнеп, уйлап, җитди эшләүче иптәш икәнен күрсәткән иде инде. «Кара чәчәкләр» дә ана телендәге әсәр төсле яңгырый, җиңел укыла.

«Төн кәрван адымыннан да акрынрак үтә кебек тоелды. Әгәр кулыннан килсә, төн пәрдәсен кулы белән генә ачып таң аттырыр иде ул». (17 бит.)

«Кызының бәхете хакында аның үз фикере бар: Җамал кагарга казыгы, ашарга азыгы булмаган бәдәвигә чыкса, гомерен суган суы суырып үткәрәчәк». (62 бит.) Мондый уңышлы һәм матур җөмләләрне байтак китерергә булыр иде. Тагын бер җөмләгә игътибар итегез:

---

[1] С. Җамал. Кара чәчкәләр. Роман. Т. Нурмөхәметов тәрҗемәсе. Казан. 1967 ел.

[2] Надир — сирәк очрый торган, күтеп алынган, тансык.

«— Эти, бүген җомга көн бит, бераз сулу алсаң иде, ичмасам». Гадәттәге «ял итсәң» урынына тәрҗемәче сирәк кулланыла торган, ләкин саф татарча «сулу алсаң» тезмәсен тапкан.

Тәрҗемәдә, бигрәк тә аерым кешеләрнең сөйләм телендә, табип, мәслихәтче, хаким, җефет, мадәт кебек гарәп-фарсы сүзләре шактый гына. Алар теге яки бу персонажны ачыграк күз алдына китерергә, әсәрнең рухын яхшырак аңларга ярдәм итәләр. Әмма хәзерге буын укучылары ул сүзләрнең күбесен аңламый бит. Шуны искә алып, аларның барсына да аңлатма бирү кирәк иде. Хәлбуки, китапта нибары дүрт-биш сүзгә генә аңлатма бирелгән.

Бер-ике урында «сыр пешерү» дигән тәгъбир бар. Аны «сыр кайнату» дию яхшырак булмас иде микән? Ә бәлки, «корт кайнату» дияргә үк кирәктер?

Без кайчакта, оригиналга ияреп, «милый мой»ны «сөеклем минем», «мой дорогой»ны «кадерлем минем» дип тәрҗемә итүебезне үзебез дә сизми калабыз. «Кара чәчкәләр»дә дә бер-ике җирдә шул хәлне күрәбез. (38 бит һәм 73 бит.) Андый очракта «минем» сүзенең артык икәнен аңлатып торуның кирәге юктыр дип уйлым.

Аннан соң русчадагы «жизнь» сүзен һәр очракта да «тормыш» дип тәрҗемә итү дөрес булмавы турында инде күп әйтелде. Бу кимчелек тә әле һаман бетеп җитми. Т. Нурмөхәметов: «Мин аңа үз күземне, үземнең тормышымны бирәм»; «Мин сөеклемнең бәхете, аның тынычлыгы өчен тормышымны кызганмаячакмын», дип яза. Кызганычка каршы, мондый хәлне тәрҗемәләрдә генә түгел, оригинал әсәрләрдә дә очратырга була. Шуңа күрә бу хакта тагын бер тапкыр сүз кузгатмый булмый.

«Жизнь» сүзен татарча **гомер** (озын гомер телим), **яшәү** (яшәү белән үлем арасында), **җан** (җанын бирергә әзер), **тереклек** (яз якынлашу белән үсемлекләрдә тереклек әсәре күренде) дип тә һәм, ниһаять, **тормыш** дип тә тәрҗемә итәргә була. Биредә күрсәтелгән синонимнарның бишесе дә рус телендәге «жизнь» төшенчәсенә туры килә. Ләкин аларның һәркайсын үз урнында куллана белергә кирәк. Озын **тормыш** дип әйтү килешмәгән кебек, бай **гомер** дию дә уңышлы булмас иде. Халык әнә: «Гомерем үтте, ирем бер үпте, анда да каенанам күреп сүкте», ди. «Үткән гомер, калган хәтер, сатып алыйм дисәң табылмый» дигән җыр да бар. Безнең тел байлыгын раслый торган мондый мисалларны әллә ни чаклы китерергә була. Мәсәлән, рус телендәге «толстый» сүзен без, урнына карап, **юан, калын, симез** дип тә тәрҗемә итә алабыз. «Тонкий» төшенчәсенә туры килә торган сүзләрнең синонимнары да берничә (нәзек, юка, нечкә, һ. б.).

Тел байлыгыннан оста файдалана белмәү бер нәрсә, ләкин кайчакта күрәләтә телебезне ярлыландыру юлына басабыз. Соңгы елларда тәрҗемәләрдә һәм оргинал әсәрләрдә дә **күкрәк баласы, күкрәк сөте** кебек тезмәләр очратырга мөмкин. (Шуңа күрә Т. Нурмөхәметовның: «Аны тапкан да, күкрәк сөтен имезеп үстергән дә шул сөекле әнисе бит инде», дип язуы һич гаҗәп түгел.) Ә менә телебездәге **имчәк баласы, ими сөте** дигән төгәл гыйбарә бөтенләй юкка чыгып бара диярлек. Ни өчен? Берәрсенең күңеленә охшамаганмы алар? Әллә берәрсе аларны әдәпсез сүзгә санаганмы? Белмим. Ләкин **күкрәк баласы, күкрәк сөте** дип әйтү мәгънә ягыннан да дөрес түгел бит. Мондый логика буенча фикер йөртсәк, **сыер күкрәге** дияргә тиеш булабыз түгелме?..

Ярый яңадан «Кара чәчкәләр»гә кайтыйк. 118 биттә: «Алдында китап янчыгын күтәргән мәктәп малаен күргәч, сөенеп куйды», дигән җөмлә бар. Аны: «Китап букчасы тоткан мәктәп малаен күргәч», дип бирү дөресрәк булыр иде шикелле. Тагын шуны әйтергә кирәк, «скромный человек» сүзен **тыйнак кеше** дип тәрҗемә итү урынлы булса да, «скромный подарок»ны **тыйнак бүләк** дип әйтеп булмый. Гомумән «скромный» сүзен урнына карап төрле очракта төрлечә тәрҗемә итәргә туры килә. Тагы бер мәсьәлә. Без үзбәк, казакъ, кыргыз телендәге китапларны турыдан-туры тәрҗемә итә алсак та, төрек, гарәп һәм башка халыкларның әсәрләрен оригиналдан тәрҗемә итә алырдай кешеләребез юк диярлек. Шуңа күрә андый чакта безгә кирәкле әсәрнең русча тексты белән эш итәргә туры килә. Һәм бу нәрсә тәрҗемәченең эшен тагын да катлауландыра, аның аеруча игътибарлы булуын таләп итә. Иң әүвәл исемнәрдә абынырга мөмкин. Гумерның Гомәр икәнен аңлау читен булмаса да, русча текстта Бахор яисә Багар дип бирелгән исемнең оригиналда ничек язылган булуын, ничек яңгыравын белер өчен бераз уйланырга туры килә. Чөнки аның Бәһәр булуы дәррәү генә башка килми. Ярый, исемнәр бер хәл әле. Шул ук Сахиб Җамалның «Фатыйма Сабри» драмасын рус-

чага тәрҗемә итүче иптәш «өмме» (ана) сүзен шул килеш бирергә уйлаган. Ләкин рус алфавитында кайбер хәрефләр җитмәү аркасында, гарәпчә сүзнең язылышы «умма» булып чыккан. Драманы татарчага тәрҗемә иткәндә дә әлеге сүз «умма» рәвешендә алынган. (Өммегөлсем, Өмменисалар да искә төшмәгән ичмаса). Һәм Академия театрында әлеге драманы караганда, күп кенә тамашачылар бу нинди сүз икән дип баш ватып утырдылар. Ул сүзне татарчада «ана» дип кенә бирү яхшырак булмас иде микән? Югыйсә, артист дөрес итеп, «өмме» дип сөйләгәндә дә, сүз матур яңгырамый бит. Аннан, әгәр ялгышып, артист «өмми» дип куйса, мәгънә бөтенләй үзгәрә, ана диясе урынга надан килеп чыга. Гомумән, без гарәп-фарсы сүзләре белән саксыз эш итәбез. «Казан утлары» журналы берничә мәртәбә «нашир» (бастырып чыгаручы, издатель) сүзен «нәшер» (басма, издание) белән бутап бирде. Беренче тапкыр очратканда, мин моны мәтбагә хатасы дип кенә уйлаган идем. Күпмедер вакыттан соң, журнал шул ук хатаны тагын кабатлады.

Ярар, сүз уңаендагы сүзләр озынга китте бугай. «Кара чәч кәләр» романының тәрҗемәсе турындагы фикерләрне йомгаклап, иптәш Нурмөхәмәтовның тырышып эшләве бушка китмәгән диясе килә. Китап яхшы булып чыккан. Югарыда телгә алынган кайбер кимчелекләр китапның икенче басмасында төзәтелер, билгеле. Ә ул икенче басманы озак көтәргә туры килмәстер кебек күренә. Чөнки укучы күңеленә ошаган ул роман.

**СӘРВӘР ӘДҺӘМОВА.**

# «ЯЛГЫЗ ҖИЛКӘН» ПОВЕСТЕНЫҢ ТӘРҖЕМӘСЕ

Дөнья һәм рус әдәбиятының иң яхшы үрнәкләрен халкыбызга җиткерү кебек авыр һәм мактаулы бурыч тәрҗемәчеләр җилкәсенә төшә. Соңгы елларда үсеп чыккан тәрҗемәчеләребез укучыларның зәвыгын тәрбияләүдә күп хезмәт куялар һәм шуның белән бергә әдәби тәрҗемә практикабызны яңа алымнар белән баеталар.

В. Шишковның К. Миңлебаев тарафыннан тәрҗемә ителгән «Хәсрәт дәрьясы» романын укучылар җылы кабул итте. Г. Ахуновның «Казан утлары» журналында (1965 ел. 12 сан) чыккан рецензиясендә бу тәрҗемә турында шактый матур, уңай фикерләр әйтелде. Танылган рус совет язучысы В. Катаевның «Ялгыз җилкән» повесте[1] да татар укучысына К. Миңлебаев тәрҗемәсендә җиткерелде.

Бу — матур, сыгылмалы тел, җиңелчә юмор белән язылган, һәртөрле маҗаралларга бай повесть. Әсәрне балалар гына түгел, зурлар да кызыксынып укырлык. «Ялгыз җилкән»... Бу исем артында әллә нинди серле, маҗаралы вакыйгалар яшеренеп торадыр сыман. Һәм укучы алданмый. Рус-япон сугышы, броненосец «Потемкин» вакыйгалары, патша манифесты, аннан соң илдә тагын да көчлерәк кабынып киткән чуалышлар — һәммәсе дә китаптагы олы һәм нәни геройларның көндәлек тормышында чагылган. Повестьны укыгач, язучының балалар психологиясен, аларның телен гаҗәеп яхшы белүенә, илнең зур вакыйгаларын бала образлары белән оста бәйли алуына сокланмый мөмкин түгел. Син гомереңдә дә күрмәгән малайлар — Гаврик һәм Петялар белән очрашасың, алар сиңа бик тә якын, үз кешеләр булып китәләр, аларны яратасың, язмышлары өчен борчыласың.

Оригиналдагы шушы тәэсир татар укучысына ничек җиткерелгән соң? Алдан ук әйтеп куясым килә: тәрҗемәче әсәрдәге тормыш сулышын, революцион романтиканы татар укучыларына җиткерү өчен күп эшләгән, нык тырышкан. Һәм шуның нәтиҗәсендә повесть татарча язылган әсәр кебек җиңел укыла. Шактый озын, катлаулы җөмләләр дә саф татарча матур, табигый яңгырыйлар. Бер генә мисал китерик:

«Баш күтәрүнең беренче минутыннан алып, — броненосец командирының өметсезлеккә бирелеп, команда алдында тезләнүеннән, беренче мылтык залпларыннан соң кайбер офицерларның мәетләре диңгезгә очканнан алып, аңарчы турысыннан

[1] В. Катаев. Ялгыз җилкән. К. Миңлебаев тәрҗемәсе. Казан. 1965 ел.

узарга һәркемнең коты чыгып торган каютаның, адмирал каютасының ишеген матрос Матюшенко шатырдатып кубарып ташлаганнан алып, Родион Жуков, бүтән матрослар кебек үк, күтәренке күңел белән, бераз һаваланып яшәде. Һәм бу хәл, румыннар кулына бирелеп, Констанцада броненосецтан төшкәнче дәвам итте»[1] (93 бит.)

«Когда с треском отодрал дверь» татарчага «шатырдатып кубарып алганнан соң» дип матур тәрҗемә ителгән, кискен хәрәкәтне белдерү өчен, тәрҗемәче фигыльләр сайлауда шактый зур осталык күрсәткән. «В легком тумане» тезмәсенең «бераз һаваланып» дип бирелүен дә уңышлы санарга кирәк.

Китапның төп геройлары турында берничә сүз әйтәсе килә. Иң элек шул: Петя белән Гаврик укучы күз алдына, оригиналдагы төсле үк, тере, җитез, кызыксынучан, фантазиягә бай малайлар булып килеп басалар. Аларны сурәтләүдәге җиңелчә юмор да тәрҗемә телендә шактый тулы сакланган.

Гаврик — чын мәгънәсендә диңгез малае. Ул «яр буенда шаландалар янына ятып, баш астына шоп-шома диңгез ташы салып» йоклый. Иркен тормышлы укытучы гаиләсендә тәрбияләнгән Петяга моны беркайчан да рөхсәт итмәсләр иде. Бар эштә дә зурларга, бабасына охшарга тырышкан Гаврик турындагы менә бу юлларны укыганда елмаймый түзеп булмый: «Картлач тамагын кырып куйды, Гаврик та тамак кырды. Бабасы чалбар каешын тарта төште, оныгы да шуны ук кабатлады». (65 бит.)

Кечкенә булсалар да, малайлар илдәге зур вакыйгалардан читтә калмыйлар: күп мәртәбәләр качкын матрос Родион Жуков белән очрашалар, әллә ничә тапкыр аны үлемнән коткарып калуда булышалар. Матросны яшереп саклаган өчен, Гаврикка полицейскийлар тарафыннан кыйналырга да, бабасын төрмәгә утырткач, ялгыз торырга да туры килә. Куркусыз мәни герой комитет члennары арасында элемтәче хезмәтен дә үти, камалышта калган отряд штабына патрон да ташый. Һәр бала белә торган нәни патриот Гаврошны хәтерләтүче бу үткен һәм зурларча җитди малайны укучы бик яратыр, аңарга охшарга тырышыр дип уйлыйсың.

Вакыйгалар барышында Петяның характеры үзгәрә баруы, тормыш турындагы беркатлы фикерләренең җимерелүе тәрҗемәдә дә ышандырырлык бирелгән. Гаврик белән шәһәрнең бик күп урыннарында, эшче бистәләрендә, полиция участогында (алар анда Гаврикның бабасын күрергә баралар) булганнан, көннән-көн көчәя барган чуалышларны, еврейләргә каршы оештырылган коточкыч погромнарны күргәннән соң, моңарчы Россияне иң бөек ил, патшаны иң изге кеше дип йөргән беркатлы гимназист Петя төн буе уйланып ята:

«Россия бичара икән. Әтидән башка да асыл кешеләр бар икән, алар сөргендә интегәләр икән. Патша аңгыра, исерек баш икән... Әле алай гына да түгел, министрлар, генераллар барысы-барысы булдыксыз, адәм актыклары икән... Юк, тормыш дигәнең әле берничә көн элек кенә күренгәнчә үк күңелле, тәти, рәхәт бернәрсә түгел икән шул!» (182 бит.)

Революцион күтәрелеш чорында Петя гади бер күзәтче генә булып калмый, акрынлап аның зиһене-күзе ачыла, һәм әсәрнең азагында ул эшчеләр маевкасында катнаша.

Китапның тагын бер үзенчәлеге — «җилкән» образының әсәрнең буеннан-буена сузылуы, геройларны күзгә күренмәс җепләр белән бер-берсенә бәйләве. Җилкәнле корабка Петя башаягы белән гашыйк; Гаврик һәм аның бабасы җилкәнле шаланда турында хыялланалар. Ләкин бабай, хыялын тормышка ашыра алмыйча, үлеп китә. Җилкәнне, соңга калып булса да, Терентий алып кайта; җилкәнле көймә матросны тагын бер тапкыр үлемнән — төрмәдән коткара. Гаврик белән Петя аны күздән югалганчы озатып калалар.

«Шаланда сикерә-сикерә, дулкын ярып, зур тизлек белән диңгезгә эчкәре кереп бара, диңгез бик нык шадраланып, ачык зәңгәр булып күренә иде.

— Бер ялгызы китте, — дип куйды Петя.

[1] Оригиналы: «С первой минуты, с той самой минуты, когда командир броненосца в ужасе и отчаянии бросился на колени перед командой, когда раздались первые винтовочные залпы и трупы некоторых офицеров налетели за борт, когда матрос Матюшенко с треском отодрал дверь адмиральской каюты, той самой каюты, мимо которой до сих пор страшно даже было проходить, с той самой минуты Родион Жуков жил, думал и действовал так же, как и большинство матросов, — в легком тумане, восторге, в жару, пока не пришлось сдаться румынам и высадиться в Констанце».

«...Ап-ак җилкән, бабаларының шаландасына куелган акчарлактай җиңел җилкән, диңгезнең томаланып торган күгелҗем офыгына кереп югала, күздән яза бара иде.

...Баш өстендә аның якты кояш,
Нурларында уйный ак күбек.
Тик ул, бунтарь, һаман давыл сорый,
Давылларда тынгы бар кебек» (273—274 битләр).

Менә кем икән ул «Ялгыз җилкән»!

Китапның шушы урнында Гавриклар, Петялар белән саубуллашабыз, куркусыз матросыбызны бер үзен очсыз-кырыйсыз зәңгәр диңгезгә чыгарып җибәрәбез. Хәер, хәзергә ялгыз булса да, аның баш өстендә якты кояш, алдында давыллы вакыйгалар — революция. Әсәрдән Гаврик, Петя белән дә, матрос белән дә әле очрашырбыз дигән өмет белән аерыласың.

Китаптан алган гомуми тәэсирләр менә шундый. Аерым сүзләрне, тезмәләрне бирүдә дә татар теленең үзенчәлекләреннән, мөмкинлекләреннән оста файдаланылган. Мәсәлән, «Сегодня дедушке и внуку предстояло много дела» дигән җөмлә: «Бүгенгесе көндә бабай белән оныкның эшлисе эшләре баштан ашкан иде», дип тәрҗемә ителгән. Бабай белән оныкның эше күп иде генә түгел, баштан ашкан иде. «Матрос не ответил» да «Матрос дәшмәде» дип кенә түгел, ә «Матрос ак та димәде, кара да димәде», дип бик матур бирелгән.

Шул ук вакытта тәрҗемәдә балаларга гына түгел, хәтта зурларга да аңлашылып җитми торган аерым урыннар да очрый. Мәсәлән, «не дрейфь» сүзен «шелләмә» дип биргәнче, «курыкма» яки «котың очмасын»; «раньше обыкновенного»ны «ялангыдан иртәрәк» дип тәрҗемә иткәнче, «көндәгедән» яки «гадәттәгедән иртәрәк» дип бирсәң, мәгънә дә, җөмләнең матурлыгы да бозылмас иде. Кайбер урыннарда «муар», «мантелье», «сочильник», «шпалер», «самодур» кебек тәрҗемәсе дә, аңлатмасы да булмаган сүзләр очрый.

Билгеле булганча, һәр телнең үзенә генә хас үзенчәлекләре була. Татар теле исә үзендә сыйфат фигыльле әйләнмәләрнең күп кулланылуы белән аерылып тора. Әммә аларны кирәгеннән артык куллану стильдә бертөрлелеккә китерер иде. Сыйфат фигыльле әйләнмәләрне татар телендә бирүнең күп кенә башка юллары да бар икән. Менә шул мөмкинлекләрдән оста файдалану хакында сөйли торган берничә мисал:

«Между тем, на степных дорогах появились отряды конных стражников, высланных к границе Румынии на поимку беглых потемкинцев» дигән җөмләне К. Миңлебаев: «Ул арада дала юлларында атлы стражниклар күренде: алар качкын потемкинчыларны тоту нияте белән Румыния чигенә баралар иде», дип тәрҗемә иткән. Күрәсез, җөмлә ике өлешкә бүленгән. Сыйфат фигыльле әйләнмә белән тәрҗемә итсәң, фраза артык озын, балалар өчен авыр булып чыгар иде.

Әйләнмә составындагы сыйфат фигыльне сыйфат белән генә дә бирергә мөмкин икән. «Это был очень хороший дом, прекрасно приспособленный для хорошей жизни» дигән җөмләдәге «приспособленный» сүзе «ипле» дип бирелгән: «Тормыш итәр өчен бик ипле, бик шәп өй инде» (102 бит).

«Он увернулся от усатого, объехавшего сбоку, вильнул, перепрыгнул через люк обратно и вскочил на скамейку» җөмләсе оригиналда матур һәм җыйнак. Ә тәрҗемә исә кирәгеннән артык озын булып чыккан: «Мыек исә люкны янынннан әйләнеп узды, матрос, аңа тоттырмыйча, ялт итеп кенә кирегә борылды да, люкны яңадан аерып чыкты һәм эскәмиягә менеп басты (51 бит).

«Таким его и передали с рук на руки кухарке Дуне, ожидавшей господ на улице» җөмләсе: «Капка төбендә хуҗалары кайтканны асраулары Дуня көтеп тора икән, Павликны йоклаган көе шуңа күтәрттеләр», дип тәрҗемә ителгән, сыйфат фигыльле әйләнмә гади җөмлә итеп бирелгән. Ләкин бер үк җөмләдә бер-берсеннән ерак урнашмаган ике сүзнең (асраулары, хуҗалары) күплек формасында бирелүе җөмләнең матурлыгын киметкән. Асраулары сүзен «асрау кыз» дип бирсәң, мәгънәгә бер дә зыян килмәс иде.

Сүзне тәмамлап, шуны гына әйтәсе килә. К. Миңлебаев «Ялгыз җилкән» кебек кызыклы, мавыктыргыч сюжетлы әсәрне тәрҗемә итеп, мактаулы эш эшләгән.

Ф. ШИҺАПОВА,
КДУ студенты.

## Зәки Нури

### Ирексездән галәмче

— Авыз ачсаң, «галәм, галәм!» дисең
Әллә инде бүтән җырың юк?
— Җыр бар ла ул... Ләкин миңа җирдә
Алиментган качар урын юк.

### Кеше һәм балта

— Әй, балта, кисмә каенны,
Бу урман — яшел койма!
— И кеше! Нигә каеннан
Сап ясап куйдың миңа?

### Һаман тәнкыйтьләнүче

— Син колакка бераз каты диләр?
— Шулай, дустым, әйе... һәм күптән.
— Мин кызыгам! Яшәү рәхәттер ул
Һич хәбәрдар булмый тәнкыйтьтән.

### «Дан иясе»

— Менә шунда миңа һәйкәл булыр,
Төрле яктан сукмак сузарлар.
Кешеләр килер!..
— Алар бер-берсеннән:
«Бу кем?» диеп сорап узарлар.

### Күренеп тора

— Ашханәдә штат артты мәллә?
— Кемнәр сезгә шулай диделәр?
— Пилмәннәре хәзер бик бәләкәй,
Ә элек бит зуррак иделәр.

## Былчыракта

— Кара әле, былчыракта нәрсә
Аунар икән көпә-көндезен?
— Чү, икесе дә минеке бит болар:
Берсе ирем, берсе... дуңгызым.

## Хатыннарының холкы

— Кайтсам, «Яле, тын ал — сула!» диеп,
Тибәргә генә тора арт санга.
— Ә минеке — тын алырга бирми,
Ничек кенә аек кайтсам да.

## Кунак киткәндә

— Әнкәсе, мин Сафинга да әйттем,
Савытны син ун пар ит инде!
— Шул бирәнне тагын ник чакырдың,
Холодильник алдык бит инде...

## Өч көн үткәч

— Безнең хакта яна-көя белү
Бер дә юк бит, иптәш директор.
— Үзем теләп эштән чыгам, дигән
Гаризаңны алдан биреп тор.

## Спектакль караганда

— Баш кагып син ник бу персонажны
Сәламлисең? Бу ни галәмәт?
— Танышым ул... Бүтән китаплардан
Монда күчкән ул сау-сәламәт!

## Искиткеч яңалык

— Нәрсә икән анда? Нинди озын
Чират баскан урам чатына?
— Казаннарда казанлылар өчен
Казан мехы, имеш, сатыла.

## Дөрес адрес

— Безгә район юл бүлеге кирәк,
Тотыйк икән юлны кайда без?
— Начар юллар бар да шунда илтә,
Иң начарын юлның сайлагыз.

# ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ЯҢАЛЫКЛАРЫ

## ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫ СОЮЗЫ ИДАРӘСЕНЕҢ ЯҢА СОСТАВЫ

Шушы елның 25—26 мартында Татарстан язучылары союзының VII съезды булды.

Съезд язучылар идарәсе составына **М. Әмир, Г. Ахунов, Г. Бәширов, Л. Ихсанова, Р. Мостафин, З. Нури, В. Синев, Х. Туфан, Ф. Хөсни, И. Юзеев, Г. Кашшаф, С. Хәким, Р. Фәйзуллин, И. Гази, А. Шамов, Р. Ишморат, Х. Госман** иптәшләрне сайлады. Идарә председателе итеп **И. Гази,** председатель урынбасарлары итеп **С. Хәким** һәм **Г. Ахунов,** җаваплы секретарь итеп **З. Нури** сайланды.

Ревизия комиссиясе **Г. Гобәй, З. Шаһиморатов, Ә. Маликов** иптәшләр составында сайланды.

## ЖУРНАЛ ТУРЫНДА ФИКЕР АЛЫШУ

29 февральдә Татарстан язучылары союзы идарәсенең киңәйтелгән утырышы үткәрелде. Ул утырыш «Казан утлары» журналының 1967 елгы 10, 11, 12 нче саннарында басылган әсәрләр һәм «Социалистик Татарстан» газетасында басылган «Әдәби хәрәкәтнең алгы сафына!» (газетаның 4 февраль, 30 саны) исемле мәкалә турында фикер алышуга багышланган иде. Түбәндә без, бераз кыскартып, фикер алышуда катнашкан иптәшләрнең чыгышларын урнаштырабыз.

**Фатих Хөсни:**

— Иптәшләр, бүгенге сөйләшү ике юнәлештә алып барылачак. Беренчесе — журналның 10, 11, 12 нче саннары турында сөйләшү. Икенчесе — «Социалистик Татарстан» газетасында басылган мәкалә уңае белән фикер алышу. Мин сүзне шул мәкаләдән башлаячакмын. Минемчә, газета журнал турында дөрес фикер йөртә, журналның уңай һәм кимчелекле якларын тулаем дөрес билгели. Мәкаләнең тоны да нормаль.

Ләкин минем кайбер фикерләрем дә бар ул мәкалә турында. Мәсәлән, бер төрле әсәрләрне тезеп кую, аларга сүз тидермичә үтү, ә кайберләрен тәнкыйтьләү, минемчә, узган этап алымы. Минемчә, газета мактап киткән әсәрләрдә дә бәхәсләшерлек урыннар бар бит, иптәшләр. Тулаем алганда, елына бер күзәтү ясаса да, газетаның мәкаләне бастыруы әйбәт. Минем теләк: газета журналга елына бер генә түгел, бәлки өч-дүрт күзәтү бирсен иде.

Инде журналның 10—12 нче саннарында басылган проза әсәрләренә килик. Мин нигездә Н. Фәттахның «Мөдир Сәҗидә»се, А. Расихның «Ямашев» романы хакында сүз алып бармакчы булам. «Ямашев» романы соңгы еллардагы прозабызның әһәмиятле казанышы. Автор Ямашевның тормышын ныклап өйрәнеп, шактый тулы тасвирлаган. Бу — әсәрнең уңышлы ягы. Хөсәенгә хас булган кайбер кимчелекләрне дә автор дөрес күрсәткән дип саныйм. Әсәрнең тагын бер уңай ягы шунда, автор шул чор кешеләрен, аларның тормышларын шактый тулы чагылдырган.

Шул ук вакытта әсәрдә кайбер кимчелекләр дә юк түгел. Минемчә, Фәрхетдин, Җәгъфәр кебек икенче, өченче дәрәҗәдәге образлар әсәрдә кирәгеннән артыграк урын алалар шикелле. Әсәрдә күп урын алсалар да, аларның эчке үсешләре, кеше буларак үсешләре тиешенчә ачылып җитми. Аннары Хөсәеннең эш-характерларында да урынурыны белән логикасызлык очраштыргалап куюы да бик үк ошап җитми миңа. Мәсәлән, Хөсәен Җәгъфәрнең Петербургта булган хәлләр турындагы сөйләвен бик мөкиббән китеп, яңа нәрсә итеп тыңлый. Бу бик ышандырып җитми. Хөсәен шул люмпеннән наиврак булып чыга. Кыскасы, большевик буларак, Хөсәеннең характерына туры килми торган урыннар да бар әсәрдә. Ләкин шул кимчелекләренә дә карамастан, бу әсәр безнең узган елгы әсәрләребез арасында иң уңышлысы дип саныйм мин.

Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» повесте миңа баштан ук ошаган иде. Ләкин әсәрнең соңгы өлеше бик үк канәгатьләндерен җиткермәде. Аның соңгы өлешен язганда ул әдәбиятта инде таныш булган юллардан юыртып үтә кебек.

Бу саннарда басылган өченче зур әйбер — Н. Фәттахның «Мөдир Сәҗидә»се. Баштан ук әйтеп китим, мин бу әсәрне бик кызыксынып, көтеп алып укыдым. Әсәрдә бөтенесе табигый, бөтенесе ышандыра торган хәлләр, вакыйгалар һәм кешеләр сурәтләнгән. Әсәрнең авыл яшьләре тормышын чагылдыруга багышланган булуы да ошады миңа. Таня белән Сәҗидә арасындагы тормышчан, табигый дуслык ошады. Бу әсәрне мин тулаем алганда шулай ук прозабызның узган елгы уңышы дияр идем.

Инде мин аның кимчелекләрен дә әйтеп китәсем килә. Әсәр озынрак бит, иптәшләр. Ул озынлык, минемчә, теманың бик үк ачыкланып җитмәвеннән килә.

Без кайчакта тормыш материалы белән теманы бутыйбыз. Тормыш материалы бик киң ул, ә тема конкрет булырга, шул тормышның инндидер бер ягын ачып бирергә юнәлдерелгән булырга тиеш. Минемчә, бу әсәрен Нурихан артык җәелдереп җибәргән.

Узган ел без илле елда әдәбиятыбыз үткән юл хакында бер зур мәкалә бирергә теләгән идек. Әмма андый мәкалә булмады. Дөрес, Ф. Миңнуллинның мәкаләсе бирелде, мин ул иптәшне яратам, яшь, өметле егет ул. Мәкаләсе дә ярыйсы гына. Әмма ул мин көткән нәтиҗәне биреп җиткермәде. Бәхәсле формулировкалар бар анда. (Мәкаләдән мисаллар китерә.) Тулаем алганда, бу мәкаләне дә үткән юлга караш ташлавы белән игътибарга лаеклы бер адым дип саныйм мин. Бу саннарда миңа И. Газиның «Томаннар артында» хикәясе дә ошады.

**Барлас Камалов:**

— 10—12 нче саннар башлыча юбилей саннары. Журнал юбилейны ничек каршылады? Минемчә, журнал юбилейга бик яхшы әзерләнде һәм аны уңышлы үткәрде. «Мәдәният тарихыннан» дигән материаллар үзләре генә дә бик мөһим иде, иптәшләр. Ф. Хөсни фикерләре белән шигездә килешкән хәлдә, үз фикерләремне дә әйтеп китәм.

«Ямашев» романы, минемчә, әдәбиятыбызда этап булырлык әсәр. Хөсәен образы буенча Фатих абый фикерләре белән килешәм, әмма Фәрхетдин образына карата әйткән фикерләре белән килешмим. Минемчә, бу образның логикасы бик төзек. Ул үсештә бирелә. Ә менә Җәгъфәр мәсьәләсендә Фатих абый белән килешәм. Әйе, борылышлар, егылулар, торулар бик күп анда. Мин кызыклы образлардан тагын Гажби карчыкны атап китәр идем.

«Туган ягым — яшел бишек» турында Фатих абый фикере белән килешәм. «Мөдир Сажидә»не мин дә кирәкле әсәр, прозабызның узган елгы уңышы дип саныйм. Таня, Сажидә кебек уңышлы образлар белән бергә, нагрузкасыз образлар (укытучы һ. б.) да бар повестьта. Бу әсәрне нык кына кыскартып булыр иде.

**М. Шабаев:**

— Журналның узган елгы 10—12 саннары — юбилей саннары диделәр. Поэзиягә килгәндә дә бу шулай. Аеруча уникчы сан җентекләп уйланып эшләнгән, поэзиянең төрле буын вәкилләреннән эпиграфлар бирелгән. Бу саннарда ике поэма, утызлап шигырь басылган. Авторлары төрле булган кебек, поэзия әсәрләре үзләре дә төрле. Ә. Давыдовның «Октябрь кояшы» шигыре әйбәт. Х. Туфанның шигырьләр циклын җыеп биреп тә редакция бик яхшы эшләгән.

С. Сөләймановаңың «Җир-су» поэмасы әйбәт кенә яңгырый. Автор бер авыл семьясы үрнәгендә халык, ил язмышын сурәтли. Ләкин поэма озынрак шикелле.

С. Хәким, Ә. Баянов шигырьләре дә әйбәт. Әмма Ә. Баянов шигырендә «Цицерон» кебек уңышсыз сүзләр бар.

Р. Гәрәйнең «Яратам мин Ленин районын» шигыре төссез, шаблон яңгырый. Н. Арслановның «Диңгез ярында» исемле озын шигыре миңа ошады.

«Социалистик Татарстан»да басылган мәкалә әйбәт тәэсир калдырды. Әмма шулай да газетаның И. Юзеевнең «Тынлык белән сөйләшү» исемле поэмасына биргән бәясе белән һич тә килешәсе килми. Анда әйтелгән фикерләр ышандырмый, бернинди дәлилсез алар.

**Х. Туфан:**

— Минем шундый гадәтем бар: укыган әйберләремнең читенә фикеремне яза барам. Журналга еллык күзәтү ясалган мәкалә басылган газетаны да шулай укыдым. Мәкаләдә журналның һаман яхшыра баруы, тиражы үсүе дөрес билгеләнә. «Ямашев», «Туган ягым — яшел бишек», «Мөдир Сажидә»гә биргән бәяләре белән дә, Г. Халит, И. Юзиев мәкаләләренә биргән бәяләре белән дә килешәм. Поэзия әсәрләренә биргән бәяләре дә дөрес.

Ә. Давыдовның 10 нчы санда басылган шигыре тиешенчә эшләнмәгән черновикны хәтерләтә. С. Сөләймановаңың «Җир-су» поэмасы да эшләнеп бетмәгән әле. Аны эшләттереп бетерергә иде. Н. Арслановның «Диңгез ярында» исемле шигыре әйбәт, уйландыра торган шигырь. Р. Харисовның Ш. Махмудов китабы турындагы мәкаләсе бик сай, аны бастырып чыгармаска иде.

Журналның поэзия бүлегенә карата шуны әйтәсе килә: таләпчәнлек җитеп бетми шигырьләргә, иптәшләр.

**З. Нури:**

— Иң элек журналга күзәтү ясаган иптәшләргә рәхмәт әйтергә телим мин. Мондый сөйләшүләр үзенә күрә әдәби осталык турында сөйләшүләр мәктәбе булырга тиеш иде. Бүгенге иптәшләр нәкъ шул юнәлештә сөйләделәр дә...

В. И. Ленинның 100 еллыгы, Татарстанның 50 еллыгы уңае белән редакция тиешле чараларны хәзердән үк күрә башларга тиеш.

Күптән түгел генә узган конференциядә Татарстан химиясе турында сүз булды. Бу турыда язучыларга да уйланырга кирәктер.

Хикәяләр һәм очеркларны күбрәк һәм яхшырак итеп чыгару максаты белән конкурслар булдыру мәсьәләсен кую да зыян итмәс иде.

**Ә. Давыдов:**

— Мин махсус хәзерләнеп килмәдем бу җыелышка. Әмма «Октябрь кояшы» исемле шигырем хакында фикер кузгалган икән, берничә сүз әйтеп китәсем килә. Мин үзем поэзиядә төрле формалар булырга тиеш дип уйлыйм. Үземчә язмыйлар дип, башкача язучыларга үпкәләмим. Нигә инде барыбыздан да бертөрле итеп язуны таләп итәргә?.. Алай итеп кую ярамас, иптәшләр.

**Ф. Миңнуллин:**

— Безне күп очракта дөрес тәнкыйтьлиләр, белеп тәнкыйтьлиләр. Әмма еш кына бик каты орышалар да. Без аларның

кирәк дип санаганнарына игътибар итәбез. Җитешсезлекләребезне төзәтергә тырышабыз.

Аннары Ф. Миңнуллин «Социалистик Татарстан» газетасында басылган күзәтүдәге үзе килешмәгән урыннарны санап чыга һәм шуларга эче пошуын белдерә.

**Р. Мостафин:**

— Бүгенге сөйләшү бик файдалы һәм кызыклы булды. Монда әйтелгән фикерләрне без эш дәвамында искә алырбыз.

Минем бер тәкъдим бар: журнал турында фикер алышуны язучылар белән генә түгел, бәлки укучылар катнашы белән дә үткәрергә кирәктер.

Газетада басылган мәкаләдә журналга карата нигездә дөрес фикерләр әйтелгән.

**М. Әмир:**

— Ф. Миңнуллинның замечаниесе урынлы. Чыннан да, тәнкыйть бүлегенә карата сүз аз әйтелде, ул бүлек читтәрәк калды. Ләкин Миңнуллинның газета мәкаләсенә карата әйткән фикерендә шактый арттырып җибәрү булды. Кызыбрак китте ул.

Проза әсәрләренә карата бик әйбәт һәм дөрес фикерләр әйттеләр. Әмма «Ямашев» романы мәсьәләсендә мин Фатих ягында түгел, бәлки Барлас ягында. Минемчә, Фәрхетдин һәм Җәгъфәр образлары уңышлы табылган образлар. Минем уемча да «Ямашев» романы безнең әдәбиятыбызның уңышы. Расих романының икенче кисәген тизрәк һәм тырышыбрак язсын иде инде.

## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫНЫҢ ӘЛМӘТ БҮЛЕГЕНДӘ

Әлмәтнең икенче китапханәсендә Г. Ахуновның «Хәзинә» романына багышлап, рус телендә укучылар конференциясе үткәрелде. Конференциядә автор үзе дә катнашты, сорауларга җавап бирде, «Хәзинә»нең икенче китабын язып бетерүе һәм андагы геройлар турында сөйләде.


* * *

Язучылар союзының Әлмәт бүлегендә Татарстанның халык артисткасы Галия Кайбицкая һәм композитор Әнвәр Бакиров белән очрашу үткәрелде. Г. Кайбицкая үз иҗаты турында һәм нефть районнарында симфоник оркестр оештырган И. Әүхәдиев турында истәлек сөйләде. Ә. Бакиров Татарстанның 50 еллыгына һәм В. И. Ленинның тууына 100 ел тулу уңае белән Татарстан композиторларының нинди яңа әсәрләр язулары белән таныштырды.

* * *

Бүлек утырышында Г. Ахуновның «Хуҗалар» исемле яңа романы турында фикер алышу үткәрелде. Р. Төхфәтуллин, М. Хәсәнов, Ә. Маликов, С. Сөләйманова, Г. Афзал, М. Хәбибуллин романның уңышлы һәм кимчелекле якларын әйтеп үттеләр, авторга файдалы киңәшләр бирделәр.

# БЕЗНЕҢ ГЕНЕРАЛ




**ҖӘҮДӘТ ФӘЙЗИ** музыкасы

**МӨХӘММӘТ САДРИ** сүзләре

*(Якуб Чанышевка багышлана)*

I

Тетри деңья Октябрьның
Дәһшәтеннән, үченнән,
Утлы ташкын, тимер ташкын,
Көзге ташкын көченнән.

Ленин сүзләрен ишетеп
Кузгала Мәскәү, Урал...
Хөрлек эшен яклар өчен
Яшь батыр ала корал.

II

Эшче полклар сафында
Ул Уралны коткара,
Яшәү чишмәсен ачканга
Котлый аны Бохара...

Нева буйларыннан ташкын
Җәелә дә көчәя,
Россиядә кызыл байрак
Көчле канатын җәя.

III

Ныгый шул байрак астында
Якубның канатлары,
Төшеп кала иңбашыннан
Батраклык азаплары.

Дошман бозгач тынычлыкны,
Ил тагын ала корал;
Ватанны яклап утларга
Керә Якуб генерал.

IV

Барып җитә Дунайгача
Безнең гаскәрләр юлы;
Алда бара бу юлда да
Совет халкының улы.

Партиябез әндәвенә
Бөтен ил ала корал...
Берлиннан да җиңеп кайта
Безнең данлы генерал.

Бәясе 40 тиен
Цена 40 коп.

# КАЗАН УТЛАРЫ (ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный и общественно-политический журнал

ОРГАН СОЮЗА
ПИСАТЕЛЕЙ
ТАТАРИИ

ИНДЕКС 73210